# казан утлары

6
ИЮНЬ·1974



М. ӘМИР.



Н. ЮЗЕЕВ.

КПСС өлкә комитетында һәм ТАССР
Министрлар Советында

# 1974 ЕЛ ӨЧЕН ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ РЕСПУБЛИКА ПРЕМИЯЛӘРЕН БИРҮ ТУРЫНДА

*КПСС өлкә комитеты бюросы һәм Татарстан АССР Министрлар Советы, Габдулла Тукай исемендәге республика премияләре комитеты тәкъдимен караганнан соң, 1974 ел өчен Габдулла Тукай исемендәге республика премияләрен түбәндәге иптәшләргә бирү турында карар чыгардылар:*

*язучы Мирсәй ӘМИРГӘ (Мирсәяф Мөсәлим улы Әмировка) — «Агыйдел» пьесасы өчен;*

*әдәби тәнкыйтьче Нил Гафур улы ЮЗЕЕВКА — «Шигырь гармониясе» һәм «Бүгенге татар поэтикасы» китаплары өчен.*

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ һӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

6
ИЮНЬ
1974

## Бу санда

З. НУРИ. Май ае балладасы. Шигырьләр . . . 3
М. ГАЛИЕВ. Пискарев каберлегендә. Шигырь . . 9
Ф. ХӨСНИ. Алтын эзләүчеләр. Повесть . . . . 10
Н. АРСЛАНОВ. Мин тауларга карыйм. Шигырьләр. 83
Г. РӘХИМ. Бу дөньяда. Шигырьләр . . . . . . 87
Ү. САТТАРОВ. Айлы төндә. Хикәя . . . . . . 92
Ә. КАМАЛ. Олы Әкбәрнең кече Әсгаре. Хикәя . 96

ДУСЛАР ҖЫРЫ

Ә. АТНАБАЕВ. Горурлык. Шигырьләр . . . . . 102

ЯКТАШЛАРЫБЫЗ СӘЯХӘТТӘ

С. СӨЛӘЙМАНОВА. Әс-сәлями, Суфият! . . . . 108

ОЧЕРКЛАР

КамАЗ елъязмасы . . . . . . . . . . . . . 126
Ф. НАСЫЙРОВ. Бәйрәм алдыннан . . . . . . 129

СӘНГАТЬ

Ә. РӘШИТОВ, Г. ШӘРӘФЕТДИНОВ. Сөйкемле сөяге бар . . . . . . . . . . . . . . . 135

ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ — ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ

Л. МӘХСҮМОВА. Татар-үзбәк әдәби мөнәсәбәтләре . . . . . . . . . . . . . . . . . 141

ТӨРЛЕСЕННӘН

С. ЧЕРВОННАЯ. Яшь рәссам . . . . . . . . . 149
Л. ШӘЙДУЛЛИНА. Ислам динендә изге хатыннар культы . . . . . . . . . . . . . . . . 156

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

С. ХАФИЗОВ. Онытылган бер әсәр турында . . 161

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА һӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

**М. ВӘЛИЕВ.** Безгә ак болыт булырга язмаган шул... . . . . . . . . . . . . . . . . 164

КИТАП КҮЗӘТҮ

**И. АБДУЛЛИН.** Әдәби тел тарихы һәм бүгенге көн . . . . . . . . . . . . . . . . 173

**Р. НӘФИКОВ, М. МӨЛЕКОВ.** Үткән гасырларга сәяхәт . . . . . . . . . . . . . . . . 177

Укучылар сүзе . . . . . . . . . . . . . . . . 180

ЧАЯН БҮЛЕГЕ

**Ш. РАХМАНКУЛОВ.** Габрово мәзәкләре . . . . 183

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

Редакциянең адресы: Казань, 420066, ул. Декабристов, 12.

Баш редактор: **Гариф Ахунов**

Редколлегия: **Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

Производствога бирелде 4/III-1974 ел. Басарга кул куелды 13/V-1974 ел. ПФ 09124. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 89.000 экз. Заказ Ю-55. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе. Казань, Декабристлар урамы, 12.

© «Казан утлары» 1974 ел.

# Зәки Нури

## Май ае балладасы

Инде яз!
Очынып
бөреләр ачыла.
Яңару, яшәрү —
язын ул изге эш!..
Елмаеп,
һәр якны нурлаган чакта яз,
Бер егет йөзендә
нигәдер
көзге төс...

Күренә, нигәдер,
бик боек, бик моңсу,
Баш иеп читләшә
күргән бер кешедән, —
Күңелгә,
күрәсең,
күңелсез җил өргән
Һәм анда
ниндидер
бер почмак... өшегән...

Инде май.
Тезелеп
бәйрәмнәр килә бит!
Зур эштән
бакчалар
баткан ак күбеккә.
Үзе дә сизмәстән
шушыны искәреп
Шау-шулы бер чатта
тукталды егет тә.

Шул чатка
кәрзинләп
ак чәчәк китергән
Кемнеңдер әбисе,
кемнеңдер әнисе.
Ак чәчәк! Ак күбек!
Агарган чәч төсе.
Ак ялкын
балкыйдыр шикелле...
Ә исе!..

Үзе дә сизмәстән
егет тә тукталды —
Тукталды
чал чәчле
бер апай каршында.
Күзендә
ниндидер
магнитлы очкын бар:
«Мә чәчәк!
Жәл түгел!
Ал, улым, барсын да!»

Һәм апай пышылдый
карашка сүз өстәп:
«Ә акчаң булмаса —
ансында эшем юк...»
— Кирәкми, — ди егет, —
бик рәхмәт, әнкәем!..
Барыбер
юк хәзер,
бирәсе кешем юк...

Ә чәчәк
барыбер
шул егет кулында!
Ул аңа
карап һәм
сокланып туймады.
Берсүзсез аңлашу иде бу,
бер сүзсез...

Беләмсез,
шул чакны
кем нәрсә уйлады?

...Штабтан хат килде:
«Бер ярчык тиде...» дип.
Дуслары яздылар:
«Җиргә баш иде...» дип.

Әйтмәде чал ана
кай көндә, кай якта
Сугышта улкаен
кем ничек күмгәнен.

...Ә егет әйтмәде
быел май башында
Әнкәсе нәрсәдән
һәм ничек үлгәнен...

Әйтмәде.
Дәшмәде.
Кайгысын йотты ул.
Тетрәтмә болай да
тетрәгән карчыкны.
Ә әнкә...
йөрәктә
утыз ел йөрткән бит
Харьковны алганда
тигән бер ярчыкны.

## НИК!

Ярыймы сорау бирергә?
Белер нәрсәм берничә:
Ник миңа яшәве кыен
Сине көн дә күрмичә?

Ник мин болай өзгәләнәм,
Ник мин болай уфтанам?
Йөрәккә ник очкын салдың —
Анда ут та ут һаман?

Ник гел синә чәчәк өзәм,
Бүтәннәргә өзмим мин?
Ник һәркайда синең шәүләң
Күренер дип эзлим мин?

Ник һәр адымда мин һаман
Синең белән серләшәм?
...Миңа бик авыр булачак
Әгәр җавап бирмәсәң...

## КИЛ

Күңелем тәрәзәсен мин
Ачып куйдым киң итеп.
Кил син, йомшак җил булып кер —
Якын күреп, тиң итеп.

Тәрәзәм төбе гөл генә,
Ул ерактан күренә.
Там, җылы яңгыр булып там
Гөлле күңел түремә.

Сине сагыну хисләрем
Тулып-ташып түгелә.
Мен, якты йолдыз булып мен
Якты күңел күгемә.

Ерактагы яшен булып
Төшкә кердең син бүген.
Кил, давыл булып дулкынлат
Минем күңел киңлеген.

Юлыңа җырлар сибәрмен,
Кил генә син, кил генә.
Кояшым итеп көткәнем
Син генә бит, син генә!

## КӨТ

Көт, йөрәгем, армый-талмый,
Очрашуны көн дә көт.
Кулның кулга тию дә
Мең бәхет ул, мең бәхет.

Булса булсын мең бәхет ул,
Кем канәгать бер белән!
Сөйгән ярың килгәнен көт
Җырланмаган җыр белән.

Мәхәббәт уты күктәге
Чулпанга тиң ут бит ул.
Күрешкән минут — шул Чулпан
Кабынган минут бит ул.

Көт син, йөрәк, көт, көтә бел,
Өмет өзмә килми дип.
Кояшын күреп туймыйча
Иртән ай да сүнми бит.

# Чәнечкеләр тезмәсе

## ҮЗ БАШЫНА

Үзе өчен Трест бер өй салды,
Темпын зурлап тагын бер эшнең.
Ә бер айдан төшәм ишелде дә...
Үз башына төште Трестның.

## КҮТӘРДЕЛӘР...

Ясле — «Старт», кафе — «Поход», кино — «Финиш»...
Әйе, спорт җене тигән исемнәр бит!
...Ә эшләнде болар бар да: «Бу колхозда
Күтәрелә икән спорт дисеннәр!» — дип.

## МӨГЕЗСЕЗ КУЯН

Киткән Куян бер көтүгә кушылып —
Урманында торган җирен ташлаган.
Һәм... бераздан, мин дә сездәй булыйм дип,
Үгезләрдән мөгез даулый башлаган.

## ОЛЫ БЕЛӘН КЕЧЕ

— Болай дөрләтсәң — үләсең бала!
Тәмәке бит ул җанны куыра...
— Мин бит гел тартмыйм — бары аракы
Эчкәчтен генә берне суырам.

Әйтә Әрем: — Чынлап торып көләр өчен
Бу тормышта җирлек тә юк хәзер, җим дә.
Әйтә Чәчәк: — Кара эчле, әрем эчле
Булсам әгәр көлә белмәс идем мин дә!

## Итек турында

*Мәсәл-баллада*

Эшлекле, кодрәтле,
гыйбрәтле бер оста
Теккәч тә бик матур,
бик чыдам күн Итек,
Көнчеләр кузгала:
берәве ярсынып
Яманлый Итекне
чүәктән ким итеп.

Берәве, төкерекне
гадәтчә күп чәчеп,
Яманлый Итекнең
балтырын, үкчәсен.
Берәве: «Мондыйны
күргән юк минем!.» ди,
«Чабатам барында
Мин Итек кимим!» ди.

Сүз ала берәве —
оста зат әвешкә! — :
«Ник миңа бу нәрсә?
Ни җитә кәвешкә!»
Һәм өсти:
«Бәяне өстемә алалмыйм...
Әшнәләр әйткәнгә
кушылмый калалмыйм...»

Шул чакны тузанлы,
таушалган күн Итек
Нәкъ үзе керә дә
бүлмәгә атылып
Кычкыра: — Ник чумар ишәсез
тел белән?
Көрәштә кирәк ул
кырыслык, катылык!

Сүзегез —
ямьсез дә,
сәер дә,
кызык та...
Сез шушы чүбекне
чәйнәгән вакытта
Һөҗүмгә бардым мин —
иң алгы сызыкка,

Меңләгән чакрымлап
юл үттем походта.

...Тузанлы киштәдә
йоклыйлар чүәкләр,
Каһарман кун Итек
төн куна окопта.

## Киресенчә теләкләр

*Икенче бәйләм*

Кунакка барсаң — шатлыгың
Эчкә сыймасын иде:
Хуҗаң сине: «Әйдә, кефир
Эч!» дип сыйласын иде.

Башлыкларның эштә бары
Шундые калсын иде:
«Дус булсаң да — эштән куам!»
Дип әйтә алсын иде.

Күсәк күтәргән тәнкыйтьче
Бәхеткә тарсын иде:
Шул күсәк белән үзен дә
Бер тотып ярсын иде.

Көйсезләнгән хатын үзен
Үзе көйләсен иде.
«Дин — агу ул!» диеп мулла
Вәгазь сөйләсен иде.

Яла яга белмәүчегә
Бүләк бирсеннәр иде.
Трамвайга кайчан картлар да
Алдан керсеннәр иде.

Безнең башлык та, ичмаса,
Елга бер көлсен иде.
Атасы чишкән мисалны
Бала да белсен иде.

Каравылчы төнлә түгел,
Көндез йокласын иде.
Больничный көткән бәндәгә
Сырхау йокмасын иде.

Ир-ат сауган җылы сөтне
Хатын-кыз эчсен иде.
Хатын алименттан качсын,
Ә ире — көтсен иде.

Бухгалтерлар алиментны
Тотмый калсыннар иде!..
Бу сүзләрдән кайберәүләр
Гыйбрәт алсыннар иде.

## Марсель Галиев

### Пискарев каберлегендә

Моңлы аһәң монда җир астыннан килә.

Сабый йөгерә
　　　　　　　　автоматка каршы,
көлә-көлә...
　　　　　　　　　　үлә...
Моңлы аһәң монда җир астыннан килә...

Бүгенге ачыш
　　　　　　　　күптән инде ачыласы иде,
　　　　　　　　　　　　　　тик менә...
Моңлы әһәң монда җир астыннан килә...

«А» хәрефен өйрәнгәндә
　　　　　　　　тынып калган сабый
Поэма язар иде илгә...
Моңлы аһәң монда җир астыннан килә...

Һәрберсе бит
　　　　　　　　　　кабатланмас дөнья иде,
Ачылмаган зур ил иде.
Хәзер аның һәркайсы да
Атлантида инде...

Ленинград, 1973.

**Фатих Хөсни**

# АЛТЫН ЭЗЛӘҮЧЕЛӘР

## САТИРИК ПОВЕСТЬ

Ул заман кем килде Мәскәү гаскәре,
Бу Казанга туп атарга башлады.
Шул вакыт ханнар, вәзирләр качтылар,
Барча малны ушбу күлгә сачтылар.
Сачтылар алтын, көмешнең һәммәсен,
Ягъни безнең мал кешегә калмасын.

*Габдулла Тукай. «Печән базары...»*

### 1



Мең тугыз йөз егерме өченче елның коры җәй башлары иде. «Ташаяк» ярминкәсе инде ябылган, көньяктан һәм Украинадан җиләк-җимеш, керамика һәм башка төр товарлар, көнкүреш әйберләре сата килгән сәүдәгәрләр киткән, ул тирәдәге складлар бушап калган, көн саен булмаса да, әледән-әле газеталарда складларны киләсе елның апреленә кадәр арендага бирү турындагы игъланнар басыла тора иде. Кабан күлендә теге баштан шәһәр ягына йөреп торучы «Нептун» пароходында типтерүчеләр дә алай сизелми, «Аркадия» паркларында сабан туйлары узган, эчеләсе сыра эчелгән, хәзер инде ул яктан ломовой извозчиклар зур, дыңгырдык арбаларында дөбердәтеп буш сыра мичкәләре генә алып кайталар иде. Шуңа кушылып, извоз хуҗасы Чукрак Зарифның Усад спирт заводыннан Казандагы аракы заводына спирт ташучы ямщикларының спирттан бушаган мичкәләре дыңгырдый. Бу соңгыларының тамашалары, әлбәттә, коры дыңгырдау белән генә калмый, әмма хәзергә әле сүз алар турында түгел. Урам оркестры тулырак яңгырасын дисәк, Олы Мещанский, Кече Мещанский, Тегәрҗеп, Иванглестовский урамнарыннан Тирес башына «төнге алтын» ташучыларны да, алардан тирә-юньгә таралып кала торган ис-хушны да өстәргә мөмкин булыр иде дә, хәер, болары үз вакытларын беләләр, күбесенчә, төнлә генә йөриләр, иртәнге якта үтә комсызлары, төнлә эшләп кенә баеп булмаган-

лыктан, тәүлекне ничек тә сузарга тырышканнары гына күренгәләп кала.

Ул арада Обжорный рядта әчкелтем-төчкелтем төтен, май исләре чыгарып, бәрәңге кәлҗемәсе, суган белән кушылган ат казылыгы, ярты-сы төеп вакланган ипидән торган арзанлы кәтлит кыздырырга тотыналар, шкафчы малайларның көйләп-көйләп товарларын мактаулары, Ашлык базары ягыннан калын тавышлы базар башлыгының «Кайда туктаттың атынны, Сәхра! Күрмисеңмени солы рәтенең кайда икәнлеген?» дип шыр акырып кычкырып җибәрүе ишетелеп кала. Капкалар, кибетләр ачыла, кыз-кыркын чиләк шыңгырдатып фонтанга суга чыга... Гыймади хәлфәнең ишрах намазыннан соң ашамаган килеш тешен казыйказый кайтканлыгы һәм кинәт, тамагы бик чатнаганлыгын исенә төшереп, кыска аяклары белән иртәнге чәйгә чапканлыгы күренеп кала.

Әлбәттә, эшчеләр дә, совет хезмәткәрләре дә бар. Ләкин боларның беренчеләре инде иртүк, караңгылы-яктылыда ук китеп барган, икенчеләре әле беразданрак кузгалачаклар.

Шулай башлана Казанның иртәсе, дөресрәге, шул без сөйләячәк мең тугыз йөз егерме өченче елның бер иртәсе.

Шулай башланган көннең бер сәгатендә, китәсе кешеләр китеп беткәч, Печән базарында сәүдәнең кызган, урам ыгы-зыгысының басыла төшкән чагында, әйтерсең шул мизгелне алдан чамалагандай, Мәскәү ягыннан Себер ягына узучы поездларның берсеннән, алдагы вагоннан зат киемле, тар кырыйлы кара эшләпәдән, бер кулына трость, икенчесенә хром саквояж тоткан мәһабәт төз гәүдәле бер кеше төште. Каршы алучы-фәлән күренмәде һәм мөсафир моны көтмәгән дә иде булса кирәк. Хәтта ул, шулай тыйнак килеп төшүенә чак кына шатлангандай, ирен читендә генә канәгать көлемсерәү дә сиздереп куйды. Шулай да Казанның тузанлы вокзал мәйданчыгында мондый галибәнә затның төшеп калуы һәм поезд киткәнче платформадан кузгалмыйча акыл җыйгандай басып торуы шул тирәдә арлы-бирле чуалучы кешеләрнең, бигрәк тә носильщикларның игътибарын җәлеп итмичә калмады. Нинди дә булса хезмәтеңне тәкъдим итәр иден, күтәреп илтердәй багажы юк, аннары тагы башны бик югары тота, әллә ниткән зур дәрәҗәле кешегә барып бәрелүең бар. Дәрәҗә иясе кеше дисәң, кем дә булса каршы алыр иде, каршы алучы да күренмәде. Озын буйлы, тройка-костюмнан, аның өстенә җилкәгә әйләнеп төшкән киң якалы накидка, аягында бу гөнаһлы Казан туфрагы әллә күргән, әллә күрмәгән ялтыравыклы шиблетлар, эшләпә астыннан, арттан бүлтәеп куе чәче чыккан, борын астында гына нечкә кара мыек, аеруча күзнең явын алырдае: таягы да таягы. Ахры, ул аны кулында чак кына уйнаткалап та ала иде булса кирәк, ялтырыймы-ялтырый Казан кояшында. Әллә Казан кояшы гашыйк булды таякка, әллә таяк Казан кояшына...

Мәгәр мөсафирыбыз таяк уйнатып йөрергә дип кенә чыккан адәмгә охшамый. Вокзал платформасында ыгы-зыгы басыла төшкәч кузгалды, вокзал алдына, шәһәр ягына үтте, тезелеп торган җиңел извозчиклар янына килде. Ләкин бик үк якынаймыйча, атларны күзләре аша уздырды — күренеп тора, мөсафирның әллә ни ашыкканлыгы сизелми. Ул әлегә карый, тикшерә, сыный, әйтерсең күзләре белән укый: янәсе, кайдан башлана бу Казан дигәннәре? Ничегрәк башлана?

Җиңел пролетка башында утырып, төрлесен күреп өйрәнгән извозчик халкы да төшеп калганнардан түгел. Берсе шундук дилбегә кагып, атын купшы биетеп килеп тә житә, якты чырай күрсәтеп, мөсафирга тәкъдим дә ясый. Ул да булмый, икенчеләре, өченчеләре килеп житә... Заманның тиешенчә утырып өлгермәгән чагы, нәфес бар кешедә дә бердәй, сүз сайлап тору юк, кайсы туры килсә шул ярый, китә берсен-берсе яманлашу, үзенекен ничек тә шәбрәк итеп күрсәтергә тырышу.

— Барасы жирен͡ә очып кына барып җитим дисәң, син инде, әфәндем, минекеннән дә шәп атны таба алмассың.

— «Әфәнде» заманасымыни, мокыт? — Атың белән мактанган булып, үзеңнең сала кабартмасы икәнлегеңне шәрран ярып торасың.

— Менә миндә ул атның и пролетканың Казанда бере. Акча да алмыйм, тигенгә илтәм, миңа акча важно түгел, седокның кем булуы важно,— дип кычкыра өченче бер карлыккан тавыш. Карлыгуын карлыккан, әмма хәйлә дигәненә муеннан баткан кеше икән. Тәки тиде бит мөсафирның йомшак җиренә. Нәкъ менә шушы урында аңына килгәндәй булды мөсафир: тукта әле, шәһәрегез бусагасын атламас борын, мине буш кесә дип кабул итмәгез, диде бугай кеше.

— Өч бәһасен алырсың, только атлатып түгел, очырып илтәсе,— дип боерды ул. Извозчикларның башкалары да ишетсен өчен, юри шулай тавышын күтәрә төшеп әйтте. Пролеткага менеп утыргач, йомшак кына, әдәп белән генә өстәде:— Щитинкин номерларына.

Әдәп белән дә сөйләшә белә, кирәксә, тавышын да күтәрә, кыскасы, тикмә кешегә охшамаган бу кунагың, Казан. Карап карыйк, үзеңне күрсәтә алырсыңмы икән син аңарга? Болай үзе синең турыда элекэлектән төрле сүз йөри. Ошатканнары бар сине, гайбәтеңне сатучылар да күп, яндыручылар да булды. Шулай да, аллага шөкер, син әле үз урыныңда, тузаның һәм юньле-юньсез кешеләрең белән кайный бирәсең.

## 2

Поезддан төшеп, платформада басып торганда Казанга беренче аяк баскан кеше кебек күренсә дә, бу аның безгә мәгълүм булмаган үз исәбеннән чыгып эшләнгән бер алымы гына булды булса кирәк. Гомумән, аның әле безгә мәгълүм булмаган, кем очраса шуңа селкергә ашыкмый торган якларын алда күрербез без. Бара торгач, инде Щитинкин номерларына якынаеп килгәндә, кинәт нидер исенә төшергәндәй, извозчикка болай дип боерды мөсафир:

— Юк, Щитинкинга туктатмагыз, «Амур» җайлы булыр, «Амур»га илтегез.

Извозчикка ни — мондый мәһабәт мөсафирны Проломныйдан бер очыртып үткәрү үзе ни тора! Юртакның дагалары нык, урамга түшәлгән таш шулай ук бирешерлек түгел. Утырып баручы кунак рәт белә торган кеше күренә, әҗерен тамызганда да, сала байлары кебек, шәт, тиенгә төртенеп маташмас.

Җил уйнатып Проломныйны узып килгәндә, кузгалган эчке дәртен баса алмыйча, әйтте кучер:

— Әтәсез икән, Бакыр бабай бакчасын эләндер дип, чүп түгел, эләндерәм, миңа ни: алашам тук, көпчәк майланган.

— Әйләндер, миңа да барыбер,— диде мөсафир, исе китмәгән кыяфәт күрсәтеп.

«Менә, ичмасам, табылды кешесе. Ишелсә ишелә инде моннан, янчык тирәндер моның, тамып кына калмас» дип дәртләнеп уйланды кучер. Һәм кунагының күңелен табар өчен булса кирәк, «очкан» шәпкә иңбашы аша гына борылып:

— Казанны беләсез булса кирәк. «Амур» инде ул такыр башлар төшә торган урын түгел, урыс Щитинкиннан алда булмаса, аннан шак та калышмый.

Кунак бу урында җавапсыз калуны кирәк тапты. Кучер белән дә җәелеп сөйләшә башласаң, сүзең тәтмәс — сүзнең кадерен белер көннәре алда әле аның. Тик бераздан, «Болгар» почмагын борылып, «Сабах» китапханәсе янынннан җилләнеп узганда, кучерга әйтүдән бигрәк, үзенең элекке тәэсирләре кузгалып булса кирәк, авыз эченнән үзенә-үзе

мыгырданды: «Без монда Галимҗан хәзрәт мәдрәсәсендә ике ел гыйльме хасил иткән кеше. Белмәсәк, йөрмәс тә идек!»

Исәп-хисап эшендә дә вак җан булмаса кирәк, «Амур» парадные алдында, кызыксынып карап торучы кешеләрнең бәбәгенә терәп, ләкин үзе аларны гүя ки бөтенләй күрмәгәндәй, бумажнигыннан нәкъ биш сумны чыгарды да бирде. Һәм, өстәвенә, ике бармагын селкеп, игътибарсыз гына:

— Ыздача кирәк түгел, — диде. «Көмешләрне яудырыр инде бу!» — дип, ат һәм хыял уйнатып кызган кучер пролеткасы төбендә катты да калды. Йа мәүлә, безнең Казаныбызга да шундый тутый кошлар килеп кунар көн бар икән!

Мөсафирханәнең кунакларны терки торган өстәле янында озак торырга туры килмәде. Кунакның, шундый мәһабәт киенгән кунакның, башны чак кына да бормыйча, тамак төбе белән:

— Нагиев. Мәскәүнең үзеннән. Әлбәттә, комфортабельный номер булуы желательно, — дип, берничә сүзне рәттән тезә белеп тезүе җитә калды, сөйкемле һәм яхшы ук шомарган хадимә ханым, мөлаем бер елмаеп алу белән, шундук телефон трубкасына ябышты. Күрәсең, монда үзләренең шартлы эндәшләре бар. Булмыйча соң! Мәскәүнең үзеннән килгән һәм «май чүлмәге» икәнлеге тышыннан ук билгеле булган шундый зур кунак, Щитинкинга туктамыйча, «Амур»га туктасын әле. Дөньяның үкчәсенә баса бит татарың!

Хадимә ханымның телефонга нәрсә дип әйткәнен шәйләми дә калды кунак, күз ачып йомганчы, бөтерчек кенә бер адәм коридорның аргы башыннан туптай тәгәрәп килеп тә җитте. Анысы да кеше белән кешене бер күрүдә аера белә торган зат икән, күрәсең, баш администратор буларак эшендә шомаруы җиткән:

— Хуш килдегез, мәрхәбә! Кем дип, кайдан дип белик? — дип, берничә сорау куярга шулай да онытмады.

— Нагиев. Мәскәүнең үзеннән. Казна йомышы белән.

Һәм кунак документ чыгарырга дип эчке кесәсенә тыгыла гына башлаган иде, баш администратор аны ул мәшәкатьтән азат итү ягын карады:

— Куегыз, куй, тәкъсыйр. Мәскәү хәтле Мәскәүнең үзеннән ат сатарга килмәгәнлегегез күренеп тора. Провинция дигәч тә... без дә кемнең кемлеген ярым сүздән үк аера беләбез,— аның авызына карап торучы һәм шул арада сирәк күренә торган бу чибәр егеткә дә күз сирпештергәләп алучы хадимә ханымга боерык тавышы белән әйтте:— 112 нчегә оформить ит. Күрше номерларда бирәү дә юк. Аулак. Телефоны, ваннасы. Бу тирәдәге бүтән вак-төяк лавочкаларның башлары аша үтеп, Кабанга и, кызыксына калсагыз, Кабанның аргы ягындагы «Кызыл фонарь»лар ягына карый. Дөрес, «Кызыл фонарь» хәзер категорически ябык. Революция андый чүп-чарларны себереп түкте.

Баш администратор чәчрәп торган бу кызыл сүзләрне үзенең нинди чорда яшәгәнлеген Мәскәү кунагына сиздерү өчен басым ясабрак әйтсә дә, китешли шулай да үз кул астында эшләп өйрәнгән хадимә ханымга аларның үзләренә генә мәгълүм булган шартлы ым кагуны кирәк тапты. Тегесе әлеге әйтелгән бүлмәгә ордер язып кунакның кулына тоттыргач, үз нәүбәтендә шулай ук бик бәләкәй кеше түгел икәнлеген сиздереп, шул тирәдә себеренеп-тузан сөртеп йөрүче ак алъяпкычлы кызга эндәште.

— Менә бу абыеңны йөз дә уникенче номерга урнаштырырсың. Кара аны, чисталык ягыннан беребезгә дә сүз килерлек булмасын.

Кунак инде кузгалгач, китә башлагач, өстәл артында аяк өсте басып калган хадимә аны туктатты, нидер әйтәсе бар кебек бер мизгел тынып торды. Керфекләрен түбән төшерүе һәм, тавышын кысыбрак, һәрхәлдә,

теге ак алъяпкычлы кызга бик ишеттерергә теләмичә, ишетсә дә, ул аңламаслык итеп:

— Әгәр берәр төрле обслуживание кирәк булса, тартынып тормагыз, кешесенә күрә бездә ул якны да җайлау мөмкинлеге бар,— дип, сүзнең хәзергә шуның белән беткәнлеген сиздерде.

Мөсафир үзенә билгеләнгән номердан бик канәгать калды. Берсе кечерәк, берсе шактый зур ике бүлмәдән тора, урын-җир яхшы күпертелгән, челтәр дә челтәр. Шулар янына тагын хәтфә кәнәфи, уртада тоныкшакмаклы, салпы-салмак эскәтер ябылган түгәрәк өстәл. Аның кыл уртасында вазада сирень чәчкәсе... Кунакның игътибарын аеруча җәлеп иткәне — түбәләр өстеннән, Печән базары мәчетенең зәңгәр гөмбәзләре арасыннан көн яктысында зәңгәр ахактай ялтырап ятаучы Кабан күле булды. Дөрес, күл бөтен киңлегенә ялтырап күренми, әлеге шул түбәләр, гөмбәзләр комачаулый, әмма күренгән чаклысы да кунакның хыялын уйнатырга җитәрлек иде. Сәфәренең Тимер казык йолдызы әнә шул күл инде, кайдадыр алла бар икән, Нагиевның күңелендәгеп уң итсен!

Өс киемнәрен, сюртугын салып, барысын да үз тәртибе белән урнаштыргач, хәтта ике буй төймә тезелеп төшкән жилетын да чишеп, сорочка изүләренә хәтле ычкындыргач, бераз җилләнеп, хәл җыеп алды, бер бүлмәдән икенчесенә йөренеп килде, караваттагы урын-җирне кулы белән басып карады — хәзергә бөтенесе майлагандай. Кәеф күтәренке, шулай фарт килеп торганда, кирәк булса-булмаса, саквояжга тыгылды. Аннан ямьшәк янтыклы, челтәрләп-сырлап коелган алтынсу пыялалы, шундый ук челтәрле бөкесе борылып ачыла торган гаҗәеп затлы фляга тартып чыгарды. Фляганың этикеткасында чит ил телендә язылган бернничә генә сүз янып тора иде, кунак аны тәрәзәдән төшкән кояш яктысына тотып, үзе дә соклангандай беркавым карап торды. Савытның бөтен сырлары-челтәрләре аша эчендәге шәрабы кояш яктысында үтәли ялтырап күренә иде. Ләкин мөсафир тыйнак кеше булып чыкты, бөкесенә дә кагылмады. Тик үзен тынычландыру өчен булса кирәк, авыз эченнән:

— Коньяк Депре. Сәгатең сукмаган әле синең, яткан урыныңда ята бир,— дип сөйләнә-сөйләнә, яңадан элекке урынына — саквояжына салып, бикләп алды.

Ул арада төш тә якынлашып килә икән, корсак та үзенекен сорый башлады булса кирәк, хәер, иң әһәмиятлесе ул түгел, иң әһәмиятлесен үзе чамалый, номерга бикләнеп яту өчен килмәде Казанга. Кешеләр арасына чыгарга, әкренләп кайнаша башларга вакыт иде. Һәр җәһәттән караганда да, иң элек, әлбәттә, ресторан бусагасын атлап керергә туры килер. Кунак тиз генә киенде, яңадан элекке ялтыравык кабыгына керде, хәтта бу юлы бераз арттырыбрак та җибәреп, жилетының күкрәк кесәсеннән алтын сәгать чылбырын да салындырды. Көзге каршында чак кына тукталып, болай да ыспай мыекларын сыпыргалап куйды.

Ләкин планы барып чыкмады. Ресторан болай үзе инде ачылган булса да, кырыйдагы өстәл янында фырт киенгән бер байбәтчә белән аның каршысында ук, авызына керергә чамалагандай, сары чәчле маргы кызы гына утыра иде. Тышкы ялтырауның әллә ни ачышлар вәгъдә итмәгәнлеген белеп торучы безнең бу тәҗрибәле мөсафирыбыз шундук тәртәне кире борды, чыгышлый швейцардан, серне бик чишмичә генә, сорый чыкты.

— Мине әһеле-базар халкы, үзебезнең мөселман зыялылары кызыксындыра иде. Сез әйтә алмассызмы, кайда күрергә мөмкин булыр аларны?

— Җамалый харчевнясында инде аларның иң кәттәләре,— диде швейцар, мыекны эре генә бөтерә төшеп. Бу зат кунакның «үз ресторанында» тукталмыйча, чыгып китүенә хәтере калганлыгы әллә кайдан

сизелеп тора иде, тавышына мыскыл чыгарып өстәп куясы да итте:— «Сарай шәриф»кә сугылырга мөмкин, кесә ягын такырдан булмаса...

Җамалый харчевнясы дигәнендә мыскылы бик өстә ята, «Сарай шәриф» дигәне өметлерәк яңгырый иде. Җитмәсә, ука чуклы швейцарның кесә ягына да суктырып әйтүе безнең кунагыбызны һич икеләнүсез «Сарай» ашханәсенә юнәлергә мәҗбүр итте. Ләкин монда да тәвәккәлләп кармак ташларлык күл җәйрәп ятмый иде. Беренче аптыратканы шул булды: ишек өстендәге вывескасына «Ашханә» дип язылган булса да, монда бер генә диярлек обед ашап утырган кеше күренми, озын зал буйлап тәртипле-тәртипсез тезелгән өстәлләр янында икешәрләп тә, өчәрләп тә, дүртәрләп тә утырган агай-эне тирләп-пешеп чәй чөмерәләр иде. Алларында олы чәйнек, кече чәйнек, тәлинкәдә пәрәмәч, сумса. Шикәрне дә керт итеп тешләп кенә эчәләр, югыйсә. Шулай да түбәләреннән бу бөркелә, кәләпүшләрен салып, ара-тирә башларын җилләтеп алалар. Сүзнең күплеге, сернең килешкәнлеге, үзара мактанышу шул хәтле ташып чыккан, Казанга яңа килеп төшкән кунак, хәтта ул да чамалый алды: юк, мондый күтәренкелек, кәеф көрлеге чәйдән генә булмастыр.

«Сарай шәриф»кә беренче визит ике якны да сәерсенү-гаҗәпсенүдә калдырды. Монда әлек-электән кереп, «пирәшләп» чыга өйрәнгән казанлы агай-энене зат киенгән, алтын сәгать чылбыры салындырган, күрер күзгә дә бик мәһабәт бу ят кешенең, үзебезнең мөселман мәсләгендә булганы хәлендә, урыс кешесе кебек, беренче, икенче, өченче блюдолардан корсагын тутыруы һәм, шунысы бигрәк колакны торгызды, икенче блюдо итеп китерелгән бәрәңгеле котлетның дуңгыз итеннән түгелме, дип бер дә шөбһәләнмичә ялмап куюы гаҗәпләндерсә, килгән кунак бер фактны аныклап мыегына бөтерде: юк, чәй дигәне күз буяу гына, корсаклы олы чәйнектәгесе кайнап суынган су катнаш шушы ук Казанда «кайнап» чыгарыла торган кырык градуслы чипмә-чи аракы икән. Су белән катнаштыргач, әлбәттә, аның градусы кими торгандыр, шулай да агайларны, такыр башларыннан су бөркетеп, сәгатьләр буена гәпләштереп утырырга бик тә җитә, имеш.

«Ну, и что же! Без рыбы и рак рыба,— дип уйлап куйды кунак, нишләптер русчалатып,— сүз сыярлык берәр кешесен тапмасак, мондыйлар белән утырып пирәшләп караудан да качмабыз!».

3

Икенче көнне Нагиев (мөсафирханәгә урнашканда без аның шул фамилиядә икәнлеген белгән идек инде — паспортыннан түгел, үз авызыннан ишетеп), һәр яктан тиешле формасын китереп, хәтта, кирәге чыгасына ышанмаса да, култыгына портфель дә кыстырып, чыгып барышлый баш администраторга:

— Мин наркоматка, эшләрем буенча киттем. Кичкә хәтле кайтып күренә алмасам, шаять, кирәгем чыкмастыр,— дип белдерә узды. Һәм Мәскәүнең үзеннән чыккан тәкәллефле кеше буларак, өстәп сорыйсы да итте.— Вәхаләнки мин сездәге тәртипләрне белмим, бәлки кунакның болай озак югалып торуы сездәге тәртип-низам кагыйдәләренә сыймый да торгандыр?

Баш администратор иронияне аңламаслык тупас затлардан түгел иде, тәкәллефле төрттереп әйтүне, шундый ук тәкәллефлелек күрсәтеп, колак яныннан уздыруны тиеш тапты.

Иртәнге туалет һәм киенү-ясану мәшәкатьләре өстенә көн дә иртән, башның фани чүп-чарлардан азат-имин чагында, Тукайның «Печән базары яхут яңа Кисекбаш»ын үзенә-үзе кычкырып, барлык интонация-

ләрен жиренә житкереп укуны ул көндәлек кагыйдә итеп алган иде. Моны ул мавыгып, фарыз эш башкаргандагы кебек бирелгәнлек белән, шагыйрьнең ачы теллелегенә сокланып үти, ләкин шул ук вакытта моны үтәгәндә кайчандыр шулай кирәк булачагын да истән чыгармый иде. Бүген булмаса, иртәгә аңарга нәкъ әнә шул декламация осталыгы белән кемнәрнеңдер күзләрен буарга кирәк булачак. Әлбәттә, дипломатлык осталыгын да шунда ук кушып.

Озаграк юанылган икән шул. Нагиев чыкканда Печән базары шаугөр кайный, кибетләр ачылган, алучысына караганда сатучысы күбрәк, шуңа күрә һәркайсы үз товарын ныграк мактарга тырыша, ә бу кирәгеннән артык тырышлык кире нәтиҗә бирә: нәрсә булса да алырга чыккан, ләкин әлегә акчасын кесәсендә әвәләп йөртә торган кешеләрне, бигрәк тә авыл агайларын сагаерга, һәрхәлдә, ашыкмаска мәҗбүр итә иде. Кычкыру һәм товарын мактау ягына килгәндә, шкафчы малайларга, әлбәттә, берәү дә житми һәм бу аңлашыла да: товар аларның үзләренеке түгел, таныш бакалейщиктан алып чыкканнар, сатылмаганын кичен кире кайтарып тапшырачаклар. Шулай да сатылса яхшырак, тиеннәрдән генә булса да аларга проценты жыела. Шул арада кыйммәтле «Сафо» папиросы гильзасына арзанлы «ындыр тәмәкесе» тутырылган «үз маркаларын» да сылап җибәрәләр, алучының төрлесе — ашыкканы, шкафчы малайның көйли белеп көйләвенә шаккатып авызын ябып өлгермәгәне бар. Шулай икән, ник такмакламаска шкафчы малайларга!

Хәер, шкафчы малайларны да гел бер төрле — тоташ бугаздан яки алдашудан гына торган процент кортлары дип раслау дөрес булмас иде. Әнә арада бер йолкышы буталып йөри. Тавышы да юк, күзгә дә чекерәеп керми. Күптән түгел генә авылдан килгән сала бәрәңгесе булса кирәк, ертлачлыкка өйрәнмәгән, шкафын кыйшык-мыйшык йөртүендә үк булдыксызлыгы күренеп тора. Ятимлек һәм борын төртердәй бүтән кешесе юклыгы сәбәпле шәһәргә килеп, берәр бакалейщик кардәшенә сыенган әрвахка охшый. Ә бакалейщикның ипине бушка ашатасы килми, күрәсең. Үтми торган җыен чүп-чарын малайга күтәртеп чыгарган. Шау-шулы шәһәр талкысы арасында бичара авыл малае аптырап йөрепме-йөри. Көйләп-көйләп товарын мактый белми, бүтән шкафчылар арасында белгән-таныган малайлары да юк, этлеккә дә өйрәнмәгән, шунлыктан янына килеп караучы да күренми.

Мөсафирханәдән бик тә вәкарьлек белән чыгып киткән Нагиев та, кинәт кечерәеп калганлыгын истән чыгарып булса кирәк, нишләптер шул тирәдә, кешеләр арасында бөтерелгәләп йөрүне кирәк тапты. Күрде, нәкъ аның күз алдында драматик хәл уйналды. Җылы түбән өйдә үскән ак бәрәңге сабагы кебек буйга сузылган бер дәүкәди эндәшмитынмый йөрүче теге авыл малаеның артына килеп басты, кепкасын күзенә басып төшерде, төшергән килеш каплап торды һәм, бичара малай өнгә килеп өлгергәнче, теге дөлдөлнең эшнәләре, төрле яктан ябырылып, авыл малаеның шкафындагы товарларын эләктергәләп шылырга да өлгерделәр.

Күреп торды шәп киенгән мөсафир, шундый икән шул бу Казан. Элек тә, ул Галимҗан хәзрәт мәдрәсәсендә «гыйльме хасил» иткәндә дә, Казанның мондый галәмәтләре юк түгел иде, хәзер дә кимсетелгәнне түбәләү бетмәгән икән. Ә бит революция булганга инде ничә ел!

Юк, шундый ук түгел, хәзер бераз башкачарак икән. Бер тамаша кыла башлагач, тагын шунысын да күрде мөсафир егет: күз ачып йомарга өлгермәделәр, елаш-талаш купкан урынга мәгърүрәнә олы гәүдәле, җыелган кешеләр өстеннән бер баш калка төшеп, башына милиция формасындагы фуражка кигән, ә калган бөтен ягы үзенеке: зур тупас борыны үзенеке, битендәге берничә бөртек тирән шадрасы үзенеке, ике якка ике канатын бастырып куйган калын һәм мәһабәт мыегы

үзенеке, җете кызыл сукнодан тегелгән галифие үзенеке, хәтта, нинди дә булса атлы эскадроннан кайткан кеше икәнлеген кычкырып әйтмәсә дә, итегенә таккан шпорлары да үзенеке булган һәм үзенә килешеп торган наганлы бер җантимер «топ!» итеп килеп чыкмасынмы!

— Шып бул, Чека Вәли үзе. Яхшы чакта таеп калуың хәерле,— дип пышылдаштылар кайберләр.

— Чека Вәли тотынса, җир тишегеннән казып чыгарыр. Җылама, олан,— дип, әле һаман бер читтә мышык-мышык елап торучы авыл малаен юатырга тырышты икенчеләре.

Чека Вәли дип үзе чыгарганмы, әллә өнәп бетермәүчеләр тарафыннан юри тагылган кушамат кынамы, ничек кенә булмасын, Чека Вәлинең бу тирәдә абруе зур һәм ул үзе тотынган эшне ахырына җиткермичә калмый торган кеше иде булса кирәк. Бу очракта да эшне озакка сузмады, кыскыч белән гөберле баканы әләктереп чыгарган кебек, әллә кайдан гына әлеге теге «түбән өйдә үскән бәрәңгене» — җәнҗалны башлаган ач яңаклы озын малайны якасыннан йолкып алып килде. Калганнарының табылачагы Чека Вәли булмаган кешеләргә дә ачык иде инде.

Зур тәвәккәллек, хәтта башсызлык белән керешкән авантюрасында Нагиевны болай да эчтән бер шик: «теге вакытта бергә укыган ач шәкертләрнең берәрсе очрап, төпченә башламагае» дигән шик кимерә иде, инде бу кызыл галифиле, мәһабәт мыеклы, шпорлы Чека Вәлине күргәч, эшнең уен түгеллеген, бу тирәдә болганып озак йөрергә ярамаганлыгын, барып чыкса-чыкмаса, үгезне тизрәк мөгезеннән әләктерергә кирәклеген яңадан бер кат күңеленнән үткәрде. Дөрес, болганчык чагы Казанның, болганчык суда балык тоту җиңелгәрәккә килә, ләкин шул ук вакытта урынлы-урынсыз «кармак салырга» йөрүчеләрне шулай ук мөгезеннән әләктерергә әзер торучы «кызыл галифиләр» дә бетәсе түгел. Кыскасы, нәрсә булса — шул, тәвәккәлләргә икән, тәвәккәлләргә!

Вак лареклар, беләккә элеп иске чалбар сатарга йөрүчеләр, хәтта базар уртасындагы зур лабазда, һәркайсы үз шүрлекләре буенда кызыл мал белән торучы, әле тик алучы килмәгәнлектән генә үрә катып, берсе икенчесенә җор сүз ташлап, үтеп китүче «Асылбикәләр»гә күзләрен майландырып калучы приказчикларда да аның эше юк — вак балыклар алар! Мәскәү хәтле Мәскәүнең үзеннән килгән «балыкчы» өчен. Алданрак та ишеткәләгәне бар, ыру-затларын да белә, кичәле-бүгенле вывескаларына күз дә салгалый йөри, бу Казанда НЭП чыккач сыртларына кинәт май җыйган берничә фамилия бар. Электән үк зур сәүдәнең рәтен белеп килгән, хәрби коммунизм чорында кибет ишекләренә ат башы чаклы йозак салып, үзләре толчокта дарчин, канәфер, нафталин тәкъдим итеп йөрүче «мескеннәргә» әверелгән, НЭП игълан ителеп, ирекле сәүдә ачылгач, яңадан элекке стихияләренә кайтып, колачны җәеп җибәргән бу «чуртаннар»ны Нагиев исләреннән үк сизә. Бер үк вакытта аларның бик үк тирәнгә чумып уйный алмаганнарын да белә, телләрен һәм җайларын белеп тотканда, аларны кулдан ычкындырмаска, әлбәттә, мөмкин булачак.

Еракка йөрисе дә юк, берсенең ике ишекле зур магазины «Амур»ның каршында ук. «Мөкатдәс Шәйдуллиннар һәм Ко эше. Мануфактура, галантерея товарлары, һәртөрле көнкүреш әсбаплары» дигән вывеска кояш яктысында әллә кайдан кычкырып-янып тора. Кичә Нагиев җиңел извозчик белән «Амур» алдына чажлап килеп туктаганны һәм, бумажникны эре генә чыгарып, банкнот ук булмаса да, извозчикка кәгазь акчаның салмак тарта торганын биргәнен кибет алдына чыгып баскан Мөкатдәс бай күреп, гаҗәпсенү катнаш сокланып карап торды. Нагиев үз нәүбәтендә байның моны күреп торганлыгын шулай ук шәйләде — Мөкатдәсне ул Казанда «гыйльме хасил» иткән чагыннан ук танып белә иде. Күрше хакы — тәңре хакы, әллә үлчәү кылын тартып карау өчен шуңа сугылыргамы? Уратып башлау кирәк булса,

уратып башларлык сүзе бар, һич булмаса дөньяда юк нәрсәдән башлап, шаккаттырырга мөмкин. Турыдан-туры әйтер: «Әссәламәгаләйкем, Мөкатдәс әфәнде. Бөтен ышаныч сездә. Сездә табарга мөмкин булганын күңелем ук сизә. Минем бугаздан китереп торткан хаҗәтем: алтын портсигар. Чит ил дипломатларына эшем төште. Бүләк итеп бирү өчен, минимум, алтын портсигар кирәк».

Чамача шулай башламакчы булып кергән иде Нагиев, хәлбуки, эш алай катлаулы булып чыкмады. Монда аның башны югары тота белү осталыгы, энәдән-җептән генә төшкән «тройкасы», ялтыравыклы шиблетлары, жилет кесәсеннән асылындырган алтын сәгать чылбыры һәм, барыннан да бигрәк, конторкага, Мөкатдәс байның үзе янына барып кергәч, оста коммерсантларча:

— Кадерле эш вакытыгызны алмыйммы, тәкъсыйр? Сез эш кешесе, мин эш кешесе, күп такылдауны гайбәтче хатыннарга калдырыйк,— дип кыска һәм оста итеп сүз башлавы картның колагын торгызды. Шундук сөйләшә, аңлаша башладылар. Нагиев, алдан ук корып куйган планы буенча, үзен дәрәҗәле мәркәз оешмалары тарафыннан бу якларга командировкага җибәрелгән, иртәгә үк булмаса, берничә көннән өязләргә чыгып китәчәк кеше итеп танытты һәм шундук, Мөкатдәс картка як-ягына каранырга да бирмичә, сүзне үзенә кирәк җайга борды.

— Болай тәкәллефсез рәвештә сез мөхтәрәмне эшегездән бүлүем дә бугаздан китереп торткан зарурият аркасында, гафу боерасыз. Кыскасы, Сез миңа Мәскәүдә таба алмаган затлы бер пустякны табып бирергә тиешсез, мөхтәрәм Мөкатдәс әфәнде. Йөреп-йөреп тә таба алмагач, мин шундук сезне искә төшердем, мөхтәрәмем. Тапса моны, мин әйтәм, мәгәр Казанның мәшһүр коммерсанты мөхтәрәм Мөкатдәс агабыз Шәйдуллин гына табар, дим. Әлбәттә, бәһадән эш тормас. Кирәк икән биш бәһасен түләргә боерыгыз, биш бәһасен түләргә әзермен. Кыскасы, Мәскәүдән Казанга килүемнең төп сәбәбе менә шул. Мин әйтәсе сүзләремне әйтеп бетердем, инде сезнең сүзне көтәм.

Бу Мәскәү егете казанлы Мөкатдәс Шәйдуллинга беренче караштан ук ошады. «Мөхтәрәм», «агабыз» кебек китап-газета сүзләре кыстыргалап сөйләнүе белән түгел, эчке энергияле, сүзне сузмыйча сөйли белүе, рәсми командировкасына сыланып ятмавы, барыннан да бигрәк, Мөкатдәс Шәйдуллинны, моңа хәтле Казанның Печән базарында гына үзен «король» итеп санаган Мөкатдәс Шәйдуллинны хәтта Мәскәүдә дә искә алулары, Мәскәүдә таба алмаган зат нәрсәләрне аның аша табарга исәп тотулары картның горурлыгын кузгатып җибәрде. Шулай да алтын портсигар турында сүз чыккач, гомумән, алтын мәсьәләсенә күчкәч, карт, елап ук җибәрмәсә дә, шулай да бик бетәшкәнгә салышты.

— Кайда инде ул алтын. Хатынның колагындагы алкасын салдырып алсаң гына инде.

— Ә без алай уйламаган идек,— дип куйды кунак, бу сүзләре белән Мөкатдәс картның мин-минлеген янә дә очындырып.

— Аны әйтәсең син, әфәндем. Мин борынгырак кеше инде, искечә җибәрәм кайчакта. «Әфәнде» дигәнгә ачулана күрмәгез тагын,— сүзне юри шулай боргалап, юргалап алып китте хәйләкәр нэпман,— буй җиткән кызым бар, Гөлчирә атлы, пешкән кура җиләге. Тот та тел өстенә сал. Тиешле кешесе чыкса, бүген тотып ярәшерлек кыз. Ә муенына тагарлык затлы энҗе-мәрҗәне, бриллиант кашлы йөзеге юк. Хөкүмәтнең үз нәфесе бик зур бит андый зат нәрсәләргә.

— Сез алты процентлы алтын заемы чыгаруны күздә тотмыйсыздыр бит? — дип сорап куясы итте кунак, тыйнаклык саклап кына.

— Мин көннең узасын, киләсе кичнең киләсен, шушы фани дөнья ыгы-зыгысына бирелеп, бүген тагын икенде-ахшам намазына өлгермәячәгемне генә күздә тотам.

Ул арада әле теге, әле бу йомыш белән хуҗа янына керә-чыга тордылар, сүз бүленә, очын югалта барды. Ә Нагиевка сүзнең очын югалту һич тә файдалы түгел иде.

— Безгә монда иркенләп сөйләшергә комачаулыйлар,— диде ул, кинәт катгый тонга күчеп,— мин үземнең өмет баглап килгән ышанычларымның болай тиз җимерелүен һич тә теләмәс идем.

— Абайламый калдым,— дип, тупас кына тегенең сүзен бүлдерде,— сезнең соң рәсми командировка дигәнегез нәрсәдә? Без — кара халык, шулай төпченергә күнеккәнбез инде, нишлисең.

Нагиев кулын гына селекте.

— Әй, ул турыда авыз ачып сөйләп торырлыгы да юк. Саранчага каршы көрәш. Бәлки колагыгызга да кергәндер, сезнең бу якларда, кайбер кантоннарда дигән сүзем, саранча бик котыра башлаган,— бу очракта сүз куертуның әллә ни зур әһәмиятен тапмагандай, бер мәл пауза ясап торганнан соң, теләр-теләмәс кенә өстәде:— заманында академия бетергән идем, янәсе, бөҗәкләргә каршы специалист. Менә хәзер шуның үчен чыгарып йөдәтеп йөртәләр.

Республиканың кайбер кантоннарында саранча күренә башлавы турында Казан сәүдәгәренең дә колагына кайчандыр кергән иде. Кунакның бу сүзләрен ишеткәч, бигрәк тә бу йомышка теләр-теләмәс кенә алынуын сизеп, аның бу шома мөсафирдан шикләнүе кими төште. Шулай да бик ачылып китәргә ашыкмады.

— Әллә мин безнең яшергән алтыннарыбызны саный килгән берәр финиспектормы дип торам, курка калдым,— диган булды ул, сүзне ничек тә уен-көлкегә борырга тырышып.— Андый куркыныч кеше булмагач, нишлибез соң? Олы җирдән чыккан абруйлы адәм белән гәпләшеп утырырга мин һәр вакыт әзер. Килеп чыгыгыз соң. Әйтик, бүген кичкә. Мөсафир кеше, миңа да әҗере тими калмас.

Бусы Нагиев өчен иң әһәмиятлесе иде. Шулай да ул нәзакәтлелек йөзеннән әйтмичә кала алмады:

— Бәлки иң элек миндә кунак булуны мәслихәт табарбыз. «Амур» мөсафирханәсе каршыда гына. Юлын табарсыз дип уйлыйм.

— Хуҗаның мөсафирда кунак булуына караганда, мөсафирның хуҗа өендә кунак булуын мактый китап. Әллә ни зур укымышыбыз булмаса да, ул хәтлесен генә беләбез, бигайбә.

Мөкатдәс карт өстәл календаренең өске битен тәкәллефсез генә ертып, тиз генә адресын тырнап бирде — булды, Нагиевның беренче визиты, әйтергә мөмкин, уңышлы тәгәлләнде.

## 4

Шәйдуллин нэпманның бик алай кинәт чишелеп, Мәскәүдән килгән мөсафирны өенә үк чакыруы үзенең Мало-мещанский урамындагы ике катлы особнягын һәм анда һәр яктан шәп куелган тормышын күрсәтү өчен генә түгел — бу хәтлесе дә юк түгел иде, әлбәттә. Шулай ук Нагиевның саранчага каршы көрәш буенча Мәскәү хәтле Мәскәүдән җибәрелгән дәрәҗәле командировкасы да түгел — саранча дигәне кайдадыр сала җирендә, монда хәзергә, аллага шөкер, Мөкатдәс Шәйдуллинның эшенә һәм складларына саранча төшмәгән. Киресенчә, ул үзе һәм аның компаниясе алу-сату эшен оста йөртә белүе аркасында, вактөяк такыр башларны, аларның үзләренә дә сиздермичә, йота бара иде.

Шәйдуллинның мөсафирны туп-туры өенә «рәхим итәргә» чакыруының ике сәбәбе бар: бердән, Нагиев фамилиясе телдән төшүгә үк аның колагы торды. Инде күптән, бу хөррият дигәннәре чыкканчы ук, Мәкәрҗә ярминкәсендә Шәйдуллинның Нагиев фамилияле бер Касыйм татары, эшне зурдан йөртүче шома купец белән склад мәсьәләсендә күчәр

башы бәрелешкән, теге хәйләкәр төлке артык бәһасен биреп, Шәйдуллин алдан килешкән складка тешләрен батырган, нәтиҗәдә сәүдәнең нәкъ кызган чакларында шушы мәсьәлә буенча тарткалашып бәгыренә төер кадалып калган иде. Хәер, бу мәсьәлә тиз ачыкланды.

— Юк, однофамилецлар гына булсак кирәк, мин укымышлылар токымыннан, безнең эш элек-электән дипломатия өлкәсе. Минем әти герман сугышына хәтле Төркиядә Россия посолының ярдәмчесе булып хезмәт иткән кеше. Сугыш елларында аннан китәргә мәҗбүр булды, үзегез беләсез, Төркия — безгә каршы союз члены иде.

Кунак шулай югартын сиптерә башлагач, Мөкатдәс карт ул турыдан гәпне артык куертмаска булды. Димәк, борынгы төерне кузгатып торуның хаҗәте юк — утыра бирсен утырган җирендә. Аның каравы, икенче сәбәбе күңелне тагын да ныграк кытыклый башлады. Алда бер сүз булган иде шикелле: Мөкатдәс картның буй җиткән кызы, Гөлчирәсе, пешкән кура җиләккәе бар. Ә бу кунак егет, әгәр сүзе чын булса, әнә нинди шәп токымнан икән. Токымы кадалып китсен, күренеп торганы: әнә нинди зур җирдән чыккан, казна эшләре белән йөри, түш кесәсеннән алтын сәгать чылбыры салынган, сәүдә дигәндә теле-телгә йокмый. «Һәрхәлдә, Казан мещаннарының, этиләре кассасыннан акча чәлдереп, сары чәчле марҗа кызлары белән итче Гыймадиның яшертен эшли торган мунчасына чаба торган бозык малайлары түгел. Әйтеп булмый, һай, ул «пешкән кура җиләген» шушы егетнең авызына салып, Мәскәүнең үзе белән үк аралашып алсаң кана! Мөкатдәс моны алдан ук күңелендә тотып, кичкә нинди кунак буласын өйдәгеләргә дә әйтеп куйган иде, югыйсә. Әзерлек чаралары да күрелде, югарыгы ак өйдә моңарчы һич кабызылмаган хрусталь люстра да кабызылган иде.

Ләкин кунак бусаганы атлап, исәнлек-саулык сорашу, йортка фатиха бирү һәм хуҗа тарафыннан ашыгыбрак кузгатылган әлеге «Нагиев» фамилиясенә карата ачыклык кертү белән үк, бик тә шом сала торган итеп, тавышын серле рәвештә кыса төшеп, кисәтү ясарга өлгерде.

— Безнең мөсахәбәбез [1] вакытында, тәкъсыйр,— диде ул, ярым пышылдау белән,— мөмкин икән, чит-ят колакның булмавы хәерле. Бигрәк тә кыз-хатын бүрәнә аша бүре күрүчән...

Менә сиңа, мә! Мөкатдәс карт аның авызына «пешкән кура җиләге» салмакчы, ә бу чибәр егет алдан ук иреннәрен йомарга тора. Бер үк вакытта кунакның мондый тыйнак күренүе, пышылдауга күчеп әйткән сүзләре, аулакта каласы килүе һәм инде онытылып бара торган «тәкъсыйр» сүзен кыстырып җибәрүе хуҗаны, гаҗәпләнү катнаш, иләсләндереп өлгергән, хуҗа бу очрашудан өметләнеп нәрсәдер көтә һәм, әлбәттә, үзе өчен файдалы булырдай нәрсә көтә иде. Кунакның ишарәсе шулай булгач, теләсә дә, теләмәсә дә, аңарга аскы һәм күрше бүлмәләргә чыгып, өйдәгеләрне дә кисәтеп, бер юргалап керергә туры килде.

— Мин инде алай зур җирләрдә булган кеше түгел, бермәл аптырабрак та калдым,— дип сөйләнә-сөйләнә, сүзне нидән ялгап җибәрергә белмичә, өстәл тирәли әйләнгәләп алды карт. Шул ук вакытта аның укымышлы кунак алдында бик үк төшеп калганнардан да булып күренәсе килми,— мөсахәбәне башлап җибәрү өчен, сүздән әйтик, шифалы зәмзәм сулары куллана торган менә бу көмеш кырыйлы нечкәбилләрне кузгатсак, ә?

Ул пыяла шкафтан затлы рюмкалар ала башлаган иде дә, кунак бу урында үзенең югарыдан килгән кеше икәнлеген янә күрсәтергә өлгерде:

— Алдан ук әйтеп куям, мин аның кешесе түгел, Мөкатдәс агам,— диде ул, бу турыдагы сүзне шуның белән өзәргә тырышкандай,— мөсахәбә икән мөсахәбә. Утырыгыз әле каршыма.

---

[1] Мөсахәбә — әңгәмә, гәпләшеп утыру.

Боерык тоны белән диярлек әйтелгән бу сүзгә Мөкатдәс карт, гәрчә үзенең хуҗа икәнен онытмаса да, буйсынмыйча булдыра алмады. Менә алар инде кара-каршы ук утыралар, өйдә икәүдән-икәве генә... Берсен-берсе үтәли күрергә теләгәндәй, беравык сүзсез күзгә-күз карашып калдылар.

— Сүзне башлап җибәрү өчен, һич югы, «Татарстан» газетасының бүгенге санына күз салыйк, агам,— дип, тегеләй-болай уйланырга һич ара калдырмыйча, эчке кесәсеннән газета тартып чыгарды Нагиев,— анда жирный хәрефләр белән басылган мондый бер игъланны укып карыйк. Хәтта игълан да түгел ул, өндәмә, дәгъвәтнамә, вызов, русчалап әйтсәк.

Һәм ул хуҗаның аптырабрак калуыннан оста файдаланып, тавышына артык басым ясамыйча, шул ук вакытта һәр сүзен иҗекләгәндәй ачык итеп түбәндәге игъланны укып бирде:

> «Отышлы алтын заемының беренче уйналышында эшче Туриков алтын бәһасе белән 50 000 сум отты. Отышлы алтын заемы облигациягез булса, 20 августта уйналуында Сезнең дә шундый зур акча ота алу ихтималыгыз бар!»

Кулындагы газетасын берничәгә бөкләп яңадан кесәсенә тыкты һәм әллә ни тирәнгә китмәгән кыяфәт саклап, сорау куйды:

— Әйтегезче, солтанәтле агам, нәрсә дигән сүз бу сезнеңчә? Һәм бүгенге санда гына да түгел, сан саен диярлек шулай дәвам итә. Нәрсә дигән сүз бу?

Кунак хуҗага кинәт шундый текәлде, бу караш алдында җавапсыз озак калырга мөмкин түгел иде.

— Нәрсә дигән сүз, дип... ни... аблигациясе булган кешегә «кесәңне җәебрәк тор, хәзер, алланың кодрәте белән, синең кесәңә меңнәр ява башлый» дигән сүздер инде. Минем үземнең аблигациям юк, шулай булгач кесәм дә, күңелем дә тыныч.

Нагиев, авызын мыскылсыз гына кыйшайтып, бермәл көлемсерәп торды — картның туры сүзлелегенә гаҗәпләнү дә, бер үк вакытта аның мәнсезлегеннән аптырау да бар иде бу көлемсерәүдә.

— Берчәк былайрак түгел шул, кәбәм,— диде ул, Сергач мишәрләречәрәк кыланырга тырышып,— без шул һәр даим үз кесәбезне генә җәеп тотарга өйрәнгәнбез. Ә Совет алай уйламый, ник дисәң, Советның үз кесәсе бар. Сез мине берчәк кенә төшенә башламадыгызмы икән?

— Сәвит белән минем ике ара законный, ул налогын сала, мин үз вакытында түләп барам, монда озак төшенәсе бәрәкәт юк.

Үз нәүбәтендә Мөкатдәс картның да бик алай таш маңгай булып күренәсе килми, кунагына мөнәсәбәтән, «Син белеп тусаң, мин элек туган!» дигән кебегрәк кыяфәт алган иде. Нагиев моны шундук сизде, тактиканы үзгәртә төшәргә, илтифатлырак күренергә тырышты.

— Мин әйтә белеп әйтмәгән булсам, пардон, кичерә күрегез,— дип башлады ул бу юлы, ерактанрак урап.— Ә көндез без сезнең магазинның конторкасында әүвәлге очрашуыбызда сүзне конкретрак башлаган идек. Мин башладым: «Сездән яки сезнең аша берәр танышыгыздан алтын портсигар табарга мөмкин булмасмы?» — дип. Сез әйттегез: хатының колагындагы алкасын ук йолкып алмасак, алтын юк ул, дидегез. Күрәсез, сүз чиста коммерсантларча башланган. Беребез сораган, икенчебез «юк» дигән. Ә Совет «юк!» белән генә калырга риза түгел. Совет юкны таптыра, агитацияли, үгетли, тупасрак итеп әйтсәк, котырта, заем уйлап чыгара. Аны тарату өчен халык арасында өндәү-димләү эшләре алып бара. Кыскасы, Советка халыкта кысылып калу ихтималы булган благородный металлны, безнеңчә әйтсәк, алтынны, ничек тә тизрәк үз казнасына суырып алу кирәк. «Ни өчен шулай? Үз Советыбыз лабаса!» диярсез.

Мөкатдәс карт ул чаклы ук җебеп төшәргә, әлбәттә, җыенмый, совет властена карата, ирекле сәүдәне ачкач беркадәр йомшарса да, аның таш булып каткан үз карашы бар: «Еврейләр һәм бәдбәхет стукиннар уйлап чыгарган шау-шу. Мәңге барачак түгел, тиздән таркалачак» дип карый иде. Шулай да алтын мәсьәләсендә төшеп калганнардан түгел, кунакның озакка сузылган бу шома сүзләрендә читләтеп-читләтеп кенә булса да алтынны яклау, хөррият дигәннәренә шикләнебрәк карау галәмәтен тотып алды. Игътибарлырак була башлады. Шулай да сүзгә кушылуга караганда, сүзне тыңлау бу очракта аның өчен файдалырак күренә иде. Беркавым сүзсез утырдылар, игътибарлы һәм илтифатлы булу ягыннан берсе икенчесеннән ничек тә калышмаска тырыша иде.

— Алайса, бер башлагач, ни өчен кабалануыбызның сәбәбен дә әйтим: «Советның казнасында алтын саега бара. Аны Врангель да алып китте, качып киткән зуррак чуртаннар да алтын-көмеш байлыкларын алдан ук валютага алыштырып Швейцария банкларына күчереп өлгерделәр. Ә большевикларга, гәрчә алар чит ил капиталистларына кул үбеп сәлам бирергә әзер тормасалар да, чит илләр белән сәүдә итә башларга кирәк, шунсыз дәүләт бара алмый. Ә капиталистлар белән сәүдә итим дисәң, рәхим итеп, кулыңда алтының булсын. Алтын заемнары чыгаруның, газета битләрендә ул заемны тарату өчен «Әллә-ли, ашыйсың килсә әлбәне!» дип кызыктыру, өндәү-димләү эшләре алып баруның серен аңладыгызмы хәзер?

Бу хәтле тәфсилләп үк әйтә алмаса да, тулаем, илдәге хәл-әхвәлләрнең ничегрәк торганлыгын Шәйдуллин үзе дә чамаламый түгел иде. Ләкин бу минутларда, Мәскәүдән чыккан егетнең болай бирелеп исбатлап азаплануларында, хәтәр елтыраган күз карашларында, үзен гаять белдекле-хәбәрдар тотышында карт төлке икенче бер сүзнең, әлеге әйтелмәгән сүзнең качып ятканлыгын шәйләде. Үләр дәрәҗәгә җитеп кызыксыну, егетнең шәп тотышына соклану һәм сирәк очрый торган бу асыл кошның башкалар читлегенә эләккәнче, нәкъ менә аның, «мануфактура һәм галантерея эше» тотучы сәүдәгәр Мөкатдәс Шәйдуллинның читлегенә эләгергә торуы аны урынында утырып кала алмаслык хәлгә җиткезгән иде. Ниһаять, ул үзен тыеп кала алмыйча, янадан пыяла шкафтагы нечкә билле рюмкаларга барып ябышты.

— Куегызчы, мөхтәрәм әфәнде,— дип, үтенеч дәрәҗәсенә җитеп, мөсахәбәне дәвам иттерүне сорады кунак.

— Коры кашык авызны ерта,— дигән булды карт, рюмкаларны теләр-теләмәс кенә янадан урынына куеп,— сүз җилеме итеп, әллә чакчак кына тәнәвел кылыйкмы, дигәнем иде.

Дөресен әйткәндә, Мәскәүдән чыккан егетнең эчемлеккә болай битараф каравы аны «пешкән кура җиләге»нең әтисе алдында янә бер карыш үстереп җибәрде — юк, азып-тузып йөри торганнардан булмаска тиеш бу, бөтен гамәле, сүзе-өне җитди кеше икәнлеген күрсәтә. Димәк, үзеннән-үзе аңлашылса кирәк, эти кешенең «пешкән кура җиләге»н ничек тә тизрәк кунак егет алдында бер ялтыратып аласы килә иде.

— Әй, кайсыгыз бар анда? — дип, ишекне ачып, боерык тавышы салды карт,— кунакны коры өстәл артында озак утыртырбыз микән? Башыгыз бармы сезнең, юкмы?

Ишектән берәүне көткәндә, язмыш шуклыгы дип әйтергәме, бөтенләй икенче, һич көтелмәгән кеше — извоз хуҗасы Чукрак Зариф килеп керде. Дөрес, Чукрак Зариф Шәйдуллиннарга бөтенләй үк ят кеше дә түгел, хатыны ягыннан Мөкатдәснең «чыбык очы», үзенең дә көймәсе комда утырып калмаган, ун-унбиш ат белән ямщик тота. Усад спирт заводыннан Казанның аракы заводына спирт ташытучы. Шулай да ике ишекле зур таш магазинда «мануфактура һәм галантерея эше» тотучы атаклы сәүдәгәр Мөкатдәс Шәйдуллинга җитәргә аңарга бик-бик ерак, ә аның, Чукрак Зарифның, җитәсе килә, җитәсе килә... Әмма кайсы

ягыннан гына килеп карама, бу очракта, бу зур кунак алдында ул мокытның эзләүсез-сораусыз якты залга хәтле үк үтеп керүе искәрмәстән генә ашка төшкән кара таракан булды.

— Кара әле, кем, Зариф туган, син инде ни, бигайбә,— дип сөйләнә-сөйләнә, тегене ничек тә ишеккә кире борырга маташты Мөкатдәс. Теге әллә чынлап та ишетмичәме, әллә бу тәкәбберлекне ничек тә ишетмәгәнгә салышыпмы, карышып, ишек төбендә таптаныбрак тора башлагач, һич тәкәллефсез кукрәгеннән тышка таба этәрде.— бүген ни... Шулай, туган. Дәрәҗәле кунагым бар бүген, бүленә алмыйм, бигайбә.

Бу ишектән этеп чыгаруның соңыннан, бер дә бер кичне, нинди тамашалар китереп тудыру ихтималы булганлыгын Мөкатдәс карт, айһай ла, алдан белгән булсачы!

## 5

Берара өйдә җайсыз тынлык урнашып калды. Утларның яктылыгы, залның зиннәтле җиһазлары бу тынлыкны аеруча йогынтылы итте, бермәл кем дә ни дип тә сүз башларга кыймый торды.

— Шундый бер әрсез алабай инде ул, ишектән кусаң, тәрәзәңнән керер,— дип сөйләнә-сөйләнә, ниһаять, урыныннан купты хуҗа. Аның яшендәге һәм аның байлыгы булган кешеләргә бик үк килешеп тә бетмәстәй юргалау белән ишеккә китте.

Ишекнең теге ягында картның шактый ук тупас тавыш белән:

— Түбәнге ишекләрне бикләп куегыз, берәүне дә кертмәгез дип ничә әйтелгән сезгә,— дип кычкырганы бу яктагы кунакка да аермачык ишетелде. Әмма кунак кем белән эш иткәнен чамалый, «тараканы» да вакытсызрак төште шул, хәерсез. Кайда монда тәкәллеф саклап торырга мөмкин булсын! Баягы каты сүзләргә ялгап ук, бусы кунакка да ишетелсенгә чамалап булса кирәк, тагын да күтәренкерәк итеп өстәде хуҗа:

— Кичнең кич буена кунакны коры сүз белән сыйлыйбыз. Өстәл әзерләгез дип тагы күпме әйтергә икән сезгә!..

Кергәндә мөмкин чаклы ачык чырайлы булырга тырышып керде һәм, тәкәллеф белән кунактан гафу үтенгәндәй, йомшак кына сөйләнде:

— Шулай инде безнең монда, кругом дуамаллык. Сез, зинһар, мәркәздәге тәртипләрне көтмәгез бездән.

— И агам-кара кашым, мәркәздә ходаның нинди бәндәләре юк дип беләсез!

Нагиевның бу тактик хуты да вакытлы ясалды. «Зарар юк, әллә ни игътибар итмәде шикелле. Бу яктан да егет үз кеше күренә», дип тиз генә уйлап куйды карт.

Ул арада ишектә кулына берьюлы эскәтер, тастымаллар, ак поднос-та чәй әсбаплары күтәргән, шактый ук юаная башлаган ханым күренде. Эскәтер, тастымаллар барысы да кар кебек ак, чиста, пөхтәләп үтүкләнгән, чәй әсбаплары көмеш тә фарфор иде.

— Бусы минем җәмәгатем, Гөлсара ханым була,— дип аңлатма кертте Мөкатдәс, мөмкин хәтле нәзакәтлелек күрсәтергә тырышып.— Асрау тотмыйбыз, хәзерге заманда кешегә ышануы кыен, өендәге хәлне урамга таратырга гына торалар.

Гөлсара исәнләшкәндәй итеп кунакка рәхимле бер караш ташлады, күренеп тора, артыгы аңарга рөхсәт тә ителми иде булса кирәк. Хатыны чыгып киткәч, башланган сүзне дәвам иткәндәй, яңадан Мөкатдәс үзе тотынды:

— Бирердәен кешегә биреп эшләтәләр, әмма әйтми булдыра алмыйм,— бу урында карт тавышын кыса төште,— хатыным да, кызым да бик уңганнар, тел тидермәслеккә тел тидереп булмый.

Хуҗаның бу сүзләрен җанлы раслау кебек булып, нәкъ шул минутта ишектә зифа буйлы, бөтен килеш-килбәте кояш нурыннан һәм җырдан коелгандай чибәр кыз күренде. Кызның кулында олылы-кечеле ике чәйнек утыртылган, чәйнекләренең өсте шакмаклы махсус салфеткалар белән капланган көмеш ак поднос иде. Подностан да бигрәк, кунакның күзләре кызның кулларына төште:— «Юк, башка адәм балаларыныкы кебек иттән, кимерчәктән, тиредән оешкан түгелдер, мәрмәрдән коелгандыр бу куллар!» дип әйтәсе килде егетнең. Гомумән, бу минутта ул бераз таркалыбрак калды, нишләп йөргәнен, бу өйгә нинди максат белән килеп кергәнен онытты — ә аңарга моны бер генә секундка да истән чыгарырга ярамый... ярамый иде. Әнә шундый дөньяны оныттыра торган һәм бер үк вакытта бәхетле бер мизгел булды бу. Ярый, нәкъ вакытын белеп, кызның әтисе сүз кушты.

— Менә бусы минем родной кызым Гөлчирә була инде,— диде Мөкатдәс, кызы белән мактанырга хакы булганлыкны, әлбәттә, сиздерәсе килеп. Һәм үз нәүбәтендә бу очракны болай шудырып кына үткәрәсе дә килми иде,— менә, кызым, бу Котдус абыең була, Мәскәүнең үзеннән, дәрәҗәле командировка белән йөрүче. Таныш үзе белән, нәрсә буенча дидегез әле? Я, ярый, калып торсын анысы. Зур специалист, бер фараз...

Кыз күтәрелеп үк карамады, шулай да куе керфекләре астыннан оялчан гына күз сирпеп алды. Һәм хөрмәтләү билгесе итеп, тәмам җиренә җиткезеп, реверанс ясады. Болай оста һәм җитез бөгелеп-сыгылып алуына караганда, егеткә — бигрәк тә болай таркалыбрак калган минутында — «бу чибәрнең сөяге шулай ук юктыр. Нәрсәдән тора икән аның бу грациоз буй-сыны? Тотып карыйсы иде бер» дигән соклану катнаш яхшы ук шәрә уй да килде. Ләкин, тәүбә-әстәгыфирулла, башка шундый юк-бар уйлар китерергә ярыймы соң? Үзең кыл өстендә йөргәндә. Тотып карау түгел, юньләп күреп калырга да форсат бирмәде кыз. Ничек очып кергән булса, шундый ук тизлек белән очып чыгып та китте.

— Менә шул,— дип куйды Мөкатдәс, товар мактаган кебек канәгать тавыш белән,— без каткан сөяк түгел кыз. Азмы-күпме гимназиясен дә эләктереп калды. Хөррият чыкканчы.

Чәйгә утырдылар. Кызы белән мактана башлаган Мөкатдәс картның мактану өянәге әлегә басылып җитмәгән иде. Бәләкәй чәйнектән алтын путаллы фарфор чынаякка кечкенә шәфәкъләй куе кызыл чәй коя-коя сөйләнүен дәвам итте ул:

— Күп җирдә безнең ише ике аяклы, ике куллы кешеләр үлән чәе эчкәндә, без менә, ходаның биргәненә шөкер, чын чәйлүн чәй эчмәктәбез,— ул мыек астыннан гына кеткелдәп куйды,— тәнгә сихәтлек өстәү йөзеннән, арага менә монысын да кушып җибәрәбез. Каюм Насыйри баба шулай мәслихәт күргән.

Ул кул астына яшеребрәк куйган шешәне тартып чыгарып, чынаякларга чамасын белеп кенә коньяк койды. Кыскасы, хәзергә ул барысыннан да, бигрәк тә сүз арасында Каюм Насыйри исемен кыстырып җибәрергә башы җитүеннән бик канәгать иде. Галимҗан хәзрәт мәдрәсәсендә «гыйльме хасил» итүе, аннары теге... кайда әле, әлеге шул Мәскәвендә инде, академия бетерүе белән бу чибәр егет кенә мактанмасын әле, Мөкатдәс абзасы да гыйлем дөньясыннан җәяүләп качкан кеше түгел.

— Однако без асыл максатка якынрак килик, Мөкатдәс агам,— дип сискәндергеч җитдилек белән картны бүлдерәсе итте кунак. Ул әлегә чәйгә авыз тидерергә ашыкмый, аны тик көмеш кашык белән бик ләззәтләнеп болгата гына иде,— минем сезгә ясаган бу визитымның төп сәбәбен көндез, конторкагызда чагында әйтә башлаган идем шикелле. Монда без Советның алтын яратуы һәм нилектән зря болай алтынга

гыйшкы төшүе турында гәпләшеп алдык. Логикасы да юк кебек беренче карашка. Ә без, мәрхүм Каюм Насыйри рецепты буенча ясалган менә бу чәйне эчә төшкәч, аның логикасын, шаять, табарбыз. Хәзергә мин сүзне алтын портсигардан башлыйм.

Бераз чәй чөмереп алды, аннары яңа кыюлык туплап, сүзнең озынга китүенә чак кына җене дә чыга башлагандай, тиз-тиз тезәргә тотынды:

— Кирәк миңа алтын портсигар, хет җир астыннан тап. Мәскәүдә Бельгия посольствосындагы бер господин белән арабыз якынаерга тора, әйтсәм әйтим, ул миңа, мин аңа кирәкле кешеләрбез — коммерция в международном масштабе. Эшнең башлангычы итеп ул әфәндегә әдәп йөзеннән нинди дә булса бүләк тәкъдим итәргә кирәкме? Сез, Мөкатдәс агам, моны үзегез дә беләсез булыр. Сезнең борын ис сизә торган кеше икәнен миңа Мәскәүдә чакта ук әйттеләр. Мәскәү шуның өчен дә Мәскәү ул — җеп очлары аңарга теге яктан да, бу яктан да килеп тоташа.

Ул ясаган чәйне эчеп җибәрде, кызарып, матураеп китте, формасын китереп ап-ак яулык белән битен, авыз читләрен сөрткәләп куйды. Шуннан соң, бу йортны бик тә үз иткәндәй, бер дә кыстатмыйча чынаякны янә хуҗага таба сузды:

— Ярыйсы булып китте бу көтелмәгән мацион, хотя минем ужин сәгате әлегә җитмәгән икән җитүен дә,— ул кесәсеннән алтын сәгатен чыгарып карады,— әйтсәм әйтим, Мөкатдәс әфәнде, Бельгия посольствосында безнең Кабан күле белән кызыксынучылар бар. Гаҗәп хәл, дисезме? Бу дөньяныкын белмәссең, гаҗәеп-хәйран хәлләр дә була икән шул. Күз алдыгызга китерегез, Каспий диңгезе белән дә түгел. Баскунчак яки Балхаш күлләре белән дә түгел, Казан каласындагы кызлар кер чайкый торган шушы уч төбедәй Кабан күле белән кызыксыналар.

— Бардыр, без белмәгәч тә,— дип җуплап куйды Мөкатдәс. Аның кунак белән кызыксынуы көчәйгәннән-көчәя бара иде. Бу юлы «Каюм баба рецептын» күбрәк сала төшеп, кунакка да, үзенә дә яңадан чәй агызды,— күпме әйбер төшеп югалды. Узган сабан туе вакытында әнә нинди тамаша чыккан диең. Ике кызма баш «Нептун» пароходында «Аркадия» бакчасы ягыннан кайтып килешли, юктан гына спорлашып, беләсеңме, нинди ахмаклыкка барып җитәләр? Берсе икенчесенең менә синеке шикелле алтын сәгатен күкрәгеннән йолкып алып суга атып бәрә. Туксан алты пробалы, тегермән ташы хәтле алтын сәгать, ди.

Бер башлагач, Мөкатдәснең дә, әлбәттә, төшеп калганнардан түгел икәнлеген күрсәтәсе килә иде. Ясаган чәен берьюлы чөмереп җибәрде дә иплән кенә янә тотынды:

— Аны әйтәсең әле син, әнә Тегәрҗеп урамындагы тирече Хәмзәне әйт. Белгән, ашын ашаган кешебез. Кай ягы беләндер безгә кода да тиешле. Шуның шул Зөһрә дигән тинтәк кызы, урта мойкада кер чайкаганда, балтадай калын алтын беләзеген төшереп җибәргән. Кирәк бит, үзе кер юарга төшә, ә беләгендә алтын беләзек. Егет күзләргә барамыни ахмак баш.

Хуҗаның үзе кебек берьюлы ук чөмереп куймаса да, теге сөйләгәндә иренен чылаткалый утыргач, кунак та чынаякны бушатты һәм күп сүзле картны шундук бүлдерәсе итте:

— Бельгиялеләр безгә караганда күбрәкне күрәләр булса кирәк,— диде ул, мәгънәле генә итеп. Бермәл тынып, Мөкатдәс картның күзләренә карап торды — икесенең дә күзләре ут яна, әмма егетнеке — яшь күзләр — очкынланыбрак яна иде.

— Илһамландырып җибәрде әле безнең бу сөхбәт,— дип дәррәү кабынып китте кунак. Шулай да картның күңеленә хуш килә төшкәнне сизеп, китап сүзләре кыстыргалап җибәрүне онытмый иде. Аякка ук торып басты, пинҗәк чабуларын икесен ике якка ачып, алтын сәгать чылбыры асылынган күкрәкне киеребрәк куйды, ике кулы ике чалбар

кесәсендә, күз өстендәге кашлары гайре-табигый рәвештә сикергәли, егетнең чынлап та илһамлана баруы сизелеп тора иде.

— Мин үзебезнең милли шагыйребез, милли Пушкиныбыз Габдулла әфәнде Тукаевның җеназасын озатканда Казанда идем. Бу югалту безнең өчен, хосусән, без шәкерт халкы өчен, кояшыбызның сүнүе булды. Шунда шул мин мескен шәкерт, кабзыятька бирелеп булса кирәк, мәрхүмнең бөтен шигырьләрен күңелдән ятларга үз-үземә ант иттем һәм антымны үтәдем. Телисез икән, хәзер, шушы минутта сөйли башларга әзермен.

Бельгия вәкиллегеннән һәм бельгиялеләрнең Кабан күле белән кызыксынуларыннан кинәт Мөкатдәс өчен исеме генә колакка чалынып калган Тукайга килеп житүе картны аптырашта калдырганлыгын сизеп, оратор шундук тормозларны төшерде, сүзне уенга борасы итте:

— Курыкмагыз, Мөкатдәс әфәнде, мәрхүм Тукаевның бөтен язганнарын белергә мин әлегә Коръән-Хафиз түгел, әмма бу әңгәмә уңаеннан мәрхүмнең менә бу юлларын искә төшерсәк, шаять, язык булмастыр.

Ул күперенке кыяфәтен һич тә шиңдермичә, яхшы ук пафоска бирелеп, сөйләп китте.

...Сүз рәте килгәч, итәм әзрәк бәян,
Таки яшрен күл төбе булсын гаян.
Анда һәртөрле гаҗәпләр бар да бар:
Кып-кызыл алтын шәһәр, жиз карьяләр;
Мөгезе мәрмәр боланнармы кирәк,
Алты йөз башлы еланнармы кирәк;
Су анасы, бик явыз, йөзе кара,
Ел да бер угъланны я кызны ала.
Ул заман кем килде Мәскәү гаскәре,
Бу Казанга туп атарга башлады.
Шул вакыт ханнар, вәзирләр качтылар,
Барча малны ушбу күлгә сачтылар.
Сачтылар алтын-көмешнең һәммәсен,
Ягъни безнең мал кешегә калмасын.
Шул заманнан бирле кем алтын, көмеш
Күл төбендә һич хисапсыз күп, имеш.

Ул бу юлларны чынлап та нык ятлаган булгандыр, алай гына да түгел, хәтта хыялында күптәннән йөрткән, күпмедер дәрәҗәдә бәлки ихластан ышангандыр да, чөнки бирелеп сөйләве, тавышының күкрәк тирәнлегеннән гөрләп чыгуы, инану нуры чәчрәп торган (һәм, әлбәттә, чәй белән кушылып эчелгән коньяк пары да өстәлгәч) күзләре шуны раслый иде. Бер кызып киткәч ул әле тагын да дәвам итмәкче иде, ләкин нәкъ шул вакытта өйнең кече як ишеге, сизелер-сизелмәс кенә тавыш чыгарып, ябылып калганы ишетелде. Картның инде туза башлаган борынгырак колагы бәлки моны ишетмичә дә калгандыр, әмма кунакның яшь колагы шундук ишетеп алды һәм егет, кызмача башлаган егет кинәт сагая төшеп, тукталып калды.

— Безне монда тыңлап торучылар бар,— диде ул, искәртмәстән генә исенә килгән сәрхуш кешедәй,— ә безнең алда сөйләнәчәк сүзләрне беркем дә, төшенәсезме, хәтта сыңар колак та ишетмәскә тиеш. Мин сезгә ясалган бу визитымның иң мөһим ноктасына якынаеп киләм. Төшенәсезме, иң мөһим ноктасына.

— Берәү дә юк, саташасыз булыр. «Каюм баба» кәсафәте түгел микән? — дигән булып шаяртып уздырырга маташты карт. Өйнең кече ягыннан әйләнеп килде.

— Ул якта да ишек бармыни? — дип тәшвишләнеп сорады Нагиев,— юк, сез, Мөкатдәс әфәнде, күзгә генә ышанмагыз. Ишекләрнең һәр икесен бу яктан бикләгез. Әйтеп торам ич, мин визитымның иң мөһим ноктасына якынлашам.

Әлбәттә, кунак үтенгәнчә, ишекләр эчке яктан бикләнде. Әмма чын дөреслектә егет түгел, хуҗа карт үзе саташа. Нагиевның, чын пафоска

бирелеп, Тукайдан өзек сөйләвен ишетеп алгысыган кыз һич сиздермичә генә кече як ишегеннән шыпырт кына үткән, бүлмә тактасы ярыгыннан егетнең бирелеп шигырь сөйләвен сокланып тыңлап торган, имеш. Яшьлек, яшьлек! Әгәр ул бер алгысыса, үтәр ярык тапмыймы соң!

### 6

— Без икәү генәме? Икәү генә икәнлегебезгә иманыгыз камилме? — дип, тәшвишле һәм бер үк вакытта кызыксынудан күңелгә шом сала торган сискәндергеч сорау куйды Нагиев. Хуҗа чынаякларга кабаттан чәй агыза башлагач, кунак кул хәрәкәте белән генә аны туктатты: янәсе, житте, чәйләп-мәйләп сөйләшә торган сүз түгел. Һәм тавышын кыса төшеп тагын да башлады:

— Белгеецлар һәм аларның Кабан белән кызыксынулары турында әйттем, сүзне сузарга яратмыйм. Тик бер уңайдан патша заманында булган бер фактны исегезгә төшерим. Белгеецлар мең тугыз йөз униkенче елда да Кабанны күпмедер срок белән концессиягә алу турында сүз кузгаткан булганнар. Дәлилләре нә диген? Дипломатиянең бәлеш капкачы кебек коры, тамакка тыгыла торганы: янәсе, Кабан төбеннән ләм чыгарып, үз илләренә жир ашларга жибәрәселәр. Патша коры «бәлеш капкачы»ның тамакны ертачагын, күрәсең, сизгән. Без генә бит аны, патшаны мин әйтәм, ахмак та канечкеч дип, каберен таптыйбыз. Кабере кайда икәнлеген белсәк тә, белмәсәк тә...

Нагиев моны Мөкатдәс картның патшага һәм элекке режимга карата «кылын тартып» карау нияте белән сөйләде, ә картның «кылы» өстә генә ята, имеш:

— Әйтмә, сагынып сөйләргә генә калды инде ул заманнар, чекасы юк, ишекне бикләп сөйләшү юк иде ул чагында,— дип офтанып куйды.

— Ишекне бикләү чекадан өркүдән түгел,— Нагиев ничек тә батыррак күренергә тели һәм чека дигәненнән үзен өстенрәк күрсәтәсе килә иде,— ишекне бикләү алда торган эшнең гаять дәрәжәдә житди булуыннан. Моны хәзергә бер зат та, хәтта сезнең хәләл жефетегез Гөлсара ханым да ишетмәскә, белмәскә тиеш. Мин инде сезнең бик чибәр һәм бик тә мөлаем кызыгыз турында әйтеп тә тормыйм. Гәрчә ул миңа жир кызы булып түгел, хур кызы булып күренсә дә...

Кызын мактаудан беркадәр изрәбрәк калган атаның нәкъ шул миңкегәнрәк чагын тотып алып, мавыктыргыч сер вәгъдә итүче бу кунак сүзен янә дәвам иттерде:

— Тәвәккәлләргә икән тәвәккәлләргә, алайса, бу хәтлесен дә әйтик: белгеецлар хәзер әлеге мәсьәләдә большевикларның, Совет хөкүмәтенең мөнәсәбәтен яңадан капшап карамакчылар. Капиталистның коммерциясе үзе белән: хәзергә, үзегез чамалый торгансыздыр, Советларның чалбар каешлары бушаган чак. Кругом ачык та тишек. Шул форсаттан файдаланып, ягъни төбе алтын-көмеш белән тулган безнең Кабан күленә кулларын тыгып карамакчылар. Бу мәгълүмат миңа Бельгия посольствосында эшләүче бер галиҗәнаб аркылы мәгълүм. Без ул әфәнде белән якынтын таныш, аның буш сүзле кеше түгеллеген мин яхшы беләм, юкка гына башта ук алтын портсигар турында сүз кузгатмадым. Ул галиҗәнабнең безгә, хосусан, миңа карата яхшы күңелле булганлыгы өчен, үз тарафыбыздан мин дә берәр затлы бүләк белән җавап кайтармакчымын.

— Аңысына инде Кабан төбеннән алтын-көмешне чыгара башлагач та өлгерербез, алла насыйп итсә,— дип, шик кыстырасы итте карт. Аның бу сүзләре кунакның ачуын китерсә дә — бу туң башларны матур сүзләр белән тиз генә эретермен димә! — ачуын чыгарып селкергә

ашыкмады, киресенчә, тегенең шикләнебрәк әйткән сүзләренә кушылгандай, тагын да нәзакәтлерәк күренергә тырышып, дәвам итте:

— Нәкъ минем кебегрәк уйлыйсыз икән сез дә, хөрмәтлем, бүләк өләшергә ник ашыгырга,— һәм шундук бөтен шик-шөбһәләрне юкка чыгаргандай җитдилек һәм катгыйлык белән ялгап алып китте:— минем белгееч әфәндемнең бу мәсьәләдә шәхси мәнфәгате бар. Ул бөек коммерсант. Безнең большевиклар файдасын күздә тотмый да тотмый, төкерә миллионер синең большевикларыңа. Шул беррәттән синең белән минем башка да төкерә. Хәтта, мин әйтер идем, аның милли-мәмләкәт интересларына да исе китми. Кыскасы, аның Бельгия өстеннән, безнең большевиклар хөкүмәте өстеннән, границалар һәм Мәскәү аша кулын сузып, рәсми даирәләр үзара сатулашкан арада, безнең Кабан төбенә төшеп, аны үз куллары белән актарып карыйсы килә.

— Актарып карау гына түгел, булган байлыкны чөмерәсе дә килә инде, алайса,— дип, сүз кыстырасы итте карт. Бу юлы аның үзенең дә күзләре елтырый башлаган иде инде, бүреләр белән рәттән яшисең икән, нигә сарык булып кыланырга! — нәфес дигәнең Парижда да, Мамадышта да бар.

Һәм кинәт туп-туры сорау:

— Ә син үзең ничек уйлыйсың? Бәлшәвикләр дә бик хитри халык бит: кабарлар микән җимгә, дим?

— Ә мин әйттем бит: аның кулы границалар һәм шәһәрләр өстеннән... Дөресрәге, границаларның һәм шәһәрләрнең астыннан, берәүгә дә сиздермичә сузылачак.

— Анысы инде берәүгә дә сиздермичә булмас инде. Кабанда әле теге мойкада, әле бусында кыз-хатын кер чайкый. Кичләрен яшь-җилкенчәк көймәдә йөри.

— Сездә мин әле дә булса ышанып җитмәү галәмәте күрәм, Мөкатдәс агам,— Нагиев кинәт урыныннан сикереп торды, ул әйтеп бетергесез җитди һәм хәтта хуҗага чак кына үпкәләгәндәй күренә иде, үпкәсен тик нәзакәтлелек йөзеннән генә сиздерми саклый иде,— нишләмәк кирәк, бөтен Казаныгызда беренче булып бу турыда сүз катуым сезгә һәм сезнең тәвәккәллеккә ышанычым камил булганлыктан иде, күрәсең, хаталанганмындыр. Икмәк-тоз, сый-хөрмәтегез өчен тәшәккердән гаҗизмын. Миңа кузгалырга рөхсәт итегез.

«Тәвәккәллегегезгә ышанычым камиллектән иде», «Сый-хөрмәтегез өчен тәшәккердән гаҗизмын!», «Кузгалырга рөхсәт итегез!» — йа хода, сүзләре нинди дә, ничек килештереп әйтә белә. Шуның өстенә, нинди югартын очучы карчыга күренә. Чит ил посольствосы. Мәскәү. Академия. Кигән киеме, үзен тотышы, ниһаять, жилет кесәсеннән салынып торган, ачуым да килмәгәе, аркан юанлыгы алтын сәгать чылбыры... Әйткәннәренең яртысы сабын куыгы булсын, ди... байлыкны арттырганнан-арттыра бару хыялыннан төн йокылары качкан Мөкатдәс карт өчен калган яртысы да башыңны чуалту өчен җитәрлек ләбаса! Аннары тагы буй җиткән кыз атасы буларак та, Мөкатдәс бу кунакны кулдан алай тиз ычкындырмау ягында иде, әлбәттә. Аның Мало-мещанский урамындагы тузып бара торган агач өе өстендә мондый тутый кошның әле кайчан очканы бар, киләчәктә очармы-юкмы?

— Тукта, чү,— дип, кунакның чабуына ябышты карт,— әле нинди дә булса җылы ризык бирелергә тиеш. Бу «Каюм баба рецепты» белән эчкән чәйдән соң түбән авыл көчекләре котырып кына калды, бер фараз.

Һәм кинәт Печән базарында алу-сату вакытындагы җитдилек белән бер-бер артлы сораулар яудырырга тотынды:

— Кулы күренми дисең, алайса? Беренче булып Мөкатдәс абзаңның тәвәккәллегенә ышанып дисең? Тәвәккәллекне анысын әҗәткә алмабыз. Юлы ничек соң аның, ягъни ничек керешмәкче булабыз да, безнең тарафтан ни сорала?

Сүз мондыйрак борылыш алгач, кунак яңадан утырмыйча булдыра алмады. Һәм, әлбәттә, марканы төшермичә генә аңлатырга тотынды:

— Алдан ук шуны белеп торыйк: ул үзе безнең Россия туфрагына аяк басмаячак. Миллионер башы белән большевиклар туфрагына басарга җөрьәт итәме соң,— Нагиев ирен чите белән көлгәндәй итте,— хәтта үзләренең посольствосында да күренмәячәк. Бөтен эш посольстводагы әлеге минем белеш аркылы барачак. Ул безгә шул эшнең, ягъни су асты патшалыгының пайтәхетләрен белеп эш итүче өч аквалангист җибәрәчәк. Безгә дигәнем, Сез хөрмәтлебез карамагына, туп-туры безнең Казаныбызга.

— Аквалангист дигәнең кемнәр, нинди нәрсәләр? Алай-болай чека каптырып алса, мине корбан тәкәсе итеп калдырып, үзләре кулдан шуып чыга торган юеш кешеләр түгелме?

— Суга чума торган кешеләр булгач, әлбәттә, бик коры да булмаслар инде,— дигән булды Нагиев, картның җор сүзләренә җорлык белән җавап кайтарырга тырышып. Тулаем алганда, ул бу урында шаярып сөйләшүне мәгъкуль күрмәгәнлеген сиздерергә тели иде. Кунак тагын аякка басты, «җылы ризык»ны көтә алмаганлыгын әйтте, алда торган җитди һәм мавыктыргыч эшнең Мөкатдәскә кагыла торган кайбер шартларына ишарәләде. Мөкатдәс үз компаниясенә тагы ике кеше куша ала. Әлбәттә, ышанычлыларны. Үзләре телсез, кесәләре акчалы булсын. Акча дигәннән, мин гел алышынып тора торган хәзерге тотрыксыз конфет кәгазьләрен түгел, өстенә «Алтын илә түләнә» дип язылган червонецларны күздә тотып әйтәм.

Иң ахырдан, инде чыгышлый, ишеккә якынлаша төшкәч, тавышын кысыбрак, ләкин үзе артык игътибар итмәгәндәй күренергә тырышып өстәде:

— Эшне башлап җибәрү өчен аванс тәртибендә алты йөз банкнотны алдан ук әзерләп куярга кирәк булыр. Аквалангистларны китерү өчен. Болай да соткарландым, мин иртәгә рәсми командировкам буенча өязгә сәфәр чыгам. Ун көннәр чамасы үтәр дип уйлыйм. Шуңа тикле мин әйткәннәр әзер булсын.

Шуннан соң бөтенләй пышылдауга күчеп, үтәли күренмәле нәфис бармагын авызы төбендә уйнаткалап алды:

— Һәм бер адәмгә бер сүз ни гу-гу.

— Кайтышлый мөсафирханәгә түгел ,туп-туры үзебезгә туктыйсың, аллаһы насыйп итсә,— дип кенә әйтергә өлгерде карт. Шул арада кунак — ай күрде, кояш алды дигәндәй — чыгып киткән иде инде.

Өйдә ялгыз үзе генә калгач, Мөкатдәс карт, чәй белән кушып тормыйча, ярты чынаяк коньякны болай гына күтәреп чөмерде, кызарып, бүртенеп китте һәм хәтфә тышлы кәнәфигә кыңгыр төшеп, уйлана башлады. Әйе, башваткыч табышмаклар калдырды бу мөсафир егет. Бер караганда, битне кызыштырырлык: чынлап та, шундый чумучылар килеп, су төбендә качып ята торган байлыкларны күрәп чыгарсалар, әй. Шәһәр дигәнең күзен йоммый тормый да, шул арада бер чума, ике чума, өч чума һәм эшләре өчен тиешле хакын ала да — син күр дә мин күр — юлларына ак җәймә. Соңыннан кайдан булса берәр очы тишелеп чыгардай күренсә,— ах алла, Мөкатдәс Шәйдуллин да төшеп калганнардан түгел. Табылган алтынны чүлмәккә салып караватт астына яшереп сакламас. Шул ук астан кулын суза белүче оста егетләр аркылы Швейцария банкысына озатыр да куяр. Чека кешеләре тик казынсыннар чүпрәк-чапрак арасында. Швейцария банкысының клиенты булу — бу сиңа саладан солы сата килгән мужикның юклы-барлы акчасын ничек тә сосып калырга өметләнеп, кибет алдында мыек бөтереп тору түгел инде.

Икенче яктан, шунысы уйландыра: алты йөз банкнот диде ич, алтмыш червонец дигән сүз. Ярый, бер кесәдән генә чыкмасын, червонецларны

шыгырдап торган ике кесә табарга кирәк. Кем бар Мөкатдәс кебек тәвәккәл? Су төбеннән табылачак байлыкны кулга төшерү өчен алдан ук егерме червонецны суга салырга әзер торучы! Монда бит бер тәвәккәллек кенә җитми, монда дуамаллык, башыңны ташка бәрергә әзер тору, акны-караны тикшереп тормаучы шашкын йөрәк кирәк. Мөкатдәс Шәйдуллинның белгән, сүз сыярдай кешеләре арасында шундыйлар бармы? Табылырмы?

Өченче яктан, Мәскәүнең үзеннән чыккан егетне дә болай гына кулдан ычкындырасы килми картның. Шушы беренче очрашуларда ук сизеп алды: төпле генә түгел, ике төпле күренә ул егет. Өске катында совет белгече ялтырап ятса, аскы катында үз акылы яшеренгән; хәйләкәр нэпманның фикеренчә, нәкъ әнә шундый «ике төпле» кешеләргә якын торырга кирәк тә хәзер...

Мөкатдәс шундый каршылыклы уйларга чумып, йомшак кәнәфидә кырын ятканда, курка-курка гына басып, хатыны Гөлсара килеп керде.

— Абау, кунагың китте дәмени? — дип сузып куйды ул, Дөбъяз ягы акценты белән. Картының, җавап бирмичә, үз уйларына чумган хәлдә игътибарсыз гына ята бирүен күреп, кинәт йомшап калды.

— Мин тагы сары майда гына эретеп пылау әзерләгән булганием. Җимешен, маен бер дә җәлләмичә.

— Әйттем. Көтмәде.

— Бер дә харап булыр ие азрак көтсә. Шундый тәмле булып пешкән ие пылавым.— Ниһаять, ул да кеше бит, иренең бик алай җәелеп сөйләшәсе килмәгәнлеген күреп торса да, кызыксынуын баса алмады, сорады:— Нинди эш белән йөрүче адәм булды соң ул, атасы? Болай үзе ни... Бик тә киенеп-ясанып йөрүче күренә.

— Күпне белсәң, тиз картаерсың. Ишеткәнең бармы шул сүзне?

Ишеткәне юкмы соң! Әлбәттә, күпне белергә, ир-ат эшенә тыгылырга ярамый. Бигрәк тә аның Мөкатдәсе яратмый юк-барга тыгылганны. Ничә ун ел бергә торалар, иренең гадәтен-фигылен белә Гөлсара ханым, бик яхшы белә. Тик шулай да аның, буй җиткән кыз анасы буларак, күз алдыннан ялтырап кына узган теге чибәр егетне, аның ни йомыш белән йөрүен белергә теләве дә бик-бик көчле иде. Нишләмәк кирәк, чишеләсе килми бит картының, бардыр инде ирләрнеке...

— Бар, пылавыңны керт. Мин үзем кунак бу дөньяда,— дип боерды карт. Бу дөньяда ук булмаса да, бу өйдә, бу диварлар арасында ул үзенең хөкемдар кеше икәнлеген бик яхшы белә, әйткәнне икенче кабатларга урын калдырмый иде. Пылау алдыннан чынаяк төбенә генә салып, теге коньяк суы белән авыз чылатып алгач, кәефе күтәрелә төште булса кирәк, ашый-ашый гына булса да хатынын мактап куясы итте:

— Дөрес әйткәнсең, пылавың тәмле,— диде элек. Шуңа ук ялгап, ләкин кыска паузадан соң өстәде:— Яманлар хәлем юк, аш-суга уңганлыгың бар, анасы.

Шуңа ук ялгап, беравыктан, ахрысы, коньяк пары пылау җылысы белән кушылып, аяк бармакларыннан бер әйләнеп менгәч, бөтенләй иләсләнеп китеп дигәндәй:

— Их, бар иде безнең дә яшь чаклар,— дип, шунда рәттән генә басып торучы Гөлсарасының биленә кулын китереп салды.

— Ну, нәрсә дигән була кыз? Егетне күреп чыккач, сиңа ни дә булса әйтмәдеме?

— Ал әле кулыңны,— дип, элек бераз читкәрәк тайпылды Гөлсара. Ире каршына, урындыкка утырмыйча булдыра алмады. Аңарга, Гөлсара ханымга, ике яклап рәхәт булып китте бу минутта. Бердән, сирәк була торган хәл — карты аның пешергән ризыгыннан канәгать. Хәтта мактап та алды. Икенчедән, төтене тышка чыкмаса да, эчендә уты барлыгы сизелә, ире тикмәгә генә алай кызыксынып сорамас: теге пөхтә

егет аларның кызларын күзләргә йөрүче бирәр очлы күз түгелме? Ә шулай да әйтүен алай турыга бәреп әйтергә кыймады.

— Алырсың безнең Гөлчирәдән сүз,— диде теләр-теләмәс кенә. Аның үзенең, ире болай ачылып торганда, әлбәттә, иркенләбрәк сөйләшәсе килә иде,— бик әчкерле бит ул, кемгә охшап шулай булгандыр.

— Ничава анысы. Хан кызларын да акылга өйрәтерлек догалар табыла бу дөньяда.— Һәм бик җитди итеп, әнисенә дә, кызына да берьюлы ачулангандай корылык белән өстәде:— Ә сөйләшергә өйрәнсен ул тәкәббер кыз. Яше егермедән ашты, мин аны тозлап куярга җыенмыйм.

— Тәкәббер дип, кызыңны кыерсытырга торма әле,— дип, тизрәк баласын канат астына алырга ашыкты Гөлсара ханым.— кыз кешенең теге ни... адәм рәтле киенәсе дә килә торгандыр. Мөкатдәс бай кызы ич, тикмә кешенеке түгел. Тора торгач, «энҗе-мәрҗәнем дә юк!» дигән сүз чыгып калды авызыннан.

— Ул мөсафир егет атна-ун көнгә өязләргә китә. Мәскәү җибәргән командировкасы буенча. Кайтышлый мин аңарга турыдан-туры үзебезгә тукталырга куштым. Ә син Гөлчирәңә әйт: сөйләшергә өйрәнсен. Шуның өчен ходай тел биргән адәм баласына.

Бераздан, чак кына йомшый төшеп, өстәп куясы итте:

— Вакыты җитәр, энҗе-мәрҗәннәре дә булыр,— картның күзләрендә хыял чаткысы кабынды,— ә хәзергә әнә, алай бик кирәксенсә, синекен тага торсын!

## 7

Гөлчирә кичә кунак кабул ителгән өске кат өйнең кече як бүлмәсендә йоклый, гомумән, өйдәге тормышының күп өлеше шул бүлмәдә үтә. Шунда аның борынгы комод өстендә зур түгәрәк көзгесе, туалет әйберләре, яраткан кино артистларының открыткалары, гимназия елларыннан бирле торып калган, инде кат-кат укылган, битләре арасында кипкән ландыш, миләүшә чәчкәләре саклана торган биш-алты китабы — авторларына игътибар итеп тормастан, кайдан кулга төшерсә — шуннан алып кайтып, өйдәгеләргә күрсәтмичә елый-елый укый торган мәхәббәт романнары, шунда аның бервакытта да кимәгән һәм кияргә үзеннән-үзе дә оялып саклый торган челтәрле әчке күлмәкләре... Шунда ук аның киләчәктә ни белән бетәчәге билгеле булмаган очсыз-кырыйсыз, алгысыткыч һәм бер үк вакытта билгесезлеге ягыннан чак-чак кына өркетә дә торган яшьлек хыялы да... Башка вакытта һәм бүтән урында аңарга хыялланып торырга вакыт тими, еш кына әтисе аны иртүк кибеткә алып китеп, галантерея бүлегенә бастырып куя — сорап килүчеләргә товар күрсәтсен, мактый алганча мактасын, ачык йөзле, тәмле телле булсын, ничек тә кул арасына керсен, эшкә ярасын, файда китерергә булышсын...

Бүген исә кызны ничектер тыныч калдырганнар иде, кояш шактый югары күтәрелеп, бүлмә эче чалт аяз бер вакытта сискәнеп күзләрен ачты. Башына килгән беренче уе: «Абау! Төш җитә язган ич... Оялмыйча шушы вакытка хәтле йоклап ят, имеш!» дип өтәләнеп кую булды. Сикереп караватыннан төште һәм шундук күңелгә борчу сала торган икенче бер хәл: көзгедә үзенең әчке күлмәктән генә калган шәүләсе чагылды. Бакчы, нинди ябык, тәнсез, салкын мәрмәрдән кырып ясалган кебек ак икән ул — моңа хәтле һич игътибар иткәне юк иде. Муены кирәкмәгән озын, иңбаш сөякләре беленеп тора диярлек, шул юка тәндә кайдан килеп болай котырганнардыр, шактый ук калкып торган күкрәкләр... Китсәнә, китсәнә, шундый ак тән булырмы кешедә? Егерме яшькә җиткән кешедә! Сабый бала тәне кебек.

Һәм кызый бөтенесен, берьюлы күңелен өтеп алган бутлачык сизенүләрне тиз генә капларга тырышкандай, өске күлмәген аннан-моннан

гына киде дә тизрәк әнисе янына — түргә өйгә ашыкты. Әйтерсең барлык хәвеф-хәтәрләрдән, шик-шөбһәләрдән котылу юлы анда — әни янында, аның канаты астында...

— Нишләп болай озак йоклаттыгыз? Әти белдеме минем йоклап калганны?

— Белмичә соң,— диде әнисе, үтә йомшак, назлы-иркәләүчән тавыш белән,— әтиең үзе әйтте: «Йокласын йокысы туйганчы, барасы җиренә аннан барыр», диде.

— Ә кибеттә? Минем эшемне кем эшли?

Юк, монда да, әнисе янында да тынгы тапмады кыз. Киресенчә. Аны тагын берьюлы берничә төрле каршылыклы сорау билэп алды. Шулай да сиздерми, сиздермәскә тырыша иде. Шундук өй эшенә тотынган булды.

— Сез иртәнге чәйне эчкәнсездер инде, әни?

Әлбәттә, ахмак сорау булып чыкты бу, ахмак килеп чыкканлыгын Гөлчирә үзе дә белде: бу вакытка хәтле иртәнге чәйне эчмичә торалармы соң! Аның әнисе бит урыныннан торуы белән тизрәк самавар тоткасына барып ябыша, «Берәр чынаяк каты чәй эчмичә кеше түгел мин иртәнчәк!» дип сөйләнгәнен бер бүген генә ишетмәгән. Югыйсә, бөтенләй башка сорау килгән иде Гөлчирәнең күңеленә, кинәттән генә әнисе янына омтылуы да шуның өчен иде. «Нишләп йөри ул кичә безгә килгән кеше, әни?» — дип сорамакчы иде. Хәлбуки, әнә нинди ахмак, буш, мәгънәсез сорау килеп чыкты. Әле ярый, әнисе аны-моны абайламады булса кирәк. Бу юлы инде назлы йомшаклык түгел, бар нәрсәне дә үз урынына куя торган гадәтилек белән:

— Самавар яңартып җибәрәм, минем инде яңадан тамагым чатнап өлгерде,— дип сөйләнә-сөйләнә, тагын самавар колагына барып ябышты.

— Минем эчәсем килми,— диде Гөлчирә, кырт кисеп.

— Сөйләп торган булма юкны. Иртән торып чәй эчәсе килмәү кайдан чыккан сүз ди ул?

Бераздан, әнисе кухня ягында самавар яңартып җибәргәннән соң, алар монда, инде җыелган, бөтен әйбере үз урынына утырган тын өйдә, янә дә икәүдән-икәү генә, сүзне нидән ялгарга белмәгәндәй, тәшвишле сагаюга күмелеп калдылар.

Дөресен әйткәндә, Гөлсараның кызы белән җәелеп сөйләшерлек сүзе дә юк, ул әлегә үзе дә билгесез табышмакка күмелгән хәлдә. «Кичәге кеше» турында картыннан кырыс бер җаваптан башка берни дә ишетмәде, төпченеп сорашырга кыймады — бүген генә бергә тормыйлар, иренең акылын-фигылен белә, төпченгәнне яратмый карты. Һәм ул кырыс кешенең кызына карата кинәт шулай мәрхәмәтлегә әверелүе, аннан да бигрәк, кичә ут ала кергәндәй генә кереп, шактый утырып киткән «Мәскәүнең үзеннән чыккан егет», әйтергә кирәк, беренче карашка бик тә мөлаем күренгән егет буй җиткән кыз анасы Гөлсара бичараны яхшы ук четерекле хәлдә калдырган иде. Гөжләп кайнап утырган самавар янында, сусап чәй эчкән атлы булып, һич югы, кызы белән, ерактанрак урап булса да, сүз башлыйсы килә иде аның. Әмма кызы самавар кайнап чыкканны да көтә алмады — ахрысы, ул алданрак, самаварга караганда кызурак кайный башлаган иде,— әнисен үзе чакырып китерде.

— Бик кызык төш күрдем бүген, әни,— дип башлады ул, шундук колак торгыза торган итеп,— кил әле, сөйлим әле шуны. Чалт аяз бер көндә, өйдә мин ялгыз үзем генә калган икәнмен, имеш: безнең шар ачык тәрәзәдән, ак якның урам тәрәзәсеннән, атылып-бәрелеп мәче башлы ябалак очып керде. Күзләре шар ачык үзенең, ә үзе берни күрми. Бәргәләнә, суккалана. Шулай җилпенә торгач, безнең теге хрусталь

люстраны бәреп төшерде. Мин дөм караңгылыкта калдым. Шунысы сәер, тышта чалт аяз, ә безнең өй эчендә дөм караңгы...

— Көндез очмый бит ул мәче башлы ябалак дигәннәре,— дип кызын тынычландырасы итте Гөлсара ханым. Аның бу сүзне бетерәсе, юкка чыгарасы, уен-көлкегә әйләндерәсе килә, шул ук вакытта хорафатларга тиз ышанучан беркатлы күңеле инде шомлана да калган иде,— кеше ышанмастайны, тузга язмаганны төш итеп күреп тә тормас ием мин булсам...

— Ник очмасын,— Гөлчирә, төшенең үзеннән дә бигрәк, әнисенең шөбһәләнеп калуыннан гаҗәпләнеп, сабыйларча беркатлылык белән тезәргә керешә: очмый хәле юк, кунаклаган җиреннән кем дә булса куркытып җибәрсә... Күрүен күрми, ә оча. Безнең Казаков мәчете манарасында ук кунаклаган булуы мөмкин. Өйлә намазына азан әйтергә менешли мәзин бабайдан курыккан да очкан да киткән.

— Самаварым кайнап тора торгандыр,— дип, дәррәү кузгалып китте Гөлсара, аның бу шомлы төшне артык тыңлыйсы килми иде.

Чәй эчәргә утырдылар. Сөйләшеп китәсе килә иде ананың. Ләкин кызы, ничектер, үзен килгән кунак кебек сәер тота, күтәрелеп тә карамый, караса да, нидәндер уңайсызланган кебек, керфек астыннан кыяр-кыймас кына карый иде. Тамагына да рәтләп капмады, бер чынаяк чәй эчте дә чокырын каплап кузгала ук башлады.

— Амин тотарга оныттың ич,— диде әнисе, шелтәләгәндәй итеп,— шушы да булдымы ашау, корышкан авыз.

— Ашыйсы килмәгәч соң,— диде кызы, аклангандай итеп. Табын кырына җәлт кенә утырып, тиз генә амин тоткандай итте, догасы кердәле-чыктылырак булса да, сүз тыңлап җоласын китерүе өчен әнисенең күңеле чак кына түгәрәкләнде шикелле.

Юк, шулай күренергә генә тырышты булса кирәк, ана күңеле әлегә һич тә урынында түгел: кызының болай аннан-моннан гына капкалап алу белән кузгалуы, үзен килгән кунак кебек тотуы, сүзсезлеге, күргән төше, ниһаять, кемгә охшаптыр шул хәтле зифа буйлы чибәр кыз булып өлгереп җитүе өчен — барысы өчен дә, барысы өчен дә тәшвишле иде аңа. Чынлап та, «Таһир-Зөһрә» китабындагы Зөһрә кыз түгел ич. Маломещанский урамындагы гади бер кибетче кызы гына, нигә кирәк аңарга андый чибәрлек? Аннары тагы кайчандыр, кайдандыр колагына да кереп калган: бик алай артык чибәрләрнең бәхете дә ким була, имеш. Ә Гөлсараның кызын бәхетле итәсе килә, һай, бәхетле итәсе килә дә соң!

Гөлчирә үз бүлмәсеннән җиңелчә генә киенеп чыгып барышлый, әни кеше аны янә туктатасы итте.

— Чәчеңне чак кына эшләпәң астынарак яшер, яхшы күз бар, яман күз бар, тора тартып алай хөррияткә чыкма,— дип сөйләнә-сөйләнә кызының башындагы эшләпәсен үзенчә төзәтебрәк кидергән булды. Бичара әни кеше кызы урамга чыгу белән эшләпәне яңадан элекке хәленә кайтарып куячагын башына да китерми иде — прическа ватылу дигән нәрсәне белмәени ул борынгы кеше.

— Гыймади хәлфә очрамасмы юлыңда,— дип ялгап алып китте аннары. Аның тавышы тагын да йомшаган, ул тагы кайгыртучан һәм хәвефләнүчән әни кешегә әверелгән иде,— менә бу көмешләрне хәер-сәдака итеп бир.

Чыгарга ашыккан кыз чыкмады, әни кешенең хәер-сәдакага дигән көмешләре әлегә учында килеш, алар беравык күзгә-күз карашып сүзсез калдылар.

— Әйт, әни... Хәер-сәдакаңнан да саваплырак булыр, әйт шуны,— тыелгысыз эчке көч белән башлаган сүзен бүлмичә әйтеп бирә алмады кыз, аңа авыр һәм уңайсыз иде. Ләкин бер тәвәккәлләгәч сорамыйча да кала алмады:— Кем булды ул? Нишләп йөрүче булды ул кичә безгә килгән кеше? («Егет» димәкче иде, ул хәтлесенә үк йөрәге җитмәде.)

Инде менә Гөлсара аптырауга төште. Үзе дә рәтләп белмәгән килеш, кызының кинәт болай кызыксынып биргән соравына, болай мөлдерәп-текәлеп карап торуына каршы ул нәрсә әйтсен соң? Шул секундта ук тагы шул исенә төште: карты әйткәне әгәр чын булса, атна-ун көннән ул егет әле тагы әйләнеп кайтачак, бу юлы хәтта туп-туры аларга кайтачак, имеш. Ходавәндә, буй җиткән кыз анасы булудан да читен нәрсә бармы икән дөньяда?

Кызның кистереп куйган соравына җавап булмады, беравыктан гына исенә килде Гөлсара: Гыймади хәлфәгә сәдакага дигән көмеш тәңкәләр аның учында калган, кыз чыгып киткән. Кая барасын, кайчан кайтасын да әйтмәгән, чыгып киткән иде.

Әлбәттә, сәдакага дип адарынган көмешләрне кире куя алмады Гөлсара ханым. Шундук чыгып урам чатындагы хәерчегә биреп керде, атаклы Гыймади хәлфәне изге җаннардан санаса да, аны ук эзләп йөрергә җаны түзмәде. Хәер, бер як бик уңай: Казанның чатлары күп һәм ул елларда әле — дәвер алышыну чоры, ачлык еллар арты — чат саен хәерчеләре дә җитәрлек иде. Пошыну һәм изге теләкләр белән бирелгән бу сәдакадан соң ананың күңеле бераз тынычлангандай итсә дә, озакка бармады. Көн кичкә авышканда аларга киенеп-ясанып Гөлчирәнең иптәш кызы Миләүшә килеп керде. Җөйче Хәербанат кызы гына булса да, бу Миләүшәсе дә дөньядан калышмаска тырыша, кыска итәкле күлмәктән, башы ялан баш, толымнарын кистереп үк аткан һәм шул «кырыкмыш тай» башын әллә кемнәрчә генә артка ташлап:

— Гөлчирә кайтмадымыни әле? Без аның белән бүген кинога барырга дип сүз куешкан идек,— дип, җанны кыршып китте. Борчу өстенә борчу: әнә нинди «кырыкмыш тайлар»га ияреп йөри бит аның Гөлчирәсе — кая алып барыр икән бу «хөррият» дигән шикәрсез чәйләре!

Кичен, карты Мөкатдәс кибетен ябып кайткач кына Гөлсара ханым бераз тынычлангандай булды: кызы Гөлчирә әллә кайда йөрмәгән, гадәттәгечә әтисе янында сату итешкән, сәүдәләре гомумән уңышлы булган булса кирәк, Мөкатдәс карт кәефле күренә иде. Хатынының «Гөлчирәне кайда калдырдың соң?» дип аптырабрак биргән соравына да «хөррият»чәрәк җавап кайтарды:

— Курыкма, тотып ашамаслар кызыңны,— диде, исе китмәгәндәй генә күренергә тырышып,— безнең ише каткан сөяк түгел, китапханәгә кереп калды. Әйдә, укысын, укымышлы кеше ходта хәзерге заманда.

Ләкин аның бу «демократлыгы» озакка сузылмады. Гөлчирә китапханәдән бер кочак китап күтәреп кайтканга мыегын бер кабартса, кызның әнисе Миләүшәнең кинога чакыра килүе турында әйткәнен ишетеп, бөтенләй кырт кисте:

— Котыртма юк белән, кичкә каршы нинди кино, ди, ул?

Юк, Мало-мещанский урамдагы аслы-өсле агач йортта берни дә үзгәрмәгән, кичә ничек булган булса — бүген дә шулай: Мөкатдәс сүзе генә сүз. Һәм Мөкатдәс картның башында шундый-шундый планнар йөргәндә дилбегәне бушату, хәер, ярамаган да булыр иде.

## 8

Төн нәрсә өчен? Төн — йоклар өчен, ял итәр өчен. Бөтен тереклек, кош-корт, терлек-туар, черки-чебен төнлә тын кала, ял итә. Кемнәр йокламый? Гашыйклар, баю хиреслеге котырган кешеләр, ат каракларры, мәче башлы ябалаклар... Һәм менә теге «Мәскәүнең үзеннән чыккан кеше» күренеп киткәннән бирле Мөкатдәс Шәйдуллинның да йокысы качты. Оеткының бик тә зәһәрен салып китте шул, каһәр. Ышанырга да белми, ышанмаса да бәхет кошын ычкындырыр кебек. Кара акыл белән дә чамалый, колагына акыллырак кешеләрнең сүзләре дә кергәли. Бу

НЭП дигәннәре большевикларның тозагы гына булса кирәк: бераз хәл җыйганчы, Мөкатдәс ише ачык авызларның бар күк байлыкларын әрчегәнче «ирекле сәүдә» дигән булып маташтырырлар да бер заман, үзләре хәл алгач, андыйларны итек кунычларына тыгарлар да куярлар. Чека подвалларына ук тыгып куймасалар... Әле хәзер дә ул ике ишекле таш кибет әллә ни саудырмый. Сугыш арты, хөррият дигән чуалышлар арты, ачлык ел арты — халыкның эч мае коелган, алучы бик ыргылып тормый. Аның каравы, һәртөрле фининспектордан баш гарык. Налогны айдан-айга күбрәк өяләр. Кыскасы, морҗа ачык, төтен булып очасы гына калып бара. Ә бөтенләй үк очканчы, алланың рәхмәте белән, теге егетнең әйткәннәре гамәлгә ашып, күктән көткәнне Кабан төбе биреп куйса! «Алтын шәһәр дә җиз карьяләр» үк купмасын да, шулай да халык теленә дә, шагыйрь сүзенә дә кергән: Кабан төбе шөйлә буш булмаска тиеш. Бәхәсләшеп атып бәрелгән алтын сәгатьләр, кер чайкаганда беләктән шуып төшкән алтын беләзекләр — азмыни безнең татарда алтын кадерен белмәүче ахмаклар... Шуның өстенә, бабайлар, аларның бабалары да бик үк чардаклы булмаганнар булса кирәк. Урыс гаскәре килә дип соң бөтен алтын-көмешне Кабанга ташламасалар ни булган. Тотасы да илтеп саласы иде Швейцария банкларына. Анда инде хөрриятең дә барып житә алмый, фининспекторларыңа да шымытыр... Их, бөтенесе өчен, бөтен ахмак татарлар, ахмак бабаларыбыз, ахмак кер чайкаучыларыбыз өчен, алланың рәхмәте белән, бер татар табылып, шул бердәнбер акыллы татар, әйтик, Мөкатдәс тәксыйрь булса, әй!

Кичтән, кино турында сүз чыккач, кызы Гөлчирәгә карата тупасрак эндәшүе беркадәр ахмаграк булды булуын. Сүз тидермәскә кирәк хәзер ул кызга. Сүз дә, күз дә тидермәскә! Һич югы, шул кыз иңбашына басып, теге күпне белүче тәти егет җилкәсенә сикерергә, аның җилкәсеннән ул әйткән Бельгия посольствосындагы кеше иңенә күчәргә һәм мондагы барлык «эш»не очлап, алтынга әйләндереп, шуңарга тагы Кабан төбеннән менәчәк алтыннарны да кушып, шома гына Швейцария банкларына күчерергә дә куярга. Һәм шуларның үк ярдәме белән бер дә бер көнне үзең дә шул якка табан ялтыратасың. Ул чагында инде Гөлчирә туташың әлеге чибәр егетнең кәләше, Мало-мещанскийдагы тузып барган бу кыйшык өйдә кем кала? Картаеп, ярык тагаракка әйләнгән ялгыз бер Гөлсара кала. Мөкатдәс абзагыз анда — фининспекторларның буе җитмәс җирдә, хәләл көче белән тапкан алтыннары янында...

Болай үзе бик татлы иде бу хыял һәм үрелеп тота алмаслык еракта да түгел, әмма хәзергесе сәгатьтә йокларга да бирми иде. Кача да качар икән йокы. Хыял басты, йокы качты. Ә кырында гына тимер мич кебек кызу Гөлсарасы рәхәтләнеп, «пуш-пуш» килеп йоклый. Аның бер иңнән икенче иңгә сикерәсе дә, алтыннарын күчерәсе дә, кеше-карага сиздермичә генә табан ялтыратырга җыенасы да юк — бар соң гамьсез кешеләре дөньяның!

Йокы кермәстәй булгач, Мөкатдәс яткан урыныннан әкрен генә шуып төште, аягына төнге чүәкләрен элде, иңенә халатын салды. Әллә кая — хыялый дөньяларга китеп, яктан-якка әйләнә-әйләнә бурсып ятканчы, чыгып бер йөреп керергә, төнге Кабанга күз салырга булды. Урамга чыкса — ни күзләре белән күрсен — таң атып килә, еракта, көнчыгыш як офыкта, кеше сатып ала алмастай кыйммәтле бәрхет кебек, озын зәңгәр сызык сузылган иде. «Соңгарак калганмын, иртәрәк кирәк иде», дип уйлады Мөкатдәс. Хәер, соңга калу аның өчен яңалык түгел, соңга калырга ул инде күнеккән. Югыйсә, байлыкны Швейцария банкысына күчерү, большевиклар һәм фининспекторлар белән тулган бу буталчык Казаннан табан ялтырату турында элегрәк уйларга да мөмкин иде ич? Әнә бит чехларга ияреп киттеләр аның кайбер «компаньоннары», димәк, өлгеррәк булганнар.

Шулай да, чүәген «лап-лоп» сөйри-сөйри булса да, Кабан буена төшеп, әтрафка беравык күз салып тормыйча борылмады ул. Кабан өсте тын һәм ничектер серле күренә иде. Шулай ук чит-читләре дә, яр буйлары да йокыга талган, этле адәм заты да күренми, хәтта яр читләрендәге эскәмияләрдә йоклап калган исерек сукбай табыйм дип эзләсәң дә, әрәм тырышлык кына булачак. Дөньяның, ягъни Кабанның да шундый тын калыр сәгатьләре булыр икән. Югыйсә, кичтән анда мандолина чиртеп, мандолина көенә җыр сузып көймәдә йөрүче яшь-җилкенчәк буталучан. Димәк, теге планга чынлап керешелсә, аны гамәлгә ашыру сәгатьләре нәкъ менә шушы изге сәгатьләр — таң алды сәгатьләре булырдыр инде. Кыскасы, йокы йокламыйча болай буталып йөрүеннән Мөкатдәс карт бик канәгать калды.

Кайтты, әкрен генә өстен салды, хатынының татлы йокысын бүлдермәскә тырышып кына одеал астына шуышты. Һәм төнге сәфәреннән тынычланып булса кирәк, үзе дә сизмәстән:

— Булды, шулай кирәк! — дип, авыз эченнән мыгырданып куйды.

— Нәрсә булды? Тузга язмаганны ни саташып ятасың? — дип, үз чиратында Гөлсара да мыгырданасы итте. Иртәнге салкынча һавада салкын җыеп килеп яткан ире аның татлы йокысын бүлдергән һәм, гомумән, ирле-хатынлы булып яшәүнең барлык көйләренә һәм көйсезлекләренә инде күнегеп беткән бу итәгатьле хатын иренең вакытлы-вакытсыз «булды!» дип лаф оруларын бик авыр кичерә иде. Сәүдә эшеннән тыш гадәти тормышта тапкырлыгы ташып тормаган Мөкатдәс карт бу очракта котылу юлын шулай да тапты.

— «Булды» дигәнем шуннан, карчык,— ул сүзне сузу ягында түгел, ләкин бер тел ачылгач, әйтәсе сүзен өзеп әйтергә ниятләде,— төшемә шулай керде, ул күгәрченнәргә ходай парлашып гомер кичерүне язгандыр, кызыңның кылын тартып карарга өлгерденме әле син?

— Рәтле-башлы сүз алып буламы соң аннан. Соңгы вакытта китапка каныкты. Иптәш кызлары белән дә йөрми.

— Китаптан суган суы да чыкмас,— Мөкатдәс сүзен үтемле итеп әйтергә тырыша һәм инде аның изелеп йокысы да килә башлаган иде,— ана кеше кызга иң якыны: син аны теге өяз чыккан егетнең кайтышына ныклап әзерлә, безнең күлдә андый ак чабаклар часто йөзми.

Һәм әйләнеп ятты да йоклап та китте. Дөресрәге, йоклап киткән атлы күренергә тырышып, гырларга ук тотынды. Инде менә Гөлсараның йокысы качты, аның күңеле пошына, уйламыйча булдыра алмый. Хәер, сәбәбе дә бар: бердән, кыз бик якын, бәгырьдән өзелеп төшкән, бердәнбере. Икенчедән, егете бер дә белгән-күргән кеше түгел, һавадан атылып төшкән яшен ташы кебек күз алдыннан бер ялтырап узды һәм менә шуңа, имеш, «кызыңны әзерлә».

Шул ук вакытта картының холкын-фигылен дә яхшы белә: ике әйтергә яратмый аның Мөкатдәсе. Алу-сату эшендәге кебек тәвәккәл. Бер уңайдан үзләренең өйләнешкән чакларын да искә төшерде Гөлсара. Башкалар кебек сөешү, гыйшык-мыйшык уйнау, хатлар язышу кайда ул! Сабан туена авылга кайткан иде, шунда күргән, ошаткан булса кирәк, ләкин кызның үзен күрүне, аның белән сөйләшеп карауны, үзенең кызга ошавы яки ошамавы белән кызыксынып торуны кирәк тапмаган. Тоткан да әйткән кызның әтисенә:

— Без Казанның потомственный сәүдәгәрләре, Шәйдуллиннар фамилиясен Казанда белмәгән кеше юк. Менә мин шул атаклы сәүдәгәрнең кече улы булам. Өйләнмәгән яшь егет. Кызың миңа ошады, мәһереннән тормабыз, күпме сорыйсың, шул булыр,— дигән.

Һәм акчага, байлыкка түеп тормаган, өстәвенә, «запас»тагы өч кызы тупырдап өлгергән сала мужыгына шул җиткән, аннан-моннан гына йоласын китергәннәр дә, шул кайтуда, куенына куян баласы кыстырып кайткан кебек, юка, чәрексез, тиз ышанучан һәм, әлбәттә, һичбер кару-

сыз авыл кызын утыртып алып кайткан. Кәефе күтәренке чакларда яка «пирәшләп» алган арты ул, сентиментальлеккә һич бирелмичә, киресенчә, үзенең өстенлеген, ирлеген, байлыгын гел сиздереп торырга тырышып, ярым шаярган булып, әледән-әле кабатлый тора:

— Син, Гөлсара кара-кашым, миңа килгәндә кесәгә сыярлык кына бер мәхлук иең, мин сине кесәмә тыгып апкайттым. Шәйдуллиннар калачында сыразы болай күпереп киткәч тә...

Гөлсараның була хәтере калган чаклары, була уенга алып уздырып җибәрүләре, ә күңелдә юшкыны кала. Калганга карап нишләсен. Авыл табигатендә туган, авыл табигатендә үскән, җитмәсә, әти-әнисе, электән килгән гадәт-йола гел тукып торган: карусыз, буйсынучан, әчкерсез бул! Гөлчирәсе дә аның, гәрчә алдашу һәм хәйлә белән тулган шәһәр җирендә туып үссә дә, әнисенең үк кызы: беркатлы, тиз ышанучан, чәрексез, йомшак күңелле. Пошынып һәм куркынып уйлана Гөлсара: һай, төшереп ватмасалар гына ярар иде ул чәрексез кызны — Гөлсараның бердәнбере. Үзенең бәхетләме, түгелме икәнлеген ул үзе белми яшәде, бу турыда уйларга вакыты булмады, һавалы кайниш арасында ул турыда уйлап торырга мөмкин дә түгел иде. Ә менә кызы Гөлчирә турында уйламыйча булдыра алмый: һай, бәхетле булсын иде аның Гөлчирәсе, бәхетле булсын иде!



9

Теге кичне Мәскәү кунагы белән ак өйдә икәүдән-икәү генә серләшеп утырганда, эзләүсез-сораусыз басып кергән Чукрак Зариф һәм аны, ишек бусагасыннан да үткәрмичә, тәкәллефсез рәвештә кире бору Зарифның бәгыренә кара таш булып кадалды. Шулай булмыйча соң! Шәйдуллинның ике ишекле мануфактура-галантерея кибете булса, Зариф Сәгыйтовның бөтен дирбияләре җиткерелгән унбиш атлы ломовой извозы бар, атларының сырты өстендә шахмат уйнарлык. Бөтен Казанның йөген Зариф ломовойлары ташып тора, бөтен Казан эчкән аракы Зариф атлары ташыган спирттан ясала. Һәм Зариф моның белән җае туры килгән саен, әллә чынлап, әллә юри, мактанырга ярата:

— Алланың бирмеш көнендә Казанның исерекләре кем аркасында артып тора диең? Шушы Чукрак Зариф ташыткан спирт аркасында.

Атлары булгач, аларны караучы һәм йөртүче дә, әлбәттә, бар, алары «Зариф абзый» дип үлеп торалар — бу да, шиксез, үстереп җибәрә кешене. Ә шулар арасында берсе бар, Бикәй дип йөртәләр, Бикчәнтәйдән бозылган исем булса кирәк — җилкә белән муеннан, көрәк хәтле кулдан һәм салынып төшкән калын иреннәрдән генә тора. Шуларга өстәлсә тик караклыгы һәм башка йөкчеләр арасында, бигрәк тә ялан-да, җиде-сигез катлап сүгенә белүе өстәлә торгандыр. Үзе дә шул Дөбъяз ягыннан, сүгенә белү осталыгы ата-бабалары мирасы, әмма утызга хәтле өйләнми йөрүенең сәбәбен үзеннән күрә.

— Кызлар минем авырлыктан куркалар, сигез потка якын тартам ич, ананның кабер ташын... фәлән-фәсмәтән...

Кәефе күтәренке чак булса (ә аның кәефе төшенке чак булганы да юк!), чак кына фантазиягә дә бирелә белә.

— Бар әле минем карап үстерә торган бер кура җиләгем. Пешә төшсен дибрәк торам. Ну, кабып йотачакмын мин аны тәңрәнең бирмеш бер көнендә. Менә шушы Чукрак Зариф муенына тагылган тәре әйткәние диярсез.

«Зариф муенына тагылган тәре» дию бөтенләй нигезсез дә түгел: бергә урлыйлар, бергә юллыйлар. Усадтан спирт тутырып кайткан мичкәләрне чайкап кына да күпмедер табыш килә. Моның өчен, әлбәттә, җаен белергә кирәк — төягәндә дә, бушатканда да. Аннары шул мичкә чайкаган суга күпмедер күләмдә колмак салырга, ничә көн тө-

нәтергә... аннары күргән-белгән шинкарлар аркылы «үзе куган» рәтеннән озаттырырга. Югыйсә, бу мичкә чайкаган суга күзләрен елтыратучылар башка извозчиклар арасында да юк түгел, әмма Зариф чукрак бу эшкә Бикәйдән бүтәнне якын да җибәрми. Ни ырымы бардыр шул бияләй авызның, ярата шуны Зариф хуҗа, башка извозчикларга башлык итеп куйган.

— Бикәйнең әйткәне сезнең өчен закон! — дип кенә җибәрә. Һәм тегеләргә аңлашыла төшсен, Бикәйнең дә күңеле булсын өченгә, үзенә бик үк аңлашылмаган, ләкин кайчандыр, кайдандыр колагына кереп калган, чиркәү кыңгыравы кебек яңгыраулы сүз өстәп куя:— Ул сезгә кәрванбаш, шуны белеп торыгыз.

Бигрәк тә хуҗаның шушы сүзе ошый беркатлы Бикәйгә: янәсе, кәрванбаш. Кем ишеткән дә, кем белгән бу сүзне Дөбъяз ягы татарларыннан? Ә менә Бикәй ишетеп кенә калмады, үзе Кәрванбаш! Аннары тагы шунысы ошый хуҗаның: икесе бергәләп «табыш»тан авыз итеп чымырдап утырган чакларында, әллә бу җильяк Дөбъяз татарын юри үчекләп, әллә тагын да ныграк тагылган тәрегә әверелдерергә тырышып, болай дип тә сөйләнгәли:

— Кем, Бикәй туган, син бу ломовой извозчикка кыз чыкмас дип ике дә уйлама. Кызларның орлыгы Бохарада түгел, мин сиңа кызның Казанда берен тамгалап йөрим. Хәзерге хәмсамул токымы кебек койрык-җал киселгәннәрдән түгел, җалы астына бер кереп сеңсәң, шикәрдәй эреп китәрсең, алла насыйп итсә. Бар шундый бер мал, үсә шундый бер мал. Еракта да түгел, шушы үз Казаныбызда. Йә, тилмермә күзгә карап, әйтсәм әйтим инде. Мөкатдәс бай кызы, түлке ни... вакыты җитмәс борын кешегә шапырынып йөрмә, әйттек сүзне — күмдек сүзне булсын. Вакыты җиткәч, мин үзем янтыгыңа төртермен.

Бикәйнең «карап үстерә торган кура җиләге» менә шул. Чукрак Зарифның муенына тәре булып тагылуның сәбәпләренең берсе дә әнә шунда инде — әлбәттә, урлашу-юллашудан, мичкә чайкаудан килгән «саф табыш»ларны да истә тотып.

Карсак кына Зарифның эчендә эремәс ачуташ йөргән икән, кичләрдән бер кичне, Усад ягыннан олау кайтып, тапшырасы йөкне тапшырып, чайкыйсы мичкәләрне чайкатып, олаучыларны мичкә чайкаган «су»ның элеккерәгеннән, атна-унбиш көн төнәп, «ачу» җыеп утырганыннан өйләренә кайтып егылырлык кына сыйлап хәер-дога теләп озаткannан соң, Зариф хуҗа Бикәйнең үзен генә алып калды. Күз-колаксыз, шаһитсез һәм акыл сатусыз сөйләшәсе сүзе бар иде, ат сарае янындагы бер генә тәрәзәле каравылчы өенә керделәр. Каравылчыга: «Бар, урам әйләнеп кер, өеңне үзем каравыллыйм»,— диде хуҗа. Алдан ук хәстәрләгән закускасын һәм аракының пичәтлесен алып керде, Бикәйне каршына утыртты.

— Мичкә чайкаганны Абҗорный ряд шырлатаннары эчсен, безгә монысы да хәрам түгелдер, үзебез ташыган спирттан ясалган ризык,— дип, стаканны мөлдерәмә тутырып, Бикәй алдына шудырды. Һәм аракыны «ризык» дип атавының гөнаһысыннан куркып булса кирәк, авыз эченнән генә мыгырданып өстәде:— үз страмыбыз.

Бикәйнең бияләй авызы аракы эчәр өчен генә яралган диярсең, ул «голт-голт» йотканда Зариф бары тик «сөбхан-алла!» дияргә генә өлгерде.

— Әллә стаканы белән үк йотасыңмы дип торам,— дигән булды, соңыннан шаярып. Берәр җитди сүзе — йомышы төшәсе булса, шулай маташтыра ул, карт төлке. Әмма Бикәйнең болай нечкәртеп торыр чамасы калмаган, авызында казылык, күзләре читтәрәк басып торган шешәдә иде. Бераз тын алсын, тәме йөгерә төшсен дигәндәй, беравык сүз башламый утырды Зариф.

— Сүз бик важныйдан түгел, бигайбә, Бикәй туган,— дип җайлап кына китте аннары,— өченче көн үз күзләрем белән күреп кайттым, пока бу хәрам ризык кермәгән авызым белән ант итеп әйтәм, валлаһибилләһи, без икебез дә дуракка чыгабыз бу килештән.

— Җелегемне суырма, әйтсәң әйт сүзеңне, ни бар? — дип кычкырды Бикәй. Элекке «фундаменты» өстенә бу алты кырлы стаканны да берьюлы түнтәргәч, ул инде яхшы ук исереп өлгергән, ә исергәннән соң кем хуҗа, кем ялчы икәнлекне аерып мәшәкатьләнми иде.

— Тукта, сабыр, юкка гына мин сине кәрванбаш итеп тотмыйм ич,— тегене ныграк тилертер өчен Зариф юри шулай әкрен кылана иде,— кыскасы, шул, мөхтәрәм кәрванбаш, минем сиңа вәгъдә итеп йөргән «кура җиләгем» синең авызга насыйп мал түгел булса кирәк. Әйтәм ич, өченче көн үз күзләрем белән күреп кайттым: Мөкатдәс бабаңның түрендә икенче бер тутый кош утыра. Белгән-күргән кешем түгел, безнең як тумасы булмаса кирәк, бик шома, бик кызыл авыз күренә. Мин төпләп-нигезләп белдем дип үк әйтә алмыйм, мәгәр бик түргә кунаклаган, Мөкатдәс ахирины тәмам авызына караткан иде. Мөгаен, мәйтәм... минем ялгышуым да ихтимал, син бөтенесен чынга алма... Әммаләкин колагыма кереп калган сүзләренә караганда, мөгаен, мәйтәм... теге ни, кура җиләгенә сузылырга йөрүче кәкре койрык түгелме, дим.

— Қыршау сукмыйча гына сөйлә сүзеңне,— Бикәй ярсып торып ук басты, Зарифның үзенә дип салып куйганын тартып алып йотып җибәрде,— иң элек сине сытып үтерәм. Кем дип шулай алдап йөрттең мине, карт тәре. Мин сиңа, анаңның әбисенең гүр тактасын каерып шулай итим, малай түгел. Бикәй диләр мине, Бикчәнтәй була мулла кенәгәсендәгесе... Мин сиңа... мин сиңа...

— «Мин сиңа», «мин сиңа»ларны мәрҗән урынына тезә-тезә, ишекне шап итеп ябып чыгып китте ул. Кая барасын, ни кырачагын хуҗасына әйтеп торуны да кирәк тапмады. Үтә кызган чакларында Бикәй гел шулай: хуҗа белән хезмәтче арасындагы аерманы онытa, «диңгез түбыктан»га әйләнә, нинди дә булса бер мажара кубармыйча тынычланмый иде. Дөресен генә әйткәндә, Зариф аны шул башсызлыгы өчен ярата да, кырын килгән минутларда яки берәр алдаш-йолдашта юлына аркылы төшкән киртәләрне алдырып ташлату өчен Бикәйне кирәкле резерв итеп саклый, «Кәрванбаш» титулын да шундый ихтималларны күздә тотып таккан иде.

Ә менә бу өстерүендә, ни галәмәттер, Чукрак Зариф көткән тамаша килеп чыкмады. Китүен, дөрес, туп-туры Мало-мещанский урамына — Мөкатдәс Шәйдуллиннар ягына китте Бикәй. Нияте дә тамаша чыгару, һич югы, кызган баштан Мөкатдәс картны якасыннан алып бер селкү, өенә яки кибетенә «кызыл әтәч» җибәрү белән котын алу иде.

Мөкатдәс үзе дә, хатыны Гөлсара да өйдә туры килмәде, ишектә звонок булуга Гөлчирә чыкты. Гөлчирә өйдә киеп йөри торган гади кечке күлмәктән генә, ялан баш, чәч толымнарының берсе инбашы аркылы күкрәгенә төшкән, кыз, ялан башлыгыннан, белмәгән-күрмәгән ир-ат алдында болай ялгыз, болай күзгә-күз карашып, болай кечке күлмәктән генә калуыннан нишләргә белмәгәндәй, ике куллап чәч толымына ябышты.

— Өйдә юк иде шул безнекеләр,— диде ул, кинәт артка чигенеп. Куркынуы, уңайсызлануы, ярдәмсезлеге — бөтенесе шушы зәгыйфь тавышында, сискәнеп чигенеп куюында чагылган иде. Аннары тагы сигез потлы, әзмәвердәй олы гәүдәле Бикәйгә ул кыз чырадай нечкә-юка һәм аның томанлы карашына фәрештәдәй җиңел-матур, кул белән кагылу түгел, каты сүз әйтсәң дә, менә-менә очып китәрдәй күренә иде.

— Мөкатдәснең синнән башка тагы кызы бармы? — дип, кызыксынудан да бигрәк сәерсенеп сорау бирде ул кызга.

— Безнең бүтән беркемебез дә юк,— дип, тизрәк җавап кайтарырга ашыкты кыз,— әти дә әни, мин — өчәү генә без.

Җавап бирергә ашыгуы, сизелер-сизелмәс кенә дерелдәве, колакны иркәли торган йомшак-зәгыйфь тавышы — бала да бала, Бикәй каршында басып торган бу кыз да бала. Кинәт айнып киткәндәй булды Бикәй, башыннан яшен тизлегендә өр-яңа уй узды: «Миңа пармыни бу Мисыр күгәрчене. Кара син теге чукрак тәренең мине алдап йөртүен!» Торсын иде бу минутта аның каршында бу нечкә бил түгел, торсын иде бу минутта Чукрак Зариф үзе. Бикәйнең кистәндәй авыр кулларына менә, ичмасам, эш булыр иде. Ә бу адәм фәрештәсе белән нишләсен ул, сытып үтерер дә башы судка китәр.

— Әтиеңдә ие йомышым, җәл, туры килмәде,— дип куйды Бикәй, ишеккә борылып. Ә шулай да «Мисыр күгәрчене» яныннан аның болай тиз генә китәсе дә килми иде. Зәһәрлеге кинәт шуклык белән алышынды. Гомердә булмаган хәл: сүгенү белән бирчәеп беткән теленә назлы-шук сүзләр килеп тора.

— Беренче йомышым шул, фәрештәкәем,— ул күзләре белән кызны «ашый» башлаган иде инде,— әтиеңә әйт: ныграк сыйласын ул сине. Ато нәрсә: карга чукырлык та итең юк ич.

Кызның битенә алсу кызыллык йөгерде, ут яктысы аны инде яна ук башлаган кебек итеп күрсәтә иде. Бу минутларда әтисез дә, әнисез дә торып калган һәм тотып кыссаң учка кереп бетәрдәй бу ялгыз-ятимә кызны юк-бар сүз белән кимсетү Бикәйнең үзенә дә ошамады. Шулай да ник килгәнен бер дә сиздермичә китү дә әллә ничегрәк. Әй, беткән баш беткән — билдән баттың ни дә, муеннан баттың ни! Икенче киләсемени бу бусагага.

— Янә дә шуны да киертеп куй колагыңа, кызый,— дип ялгап алып китте Бикәй, бу юлы инде яхшы ук җитдиләнә төшеп,— сезнең өй өстендә, монда, карчыга очып йөри башлаган дип ишеттек. Кара аны, тырнакларына эләктереп алып китмәсен. Вчүтки, синең ише каз бәбкәләре бездә санаусыз түгел!

Кайтышлый — ә аның өйгә кайтасы килми, аңа урамда буталып йөрү рәхәтрәк иде — юл буе кызга әйткән сүзләреннән үзе үк ләззәт табып, авыз эченнән гел шуны мыгырданып кайтты: «Вчүтки, синең ише каз бәбкәләре санаусыз түгел бездә!» Шәп әйтте бит, теленә алланың рәхмәте төшкере. Хәер, кызы да кыз икән, менә хәзер яныннан китеп баргач, урамда буталып йөргәндә күз алдына китерә: нечкә билле бал кортымыни. Их, кысып, авызыннан балын суырырга иде!

## 10

Күңелендә булганны әнисеннән бервакытта да яшермәгәнне — кичә кич, әти-әнисе кунакта чакта, боларга иләмсез зур гәүдәле бер кеше килеп киткәнлеген, үзенең куркудан «җаны чыга язганлыгын» Гөлчирә әнисенә тәфсилләп сөйләде. Исемен дә, йомышын да әйтмәгән, сүз арасында аңлашылмый торганниндидер «Кәрванбаш» дигән сүзен генә тотып калган кыз. Моны Гөлсара түкми-чәчми картына җиткерде — нишләсен, шикләнә калды ул бу сүздән, ә шиген-шөбһәсен бүлешердәй башка тагы кеме бар?

— Ни әйткән мин сезгә: «Мин юкта белер-белмәс кешегә ишек ачмаска!» — дип. Мөкатдәс һәр вакыттагы кебек бу юлы да төрпә дәште. Хәер, аныңча, хатын белән бервакытта да төче телләнеп уйнарга ярамый, нәрсә ул хатын? Алып сатасы уртак эшең төшәчәкме аның белән! Ләкин дөньяны, дөньяны булмаса, Казанны яхшы белә торган Мөкатдәс «Кәрванбаш» дигән сүзне ишетеп, шундук нәтиҗә ясарга да өлгерде: димәк, Чукрак Зариф кулы уйный булса кирәк, Кәрванбаш Бикәйнең аның кешесе икәнлеген ул яхшы белә иде. Кибетенә китешли,

хатыны капкага чаклы озатырга чыккач (шулай куелган!), Мөкатдәс, тавышын кыса төшеп, Гөлсараны кисәтүне кирәк тапты:

— Син ул кызыңны әзерлә, — диде ул, мөһим алыш-биреш алдыннан гына мөмкин булган җитдилек белән. — Мәскәү кунагының кайтыр көннәре якынлаша. Мондый чакта буй җиткән кыз анасының ачык авыз булып торуы башка сыймый. — Китә башлагач, борылып тагы шуны да өстәде: — Кибеткә барып йөрмәсен, кибеттә ансыз да эш туктамас. Сөйләш, майла-җайла, җелегенә сендер: гомер буена ата өендә сузылып яши алмас. Җитмәсә тагы, алла биргән кешесе чыгып торганда...

Бик ачык, моннан да ачык искәртүнең булуы мөмкинме! Ачыгын ачык та, шулай да ана белән кыз арасында сүз ялганмый гына бит. Гөлсара, әни кеше буларак һәм, бигрәк тә тагы, «алла биргән кеше»не үзе дә рәтләп белмәгәнлектән, сүзне ничектер каушабрак, ымлар белән генә башламакчы, ә теге исәр баш аңларга да теләми. Соңгы вакытта китаплар белән артык җенләнде, берсен алып кайта, икенчесен илтеп бирә — китапханә юлын таптый. Әлегә, дөрес, ул чаклысын ук телдән әйткәне юк, Галекәй клубында китапханә һәм типография яшьләре көче белән уздырылачак концертка катнашырга исәплап йөри. Бик тә сәхнәгә чыгасы килә иде кызның. Аннары тагы... Юк, бу хәтлесен эченнән генә уйларга да базмый, илла күңелендә шундый сискәндергеч коткылар да баш калкыта: алсалар әгәр, бай кызы дип кире какмасалар, комсомолга да керер иде. Чәчне кистерергә диләр икән, нигә кистермәскә! Башкалар кыңгыр салып йөргән шакмаклы кепканы нигә Гөлчирәгә дә кыңгыр салмаска!

Кыскасы, ана белән ата бер котыпта булса, кызлары әнә капма-каршы котыпта. Шулай да теге кичне күзгә чалынып калган чибәр егет аларны, чамача, бер тирәгәрәк тартып китерә язды кебек. Бик тә тилереп калды шул көннән бирле кыз. Тиздән кайтасын һәм бу юлы инде үзләренә туктыйсын күз алдына китереп, шомлана-шомлана тилерә. Кинәт Тукай шигырьләренә хиресләнеп ябышуы да шул татлы шомлыкның бер галәмәте иде түгелме икән! Укый гына түгел, өйдә ялгыз гына калганда кычкырып-кычкырып кабатлый — шул егет сөйләгән кебек оста чыгарырга тырышып, я булмаса типография яшьләре белән узачак концертка катнашу максаты белән. Кыскасы, бу соңгы көннәрдә буталып бетте кыз.

Буталды димичә ни диясең. Менә бу сөекле әнисе белән икәү генә калган минутларда да бит — ничек икесе ике котыпта таптаналар. Әнисе Гөлсара, фәрман биреп киткән үзсүзле картының әйткәненә ничек тә якынаерга тырышып,ниләрдер ымларга азаплана. Ә кызы исәр, дуамалдан туп-туры дигәндәй, баш җитмәслек сорау китереп куя:

— Әйт әле, әни, Газраил да җылый микәнни?

Гөлсара, аптыраудан да битәр куркынып, күзләрен шарландырып кызына карап торганда, Гөлчирә тиз генә Тукайның җыентыгына барып ябыша һәм, озак та эзләп тормастан, аннан «Көзге җилләр» шигырен шаулап укый башлый. Бу аның, күңеленә бик хуш килгәнлектәнме, әллә хыялында йөрткән концертта сөйләнәчәк шигырьләрдән берсеме, каткат укылган, инде яртылаш хәтердән ятланган шигыре булды булса кирәк, кыз аны чынлап та зур дәрт-кабыну белән башлады, әмма укыган саен хисләнә, тәэсиргә бирелә барып:

...Бер сынык юктан гына
үлгән таза ирләр күреп,
Җан алырга кызганудан
анда Газраил җылый,—

дигән юлларга җиткәч, кинәт күзләре яшьләнде, тавышы калтыранып-сынып куйды һәм, янында әнисе барлыгын бөтенләй истән чыгаргандай:

— Юк, юк, мин аның кебек матур итеп чыгара алмыйм, мин җылак, булмый, булмый,— дип, китапны кәнәфигә атып бәрде. Кызының бу

халәтеннән беркадәр таркалыбрак калган ана, бермәл тынлыктан соң шулай да акылына килеп, айныткыч сорау бирде:

— Кем ул «аның тәсле булдыра алмыйм» дигәнең?

Инде кыз өчен читен хәл килеп туды, инде аңарга «Шүрәле»дәге кебек кысылып калган бармакны ычкындырырга кирәк. «Теге кичне бездә булып киткән егет. Мин аны бик яратып калдым, әни!» димәс бит инде. Әйе, әйе, бу четерекле хәлдән ничек тә тизрәк чыгарга кирәк иде.

— Саҗидә апа, минем иптәш кызымның әнисе, бер көн ирен каргап шулай җылап утырды. «Җан алучы Газраил ул, адәм түгел»,— ди. Ире көн саен эчеп кайтып сугыша, Саҗидә апаны кыйный икән.

Хәйләгә оста, тапкыр булуыннан чыгарды димәс идем мин бу җавапны. Күрәсең, кызның бу минуттагы эчке халәте дә, кайдагыдыр Саҗидә апасын кызгануы да булгандыр. Шуңа тагы сабак бирүче абыстайдан, әти-әнисеннән кереп калган сүзләр дә өстәлгәндер. Бөтенесе Газраилны гел яман, мәрхәмәтсез итеп күрсәтә киләләр иде ич... Ә кинәт шул рәхимсез Газраил, җан алудан туеп, җан бирүчеләрне кызганып үзе елый башлады. Ничектер башка сыймый, бер үк вакытта зирәк күңелле кызны тетрәтә иде бу шигырь юллары. Кем белгән, бәлки зирәклек, гомумән, шундый саташулы тетрәнүләрдән соң туа да торгандыр.

Әмма айнык акыллы һәм, өстәвенә тагын, иренең кисәтүен дә истән чыгармаган Гөлсара өчен бу минутта кызы белән ачык сөйләшү кирәк иде. Һәм ул әңгәмәне шул якка борырга булды.

— Теге кичне бездә бер егет булды ич, — дип, дуамал тиз борып алып китте ул сүзне, — хәер, син күрмәдең дә бугай аны. Мәскәүнең үзеннән чыккан егет.

— Котдус абыйны әйтәсеңме? — дип тыелгысыз кабалану белән сорап куйды кыз һәм, үзенең болай кабалануы өчен колакларына чаклы кызарып, ничек тә тизрәк төзәтергә ашыкты: Ник күрмәскә. Әткәй таныштырды ич. Шуннан нәрсә?

— Шуннан шул менә... — Гөлсара ханым сузып куйды, ләкин «шуннан нәрсә?» не ачык кына әйтеп бирергә теле бармый, үзе дә икеләнә, бердәнбер кызы белән алай ялангачландырып сөйләшүне күңеле дә тартмый иде.

— Шуннан нәрсә? Шуннан нәрсә? — Ике мәртәбә кабатлады, ике мәртәбә сузды, ләкин аңа карап кына хәле җиңеләймәде, — мин үзем дә белмим шуннан нәрсә икәнлеген. Әтиең әйтә әнә, кистереп куйды, ул егет өяз киткән җиреннән безгә кайтачак, ди. Әзерләнеп торыгыз, ди.

Кыз аны-моны белмәмешкә салышты.

Нәрсә әзерләнәсе? Өй иркен. Тора бирсен торасы килсә.

— Тора бирсен, дип... ни... Ичмасам, алдын-артын дигәндәй яхшылабрак уйлап карар иең. Әтиеңне бүген генә белмисең, сүзенең җае бардыр, җае булмаса, болай үҗәтләнеп әйтмәс ие.

Кыз һаман белмәмешкә салышкан була, ә белә, әнисенең ни өчен шулай сүзен әйтә алмыйча азаплануын да белә, соңгы көннәрдә әтисенең нилектән болай үтә мәрхәмәтлегә әйләнергә маташуын да күреп тора. Ниһаять, үзенең иләсләнүен дә сизә шайтан, иләсләнмәгән булса соң, Газраилны кызганып, кемнең күзенә яшь килсен...

Бөтенесен белгәне хәлдә, бөтенесеннән дә бигрәк үзенең тилереп шашынган йөрәген тыңлаганы хәлдә, шулай да кыз берьюлы, әти-әни сүзенә бүтән бервакытта да каршы килмәгән көндәм кыздан һич көтелмәгән дуамаллык белән, өзеп әйтүне кирәк тапты:

— Әни, мин кияүгә чыкмыйм, әйт шуны әтигә үзең төзәтеп.— Соңыннан бераз исенә килә төшеп, йомшартырга тырышып маташты:— Ник? Шулай да була ич. Бөтен кызларга да кияүгә чыгарга димәгән. Торам да торам гел сезнең кызыгыз булып.

Бусы инде чияли бәйләнгән төеннәрең чишелә башлавы иде, моннан соң Гөлсара ханым да ачыклана төште:

— Сөйләмә юкны, тел очыңа төер чыккыры,— дип ялгап китте анысы, тавышын яхшы ук кырысландыра төшеп,— ия чыкмыйча, гомер буе атасы өендә утырып калган сазау кызларның хурлыгын кем күтәрә дип уйлыйсың? Барыннан да элек, ата-анасы күтәрә. Утырып калырга синең кай җирең кешедән ким? Коеп куйган буең-сының, укымышлы башың белән. Атаклы Мөкатдәс бай кызы була торып...

— Ә кияүгә чыгып та бәхетле булмасам? Бу синең өчен бик тә дан булыр идеме?

Әни кеше дә, кыз үзе дә кинәт телсез калдылар, берсеннән икенчесенә пошаманлы караш чәчрәп үтте, карасана инде, ана мондый хәтәр сорауны көтмәгән, кыз ул сорауны бирергә уйламаган иде, ничек телдән ычкынды соң?

Онытырга, оныттырырга, бөтенесен берьюлы тузгытып ташларга кирәк иде. Гөлсара әнә шуны минуты-секунды белән эшләү өчен, шактый ук кыза төшеп, дәррәү очып кунды:

— Син генә ризык үтмәс нечкә тамак булдың. Бәхетсез, имеш. Бәхетнең нинди булганын син беләсеңме, мин беләмме? Берәүнең дә бәхетне ипигә ягып ашаганын күргәнем юк.

Әнисе кызып туктаганчы Гөлчирә дәшмәде, аны бүлдермәде, гадәттәге тыңлаучанлыгы, карусызлыгы белән, күзләренә кинәт тибеп чыккан яшьне яшереп, тыңлап торды. Әмма инде бу ноктага күтәрелгән аңлашуны коры карусызлык белән генә уздырып җибәрү мөмкин түгел, кызның купшынган күңеле моны булдыра алмый иде.

— Ә мин, әни җаным, синең балаң гына булсам да... — дип башлады ул, яшьләнгән күзләрен ничек тә әнисенә күрсәтмәскә тырышып,— беләм бәхетнең нинди булганлыгын. Ир белән хатын арасындагы бәхет ул гомер буена... бай булсаң да, фәкыйрь булсаң да, берсенә дә исең китмичә, гомер буена бер-береңне яратышып яшәү. Менә мин шундый бәхет булмас дип куркам.

— Әй, сөйләнеп торган булмасана китаптан отып алган сүзләреңне!— Бу юлы инде ана кызын ачулану белән дә, үгетләү белән дә түгел, җиңелчә генә мыскыллау белән күмеп ташламакчы булып керешге: — Менә без атаң белән, сөбаханалла, әйтмәгәнем булсын, егерме биш ел никахлы ир-хатын булып торабыз, бәхет дип күршегә әҗәткә кермәдек. Талашкан чагыбыз да, ялашкан чагыбыз да булгандыр, үзебезнеке үзебез белдек.

Әнисенең мондый җиңелчә тонга күчүе, болай караганда, Гөлчирәне дә чак-чак кына бушатып җибәрергә тиеш иде кебек, хәлбуки, нәкъ әнә шул җиңелчәлек, әнисенең үз тормышына гамьсез мөнәсәбәте кызны үтә житди кешегә әверелдерде — аның күзендә яшь кипкән, бер мизгел чакма-чаткы ялтырап узды.

— Мин әйтеп карыйммы, әни, сезнең ничек торганны? Ачуланмассыңмы? — дип, әнисеннән рөхсәт сораган атлы булып, ләкин чынлыкта күңеленә килгәнне әйтмичә калдыра алмыйча тотынды Гөлчирә. «Әйдә, бер тел ачылганда бетсен! Китаптан отканмы, үзем сизеп йөргәнме? Әйтәсемне әйтим!» дигән тәвәккәллек белән керешге: — Сез бәхетле булып яшәүне, минемчә, гел белмисез. Аның белән кызыксынмыйсыз да. Әйтимме безнең әтинең иң элек нәрсә белән кызыксынуын?

— Алай бик белдекле булгач, әйтерсең инде, йомырка өйрәтеп карасын тавыкны,— Гөлсара ханым, болай үзе дуамал чәчрәп чыкмаса да, кызының сүзеннән яхшы ук рәнҗегән күренә, ләкин бер үк вакытта уйланып калганлыгы да сизелеп тора иде. Моны сизгер күңел-Гөлчирә, әлбәттә, сизми калмады. Аның күңеленә «Әти сине түгел, әти акчаны, байлыкны күбрәк ярата!» дигән үтә шәрә фикер килсә дә, моның артык дорфа чыгачагын, әнисен тагын да ныграк рәнҗетәчәген уйлап, ничек тә йомшартыбрак әйтергә тырышты:

— Бәлки мин ялгыша да торганмын, анысын әйтә алмыйм, илла да мәгәр, миңа калса... мин дивананың башына килгәне: безнең әти синнән дә, миннән дә әүвәл акча ярата, әни.

Бу инде — бүгенге сөйләшүнең иң биек күтәрелеш ноктасы иде, шуннан да югары күтәрелергә икесенең дә мөмкинлеге калмаган, төшсәләр бары тик түбәнгә тәгәрәргә генә юл ачык иде. Ана белән кыз дөньяны икесе ике төрлерәк аңласалар да, тамырларында бер үк кан йөри: ирешкән югарылыктан үз ирекләре белән түбәнгә тәгәрәүне берсе дә килештермәде. Ә уйлап карасаң, дөрес сүз яңгырады бит өйдә!

Бераз бушану, бу кырыс сөйләшүне онытып тору өчен икесе ике якка китеп, һәр икесе үз эшләре белән мәшгуль булып күпмедер вакыт уздырганнан соң, Гөлчирә янә энисе тирәсенәрәк елышып, гадәттәгечә тиктомалдан, башка килмәгән сүз уйлап тапты:

— Габдулла Тукайның җеназасын озатканны хәтерлисеңме, әни? — энисе сорауны ишетмәгәнгә салышты, ә Гөлчирә өчен барыбер, аның сөйлисе, ничек тә үз энисенең күңелен табасы, йортка җан өрәсе килә иде, — ә мин бүгенгедәй хәтерлим, тугыз-ун яшьлек орчык хәтле кыз, әмерә истә калдырганмын. Без мулла абзый Рокыясы белән мәчет манарасына менеп карап калдык. Әй, кеше... Әй, кеше... Дөньяда шул хәтле күп кеше булыр икән!

Һәм шундый ук кинәтлек һәм очыну белән икенче темага күчте:

— Кем булды соң ул, әни, бер көн бездә кунак булып киткән абый? Өе бармы икән аның? Алтын сәгать таккан булган үзе.

— Нишләп сиңа абый булсын, ди, ул? Булса, тик синең яшьләрдәдер,— бу юлы Гөлсара ханым бик теләп сөйләшергә әзер, тавышы да йомшак чыга, анда-санда кызына, сиздермәскә тырышып кына, ягымлы карашын да ташлап ала иде. Әни кеше шул, ничә әйтсәң дә әни шул! Бер сүз дә тапмагач,— ә сүзне ничектер дәвам иттерергә кирәк иде — үзе дә бала хәлендә калгандай кирәгеннән артык кычкырып ялгап куйды:— Мәскәү хәтле Мәскәүдә торсын да, өе булмасын, имеш. Син дә, җүләр, таптың сүз. Ничә катлы гынадыр әле...

## 11

Кызны энисе әзерли торганда, Мөкатдәс үзе кибетендә түшен киереп, товар сорап керүчене көтеп тору белән генә, әлбәттә, чикләнеп калмады. Чарасына кереште, сорашты, исәнде, кешеләрен белеп, «сары шайтан»ның кайда, кемдә качып яту ихтималын чамалап исәнде һәм, ниһаять, алтын портсигарны биш бәясен биреп булса да кулга төшерде. Бу әлегә эшнең башы гына иде әле. Кызны ничек тә сылау өчен алтын портсигар ярап куяр куюын да, ул Мәскәү мөсафирының нәфесе киң күренә: алты йөз диде ич, алтын бәясенә йөри торган червонецлар теленә күчергәндә, алтмыш червонец дигән сүз бу. Моны Мөкатдәс, гәрчә ике ишекле таш кибет хуҗасы булса да, ялгыз үзе генә күтәрә алмаячак. Алтын портсигар өчен дә ярыйсы гына түләде, юк-юк, күтәрә алмастайны күтәрәм дип көчәнүнең хәере юк. Шул ук вакытта, Кабан төбендәге «сары шайтан» балалары да аңа тынгы бирми, форсаты бик тә мавыктыргыч, ычкындырырга ярамый. Димәк, алтын исе борынына кагылса күзе ут яна торган тагы ике «компаньон» табарга кирәк. Кешеләр бар, ләкин Мөкатдәс карт ышанып җитми, телләре авызларына сыймый торган буш бугаз булып чыгулары, планны җимереп ташлаулары мөмкин. Күп уйлана торгач, шулай да Тегәрҗеп урамындагы тирече Хәмзә кандидатурасына ныклап тукталырга булды. Беренчедән, ул Чистай мишәре — черегән бай, сала мужиклары арасында тире җыеп, тире төятеп һәм су юлы белән партия-партия килгән ул тиреләрне Игумный бистәсендә, Бишбалта читләрендә әлегә сакланып калган хосусый күн заводларына биш бәһасе-

нә «сылап», җал төбенә шактый зур май катламы җыйган кеше. Икенчедән, Хәмзә мишәрнең Кабан күле белән үзенә бер исәп-хисабы бар — кызы Зөһрә, ачык авыз, кер чайкаганда беләгеннән төшергән алтын беләзекне әлегәчә кем яшереп ята? Шул сихерле Кабан төбе яшереп ята. Әллә Хәмзә моны онытты, Кабанны гафу итте дип беләсезме? Онытты-рырсың Хәмзәне! Өченчедән, Хәмзә — арт санында ике потка якын май күтәреп тә көтүдән чапмыйча гына кайта торган куй сарыгы кебек, әкрен һәм тыныч кала белә торган мыштым куй. Аның авызыннан урынлы-урынсыз сүз алырмын димә. Хәер, авызының тик торганы да юк аның. Берөзлексез канәфер чәйнәп йөрер. Аны якыннанрак белгән кешеләр (ә Мөкатдәс шуларның берсе!) әйтәләр: Хәмзә ул канәферне тире исен җуяр өчен чәйни, диләр. Әмма бу яктан ул максатына ирешә алмый, канәфер исе белән кушылган чи тире исе аңардан ике метрга гел аңкып тора. Әмма байлыгы бар каһәрнең, ә бай кешегә мондый гына кимчелекне кайсыбыз да гафу итәр.

Мөкатдәс бер көнне кибетенә килү белән ике бүлектәге ике приказчигына бирәсе боерыкларын бирде дә вак-төяк йомышларга чаптыру өчен берничә сәгатькә кибеттә тота торган йомышчы малайны Тегәрҗеп урамына — Хәмзә абзыйсына әйтеп килергә йөгертте.

— Әссәламәгаләйкем, ходаның итагатьле коллары,— дип, ишектән үк бөтенесенә берьюлы сәлам биреп керде Хәмзә. Аның өстендә май-ланып-керләнеп беткән утыртма якалы казаки, башында шулай ук каеш-ланырга өлгергән түбәтәй иде. Мөкатдәс сәүдәгәр хәтле Мөкатдәснең махсус кеше җибәреп чакыртуыннан, нинди дә булса бирәр төшемле тәкъдим булмагае дип, аның өстен алыштырырга да онытып, кабаланып килгәнлеге әллә кайдан сизелеп тора иде. Шуның да өстенә тагын, гомумән алганда, тома надан кешенең, бик шәп күренергә тырышып, китап сүзләре кушып шаулап килеп керүе мондагыларда — барысында да — көләсе килү хисе кузгатты. Җитди калучы бердәнбер кеше — хуҗа үзе иде.

— Әйдә, кем, Хәмзә туган, бу якка үтик әле,— дип, җитәкләп диярлек, арткы бүлмәгә алып чыкты Мөкатдәс аны.

— Сине болай тинтерәтеп йөрүемнең сәбәбе бар, Хәмзә туганкай,— дип сүз башлады Мөкатдәс, тавышын кыса төшеп. Һәм болай куырып тотынуның урынсыз чыкканлыгын абайлап, әлек бер мәл урап йөрергә булды.— Әле ярый, өйдә чагыңны туры китергәнмен, сине өйдә туры китерү дә, ай-һай, һәндәсә уку белән бер. Көн вә төн өяз чабасың, дөнья куасың — куа алган хәтле.

Булганы белән Мөкатдәс карт та китап сүзләре кыстырырга оста, кыскасы, астыртынлык ягыннан берсе икенчесеннән калышмаган бер пар итекнең икесе ике сыңары иде.

— Мондый иртә җәйдә өяз чыгуның хасияте юк, мужик бу вакытта терлек суярга ашыкмый,— дип, теләр-теләмәс кенә җавап кайтарды Хәмзә. Моның әле үзе көткән сүз түгеллеген, әйләнеп йөрү генә икәнлеген ул, хәйләкәр төлке, әлбәттә, чамалый иде,— вакытлы-вакытсыз сала тузаны йотып йөрүдән ни файда. Сезнең кебек куш аяклап сикерә алмасак та, безгә дә аякның кирәк чаклары чыккалап тора.

Һәм кирәкле-кирәкмәс сүзне ычкындырмас өчен, шундук түш кесәсеннән бәләкәй генә шешә тартып алып, аннан учына берничә канәфер кагып төшерде, авызына капты, җиренә җиткереп, бер дә ашыкмыйча гына чәйнәргә тотынды — алырсың хәзер аның авызыннан сүз. Иреклеирексез Мөкатдәс картка ялгап җибәрергә туры килде.

— Сәламнең сәкене шул дигәндәй, чакыртып китерүемнең сәер бер сәбәбе бар,— Мөкатдәс як-ягына каранды, ишеккә күз төшерде.— мәгәренки монда сөйләнә торган сүз түгел, монда безнең ишекләр бик шыгырдап ачыла, шыгырдаган саен кеше. Ә минем сүз икәүдән-икәү генә калып сөйләшә торган сүз. Шаять, төшенә торгансың дип беләм.

Төшенмәгән кайда! Канәфер чәйнәүне шундук туктатты Хәмзә. Тоташ игътибар чүлмәге булып калды. Шул «чүлмәк»нең алгы ягында күзләр дип атала торган ике тишек: аларда кызыксыну, майлану, тизрәк беләсе килү һәм, ниһаять, комсызлык бөтенесе бергә буталган иде.

— Алайса, кая барабыз? Җир тишегенә керер идек, икебез дә түшкә шактый үскән, икебез бер тишеккә сыймабыз,— Хәмзә уен-көлке корып азапланган була, ләкин бу очракта юк-бар сүз белән вакыт уздырганы өчен эчтән үзен-үзе битәрли иде. Һәм кинәт үзе чып-чын кешегә, ә Мөкатдәс «азыкай»га әйләнмәсенме, — алайса, без, Мөкатдәс азыкаем, менә болай итәбез. Тотасың да син бүген кичкә минем үгә рәхим итәсең. Ишекнең кай якка ачылганын үрәтеп торасы юк, беләсең. Аш-су хет завались...

— Менә, менә, анысы кирәк түгел, Хәмзә,— Мөкатдәс бик җитди иде бу минутта, аңарга каршы килеп сүз әйтерлек түгел иде, — хәтта мин шуны да шарт итеп куям: өйдә синең белән миннән башка бер җан иясе дә калмаска тиеш.

— Үдәгеләргә минем бер сызгыру җитә, — диде Хәмзә, үз өендә үз хөкеме өстенлек иткәнне ачыктан-ачык сиздерергә тырышып. Һәм эш кешесенә хас кискенлек белән урыныннан сикереп торды.— Алайса, вәгъдә — иман: бүген кич син миндә.

— Тукта, чү, кабаланма, — ишеккә борылган Хәмзәне янә туктатты Мөкатдәс, — өеңдә коръән-шәриф бармы?

— Татар ызбасы булсын да, коръәнсез булсын. Аллага шөкер: муеныбызга тавык тәпие тагылмаган.

— Бөтен коръән булсын,— дип калды Мөкатдәс, ниһаять, соңгы шартын куеп.

Кичен Мөкатдәс бернинди шау-шусыз, хәтта хатынына да тынын чыгармыйча, Тегәрҗеп урамына китте. Хәмзәнең «бер сызгыруым җитә!» дип әйтүе коры мактанчыклык кына булмаган икән. Чынлап та, өйдә хуҗаның үзеннән башка этле адәм дә юк иде. Хәтта аяк астында чуалып йөргән мәчене дә:

— Бар әле, сүз бурыдай чуалып йөрмә монда, — дип, ишектән типкәләп чыгарды Хәмзә. Икәү генә калгач, хәтәр эш алдына килеп баскан кешеләрдәй, бер-берсенә сүзсез генә карашып калдылар. Гәрчә Хәмзәнең тизрәк беләсе килүдән тәкате корыса да, сер сынатмады, очынып сорашырга тотынмады — алыш-бирештә каешланган кеше, белә, мондый эштә бик тәкатьсезләнү килешми, оттыруың бар. Торып-торып та кунагы сүз башламагач, шулай да әйтми булдыра алмады:

— Әллә тел ачкычы итеп берәрне тотабызмы, Мөкатдәс азыкай? Беребез дә рәсүлебез тырнагыннан ясалмаган, сүз башлау алдыннан берчәк, шәт, мишәйтләмәс ие.

— Куйчы юк сүзне, — диде Мөкатдәс һәм, бармагы белән ишарәләп, Хәмзәгә якынрак килеп утырырга кушты. Һәм бик серле генә башлап та җибәрмәкче булды. Ләкин, кадалып кына киткересе, иң мөһимен ычкындыра язган икән.

— Мөкатдәс абзыкаеңны зря дә тиз ашыктырма, аның каушый торган өянәге бар, — диде ул элек, бераз шаярткандай итеп. Ләкин шаяртып тору сәгате түгел икәнлекне бик яхшы төшенә, кызыксынудан күзләре ут булып яна барган ач бүре Хәмзәне отыры кыздыра төшү өчен юри шулай суза иде. — Иң элек алдыбызга коръәнеңне китереп куй.

Менә коръән дә килде, инде артык көттерергә урын калмады.

— Монда сөйләнгән, Мөкатдәс абзыкаем авызыннан ишеткән сүзләрне, — дип, сүзләрен өзек-өзек һәм бик ачык әйтеп һәм, өстәвенә коръәнне кулына тотып, иман яңартырга керешкән фанатик мөриттәй сузарга тотынды ул, ниһаять, — әйе, Мөкатдәс әфәнде Шәйдуллин житкергән бу хәбәрне башка бервакытта да, бер кемгә дә, хәтта хәләл җефетем кызыксына калса — аңарга да чыгармаска изге кәләм-шәрифне үбеп

ант итәм, дип үз авызыннан вә үз телең белән кабатла. Беренче шарт шул.

Мондый тантаналы купшылыкны күрмәгән һәм китап сүзләре кыстырып сөйләү ягыннан да Мөкатдәстән күп калыша торган тирече Хәмзә, әлбәттә, Мөкатдәс карт сузганча ук суза алмады, анықы кыска һәм корырак чыкты, әмма гамәле шул — Мөкатдәс әйткәнне кабатлау булды. Инде коръән үбүгә килгәндә, ул Мөкатдәс киткәннән күп уздырды, кайдадыр шүрлек почмагында озак вакытлар кузгалмый тузан җыеп яткан коръәннең ике як тышлыгын да сабак баласыдай тырышлык күрсәтеп ялап-ялап алды.

Мондый анттан соң да ышанмаскамы? Һәм Мөкатдәс, әңгәмәдәшен дәртләндерә төшү өчен кайбер урыннарда бизәкләрне үзеннән дә кушкалап, эшнең асылын сөйләп бирде. Кайчан һәм нинди мөсафир безнең бу якларда пәйда булган. Аның өсте-башы, килеше-килбәте, үзен тотышы, кайдадыр югарыда, хәтта Мәскәүнең үзеннән дә югарыдарак нинди бәйләнешләре булганлыгы, рәсми командировкасы, шул эше буенча әлегә өязгә чыгып киткәнлеге, кайчанрак кайтачак һәм кайчанрак китәргә исәп тотканлыгы турында һичнинди шик-шөбһәсез бәйнә-бәйнә сөйләп бирде дә, ниһаять, соңгы өлешендә инде беркадәр шикләнебрәк, тавышын кыса төшебрәк, ул мөсафирның нинди мавыктыргыч тәкъдим ясаганлыгын, ул тәкъдимне тормышка ашыруда нинди планнары булганлыгын, әлбәттә, бу хикмәтле эштә чит ил миллионерларының да кулы уйнаячагын, әмма Кабан төбеннән алыначак байлыкның бары тик чирек өлеше генә алар кассасына китеп, дүрттән өч өлеше бу хәтәр тәвәккәллеккә катнашырга йөрәге җиткән Казан могтәбәр затларының кесәсендә калачак икәнлеген аңлатты.

«Могтәбәр зат», «хәтәр тәвәккәллек» кебек китап сүзләрен колагы яныннан уздырса да, әмма «дүрттән өч өлеше безнең кесәгә» кебек мәгънәле сүзләре Хәмзәне яхшы ук эретте. Әлбәттә, бу, өяз чыгып, сала мужиклары арасында тире җыеп йөрү кебек вак һәм пычрак эш түгел, шулай да бик үк коры эш тә булмаска кирәк, суга чумып уйнау бит... дәррәү тончыгып калуың да бар. Бер үк вакытта, эшнең хәтәрлеге Хәмзәнең мажара ятучы авантюристик җанын яхшы ук кытыклый да: чит ил миллионерлары, Швейцария банкысы, алтын, бабайлардан калган хәләл байлыкны кулга төшерү...

Әйе, бу чаклысы Хәмзәне нык кына кузгатты. Бу эштә Казан байларыннан бары тик өч кенә ышанычлы кеше катнашырга тиешлекне һәм шул ышанычлы өч кешенең берсе итеп Хәмзәне күздә тотуларын әйткәч, аның мактаудан тиз исерүчән канатлы җаны авызыннан очып чыгып китәрдәй дәрәҗәгә җитеп талпына башлады. Шулай да үзен тотып тора, очынганлыгын сиздерми, хәтта, киресенчә, бу эшнең барып чыгуына бик үк ышанып та җитмәгәнлеген күрсәтеп, мәзәккә әверелдергән атлы булып күренергә тырыша иде.

Башкасына әллә ни өметем юк, минем Зөһрә ачык авыз төшергән алтын беләзекне алып чыгып бирсәләр дә бер файда. Туксан алты пробалы саф алтын беләзек менәтерәк. Балта хәтле.

Сөйләшүне сатулашуга әйләндерерлек сәбәп чыкмады—алда торган бу хикмәтле эш икесен дә бердәй тиң кызыктыра иде. Тик әлеге Мәскәү егетенә эшне башлап җибәрү, чит ил кешеләре белән элемтәгә керү, алар аркылы суга чумучылар китерү өчен алтмыш червонец акча җыеп бирен җибәрергә, өчкә бүлгәч, аның янчык башына егермешәр червонец төшәчәген ишеткәч кенә Хәмзә тирече бераз җилкәсен кашып куйды.

— Судан алыначагы әлегә ходай кулында, суга салыначагының суммасы билгеле икән,— дигән булды, әллә үзен, әллә Мөкатдәс картны

ирештергәнлеген ачык сиздермичә. Хәер, кузгалган тел нәрсә әйтмәс— андамыни эш. Эш шунда: тиречә Хәмзә бу хәтәр эштә компаньон булып катнашырга сүз бирде. Шуңа тагын коръән тышлыгын ялауны да китереп өстәгез.

## 12

Өченче компаньонны табу ул хәтле читен булмады. Монда Мөкатдәс ялгыз үзе генә түгел, корьән үбеп керешкән тиречә Хәмзә дә ярдәмгә килде. Хәмзә озак баш ватарга бирмәде, Суконный бистәсендә бакалей кибете тотучы Ясәви Әфләтуновны атады. Ясәви аңарга хатыны ягыннан ерак бер «чыбык очы» да туры килә икән, арада Кабан күле җәелеп ята дип тормыйлар, ашка-суга да йөрешәләр. Нәкъ менә шушы максатны күздә тотып, аннары өлешчә Хәмзә кодасының борынына чиертү өчен (янәсе, күрсен безнең тире-күн сасысы эчендә генә күмелеп ятмаганны!) моторлы көймә сатып алган. Үзе бора, үзе йөртә. Хәмзәләр аларга кунакка чыкканда, тегене хатыны белән көймә түренә рәттән утыртып, Кабан өстеннән бер зырылдатып әйләндереп алып кайтырга ярата. Хәмзәнең хатыны, бусага атлап чыкмаган өй тавыгы, куркып чырылдый башласа, Ясәвинең җавабы кыска: «Кабан безнең үзебезнеке, өстәвенә Батан бакчасын да кушып сатып алам!» дип кенә җибәрә. Ул гынамы соң әле! Хәмзәгә хәтта мактанганы да бар: «Әхтәмбил алып җибәрсәм дә кодрәтемнән килә, түлке ни... Шикләнәм, сезнең чека Вәли ише калай әтәчләр безнең Суконныйда да бетәсе түгел, житкерерләр: комиссар абыеңларга эләкмәгәнне кибетче Ясәви әнә әхтәмбил белән йөри, диюләре бар».

Бәләкәй генә гәүдәле, елтыр күзле «пирәшләп» алса, бөтенләй туарылып китүче, әмма дөньяда ике нәрсәдән — чекадан һәм хатыныннан куркып яшәүче бу Ясәви мактанчыкка Хәмзәнең саруы кайнаган минутлары болай да булгалый иде булса кирәк, эченнән генә «янсак, бергә янарбыз!» диде дә, шундук Кабан артындагы Ясәви кодасының башына очып кунды.

— Берүзе бөтен Суконныйны имеп ята,— диде ул Мөкатдәскә икеләнергә һич урын калдырмыйча, — акчасы кырын-кырын өелгән булырга тиеш. Кибете синеке кебек ике ишекле түгел түгеллеккә, но ул бер ишектән күренгән кешене дә әрчемичә чыгармый. Сүзгә-хәйләгә дисәң, ике Сәет Батталыңны берьюлы орып салырлык.

Хәмзәнең Суконный Ясәви турында белгәннәре хәтта болар гына да түгел, ул аның хатыныннан ни өчен ул чаклы курыкканлыгын да белә. Һич югы, аны шул яктан бармагын кыстырып, шүрәле хәлендә калдырырга мөмкин. Ләкин хәзергә Хәмзә кодасының барлык йомшак яклары компаньоны алдында ул чаклы ук чыгарып селкергә ашыкмады, ачылмаган карта итеп калдырды, үтә хәтәр эш алдында торалар ич, эш дигәне кай ягы белән әйләнеп чыгар, бу Мөкатдәс — корьән колы алдында бик алай тугарылып бетәргә ярамас. Шулай да ул Мөкатдәс Шәйдуллинны эшнең барып чыгасына нык ышандырып алып китте.

Әлбәттә, көнгә караңгылык капкач, кеше аягы басылгач киттеләр. Асраулары юк икән, әллә булып та ишек ачу кебек житди эшне асраугa ышанмадымы (кем булмас ишектә!), ишекне байбикә үзе ачты. Мөкатдәснең бу йортта булганы юк иде. Ясәвинең үзе турында да ишетеп кенә һәм менә Хәмзә авызыннан чыккан тасвир буенча гына белә, ишекне ачып керүгә аны дуамал хәйранга калдырганы шул булды: Ясәви үзе чүрәкәй үрдәк кенә, ә хатыны исә яңгырсыз елны әллә кайдан шәрәләнеп күренә торган Ослан тавы хәтле. Тышкы ишекне ике бигенә дә бикләп, буяулы баскычтан өскә күтәрелгәндә дә хатын ире Ясәви артыннан, үзен ураза дип йөреп тә көндез кайдадыр «пирәшләп» сәхәр

ашаган кешенең артыннан иярә килүче гөнаһысы кебек, сүзсез һәм кара көеп менде. Ләкин менеп житкәч, Хәмзә аңарга тагылып йөрүнең кирәк түгеллеген аңлата торган итеп әйтте:

— Безнең өчебезнең генә үзара сөйләшәсе бик мөһим сүзебез бар, Хәсби кодагый. Барып чыкса әгәр, Мәскәү сәүдәгәрләрен тез чүктерерлек,— диде сүзләрен өзек-өзек әйтеп. Бу да житмәсә, «менә без нинди агай-эне белән эш итәбез!» дигәнне аңлатырга тырышып, Мөкатдәс карт жилкәсенә ымлады,— менә бу Мөкатдәс абзаң Шәйдуллин булыр. Мануфактурчы. Бөтен Печән базарын уч төбендә биетә.

Бер мәл аптырабрак калды «Ослан тавы» да. «Ә син нигә теленне йоттың?» дигәндәй, өстән аска таба текәлеп үзенең Ясәви чүрәкәенә карап алды, әгәр ире Хәмзә кодасы белән икәве генә булса, алай тәкәллеф саклап тормас, ирен баскан урыныннан дәррәү алып, үзе биеклегенә күтәрер, авызын авызга куеп: «Сула! Эчкәнсең бит, чукынчык!» дип, сорау-җавап кичәсе уздырырга да күп алмас иде. Әмма «бөтен Печән базарын уч төбендә биетүче» чал чәчле өлкән кеше алдында алай тупас кылануны килештермәде. Өстәвенә, тагы Хәмзә кодасы да куыра иде:

— Сезнең егерме биш бүлмәле бу гүрнәчәгездә,— диде анысы, кодагыеның салпы ягына салам кыстыра төшеп,— без өч гөнаһысыз бәндәне яшерерлек кенә урын, шәт, табылыр.

«Егерме биш бүлмәле гүрнәчәгездә» дию белән хатынны берьюлы эретте дә куйды бит Хәмзә төлке.

— Әнә теге ак ишекле чат бүлмәгә үтегез,— диде Хәсби. Аннары ире алдында итагатьлелек күрсәткән атлы күренергә тырышып сорады:— Сезгә чәй-мазар кертергәме, сиңайтәм.

«Сиңайтәм»нең чәйгә бик алай исе китмәсә дә, «мазар»дан баш тартыр исәбе юк иде. Ләкин аңа хәтле тагын Хәмзә җавап биреп өлгерде:

— Никакой чәй, никакой мазар. Безнең сүз озын түгел, илла бик деловой сүз. Шуны белеп тор, кодагый.

Ак ишекле чат бүлмәгә керү белән беренче эш итеп Мөкатдәс карт эчтән ишекнең келәсен төшертте.

— Артык күзнең кереп-чыгып йөрүе катгыян тыелган булырга тиеш,— диде өстәп. Хатынының сораулы караш белән озатып калуыннан бер куырылып төшкән Ясәви чал чәчле могтәбәр мануфактурачының болай кистереп куюыннан бөтенләй коелып инде — баш китәрдәй эш булмаса гына ярый. Эшнең житдилеген тиешенчә төшенгән һәм Ясәви «чыбык очын» якыннанрак белгән Хәмзә булачак компаньонны алдан ук болай өркетеп кую ягында тормый иде. Шуңа күрә серне чишүне үз өстенә алды һәм шактый ерактан уратып, ара-тирә шук сүзләр дә кыстырган булып, әкренләп-әкренләп кенә алып килде. Ниһаять, менә житте, алтын бәһасе белән Ясәви өлешенә төшәчәк ике йөзгә, червонецлап санаганда егерме червонецка килеп життеләр. Иөрәкне кузгата торган бу зур сума, әйтик, Ясәви кесәсенә керәчәк булса, бәлкем ул кырган баш сүз дә әйтмәс иде, ә бит бу, кадалып киткере, хәзергә әле Ясәви кесәсеннән чыгарга тиеш. Бәләкәй гәүдәле бу бөтерчек кешене урыныннан сикертер өчен, аллага шөкер, бик саллы удар булды бу.

— Карагыз әле, мөселманнар, сез әллә мине завод тотучы Крестауник дип белдегезме? — дип чәчрәп торды ул.— Имештер, чиш янчыгыңны да сразы егерме червонец акчаңны чыгарып бир.

— Әкренрәк! Кычкырып сөйләшә торган сүз түгел ич бу. Ишекнең теге ягыннан Хәсби тумачи тыңлап тормасын.

Усал да соң, тирече Хәмзәне әйтәм. Нәкъ кирәк вакытта Хәсби исемен атап, тегенең тез астына китереп сукты бит. Ясәвинең кинәт шиңеп төште, тавышы кысылды гына түгел, бөтенләй гыжгылдыкка әйләнде.

Күп эчкән арты шулай гыжгылдыкка әйләнә ул, ә бу очракта, алла үзе шаһит, авызга бер тамчы алмаган килеш бит!

— Товары-ние белән кибетемне торгига куеп сатыгыз, өстәвенә, моторный лодкам белән бәхилләшергә әзер, алай да ул егерме червонецны җыеп булыр микән?

— Бише белән кайтачак бит ул, алла боерган булса,— дип, тегене тынычландырырга тырышып, сүз кыстырасы итте Мөкатдәс.

Әмма кодасын якыннанрак белгән кеше — Хәмзәнең алай җебеп сөйләшәсе килми иде.

— Җылап кемне ышандырмакчы буласың, Ясәви,— диде анысы кискен һәм каты итеп.— Әллә мин синең җидлыгыңны бүген генә белгәнме. Әфтәмәбил алырга җыенучы кеше кем?

Бичара Ясәви мондый кысу астында, әлбәттә, йомшамыйча булдыра алмады. Ләкин үз шартын куймыйча тугарылырга да ашыкмады.

— Ник өч кенә кеше страдать итәргә тиеш? Ник ун кеше түгел,— башына кинәт килгән бу идея аны тәмам тереләткән иде,— ун кеше җыелсак, әйтик, алтышар кызыл кәгазь, бусы әле тудым-судым.

— Ник йөз кеше түгел, дип тә куярсың син саран бака. Йөз кеше җыелсак, кеше башыннан алтышар сум гына чыгачак,— Хәмзәнең кызып барганын күреп, Мөкатдәс карт эченнән генә: «Җонын коя бу көзге чебешнең. Мин түгел, сөйләшә бел-ә!» дип шатланып утырды.— Алайга китсә син, Ясәви кода, шәһәр уртасына прәме Проломный чатына контора ачып, «Кабан төбеннән алтын эзләүчеләр ширкәте» дигән вывеска элеп куярга да кушарсың.

Бер кавым өчесе дә телсез калдылар, шуннан да артык кызарга урын юк, артка чигенү өчен юллар шулай ук ябык иде.

— Ходай бәндәсе, төшендерерлек итеп эттек ләбаса,— дип яңадан тотынды Хәмзә,— баш китәрлек секрет бу. Чит ил кешеләре белән, посольство белән бәйләнгән. Әллә синең, Кабан төбенә чумып, аннан тубалы белән алтын-көмеш күтәреп чыкканыңны Совнарком абыең яр буеннан тыныч кына карап торыр дисеңме? Яхуд чека?

— Шулай, шулай, Ясәви туган, зря дә яшертен эш бу,— дип, Хәмзәнең сүзен җай гына куәтләп торды Мөкатдәс,— гаять тә зур фидакарьлык сорала бу өч кешедән. Вә янә сер саклый белү сорала. Мин үзем, мисалга алсак, шул егерме червонец өстенә әле ул чит ил белгечләрен өемдә тотарга да тиешмен. Минем дә башым ике түгел, мәгәр хикмәте күренеп торган эшкә тәвәккәлләмичә дә булмый. Тәвәккәлләгән — таш йоткан.

— Ә сиңа, эчеңә сыя алган хәтле, алтын-көмеш йоттырырга торалар, тиле,— дип, сабырсызланып, янә тирече ялгап алып китте,— озакка сузыла торган эш түгел бу. Чит ил белгечләренең кәфеннәре өсләренә үлчәп тегелгән. Су асты фонарьлары и бүтән разный кирәк-ярак келәщәмазарлары үзләре белән, ике көндә актарып чыгачаклар Кабан төбен.

— Көндә түгел, алла сакласын, төнлә диген — адәм түгел, балыклар йокыда чакта.

Ясәви каршы килеп тә, болар әйткәнгә кушылып та ни дә булса әйтә алмыйча бер мәл сүзсез утырды — бу аның «бүреге белән» чын-чынлап киңәшләшү минутлары иде булса кирәк. Тирече Хәмзәнең кулында тагын бер, моңарчы саклап тотылган козыре бар иде. Ясәвинең телсез калган минутында ул нәкъ әнә шуның белән сугып, аның өнен алырга булды.

— Сер тотардай и, әлбәттә, тиешле авансны кертердәй өч ышанычлы кешенең берсе итеп сине санаганбыз икән, белеп тор, Ясәви кода, бу эш болай гына узмаячак. Син эт каешы булсаң, без синнән дә болайрак каеш: май аеның егерме бишенче кичәсендә, айлы төндә, итче Гыймадинең безнең ише үз хатыныннан үтләгән кешеләр өчен тота торган яшертен мунчасыннан Мәрүсә белән тирләп-пешеп чыгып килгәнеңне күреп

калучылар бар. Шуны Хәсби кодагыйга җиткерсәк, ни булачагын, шәт, үзең үк чамаларга тиешсең...

— Тукта, чү, телең коргыры,— дип пышылдап, Хәмзәнең якасына ук барып ябышты Ясәви. Үзенең Хәмзә янында чүрәкәй генә икәнлеген онытты,— бер генә дә иснәнмәгәнең юк икән, иблис токымы.— Аннары берьюлы йомшап төшеп, шулай да Хәмзәгә түгел, Мөкатдәс картка чишелгән атлы күренергә тырышып, өстәде:— Кайчан, кайда, кемгә тапшырырга ул егерме червонецны? Янә дә килеп, әйтү шушы булсын: Суконный яры буйдан буйга минеке, аннан чыккан байлыкка берегез дә күзегезне ялтыратасы булмагыз.

Акчаны әзерләп куярга, вакыты җиткәч кая, кемгә тапшырылачагын аерым хәбәр итәргә булып, инде чыгарга дип ишеккә борылгач, — «чыбык очы» бит, кем белән эш иткәнлеген белә — Хәмзә тукталып, Ясәвине авызы каршынарак тартып китерде.

— Безнең болай вакытсыз йөрү тәк кенә узмас, — диде ул пышылдап, — Хәсби дуамалны мин беләм, якаңнан борып алачак. Бик төпченә башласа, әйт: банкротлыкка чыккан бер Мәскәү нэпманы трикотаж фабрикасын сатачак икән: җыйнаулашып шуны алу, шул эшнең төшемле булып-булмавы турында сүләшеп, счет түмәсе тарткалап утырдык, диең.

Каһәр генә суккан икән бу Хәмзәне, бер дә белмәгәне юк икән! Кайтышлый Мөкатдәс карт аңардан нинди дога белән Ясәвине кинәт йомшата алуы турында кызыксынгач, элек урам тутырып, шаркылдап көлде, аннары кеше ишетмәсенгә җайлабрак тезеп китте. Өлкәнрәк яшьтәге һәм, аннары, табыш кебек нәрсәләр белән башы каткан Мөкатдәс карт белеп кенә җиткерми, бар икән бу Казанда хәлләр! Итче Гыймади дигән, карар күзгә бик тә тәкъва күренгән бер бәндә үзенең Нәриман урамындагы өе артына, түргә, бакча эченә кертеп, берсен икенчесеннән чак-чак кына аера төшеп, өч ак мунча салдырып җибәргән. Ак мунча, зат мунча — хәтфә япмалары, крахмалланган җәймәләре, сөлгеләре, кирәксенгән кешегә сырасы, зильтерски куасы белән. Шунда шул күнлек сәүдә-табышлары уңышлы чыккан кара мыек сәүдәгәрләр һәм мыекны борын төбендә генә калдырып йөртә торган мут хезмәткәрләр, көнгә караңгылык кунгач, анда-санда нәмәхрәм алып барып, «тансык аштан авыз иткәлиләр» икән.

— Ходайдан курыкмаганны синнән яшергән юк, Мөкатдәс абзыкаем, — дип, күзен дә йоммыйча әйтте дә салды Хәмзә. Биле сынса да бөгелмәс Ясәви кибетчене бөгә алганлыктанмы, ул бик ачык һәм киң күңелле иде бу минутларда, — үземнең дә булгалаганым бар, шәп мунча. Сиңа да бер барып караганда эчеңне тишмәс иде.

Сүз сүзне чыгарды: Ясәви тешләкне бөгүнең сәбәбе дә шул мунчага барып тоташа икән. Үзе чүрәкәй үрдәк кенә булса да нәфсесе зур: могтәбәр кибетчебез Ясәви кода да барып кайткалый икән ул мунчага. Хәер, мәсьәлә анда түгел, җегәренә ышанган кеше йөри бирсен, караңгыда башкарылган эшне кем хөкем итеп бетергән! Ә менә Ясәвинең борыны ис сизүчән Хәсбие әгәр иренең мондый кыңгыр эшен сизеп ала калса, каты хөкемле һәм аның хөкеме үзенчә була икән: егып сала икән теге «чүрәкәй»не идәнгә дә, өстенә менеп атлана икән, әй кай җирең кычыта, өстерәлчек! Тәмам миңрәткәнче тукмый икән тегене.

Тукмавы — анысы дөрес хөкем, аягы белән атлап барган — җилкәсе белән күтәрсен! Ә Хәсби мөртәт тукмау белән генә дә калмый. Кыйныйкыйный да икән, аннары үзенең кай җирендер күгәртеп, я булмаса — тәмам имансыз икән! — чәч пәкесе белән чак кына ышкып кан чыгара икән дә райсоветның женотделына йөгерә икән — ирен әләкләргә. Бичара Ясәвине шул нигездә ничәмә-ничә тапкыр чакыртып кисәткәннәр: янәсе, нэптан файдаланып үрмәкүч җәтмәләреңне сузу гына җитмәгән,

әле син совет властенда хатын-кызга кул күтәрергә тотындыңмы? Кара аны...

Хәмзә бу эшләр турында Мөкатдәс картка сөйләгәндә рәхәтләнүдән яртылаш яшәргән кебек булды. Яшәрерсең, гайбәт сөйләү гомумән кызык нәрсә ич ул. Үз кодаңның гайбәтен сөйләү бигрәк тә!

## 13

Ниһаять, урыс алласы ярата торган өчлек өлгерде, ул яктан Мөкатдәс Шәйдуллинның күңеле тынычлана язды. «Язды» гына диюне кирәк табабыз, чөнки үз тирәсендәге кешеләрне белә Мөкатдәс: балыклары бик шома балыклар, тоттым дигәндә генә кулдан шуып китүләре дә мөмкин. Мөкатдәс үзе бу хәвефле эшкә, күңеленнән бик үк ышанып житмәсә дә, шулай да ныклап тотынган икән, аның, Кабан төбеннән чыгачак алтын-көмешләргә нәфсесен сузудан башка тагын, чымырдап торган анык бер оеткысы бар: буй житкән кызны гомер буе өйдә тозлап яткыза алмас, аны ничек тә бу Мәскәү егетенә сыларга исәбе! Ул моны болай шәрәләндереп бераүгә дә, хәтта хәләл жефете Гөлсарага да сиздерми. Әмма хәрәкәтләренә, ир башы белән өй җиһазларының урынлымы-урынсызмы булулары белән кызыксынып, киңәшләр биреп, ашыгыч чаралар күреп йөрүенә караганда, аның Мәскәү кунагын чын-чынлап көткәнлеге әллә кайдан сизелә иде. Тиз генә оста китертеп, кәнәфинең кырыла башлаган тышлыгын куптартып, аны ялып торган яшел хәтфә белән тышлатты. Зал идәненә шулай ук «мөселман жирендә» тукылган яшькелт-чуар келәм кайтартып җәйдерде. Стенадагы борынгы шәмаилләрне, пыяла астына — рамга куелган «Мәккәи-мөкәррәмә» манзараларын алдырып, алар урынына, шулай ук рамга пыяла астына тарттырып, берсенә Буденныйның атка атланып төшкән шәп мыеклы мәһабәт портретын, икенчесенә немец шагыйре Генрих Гейненыябып куйды. Бу хәлдән Гөлсара ханым нык кына аптырап калса да — бүген генә тормаган — иренә каршы килеп сүз әйтергә базмады. Тик үзен бу кадими әти-әнисенә караганда, һәрхәлдә, өстенрәк санаучы һәм соңгы вакытларда китап белән аеруча мавыккан Гөлчирә генә, белгәнлеген күрсәтергә тырышудан түгел, киресенчә, бу үзгәртеп коруларны нәрсәгә юрарга белмәүдән, кызыксынып:

— Әткәй, бу портретларның безнең йортка ни катнашы бар — берсе немец шагыйре Гейне, икенчесе хәрби кеше, бездән бөтенләй ерак кешеләр? — дип, сүз кыстырып караган иде, әтисенең җавабы ярлы кешенең талканы кебек коры булды:

— Тимә син аларга: берсенең мыегын кара да икенчесенең чәчен күр: чын азамат егетләр, — аннары мәгънәсенә тирәнрәк ишарәләргә исәплә булса кирәк: — минем бусаганы атлап керәчәк укымышлы әфәнделәр: «Бу Мөкатдәс карт кеше белән кешене аера белми торган томана икән», дип уйламасыннар, — диде.

Аннары тагы бер көнне Гөлчирә үз бүлмәсендәге комод өстенә наборы белән бизәнү-ясану әйберләре тартмасы кайтып утырганны күргәч, кызның шикләнүләре гаҗәпсенү катнаш алгысыну белән алышынды: я хода, чандыр һәм бала акылы чыкмаган дигәч тә, әллә аның эчендә җаны юкмы? Зөһрәнең Таһиры булганы кебек, әллә аның да кайдадыр Таһиры каңгырып йөрми торгандырмы? Әгәр әйтик (тфү, тфү! Әстагыфирулла, уйларга да оят!), аның ул Таһиры теге кичне аларга сугылып киткән шул чибәр Мәскәү егете булса? Кайтышлый бу юлы аларда тукталачак дигән сүз дә колагына кереп калган иде, әллә, ходаем, өйдәге бу ыгы-зыгы шул кунак егетне каршылау өчен куптымы? Юк, юк, башка китерү дә хәтәр: Гөлчирәнең соң кеше күзе төшәр жире бармы? Комод өстенә кайтып утырган теге тартманы да гомердә

ачасы юк, кершән-иннекне дә гомердә ягынасы юк. Янәсе, Таһирыма матур булып күреним дип Зөһрә онга төшкән таракан кебек кершән-иннеккә буялып йөрсен, имеш. Таһир икән, бернинди ялган буяуга алданмаслык чын Таһир булсын. Танырга тели икән үзенең Зөһрәсен, бернинди ясалмасыз, ничек бар — шул хәлендә, шушы чандыр кыз хәлендә, шушы ходай биргән күзләре, кашлары-керфекләре белән таны-сын. Нигә ул стенадагы шәмаилләргә, «Мәккәи-мөкәррәмә» күренеш-ләренә кагылырга кирәк булгандыр?

Шулай да кызның күңеле шик-шөбһәләрдән, хәвефләнү катыш җил-кенүләрдән һич кенә дә арынып тормый. Соңгы вакытта төнге йокысы-ның рәте чуалды, йоклый алмыйча азап чигә, йокладымы — төшләр, төшләр... Куандыра торганы да, куркынычы да бар. Кайтса кайтсын иде дә тизрәк үзенең Мәскәвенә китсен иде ул егет. Кичә кич, җыелган залда үзе генә йөргәндә төсмерләп алды кыз: карасана, кай ягы белән-дер Генрих Гейнены искә төшерә түгелме соң ул? Юктыр, юктыр, уйлаганныкы гынадыр, бер күреп алуда кайдан ул чаклы охшашлык-лар тотып калып булсын, ди. Ничек кенә булмасын, кайтсын иде дә, тизрәк үзенең Мәскәвенә олаксын иде. Башка берәүгә дә, әтисенә дә, әнисенә дә, Таһир белән Зөһрәгә дә бернинди дәгъвасы юк Гөлчи-рәнең. Бары тик аны тынычта калдырсыннар да югалган йокысын кире кайтарсыннар, бары шул гына!

Шулай да, кыз күңелендәге шашынулар белән исәпләшмичә, тор-мыш үз юлы белән ага бирә иде. Санаулы көннәр, хәтта артыгы белән дә булса кирәк, үтеп киткән, бер көнне, һич тә исәптә-уйда юк чагын-да, Мөкатдәс Шәйдуллин магазинына ул — соңгы атналарда Шәйдул-линнар өендә зык кубарырга сәбәпче булган мөсафир егет Нагиев килеп керде. Күрәчәккә каршы, ул көнне кибеткә — прилавка артына Гөлчирә дә килеп баскан иде. Әлбәттә, карап кына торырга түгел, сату итәргә.

Гөлчирә һәр вакытта кибеткә сату итәргә килгәндә, әтисенең шулай кушуы буенча, киенеп-ясанып, искерәк модалы булса да калфактан, калфак өстеннән газовый шәл салып, беркадәр сабын кәгазендәге мадоннага охшап килә. Болай киенүне үзе бер дә яратмый, әмма әтисе кушкач ни чара! Кызганычка каршы, бүген дә ул беркадәррәк «сабын кәгазе» иде. Шул хәлендә «Котдус абыйсы»на күренү аны берьюлы куырып ташлады. Хәер, бу озакка сузылмады. Нагиев кыз янынннан, чак кына күз ташлаган булып, кызны оялтмаска тырышудан бигрәк, үзенең уңайсызланганын сиздермәскә тырышкандай ялт кына эчкә — канторка ягына үтте. Нәрсә дә булса әйттеме ул кызга, әллә әйтмичә, исәнләшмичә үк уздымы — кыз хәзер аны аерып хәлдә түгел. Кояшта йөреп бераз карала төшкән, арыган-талчыккан йөзле ул егетнең кыяр-кыймас кына күз сирпеп узуы муенынннан ашкан — кыз шуңардан да бәхетле иде бу минутта.

Анда, эчкәреге бүлмәдә, сүз озын булмады, хәтта утырып та торма-дылар.

— Эшләр ничек тора, Мөкатдәс агам? — диде Нагиев, кыска һәм беркадәр коры итеп.

— Эшләр дип... ни... Тукта, син, әфәндем, һич югы, утырып сөйләш әле.

— Утырып торырга вакытым юк, кичерә күрегез. Утырып торганчы, һич югы, юл тузаннарыннан арынырга, ванна керергә, өс-башны алыш-тырырга кирәк.

Кунагының болай кызу тотуыннан Мөкатдәс беркадәр аптыраштарак калды, ә теге аны юри шул хәлгә төшерергә тырыша, аптыраган кеше-не үзенә кирәклерәк якка юнәлтү ансатрак икәнлеген ул төгәл чамалап эш итә иде. Үзенең болай курт сөйләшүенең сәбәбен әйтеп, акланырга тырышкандай, аннары егет өстәп тә куясы итте:

— Бик озак утырып торырга кушмыйлар, тәкъсир. Мин кайтканчы монда телеграмма көтеп яткан: эшләр, эшләр, понимаете ли...

— Без бит... ни... бездә бераз кунак булырсыз дип өметләнеп торган идек. Хәләл җефетем Гөлсара ханым да, туташ та, тиле кеше әйтмешли...

«Туташ» дигән сүз Нагиевның колагына, әлбәттә, керде, шул ук вакытта телеграмма дип телгә алу, эш күплек белән мактану, Мәскәүдә, имештер, аны түземсезләнеп көтәләр итеп күрсәтү дә кирәк, марканы саклау өчен кирәк иде.

— Монда мин сөйләшәсе кешеләр белән сөйләшеп куйдым.

— Конспирация ягы әйтелгәнчә сакланамы? — дип, тегенең сүзен бүлдерәсе итте Нагиев. «Конспирация» сүзе картка, әлбәттә, бик үк аңлашылмады, бу сүз элеккерәк елларда Шәйдуллин ишеләрнең йөрәгенә таш булып утырган «контрибуция» сүзенәрәк охшавы белән аны беркадәр сагаерга мәҗбүр итте.

— Ни дип... ни инде, ничек сөйләшенгән — шулай эшләнде, мәгәренки без әле алай ашыгыч тотарсыз дип шөйлә дә уйламыйдыр идек. Хатын-кыз ду килеп әзерләнгән булды. — Бик үк бетәшеп маташасы килми Шәйдуллинның да, Мәскәү егетенең маркасы югары булса, Шәйдуллинныкы да юлда аунап ятмый. — Югыйсә, әйттем үзләренә, эш кешесе — эш кешесе, ул бездә атналап ятарга килмәгән. Әгәр ошатып китсә әгәр, күздә тотылган эш тә барып чыкса, менә, алла боерса, икенче килер, мин әйтәм.

Мөкатдәс соңгы сүзләренә аеруча басым ясап әйтте. Хәер, Нагиев та ахмак түгел, картның тел төбендә нәрсә ятканын чамалый, буй җиткән кыз ата-анасы ниләр уйламас. Исәнләшкәндә уңайсызланып, алсу-кызылга манылып, сөрмәле күзләрен кая куярга белмәгәндәй түбән карап, сүзсез калуына караганда, «буй җиткән кыз»ның үзенең дә итәгенә ут капкан булса кирәк, итәгенә генә кабып калган булса әле! Шуңа күрә Нагиев та башны бик югары тотып сөйләшүне килештермәде.

— Мин барысын да, шул җөмләдән туташ, ханымның кунакчыллыгын да бик яхшы аңлыйм, тәшәккөрдән гаҗизмен яхшылыклары өчен. Шулай дип үзләренә җиткерсәгез икән. — Ул тынып, бер мәл уйланып торды. — Впрочем, өс-башны алыштырып, үземне чак кына тәртипкә китергәч, кичкә таба, һәрхәлдә, кеше күзенә чалынмастай вакытны җиткезеп, мин бәлкем сезгә үзем үк сугылырмын әле.

— Бәрәкалла! Минем авыздан чыгасы сүзне әйттең. — Мөкатдәс карт ачыла төште, әле бөтенесе алда икәнлеген чамалау аңарга яңа дәрт өстәде, — без кайтышлый ук шөйлә үзебезгә генә кайтырсыз дип көткән идек. Өебез иркен, күңелебез аннан да болай иркенрәк.

— Яхшы нияттә булуыгыз өчен мең кәррә рәхмәт, тәкъсир, — үз нәүбәтендә Нагиев та тәкәллеф күрсәтү ягыннан провинциаль сәүдәгәрдән калышмый иде,— әмма дә ки, сентиментальлек күрсәтешергә, бер-беребезгә кунакка йөрешергә ашыкмыйк. Онытмыйк: алдыбызда зур эш тора. Безне хәзергә бергә күрмәүләре хәерлерәк. Алда торган эшебезне башкарып чыкканчы дигән сүзем.

Нагиевның бу соңгы сүзе Мөкатдәс картның, ягъни буй җиткән кыз атасының, еракка төбәлгән өметләрен яңадан тергезеп җибәрде — димәк, өзеп үк ташлар исәбе юк, төпле егеттән төпле сүз ишетәм, шөкер ходайга.

— Алайса, кичкә хәтле мин сезне калдырып торам,— диде Нагиев, хәзергә сүзне шуның белән очларга теләгәнлеген аермачык сиздереп, — клиентлар кемнәр һ алар белән кайчан, кайда, кай сәгатьләрдә очрашачагыбызны да кичен уточним.

Мөкатдәс карт та төшеп калганнардан түгел, «калдырып торам!»-ның астында нинди мәгънә ятканлыгын, һич югы, ятарга тиешлеген

чамалый. Бу сүзләрне әйткәндә егетнең күзләрендә бигрәк тә хәтәр бер чаткы җемелдәп калгандай булды. Һәм шундук Мөкатдәс моны үз теленә үзенчә «тәрҗемә итте»: «Син, карт әтәй, канторка дип зурдан кубып атый торган шушы комырыгында утыра тор хәзергә. Буш утыру күңелсез дисәң, әнә счет төймәсе тарткалый утыр: ягъни мәсәлән, теге безнең Кабан төбе дигән эшебез барып чыга калса, аның саф табышы күпме чамасы төшәр икән? Мәскәү, Бельгия кешеләренә дигән өлешен бер якка аерып куй, ягъни безгә — пай керткән Казан татарларына күпме төшә? Менә сиңа шөгыль бу минутларга. Ә шул арада алар — яшь күгәрченнәр — кара-каршы килеп, бер мәл гөлдерәшеп алсыннар. Шаять, «исәнме, саумы?» белән генә калмас аларныкы. Бу Мәскәү тутый кошының канат-каурые бик шома, сүзгә-өнгә дә күршегә керә торганнардан түгел, кызлар белән сөйләшкәндә дә, шәт, авызына су кабып тормас. Минем дөнья күрмәгән куй бәрәне генә ачык авыз булып тормаса....»

Менә шундыйрак уйлар йөгереп узды картның башыннан һәм ул уйлар, чамача, дөреслеккә дә туры килә язды. Нагиев прилавка артында басып торучы Гөлчирә каршына һич тәкәллефсез килеп туктады:

— Сезне, туташ, нәкъ шул элеккеге гүзәл төсегездә күрүемә шатмын, — дип, кызның оялчанлыгы, таркалып калуы белән тамчы да исәпләшмичә, сүз башлады, — бу өяз юлларының тузанын йотып, төбәктән-төбәккә сәяхәт кылып, саранча белән сугышып йөрмешемдә күңелемдә бердәнбер юанычым — ул сез булдыгыз. Менә нишләтте мине сезнең теге көнге күз сирпеп бер карашыгыз, туташ.

Гөлчирә, әлбәттә, тел әйләндереп ни дә әйтә алмады, шул ук вакытта бу купшы сүзләрнең мәгънәсен дөрес шәрехләрлек хәлдә дә түгел, ул тоташы белән ут эчендә, битләре кызышып яна, шул ук вакытта, бу хөррият заманында иске модалы калфак киеп, Мәскәү хәтле Мәскәүдән чыккан чибәр егет алдында сүзсез басып калганлыгы өчен дә җир тишегенә керерлек хәлдә иде. Кызның, нишләргә белмичә, әледән-әле канторка ишеге ягына таба караштыргалавын үзенчә аңлап, егет аны бу бәладән тизрәк коткарасы итте.

— Күрәм, сез, туташкай, әтиегез килеп чыкмагае дип шикләнәсез, аңлашыла торган хәл бу, — Нагиев бу юлы җиргә якынрак килү ягын карады, — мин сезне бу авыр хәлдән коткарам, тик бәләкәй генә бер шартым бар.

Ул тиз генә портфеленә тыгылды, аннан күзнең явын алырлык чуар һәм ефәк зияк белән уралган шоколад тартмасы чыгарды:

— Өч өяздә булып бер җирдән, анда да итәк астыннан гына диярлек таптым, — диде ул, тартманы Гөлчирәнең алдына куеп, — сезнең өчен генә таптым, туташ. Зинһар, шушы бәләкәй бүләгемне, гаеп-кыек итмичә генә кабул итеп алсагыз икән.

Бичара Гөлчирә нәрсә дип әйтергә дә белмәде: аңа бер үк вакытта рәхәт тә, баш әйләндергеч дәрәҗәдә аптыраткыч та иде. Дөрес, китаплардан укыганы бар: бүләк бирешү дөньяда була торган эш, ләкин үзенең моңа хәтле егет-җиләннән затыннан бер бүләк тә алганы юк һәм аның ничек булганын күз алдына да китерә алмый иде. Шулай була икән шул, бирәләр дә китеп баралар икән! Ул аңына килгәндә, Нагиев инде аның каршында юк, кызның нindирәк хәлдә калганлыгын күреп, ул тизрәк ычкыну ягын караган иде.

Ходавәндә! Калды бит кыз шашыну белән хәтәрлек уртасында. Ичмасам, кеше-кара күзе төшкәнче алып тыксын иде берәр яры. Кагылмый да, күзен дә ала алмый тартмадан. Шушындый матур тартма дөньяда булыр икән. «Өч өяздә йөреп бер җирдән сезнең өчен таптым, туташкай!» дигән сүзләре яңгырап калды колакта. Кыскасы, иләсләнгән иде кыз бу минутта.

Хәлбуки, иләсләнерлек әллә ни юк иде монда: «Өч өяздән» дигәне уйлап чыгарылган сүз, «сезнең өчен генә таптым» дигәне дә купшы сүз булганлыктан гына әйтелде, Нагиев бу шоколад тартмасын «Тукта, җае килеп чыкса, әлеге француз коньягы янына ярап куюы бар» дип, Мәскәүдән үк саквояжына тыгып чыккан иде.

## 14

Сабый күңелле түгел диген син аны! Гөлчирә Нагиев кучтәнәч итеп биргән тартмалы шоколадны, кош тоткандай алып кайтып, әнисенә күрсәтте. Хәер, аның куанычы куенына сыймый, кем беләндер бүлешергә кирәк, ә аның — чәче киселгән кызлар янына барып кушыла алмаган, чәче киселмәгән Иске бистә кызларыннан үзен кай ягы беләндер өстен тотучы горур җанлы элекке гимназистканың — сер бүлешердәй бүтән кешесе юк иде.

— Кара әле, әни җаным, моның язуы ук русча түгел, французчамы дип әйтим, — ул бер куйган тартманы яңадан күтәреп килде, укып маташкан булды. Чынлап та, тартма һәм аның пөхтә төрелүе ул елларда бик популяр булган һәм сирәк-сирәк кенә провинциядә дә күренгәләп калган «Моссельпром» тартмаларыннан аерылып тора иде.

Аналы-кызлы шулай юрашып торганда, көндезге чәйгә кайткан атлы булып (башка көннәрдә кайтмаганны) Мөкатдәс тә кайтты, кичкә әлеге егетнең үзләренә киләчәген, итәкне-җиңне җыебрак торырга, бигрәк тә «теге ачык авыз кыз»ны искәртебрәк куярга кирәклекне хатыны Гөлсараның исенә төшереп китте. Бу хәбәрдән Гөлсара аптырап калды, чынлап та, бурычның зурысы куелды бит! Кичнең ерак түгеллеген, киләсе кунакның зур кеше икәнлеген, аның алдында үзеңне ничек тотарга кирәклекне әле теге яктан, әле бу яктан ишарәләп-ишарәләп тә «теге ачык авыз»ның бик алай бизәнергә ашыгуын күрмәгәч, ниһаять, комод өстендә әлегә пичәте дә ертылмаган парфюмерия тартмасына төртеп үк күрсәтергә мәҗбүр булды әнисе.

— Әтиең әллә сиңа уенчык итеп апкайтканмы әнә ул тартманы,— диде, чак кына шелтәләгән тавыш белән,— ничек апкайтып куйган, шулай тора, ачып та карамагансың.

Ә Гөлчирә исә мондый ишарәләрдән югарырак очып йөри, аңарга кичне көтүе бер үк вакытта рәхәт һәм баш әйләндергеч дәрәҗәдә куркыныч иде.

Хәлбуки, кич һич көтмәгәнчә гадәти булып чыкты. Киләсе кунак килде, хуҗа белән икәве өске өйнең кунак залына кереп эчтән бикләнделәр, дәррәү эш турында тотынмас өчен, Нагиев залдагы үзгәрешләргә — идәнгә җәелгән хәтфә келәмгә, шәмаилләр урынына рамнарга куелган мыеклы Буденный белән тузгый чәчле Гейне портретына игътибар иткән булды:

— Сезнең өйдә күзгә ташлана торган үзгәрешләр күрәм һәм һичшиксез прогресс ягына...

Аңа җавабында Мөкатдәс, бик үк шәрәләндерергә ашыкмаса да, колагы бар кеше тотып алырдай итеп әйтте:

— Мин катнашкан эш түгел, кызлы өй көнгә кырык төрлегә әйләнә, — диде игътибар итмәгәндәй. Ләкин шундук өстәмичә дә булдыра алмады: — Без түгел — хатын-кыз халкы, кунак кайтасын белеп, үзләренчә җыйналып торган булуларыдыр инде.

Һәм шушы бер-ике авыз сүздән соң, көнозын канатланып, күкләрдә очынып йөргән кыз онытылып та калды. Нагиев шыпыртрак тавышка күчте һәм шундук үгезне мөгезеннән борып аласы итте.

— Минем сәфәрем бетү алдында, Мәскәүдән телеграмма барлыгы турында көндез исегезгә төшергән идем шикелле. — Ул мөһим сүз

алдыннан әтрафка колак салгандай беравык тынып торды.— Инде сезне тынлыйсы килә: эшләр ничек тора сезнең бу тарафларда?

— Ничек дип әйтим, безнеңчә хуп, сез менә ничек кабул итәрсез тагы?

— Китап сүзләре белән сөйләшүне калдырып торыйк: ничә кеше белән сөйләшенде?

— Ничек сөйләштек, шулай: өч кеше.

— Ышанычлыларммы? Сер саклый алырдай кешеләрме дигән сүзем?

— Җаннарын бирерләр, серләрен бирмәсләр. Иманлы авызым белән шуны гына әйтә алам.

— Шулай булуы нәкъ точкасы, — дип, үзенең бу җаваптан канәгатьләнүен белдерергә ашыкты Нагиев. Ләкин тел төбендә әйтелмәгән сүзе, дөресрәге, соравы калганлыгы күзләреннән үк күренеп тора иде. Тимерне кызуында сугып куясы итте: «Ышанычлыларммы?» дип куйган соравымны, туры әйтүем өчен сез мине гафу итегез, тәкъсир, сез ничектер берьяклырак аңладыгыз. «Ышанычлыларммы?» дигән сорау тиешле авансны бүген соралса — бүген чыгарып бирергә әзерләрме, дигән сүзебез дә. Кабатлауны кирәк тапмыйм, миңа иртәгә булмаса, аның иртәгесеннән дә калмыйча китәргә кирәк.

— Соң, алайса, менә болай итик, бер фараз, ягъни мәсәлән, сез, Котдус әфәндем, мөсафир кеше буларак минем кунагым сыйфатында бездә каласыз, бездә кунасыз. Без карт сөякләр белән мөсахәбә сезнең өчен күңелсез тоелса, аллага шөкер, бездә заман теле белән сөйләшә белүче яшь кеше дә бар. Мин үз вакытында гимназия күргән, аз-маз гына французча да сукалый торган Гөлчирә туташыбызны күздә тотып әйтәм бу сүзләремне.

— Бу әле минем сорауга җавап булмады, — дип, кискен итеп бүлдерәсе итте Нагиев, — мин әлеге өч компаньонның бүген дисәк — бүген тиешле авансны кертергә әзерме-түгелме икәнлекләрен белергә теләр идем.

— Беләсе-нитәсе юк, — хәзер инде Мөкатдәс тә сүзне сузмыйча сөйләшә башлаган иде: «французча сукалый» торган кызы турында ымлавын җавапсыз калдырды бит кунак! — Иртәгә кичкә, телибез икән — нәкъ шушы сәгатьләрдә червонецлары белән минем шушы залда булырлар.

— Монда түгел, миндә. «Амур» мөсафирханәсе, 112 номер. Сүз алып бару өчен анда тынычрак булыр, — дип өзде Нагиев. Аның өзеп әйтүенә болай да каршы килү мөмкин түгел иде, ләкин ул аны соңыннан булса да җайлап-төзәтеп куярга да онытмады:— Бу кунакчыл йортка минем визитлар әле дә җитәрлек булды, киләчәктә дә юл өзелмәс дип уйлыйм. Әлхасил, бер мәртәбә минем дә сезне үз кунагым итеп күрәсем килә.

Я хода! Киләчәкне дә истә тота, имеш, әле бу егет. Болай булгач зык купмый мөмкинме соң! Әйтик, куна калдырырга күндереп тә булмасын, ди. Һич югы, яшелле-зәңгәрле нурлар чәчә торган шушы хрусталь люстра яктылыгында дөньяда юк ризык-нигъмәтләр куеп һәм күпне белә торган бу Мәскәү егете каршына үзенең «французча сукалый» торган Гөлчирәсен дә утыртып, шаулап бер чәй эчмичә, кунакны коры өйдән буш җибәрү татарча булмас! Казанның атаклы бае Мөкатдәс Шәйдуллинның абруена сыймас бу.

Шундый уйлар белән җильякланып, ишекнең келәсен ачканын, тегеяктагыларга:

— Кайсыгыз бар анда? Кайчанга хәтле безне коры өйдә бикләп утыртырсыз икән? — дип тавыш салганлыгын Мөкатдәс үзе дә сизми калды. Кунак тыйнаклык йөзеннән, әлбәттә, каршы килгән булды, урыныннан кузгалып, китәргә җыйналды. Ләкин моның тыйнаклык йөзеннән генә эшләнгәнлеге әллә кайдан сизелеп тора, чәй өчен әллә ни исе

китмәсә дә, көндезге булактән соң кыргый кызның үзен ничегрәк тотуын егетнең бик тә күрәсе килә иде. Башка якларга да күзе очлы бу Мәскәү мишәренең, кызлар тану ягына килгәндә дә йөрәге йоклап ятмый, исәбе үзе белән иде: Кабан төбеннән табылачак алтын миф тә булсын, ә ул Гөлчирә дигәннәре миф түгел ләбаса! Ник, әйтик, бу яктан да бәхетне бер сынап карамаска икән?!

Ләкин эш Нагиев уйлаганча килеп чыкмады. Хәтта кызның әтиәнисе корган план буенча да килеп чыкмады. Гөлчирә, әнисенә булышып, табын әзерләшкәндә кунак абыйсы белән артык очынмыйча гына исәнләште, тегенең сорауларына бер сүз, ике сүз белән генә җавап кайтаргалады, күз сирпеп бер карап алды — нәрсә генә аңлатасың бу бер караштан! Ә табынга утырып чәй эчә калырга уңайсызланды, никадәр кыстасалар да, хәтта кунак егет аның укымышлылыгына, гимназия күргән кеше икәнлегенә киная белән, «Сезнең кебек просвещенный туташкамы? Килешми мондый пассаж!» дип караса да, утырта алмадылар. Соңыннан, бер чыкканда, әнисе шелтә белдергәч, һич боргаланмыйча, туп-турысын әйтте дә салды кыз:

— Ничек утырыйм, үзегез «ир-ат арасында чәч-баш туздырып күренү килешми» дип гел тукып торасыз, ә мин андый олы җирдән килгән яшь кеше алдында абыстайлар кебек яулык бөркәнеп утырырга теләмим, — диде. Моңа хәтле гел карусызлык күрсәтеп, әти-әнисенең һәр әйткәнен тел кайтармыйча кабул итә килгән кызының болай ачык сөйләшә башлавы әни кешегә, әлбәттә, уйланырлык сәбәп иде. Тик кай арада монда уйланыр вакыт: теге өйдә шундый зур өметләр баглаган кунагың утырганда.

Бу утыруда нечкә билле рюмкаларны кузгатмадылар, хәтта «Каюм хәлфә» методын да кулланып тормадылар. Чөнки эш җитди, көннәр санаулы калган, һәркайсы вакытны үзенчә ныграк отып калырга чамалый иде. «Компаньоннар»ның ниндирәк кешеләр икәнлеген, иң әһәмиятлесе, сер саклый белү ягыннан таш кебек телсез булырга тиешлекләрен, бер үк вакытта чека кешеләренең дә, әлбәттә, йоклап ятмаячакларын кунак янә бер кат «Мөкатдәс әфәнде»нең исенә төшергәч, мондагылар үз нәүбәтләрендә кунак егетне сораулар белән күмәргә тотындылар. Әлбәттә, турыдан бәреп түгел, кыеклап-кыеклап кына: янәсе, әти-әниләре исән-саулармы? Кайда, нинди кәсеп белән көн итмәктәләр? Мәскәүдә тормыш яклары ничек? Егетнең тора торган җире? Сүз дә юк, безнең мондагы кебек утын белән ягылып чиләнә торган түгелдер инде? Суы да үзенә үк киләмени? Җан рәхәте, безнең мондагы кебек фонталда чират торасы түгел икән! Шундый зур өйдә ялгыз баш яшәү, шик-шөбһә юк, ансат түгелдер һәм башка, һәм башка кыек атып туры тидерергә маташулар...

Сорауларның шулай күплегеннән һәм аларның кай юнәлештә куера баруыннан Нагиев үзе дә, әлбәттә, сизенеп утыра: тикмә түгел бу, карт белән аның хатыны кавалерны ошаттылар, җае чыкканда ничек тә кызларын сылыйсылары килә. Ул арада егетнең бөтен сорауларга күңелгә хуш килердәй җавап биреп торуыннан, исерткеч эчмичә дә сәрхушлана төшкән Мөкатдәс кинәт, гадәттәгечә сатулашып торырга һич урын калдырмыйча, хатыны Гөлсараны тыкырдатырга тотынды:

— Бар әле, анасы, алып кер шул дики кызны, әйтәсе сүзем бар барыбыз бергә чакта. — Хатыны чыгып киткәч, сер итеп кенә әйткәндәй, дәвам итте: — Нишләтәсең, артык оялчан бала булып чыкты, кызыбыз Гөлчирәне әйтәм... Әнисе дә шулай иде кыз чагында, зарланыр хәлем юк, гамәленә ярады тагы.

Мөкатдәс үзен ат базарындагычарак тота башлаган иде, ярый әле, кызы белән хатыны килеп керде. Гөлчирә ялгыз үзе генә чакта барысын да уйлаган булса кирәк, аннан килеп, «дики» дип нихәтле генә яман атын сатмасыннар, аның да «леп-леп» тибеп торган йөрәге бар,

шулай ук күзе дә бар: бу Мәскәү егете ошый аңарга, ошый. Хәер, кирәк чагында әйтер сүзен әйтә ала торган теле дә бар икән.

— Минем кемгә кирәгем чыкты икән тагы? Курка калдым кинәт, — диде ул, бу юлы инде кунак егеткә туп-туры карап. Аның бу карашында тәкәббер чаялык чаткысы чагылып узды — үз бәһасен белгән, ләкин күңеле купшынган кызларда гына кузгала мондый чая тәкәбберлек.

Бөтенесен алдан күреп, әзерләп куйган булган икән хәйләкәр карт. Кызына артык сүз куертырга ирек бирмәде, кулыннан житәкләп диярлек, люстра яктысына табарак алып килде. «Менә ул! Минем товар менә шушы!» дигән кыяфәт белән Нагиевка бер карап алды, аннары, бөтенесе дә аптырабрак калган бер минутта, кесәсеннән йомшак ак кәгазьгә төрелгән нәрсә чыгарды. Кәгазен фокусникларча тизлек белән атып бәрде, люстра яктысында алтын портсигар ялтырап күренде.

— Мә, кызым, үз кулың белән бир бүләгеңне абыеңа, — ул үзе уйлап чыгарган бу тамашадан әйтеп бетергесез канәгать, кинәт яшәреп киткәндәй күренә иде,— бүләккә каршы бүләк. Абыең бүләк алып кайткан сиңа, инде менә абыеңа син бүләк ит. Юкса, хәйләкәр хәзерге яшь-жилкенчәк, шундый келтерифутлы эшне дә әтисе жилкәсенә качып эшләмәкче...

Тагын теле югалды Гөлчирә бичараның. Ул соңгы чиккә житеп аптырады, бит алмалары алсу-кызыллыкка манылды, кемгә күтәрелеп карарга да белми, шул ук вакытта күңеленнән әнисенә карата «әтигә шуны да житкергән икән!» дигән рәнжүле уй да узды. Кыскасы, күбәләктәй килеп керде янгынга, әллә портсигар кулны яндыра, әллә кул портсигарны?..

— Рәхим итеп... Мөмкин булса, гаепләмичә, — дигән сүзләрне көчкә-көчкә генә әвәләп, бүләкне егеткә сузды ул. Аңарга тизрәк котылырга, гомумән, күздән югалырга кирәк иде. Тик Мәскәү егете аның кулын бер тотып алгач жибәрмичә торды. Мәскәү егете дә төшеп калганнардан түгел, кулга берьюлы мондый зур хәзинә: кыз һәм алтын портсигар килеп эләккәч, тиз генә ычкындырырга теләми иде.

Ләкин һәр рәхәтлекнең бер чиге бар, сөйләшә һәм чәйли торгач байтак вакыт узган, кузгалырга вакыт житкәнлеген белдереп, егеткә жилет кесәсеннән алтын сәгатен чыгарып күрсәтергә янә бер форсат булды. Куна калырга бик кыстасалар да, риза булмады, иртән наркоматка барасы барлыгын һәм башка сылтаулар табып, бүгенгә саубуллашып торуны тиеш тапты. Гөлчирә башта, әлеге портсигар бүләк итү минутларында, көтелмәгән бу хәлдән уңайсызланып, тизрәк күздән югалу ягын караса да, кулы егетнең учында бер мәл эреп чykканнан соң, кыюлык алды, сүзгә бик үк катнашмыйчарак кына шул тирәдә чуала, олылар әвәрә килгән арада егет белән сөйкемле генә карашып алырга да өлгерә иде.

Сюрприз артыннан сюрприз һәм һич көтмәгәндә. Башка вакытта кызына карата мондый «хөррияте» һич рөхсәт итмәгән иске фикерле Мөкатдәс карт, кунак китәргә дип ишек төбенә килгәч:

— Булмаса, бар, кызым, абыеңны Мәскәвски чатына хәтле озатып куй. Чит шәһәр кешесе, буталып йөрүе бар, — дип әйтеп ташламасынмы!

— Әй, ошамаганны сөйләп торган булмасана, — дип, Гөлсара каршы төште бу сүзгә. Ә кызлары Гөлчирәгә килгәндә, ул бичара оятыннан сүз әйтерлек дәрәҗәдә түгел, киреләнгән баладай аркасы белән үк борылган иде.

— Сез, Мөкатдәс әфәнде, бигрәк... туташны уңайсыз хәлгә куйдыгыз,— дигән булды Нагиев, тынычландырырга тырышкандай кызга якыная төшеп, — кинога билет алып, иртәгә кичкә мин аны үзем алмага килсәм... Сез каршы килмәссез бит, Гөлчирә туташ?

Туташ бер сүз дә дәшмәде, туташ сүз дәшерлек хәлдә түгел иде.

— Әссөкүте галәмәте-риза дигән сүз бар түгелме? — дип, нишләптер гарәпчәләтеп, кызның әтисенә мөрәҗәгать итте егет. Һәм житди тонга күчеп өстәде: — На всякий случай, без теге әфәнделәр белән очрашуны бераз алгарак, әйтик, сәгать алтыга күчерик.

Болар үзара ым белән генә аңлаштылар, ә кыз-хатынның бу эштә аңламый калуы хәерлерәк иде.

Кунак китте, олы люстраны шундук сүндерделәр, табын җыю өчен бәләкәй лампочка яктысы да бик житкән иде. Аннары, табын җыелып беткәч, олылар йокларга яттылар, үз бүлмәсенә кереп, Гөлчирә дә йокларга ятты. Әмма әйтергә генә ансат — йокларга мөмкинме соң шундый-шундый хәлләрдән соң? Бигрәк тә иртәгә, әгәр әйткән сүзе чын булып, кинога алмага килүен көткәндә! Ходавәндә, кешеләрнең күңелләрендә, кемдә күпмедер, мәкер яшеренгән, бәлки бөтен дөньясы мәкер белән тулгандыр, әмма Мало-мещанский урамында яшәүче Гөлчирә атлы кызда, мәсәлән, тамчы хәтле дә мәкер юк: ул иртәгә аның белән кинога барачак!

## 15

Иртәгесен Мөкатдәс тирече Хәмзәгә дә, Сукконный Ясәвигә дә үзе барып, колакларына гына пышылдап килде: ягъни очрашу урыны «Амур» мөсафирханәсе, йөз дә уникенче номер, кич 6 сәгатьтә һәм һич шау-шусыз. Алай-болай дежурный-мазар кызыксына калса, җавап кыска һәм каушаусыз булырга тиеш: «Без чакырулы!» Алда торган очрашуга үтә мөһим төс бирергә тырышып булса кирәк, бу чаклысын үзеннән уйлап чыгарып:

— Шефның әмере шулай! — дип тә өстәде. (Әңгәмәләрнең берсе вакытында Нагиев, янәсе-имеш, чит ил илчелегендәге танышына карата «шеф», «минем шефым!» кебек сүзләр ычкындыргалаган һәм бу сүз Мөкатдәскә бик тә ошап, хәтеренә сеңеп калган иде.) Әлбәттә, тегеләрнең буш кесә белән килергә тиеш түгеллекләре янә бер кат искәртелде.

«Кунаклар», эш кешеләре буларак, төгәл үз вакытында җыелдылар. Нагиев та беренче очрашучы тәвәккәл казанлыларны коры бүлмәгә түгел, кайнар пәрәмәч, сумса һәм кондитер әйберләре, олылы-кечеле чәй чәйнекләре куйдырып, өстәл әзерләтеп каршылады. Алай-болай кирәк-ярагы чыга калса дип, Депре коньягын да якынгарак чыгарып куйган иде.

«Кунаклар», олылы да кечеле, өчесе берьюлы дәррәү килеп керделәр һәм, сәлам бирергәме икән, кирәк түгелме икән, дигәндәй тиз генә берберенә карашып алдылар. Хәер, укымышлы яшь егет бу якка алай талымлы түгел икән, «Сәлам биреп керегез!» дип тегеләрне кире борып чыгармады, андый тәкәллефкә бөтенләй дә игътибарсыз калды.

— Хуш килдегез, мәрхабә, — дип, ачык йөз белән каршылады ул кунакларын. Ләкин шул «мәрхабә»ләр рәтеннән үк, тавышына яшертен серлелек төсмере чыгарып: — Швейцар вә дежурный ханым өстәле яныннан шома гына уздыгызмы? Кая, кемгә килүегез белән кызыксынучы булмадымы? — дип сорау куярга да онытмады. Аллага шөкер, алай кызыксынучы булмаган икән, димәк, һич тәкәллефсез, эш кешеләренә хас рәвештә, түгәрәк өстәл кырына якынрак килеп утырырга да мөмкин. Тирече Хәмзә, татарның бетмәс-төкәнмәс гадәт-йолаларына бирелгән адәм буларак, урындыкка килеп утыру белән, «я, алайса, йортка бер дога!» дип учын авыз тирәсенә китерә башлаган иде дә, аның бу тәкъдимен хуплап алучы бик күренмәгәч, күтәрелгән кулын буш төшермәс өчен шундук түш кесәсенә тыгылып, аннан канәфер

шешәчеген тартып чыгарды. Бер канәферне сак кына учына кагып төшерде, шундук кабып җибәрергә дә өлгерде.

— Ризыктан олы нәрсә юк, иң элек ризыктан тәнәүвел кылыйк, — дип сөйләнә-сөйләнә, аш-су өстенә ябылган газетаны тартып алды Нагиев. Ул хәйләкәр төлке барысын да җиренә җиткереп, бу диндар татарларның күңелләренә хуш килсен өченгә, Галимҗан хәзрәт мәдрәсәсендә укыган чагында ук күңеленә сеңеп калган гарәп сүзләре кыстыргалап җибәрә иде. Чәйнектәге чәй кайнар сакланган иде, аны тагын да «кайнарлый» төшү өчен Депре коньягы да чыкты.

— Мөкатдәс әфәнде, сез ничек карыйсыз, әгәр Каюм хәлфә дозасында гына кушып җибәрсәк? — дип, арада өлкәнрәк кеше булганлыктан, Мөкатдәскә мөрәҗәгать итте хуҗа. Каршылык күрсәтүче булмады. Тик ялангач хатын-кыз сурәте күрсә тәкатен җуя торган Суконный Ясәви генә, коньяк савыты этикеткасындагы шәрә тәнне күреп:

— Әллә-лә-лә, төшерә белгәннәр нәмәхрәмне... безнең җирдәге шомлык түгелдер бу, — дип сузып куйды һәм үзенең бу тәкатьсезлегеннән үзе үк, намаз укыганда күршесенә ишетелерлек итеп тәһарәте бозылган хак мөселмандай, кызарып-уңайсызланып калды. Аның каравы, Ясәвинең бу кызыксынуы Нагиевка элек чит илдән килгән коньягы, аннары үзенең гомумән абруйлы элемтәләре белән чамача гына бер мактанып алырга сәбәп булып чыкты. Булдыра алганча әдәплелек күрсәтергә тырышып, «пирәшләп» алдылар, күңелләр күтәрелә, телләр ачыла төште. Тиречe Хәмзәнең әдәплелек «нормасы» хәтта шуның белән бөтенләй очланды булса кирәк, бер мәл кызарынып-бүртенеп, берни дә ашамыйча утырганнан соң:

— Кара әле, кем, исемеңне оныттым, теге нечкә билле вәсвәсә авызыннан тамган кәүсәр суы тәнгә бик сихәт булып китте... Чәй белән бутамыйча, үзен генә бер тәмләп карыймчы шуны, — дип соранырга тотынуын да сизми калды.

Кыскасы, утыра торгач яхшы ук кәефләнә төштеләр, бөтенләй тугарылганчы сүзгә керешергә бик вакыт иде.

— Алда торган эшнең төп аслы белән Мөкатдәс әфәнде сезне таныштыргандыр дип уйлыйм, — Нагиев булдыра алганча эшем кешесечә күренергә тырышып, кыска, ләкин житкезә торган итеп сөйләшергә тырыша иде. — Хәзер безнең бурыч, безнең изге бурыч дияр идем мин, шау-шусыз гына һәм мөмкин чаклы тизлек белән шуны гамәлгә ашыру. Ни өчен изге дип кызыксынучы булса, яшерми-нитми әйтәм: алтын вә көмеш кебек затлы мәгъдәннәрнең бер вакытта да, бер халык өчен дә изге булудан туктаганы юк, шуны белеп торыгыз, әфәнделәр. Ул асыл мәгъдәннәр шулай ук большевиклар өчен дә изге. Изге булмаса соң, Кремльдә утыручы зур башлы абзыйларыбыз, мәсәлән, алты процентлы отышлы алтын заемы дигән нәрсә уйлап чыгарырлар идеме? Вә дәхи аны халык арасында мөмкин хәтле күбрәк таратып, алтынны халык кесәсеннән Мәскәү банкысының подвалларына күчерү максаты белән газета битләре саен менә мондый агитация вә пропаганда эше алып барырлар идеме?

Ул табын өстеннән читкә алып ташланган, ләкин чын дөреслектә алдан ук шулай хәзерләнеп куелган, үз вакытында Мөкатдәс картка инде бер укып күрсәтелгән игъланны кычкырып укыды. Һәм, әйтергә кирәк, авыз эчендә бутка пешерүче кайбер артистларыннан болайрак укыды. Башка яклары белән бергә, аның сөйли белү, ораторлык куәсе дә бар икән. Күрәсең, бу сәләтен үзе дә белә, әгәр теләсә, такыр башлы бу өч татарны бармагы тирәсендә әйләндереп йөртәчәк... Тегеләрнең ул сөйләгән сүзләрдән авызлары ачыла барган саен, Нагиевның чаялыгы, үз көченә ышануы арткannan-арта барды — башта купшыланып, теләр-теләмәс кенә тотынган егет хәзер инде туктый алмый, үзе эчен-

нән генә уйлый: кара инде бу диваналарны, үзләре дә сизмәстән, авызга керә баралар, керә баралар...

Бер кызып киткәч, урынлымы-урынсызмы — ул хәтлесе белән исәпләшеп тормастан, «Кисекбаш»тан нәкъ әнә шул баш әйләндергеч Кабан һәм аның төбендә качып ятучы «кып-кызыл алтын шәһәр, җиз карьялар» белән бәйләнешле урыннарын (дөресен генә әйткәндә, инде күп мәртәбәләр укып, ятлап, үзе дә ничектер ышангандай булып, башкаларны да ышандыра алачагына иман беркеткән урыннарын!) зур эчке пафос белән сөйләп чыкмыйча тыела алмады.

— Баягынак мин «изге бурычыбыз» дидем, арырак, кирәк булса, тагы әйтермен, — ул чәй чынаягына иренен тидерде, ишарә белән генә кунакларына да ашый-эчә утырырга ымлады, «кирәк тапкан кешегә чәй белән бутамыйча да мөмкин» дигәндәй, ялангач кызлы француз коньягын өстәлгә үк чыгарып утыртты. Үзе, бу минутларда андый фани эшләрдән күп өстен торганлыкны күрсәтергә тырышкандай, кайнарланып нотыгын дәвам иттерде:— Әйе, кирәк булса тагын әйтермен һәм әйтәм дә: безнең газиз бабаларыбыз, үз җирләренең, үз суларының чын хуҗасы булган фидакарь бабаларыбыз якага хәтәрлек килеп ябышканда да хәләл мал-мөлкәтләрен патшага калдырмас өчен милли Казаныбызның милли Кабанына ташлаганнар икән, я хода, без, хөрмәтле тәкъсирләр, шул мәгърур бабаларыбызның дошманга калдырмас өчен күл төбенә ташланган байлыклары Мәскәү банкысына, большевиклар банкысына күчерелгәнне кул кушырып карап торыйкмы? Әлегә соң түгел, әлегә большевикларның күл төбенә чумардай чамалары юк, аларның җирдәге эшләре дә җиткән, форсатны ганимәт белик, мөселман кардәшләр! Мин моны сезгә ышанычлы чыганакларга таянып әйтәм һәм ул «ышанычлы чыганаклар»ның безнең бу тәвәккәллегебезне һәр даим яклаячакларына, махсус киендерелгән, махсус кораллар белән коралландырылган аквалангистлары белән ярдәмгә килергә әзер торуларын күздә тотып әйтәм. Ниһаять, мин, әлбәттә, монда утыручы бу өч каһарман ирнең алда торган эшебезне, җитди вә шанлы-шәүкәтле эшебезне башкарып чыгуда сак вә дәхи киң күңелле булуларына зур ышаныч белән әйтәм. Чын ихластан инанганым хәлдә, хәтта шуны да әйтергә җөрьәт итәм: Казан хәтле Казан шәһәреннән бу тәвәккәллеккә бары тик өч кенә кеше, өч фидакарь ир генә сайланып алынган икән, моның кадерен белик, ир йөрәкле булыйк, әфәнделәр. Безнеңме тамырларыбызда горур җанлы бабаларыбызның каны акмый, безме аларның лаек варислары түгел?

Шактый кызмага бирелеп әйтелгән бу кайнар нотыкның азагы, ахыр чиктә, алдан ук әйтелгән егерме червонецны чыгарырга вакыт җиткәнлекне ишарәләү белән беткәч, тиречә Хәмзә белән Суконный Ясәви бердән сагаеп тирән сулап куйдылар. Гомумән алганда, аларга бу Мәскәү егете үзе дә, сөйләгән нотыгы да, бигрәк тә алып килгән күчтәнәче Депре коньягы да ошады, алда торган хикмәтле эш тә хыялларын кытыклый иде. Тиречә Хәмзә үз нәүбәтендә «минем Зөһрә шәүлеген төшергән алтын беләзекне генә табып алып чыксалар да....» дип тә уйлап куйды. Шулай да үз кулың белән кесәдән берьюлы егерме червонецны чыгарып салу, ай-һай ла, берсе өчен дә җиңел түгел иде.

Арада из тәвәккәле Мөкатдәс карт булды (хәер, белгәнебезчә, бу тәвәккәллекнең астында яшеренеп яткан сәбәпләр дә юк түгел иде):

— Шундый һимматле эшкә, бабаларыбыз калдырган васыятьне үтәү эшенә мал түгел, җан фида! — дип, катышлы шом белән, алдан ук санап-әзерләнеп куйган егерме банкнотны кесәсеннән чыгарып, Нагиевның алдына китереп салды ул. Инде чират тегеләрнең икәвенә терәлеп калды.

— Йә, Ясәви кода, кашына башла, — дип, терсәге белән җиңелчә генә Ясәвигә төртте тиречә Хәмзә. Үзе кашынырга бик үк ашыкмый,

түш кесәсеннән канәфер шешәсен тартып чыгарырга маташкан булып кылана иде.

— Ә үзең... ә үзең, — дип авыз эченнән мыгырданды Ясәви.

— Күрмисеңмени кулым буш түгеллекне, — Хәмзә кодасы белән каты сөйләшә һәм аның Ясәвине «кашындырмыйча» үзенең янчык чыгарып чамасы сизелми иде, — алай мәхәлләдән узып оҗмахка керергә маташсаң, мин теге... ни.. Мәрүсә апаң белән итче Гыймади мунчасыннан чыкканыңны Хәсбиҗамал сеңелгә җиткерергә дә күп алмам.

Күрәсең, бу — Ясәвинең иң нечкә җире иде булса кирәк, кодасына күзенең агы белән бер карап алды да:

— Син инде гел шулай... Үзең карунның каруны, кеше кесәсеннән тарттыруны чүпкә дә санамыйсың, — дип сукрана-сукрана, куен кесәсеннән бумажнигын чыгарды. Әлбәттә, сорала торган егерме червонецны алдан берничә кат санап, санаган саен ныграк әрнеп, ул да алдан әзерләп килгән, әмма монда, кешеләр алдында, бармак очларына төкергәләп, янә бер кат санамыйча ычкындырырга ашыкмады.

Бу минутларда тирече Хәмзә, теш арасындагы канәферне суыргалап, бик канәгать бер кыяфәт белән эндәшмичәрәк утыру ягын карады, хәтта күңелендә «шулай узмасмы?» дигән фетнә дә кузгала башлаган иде. Әмма эшне башлап йөрүчеләрнең берсе, яше һәм байлыгы ягыннан да арада иң өлкәне буларак, Мөкатдәс карт аны уянырга мәҗбүр итте.

— Ник болай сөхбәткә киттең, Хәмзә туган? Мәҗлестәгеләр арасыннан беренче булып оҗмахны искә төшерүче син булдың, үзең кермичә ишек төбендә посып калырга ниятләмәгәнсеңдер бит?

— Ә... минмени? Миңа да чират килеп җиттемени? — Хәмзә йокысыннан яңа уянган кешедәй сискәнеп куйгандай итте. Шулай да кесәсенә тыгылырга ашыкканлыгы күренми. Һич югы, башны диванга салып, вакытны ничек тә сузарга маташа иде,— монда безнең, кадерле мөселман кардәшләр, болай да шактый җыелды, бәлкем, мәйтәм, мин соңыннанрак бирермен, эшкә тотынгачрак, алла насыйп итсә.

— Коръән үбеп керешкән изге эшкә тиешле өлешеңне кертмичә алла исемен телгә аласы булма, — диде Мөкатдәс кырыс кына. Һәм тагын да кырысрак итеп тегенең исенә төшерәсе итте:

— Коръән үбеп ант итүнең нә икәнлеген, шәт, беләсеңдер. Ике иңбашындагы ике фәрештә бөтенесен дә теркәп баралар. Мөкатдәс абзаңны санга да сукмадың, ди.

— Коръәнгә тимә, коръән безнең фани эшләрдән югары тора,— дип, үз нәүбәтендә Мөкатдәснең үзеннән дә корырак итеп җавап кайтарды Хәмзә һәм, әлбәттә, бумажнигын чыгарырга мәҗбүр булды. Үзе червонецларны берәмтекләп саный, үзе авыз эченнән бутка пешерә: — Бу тиклем акчаны... бернинди распискасыз дигәндәй... Дөрес, ике иңбашымда ике фәрештә утыра, но бит акчаны фәрештә бирми, мин бирәм.

Наразыйлык катнаш уен-көлкеле күренергә тырышып, бик тә вәзенләп санады ул,унбишне санады, уналтыны, унҗиде, унсигез, ниһаять, унтугызны... һәм кинәт шаккаткандай булып, табындагыларга күтәрелеп карады:

— Бакчы, берәү чыкмый бит минем монда. Нәкъ егермене санап тыккан шикелле нем, менә син хикмәт.

— Яхшылап кара бумажнигыңны, берәр бүлемендә кысылып калмаганмы? — дип, чын-чынлап ышанып, кодасына ярдәмгә килергә ашыкты Ясәви.

— Нибары ике бүлеме бар бумажникның, менә, ышанмасагыз үзегез карагыз, — Хәмзә, бәрән тиресе селеккән кебек, шап-шоп сугып, бумажнигының эчке бүлемнәренә хәтле ачып, табындагыларга күрсәтте. Аннары ялварулы тавыш белән Мөкатдәскә иңәлде:— Син бай абзый

аягына килеп егылырга туры килә бу яктан да. Биреп тор, Мөкатдәс абзыкаем, минем өчен. Җәлләмә бер червонецка калгач.

Нагиев бу сатулашуларны, акча санаганда, бигрәк тә акчаны распискасыз-нисез «общий котел»га сузганда кулларның ничек калтырауларын күреп тора, ләкин күрмәгәнгә, игътибар итмәгәнгә салыша. Янәсе, аның кесәсенә керәсе акчамы әллә? Эш башлап җибәрү өчен, Бельгия белгечләрен китерү өчен, бүген-бер кул белән бирсәләр, күпмедер вакыттан соң ике кул, хәтта кочак белән үзләре көрәп алачаклар.

Шул исе китмәгәнлекне күрсәтү өчен, җыеласы акча җыелып беткәннән соң да ул кабаланып акчага ташланмады, червонецлар өстәл өстендә өелеп ята бирде, хуҗа кунакларны ашый-эчә утырырга кыставын дәвам итте. Ләкин табында шул хәтле акча өелеп ятканда һәм ул акчаларны кесәдән чыгарганда «өзелеп калган бәгырь» урыннары әле һаман сызланып торганда, берсенең дә ашау-эчү әйберләренә карыйсы килми иде. Шуны сизеп, Нагиев, бик комсызлык күрсәтмичә генә, туплаңган «мая»ны җыештырып алырга булды.

— Сезнең рөхсәтегез белән, хөрмәтле әфәнделәр, һәм уйланылган эшебезнең шик-шөбһәсез барып чыгачагына камил ышанганым хәлдә,— дигән тәкәллефле сүзләр белән тотынды ул тотынганда,— алайса, бу сәрмаяны мин алып тыгармындыр. Кемнең дә булса күңеленә шикшөбһә килә калса, рәхим итеп, минем Мәскәү адресымны блокнотыгызга язып алыгыз, сезне кунагым итеп каршыларга һәр вакыт әзермен.— Ул булачак кунаклары өчен алдан ук куаныч белдергән тантаналы кыяфәт белән, сүзләрнең иҗекләрен өзек-өзек әйтеп бирергә тырышты: Москва, улица Трубадуров, 30, квартира 56. Ишегалдындагы флигельдә торам. Бөтен флигелендә берүзем диярлек, урын җитәрлек.

Шик белдереп кара шундый төгәллектән соң! Аннары үзенең, чит ил аквалангистлары белән кайчанрак киләчәген, әлбәттә, айның тулы, төннең якты вакытында түгел, айның бетеп, төннәрнең караңгыланып торган чагын чамаларга туры киләчәген дә искә төшерергә онытмады.

Барысы да — телдән әйткәне телдән, телдән әйтергә ашыкмаганы күңеленнән «Бәрәкә-алла! Бирсен ходай!» дип аяк-өс калыктылар. Нагиев, «күрмәгәннәр күреп калсын!» дигәндәй, жилет кесәсеннән алтын сәгатен чыгарды. Моның нәрсәгә ишарә икәнлеген кунаклар, әлбәттә, чамаладылар. Мөкатдәс карт, бигрәк тә алтын сәгатьле егет үзе бу ишарәнең нигә икәнлеген ачык белә́ләр иде.

## 16

Беренче экранлы «Электро» кинотеатрында «Мисс Менд» исемле күп серияле маҗаралы фильм бара иде. Чират торса озакка китәчәген уйлап, ул шул тирәдә чуалучы спекулянт малайлардан ике бәя түләп, сигездә башлана торган сеанска ике билет «кулга төшерде». Гомумән, ул эшне шулай яшертен йөртә белүчеләрне өстен күрә, андыйлардан үзе теләп, хәтта беркадәр ләззәтләнү тойгысы белән алданырга да әзер иде. Үзе дә, әлбәттә, бурычлы булып калмый, ләкин вак җимгә ташланмый, була икән — аңарга чәчләрне үрә торгызырлык авантюра булсын.

Ләкин шулай да киногa керә алмадылар. Проломныйдан Маломещанскийга хәтле барасы бар. Сиңа кирәктә генә атлы экипажы да туры килеп тормый, тыр-тыр йөгерүне егет натурасы күтәрми, җәяүләп булса да кыяфәт саклап, Болак артының үз вак-төякләреннән ничектер аерылыбрак, үзен күрсәтә төшебрәк бара торгач, моңа да байтак вакыт китте. Телне аркылы тешләп сабырлык күрсәтергә мәҗбүр иткәне бигрәк тә туташ үзе булды. Болай ачыктан-ачык күренеп тора:

шундый кавалер билет тотып алмага килгәнгә Гөлчирәнең башы күктә, ләкин моңа хәтле мондый эш булмаганлыктан, әти-әниләреннән уңайсызлана, үз икеләнүләре дә юк түгел иде. Ничек кирәк алай алып чыгып китеп, Мало-мещанскийдан кире Проломныйга барып житкәнче сәгать тугызынчы ярты булган, сеанс әллә кайчан башланган, Нагиев кыз алдында ишек төбендәгеләргә ялынып торуны кирәк тапмады. Билетларны шундук урталай ертты да:

— Мәгез, ертылган жирен ябыштырыгыз да алдагы сеанска бирәр ачык авызга сатарсыз,— дип, билетершаларның өстенә атып, чыгып китү ягын карады.

— Безнең бәхетле кичебезнең беренче адымнары уңышлы чыкмады. Моның сәбәпләре кемдә икәнлеген тикшереп тормастан, мин сезнең алда түбәнчелек белән гафу үтенәм, туташ, — дип сөйләнде Нагиев, Гөлчирәнең култыгыннан алып. Кыз ни дип тә сүз кайтармады. Киного керә алмауга да, егетнең нәзакәтле күренергә тырышып янында сайрап баруына да, шушы ук нәзакәтле егетнең ертылган билетларны тупас рәвештә билетершаларның өстенә ыргытып китүенә дә — берсенә дә, берсенә дә исе китми, ник шунда бер читеннән дөньясы ук жимерелә башламый. Бу минутларда кызга әйтеп бетергесез рәхәт, кызыклы һәм, бер үк вакытта, чак-чак кына хәвефле дә иде. Моңарчы кузгалмыйча тынып яткан эчке дөньясы берьюлы кузгалганлыктанмы, бичараның уттай януы тышка ук сизелә, бу яктан алганда да дөнья күргән тәжрибәле Нагиев шулай да туташның кызуында эреп китәргә ашыкмый, кулына эләккән яки эләгергә торган бу нәфис кошны куркытып очырып жибәрмәгәем дип шикләнә иде.

— Мин хәзер сезне өегезгә кире илтеп куярга да могу, — дип куйды Нагиев, сүзсез баручы Гөлчирәне ничек тә «телгә» китерергә тырышып, — өйдәгеләрегез «ник болай тиз әйләнеп кайттыгыз?» дип сорасалар, җавабыгыз әзерме, туташ?

Туташ акылы белән бер нәрсәгә дә әзер түгел, әмма берьюлы котырып кузгалган хисләре белән, бу егет кая барырга кушса, шунда барырга әзер иде.

— Иртә дип әйтсәк, «Чаткы» бакчасында чак кына утырып торырбыз соң, — диде, ниһаять, кыз. Әйтмәгез, туташның теле бар икән. Нагиевның аеруча игътибар иткәне — туташ алай бик тиз өйгә кайтып китәргә дә ашыкмый, хәтта бакчада утырып торырга да риза. Әллә бераз батырая төшкәндә дә ярармы икән? Соравына җавап эзләп тормастан, егет кызның ялангач беләген кыса төште, шул уңайдан, әлбәттә ялгыш кына кагылып киткәндәй итеп, кулының аркасы белән генә күкрәгенә дә кагылды. Кыз тартылды, тетрәнеп куйгандай итте, ләкин куркып очып китмәде, хәтта «кулыгызны алыгыз» дип тә әйтмәде. Тәжрибәле Нагиев моны шулай ук эченнән генә мыегына урап куйды: «Алай икән! Без алай кеше куркытырлык кыяфәтсезләрдән түгел шул!» — аңарда эчке тәкәбберлеге уянды, шуның белән рәттән үк, әлегә өскә бәреп чыгарга базмыйчарак, ирлек комсызлыгы үзен сиздерә бара иде. Көнгә эңгер-меңгер инде, элекке Икенче гимназия бинасы янындагы тар күперне узып Болакның бу ягына чыктылар, урамда кешеләр сирәгәя төшкән, хәзер инде туташның күкрәгенә кулның аркасы тиеп кенә китми, хәзер инде ул кызның кызулыгын сизеп-тоеп бара иде. Базар мәйданын шулай култыклашкан килеш уздылар, кибетләр арасыннан анда-санда каравылчы яки төнгә баш тертеп йоклардай урын караштырып йөрүче берәр сукбай килеп чыкса, Гөлчирә һич ясалмасыз куркынып, егетнең куенынарак сеңә бара иде.

— Яратмыйм шушы Обжорный ряд исегезне, ничек яшисез шушы Казаныгызда? — диган булды Нагиев, базар мәйданын үтеп киткәч. Ләкин бу алдан ук үзе уйлап, әйтергә әзерләнеп килгән тәкъдимен әйтү алдыннан ясалган бер ход кына иде.

— Бу тынчу һаваны иснәп йөргәнче, бәлки минем номерга кереп утырырбыз. — Егет бу юлы кызны биленнән ук алды, аңарга озак уйларга ирек бирмичә, кистереп әйтте: — Мин бүре, син куй бәрәне түгел, бер-беребезне, әлбәттә, ашамабыздыр.

Нагиевның тавышында яшертен мыскыл, баласытып карау ишеткән кебек булды Гөлчирә. Бу аның горурлыгына тиде, нәрсә булса шул, тик шуны уйламасын: Гөлчирә алай куркаклардан түгел!

— Только озакка түгел, — диде кыз, ниһаять, бөтен тәвәккәллеген һәм кайнаган эчке хисләрен туплап. Һәм егетнең нәзакәтле рәвештә ишекне ачып торуына һәм үзенең эчке икеләнүләренә һич игътибар итмәстән, киресенчә, ясалма нәзакәтлелекне, тотрыксыз икеләнүләрне таптап узгандай, эчкә атлады.

Нагиев олы кунакларын озата чыгышлый, Депре флягасын эчкәрәк алып куйганнан соң, этажга хезмәт күрсәтүче хадимә ханымга номерны җыештырып алырга боерык бирә киткән иде. Боерык үтәлгән, табын җыелып алынган, бүлмәдә тәртип, хәтта форточкага хәтле ачык, һава ишегә ягып ашарлык ук булмаса да, шулай да аш-су һәм кунаклардан сеңеп калган саранлык исе чыгып беткән иде.

— Якын итсәгез, иң элек мәнә бу бөркәнчекне салып куябыз,— дип, артык нечкәртеп тормастан, Гөлчирәнең башыннан газовый шарфны алып бер якка куйды хуҗа. Өйгә кергәч аның батырая төшкәнлеге сизелеп тора иде, — мондый дөньяда юк толымларыгыз булганда тем более.

Нагиев Гөлчирәнең чәч толымнарына кагылып куйды, кызның йөрәге янә бер, күкрәк тартмасыннан сикереп чыгардай булып, депелдәп типкәне сизелде — әллә куанычтан, әллә каушаудан?

— Берәр чынаяк чәй китертәбезме? Казенный чәй, — дип тәкъдим ясады егет һәм, үзен-үзе мыскыллап, өстәгән булды: — Хәер, кунактан сорап тору килешәме соң? Әлбәттә, китертәбез. Минем бу профанлыгымны, зинһар, үз алдымда ук гаепләмәгез, туташкаем.

Ул звонок төймәсенә басты, хадимә ханым шундук йөгереп килеп житте.

— Безгә берәр чынаяк чәй. Кайнар һәм куе булсын. — Боерык бирергә өйрәтәсе юк Нагиевны, дөнья күргән кеше, тавышы бөердән чыга иде. — Чәй янына нинди зат әйберләрегез бар? Катып беткән кондитер чүп-чары булмасын. Кунагым да, мин үзем дә свежий ризыкларны гына кабул итәбез.

Хадимә ханым чыгып киткәннән соң, Гөлчирә болай зурдан кубуның урынсызлыгын әйтә генә башлаган иде, егеткә эрсезләнә төшәргә бу бер сәбәп кенә булды.

— Сез тик кенә утырыгыз, крошка, — дип, якын ук килеп, кызның иңбашларына кулын салды Нагиев һәм, иелә төшеп, чәчен иснәгән булды.— Кайдан килә бу хуш ис дисәм, сезнең чәчегездән икән. Ачыктан-ачык әйткәндәме? Гафу итегез, Гөлчирә туташ, мин боргалана белмим: бу буй-сыныгыз, бу толымнарыгыз, бу җазибәле күзләрегез белән Сез бу сасы Казан өчен эрәм. Хәтерегезгә авыр алсагыз алырсыз, әйтми булдыра алмыйм: эрәм сез бу Обжорный рядлар өчен.

— Әрәмдерме, түгелдерме, минем үз Казаным. Үз Казанында кайнамыйча кая бармак кирәк?

Кызның бу репликасы Нагиевка сүзне үзенә кирәк юнәлештә куерта төшәргә бик уңай җирлек бирсә дә, чәйнек һәм чынаяклар, табадан гына төшкән кайнар пәрәмәч, пирожныйлар төялгән поднос күтәреп кергән хадимә хатын сүзне бүлдерде.

— Счеты соңыннан, — диде номер хуҗасы, тегенә тизрәк чыгып китәргә ишарәләп.

— Өстәлгә елышыбрак утырыгыз, туташ, — Егет артык тәкәллефләнеп торуны кирәк тапмый, кызның күндәмләнә баруын ул сизеп тора иде. — Безнең Москвада булса, җиргә сирәк очып төшә торган сездәй фәрештә өчен, әлбәттә, сый-хөрмәтнең затлырагы да табылыр иде. Нишләмәк кирәк, Казаныгызның түшәме шулай тәбәнәк булгач...

— Безнең Казанга алай еш тел-теш тидерә башласагыз, карагыз аны, Котдус абый... Мин чыгып китәргә дә күп алмам.

Сүз булганга гына әйтте моны Гөлчирә. Чынлыкта исә, Котдус абыйсының шулай зурдан кубып, шундый ачык чырай белән, җитмәсә тагын ялтыравыклы Мәскәү тормышы турында чама белән генә сүзләр кыстыргалап, кызның болай да алгысыган күңелен алгысытып куюлары кызга ифрат та ошый, бигрәк тә егет үзе ошый, карасана әле, өске пинҗәген дә салып җилеттән генә калгач ул бигрәк тә яшәреп, нечкәреп, озынаеп киткәндәй булды.

— Мин үзем чәйгә менә бу әкәмәтне тамызып эчәргә яратам, — дип куйды Нагиев, яшергән җиреннән Депре флягасын чыгарып, — заграничный, чәйгә үзенә бер төрле аромат бирә. Әгәр рөхсәт итсәгез, туташ...

Рөхсәт сораган булды, әмма текәлгән үткен карашы каршы килеп булмаслык итеп боера һәм бер үк вакытта ялвара да иде. Дөнья күрмәгән беркатлы Гөлчирә мондый карашка ничек каршылык күрсәтә алсын! Бигрәк тә «заграничный шәраб»та булгач. Дөрес, ул «салыгыз», «салмагыз» дип бер сүз дә әйтмәде, әмма моны ризалык билгесе дип уйларга хуҗаның нигезе бар иде. Фляганы чынаякка якынайткач, хәтта тамызу белән генә дә чикләнмәде, яхшы ук нык чөйкәлтеп коеп җибәрде.

...Шул бер чынаяк чәйдән соң кызның тамырларында кинәт тилемсә кан уйный башлады. Әллә нишләде, курка һәм ояла башлады, ризыкка сузылырга теләми, сүз әйтергә теле бармый, торып чыгып китмәкче була, шул ук вакытта моның килешеп җитмәгәнлеген дә чамалый, «Бу ниткән кыргыйлык!» дип калыр Котдус абыйсы. Ә ул үзе турында егетнең алай уйлавын һич кенә дә теләми, гомумән, бу минутларда ул бөтән бер нәрсә дә теләми, бары тик менә шулай кара-каршы утырып кына торсыннар, утырып кына торсыннар иде.

Хәлбуки, һәр эштә практик акыллы Нагиев «утырып тору» белән генә, әлбәттә, канәгать түгел, бу соңгы кичне ул ничек тә нәтиҗәлерәк итеп файдалану ягында иде.

— Сез Мәскәү салоннары өчен яралган кеше, туташ, — диде ул, һич тәкәллефсез Гөлчирә янына күчеп утырып, — киләсе визитымда мин сезне... мин сине, канатым, үзем белән Мәскәүгә очырып алып китәчәкмен.

Әлегә бу минутларда, Мәскәүгә караганда, кызның алсу иреннәре якынрак иде. Егет, һич рөхсәт сорап тормастан, кызның муеныннан кочып, авызына үрелде һәм моңарчы тыелып торган җенле дәрт белән үбәргә тотынды.

— Мин китәм... Минем шарфымны бирегез, Котдус абый, — дип, кинәт урыныннан сикереп торды кыз. Аңа әйтеп бетергесез уңайсыз һәм, кызыклы хәл, ул шушы уңайсызлыкның дәвам итүен тели иде.

— Синең шарфыңны минем вовсе дә күргәнем юк, бәлки син аны урамда төшереп калдыргансың, — Нагиев, шаярткан булып, тагын Гөлчирәнең каршына килеп басты, юлына аркылы төште, иңбашларына кулын салды. Кыз бөтен тәне белән сизелер-сизелмәс кенә дерелди, тоташ ут эчендә, ә Нагиевка ул нәкъ менә шул ут эчендә калган, янган вакытында кирәк тә иде. — Син минем рөхсәтемнән башка, минем ризыгымны ташлап китмисең, китә дә алмыйсың, җүләр кыз. Әтиең белән әниеңнең сиңа кирәгенчә сиздермәгән булулары, әлбәттә, кызга-

ныч. Мәгәр монда минем тамчы да гаебем юк. Алар әйтмәгән булса, алайса, мин әйтим: син ярәшелгән кыз, Гөлчирә туташ. Син минә миңа ярәшелгән кыз. Алдагы килүләремнең берсендә безнең туебыз булачак, мин сине Мәскәүгә алып китәчәкмен... — Гөлчирәне кулыннан ычкындырмаган хәлдә кызып-кызып сөйләгән җиреннән бүленеп, ул сюртук кесәсенә тыгылды, аннан теге кичне бүләк ителгән алтын портсигарын чыгарды. — Ышанмасаң, менә сиңа вещественное доказательство, җүләрем. Мондый кыйммәтле әйберне зерә генә бүләк итмиләр, белмәсәң, бел. Моны синең этиең, хөрмәтле Мөкатдәс әфәнде, миңа алдан сөйләшенү буенча, ярәшү бүләге итеп бирде...

Ничек аңларга, ничек кабул итәргә соң бу хәтле ачыклыкны — бәхетме бу, тозакмы бу? Ичмасам, бу хәтле ачык әйтелмәсен иде, мондый шәрәлеге белән ишетелмәсен иде. Дөрес, алар өендә нинди-дер ишарәләр булды, истә-оста юк чагында кыз бүлмәсендәге комод өстенә парфюмерия тартмасы кайтып утырды. Кызны этисе кибеткә — сату итәргә алып йөрми башлады. Кунак өенең идәненә яңа келәм кайтып түшәлде. Стенадагы иске шәмаилләр, «Мәккәи-мөкәррәмә» күренешләре мыеклы Буденный, тузгый башлы немец шагыйре белән алышынды, ләкин кызның үзе белән бер утырып сөйләшсеннәрче! Йа хода, синең бу дөнья дип яратканың шушы хәтле вафасызмыни?

Берничә секунд эчендә кызның башыннан әнә шундый уйлар йөгереп узды. Ләкин хәзер инде ул шарфын таптырмый, китәргә кирәклеген дә, кирәк түгеллеген дә белми, аның өне алынган, урта бер җирдә басып тик тора. Күтәрелеп карамый, шул ук вакытта эчендә кайнаган хисләрен яшереп саклау да әйтеп бетергесез читен иде. Ахры, шуның котылгысыз бер галәмәтедер, кинәт ул Котдус абыйсына күтәрелеп карады — аның күзләре гаҗәпләнү һәм инәлү белән тулган иде бу минутларда.

— Ә соң син үзең... син үзең, Котдус абый...— Аңа сүзен дәвам итү читен, зиһене чуалган, бәхетле икәнен дә, бәхетсез булса — анысының ничек киләчәген дә белми, ә ишетәсе килә, шул сүзне, күптән көтелгән сүзне егетнең үз авызыннан бик тә ишетәсе килә иде. — Син соң үзең мине яратасыңмы?

Җүләр кыз, мәхәббәттән саташкан кыз, дөньяның мәкерен белмәүче сукыр җан! Соң синең бу соравыңа тиз генә җавап бирергә мөмкинме? Гомумән, ярату-яратмауны тел белән әйтеп бирергә мөмкинме? Җавапның бик шома, баш әйләндергеч матур булуы да мөмкин, ләкин шул тышкы матурлык астында киләчәктә борын төртәчәк, шытып чыгачак һәм үсеп китәчәк хәйлә-мәкер качып ятмас дип әйтә аласыңмы? Шуны белә аласыңмы?

Шулай да кызның бу соравы Нагиевта әлегә ычкынып ук бетмәгән ирлек комсызлыгын кузгатып җибәрергә җайлы форсат булып төште:

— Яратаммы мин сине? — Шул сорау белән сикереп торды ул һәм идән уртасында иләс-миләс калган кызны уенчыктай җиңел генә күтәреп алды, диванга алып барып алдына утыртты. — Мин синеме? Мин синеме? Әйт шушы минутта, тагын ничек яратырга кушасың?

Дөньяда сәгать дигән нәрсә булганлыгы да онытылды, кинодан ничәдә чыгалар, кыз өйгә чамача кай сәгатьләрдә кайтырга тиеш? — Ул турыда да уйлап тормадылар һәм шунда дөньялары онытылган, бирелгән сораулар җавапсыз югалган минутларда Нагиевның ахыр чиккә хәтле тыеп килгән иң соңгы сүзе пышылдап чыкты:

— ...Син минем булачак кәләшем, ярәшелгән-килешенгән... Боже ты мой, кайчан булса да барыбер түгелмени?

Гөлчирә дә тере җан иясе ләбаса! Шулай да ул байтакка хәтле, сүзсез генә булса да, каршылык күрсәтергә, бирелмәскә маташты. Ниһаять, каршылык күрсәтүнең дә бер чиге була икән.

— ...Оялам... Утны сүндер, Котдус абый, — дип пышылдады ул, арган-талчыккан тавыш белән.

Ә номер тәрәзәсе аша, түбә калайлары өстеннән, Кабан күленең ай яктысы төшкән өсте көзгедәй ялтырап күренә иде.

17

Иртәгесен чибәр мөсафирның Казанда эзе дә юк. Килгәндәге кебек купшылык күрсәтмичә, Себер, Урал якларыннан Мәскәү ягына үтүче поездларның берсенә, ничек эләгә алса шулай эләгеп, тавышсыз-тынсыз гына сызган иде. Номер һәм һәртөрле хезмәт күрсәтүчеләр белән араны тиешле тәртиптә өзгән, дәгъвага урын калдырмаган, үзе туплаган «өчлек»кә килгәндә, дәгъвага әле иртә, алар һәркайсы үз урынында мыштым гына сер саклыйлар. Тик бер кешедә генә егет киткән көннән үк тынгысыз борчу урнашты — бу Гөлчирә иде. Әйткән иде, нинди поезд белән китәсен кисәткән иде, кешегә бик сиздермичә генә озата чыгарсыз, әйтелеп өлгермәгән сүзләрне шунда искә төшерербез дигән иде. Җаен тапты кыз, киенеп-ясанып, хушбуйлар сөртеп, әйтелгән вакыттан байтак элек вокзалга килде. Номеры алдан әйтеп куелган поездны түземсезлек белән көтте, ләкин утырасы пассажир юк та юк, поезд пошкыргалап, пар бөркеп торасы минутларын торды, утырасы кешеләр утырдылар, төшәселәре төште, ләкин Гөлчирә күрергә теләгән кеше тәки күренмәде. Поезд киткәннән соң да шул якка карап, аптырап та, багажы китеп, үзе чит-ят шәһәрдә торып калган ялгыз пассажирга да охшап, перронда хәтсез вакыт басып торды кыз. Һәм, бәлки нәкъ шул минутлардадыр дөньяга өметсез караш уянды аңарда: юк икән, бу миһербансыз дөньяда чын сүзле кеше юк икән!

Соңыннан, берәр атнага хәтле хат көтеп, үзен тынычландырырга тырышып йөрде, хат-фәлән дә килмәгәч, бөтенләй өметен өзде, алданганлыгына тәмам ышанды, әрнеде, хурланды, башын кая куяр урын тапмады. Ниһаять, гаҗизлектән күңеле әкренләп таш булып ката башлады. Кемгәдер каты сүз әйтәсе, дулаган йөрәген чак кына булса да басасы килә иде. Күрәсең, олылары да тынычсызлана башлаган иде булса кирәк, бер көнне әтисе белән әнисе арасында:

— Кыйбла якларыннан җилләр искәне сизелми, хатын.

— Вакыты җитми торгандыр, бер без генә түгел бит кешенең шөгыле,— дигән шикле пышылдауларны да ишетеп калды кыз. Һәм моңа хәтле бер вакытта да, бер очрак уңаеннан да әти-әнисенә каршы тел ачып, тупас сүз әйтмәгән Гөлчирә кинәт, үзен-үзе тота алмастан, дөрләп кабынгандай кабынды:

— Пышылдашмагыз, биргән бүләкләрегезне, куйган сыйларыгызны сәдакадан санагыз, алдакчы ул сезнең мактаулыгыз. Менә әйткән иде диярсез.

Мөкатдәс тә, хатыны Гөлсара да, кызларын беренче кабат күргәндәй, күзләрен шарландырып Гөлчирәгә карап калдылар. Нәрсә булса да әйтергә телләре әйләнмәде — әллә сүз әйтеп карарга, әллә сүзсез генә янагына менеп төшәргә бу шомлы кызның. Шулай да кулына ирек бирмәде карт, үзен тотып калды. Дөресен генә әйткәндә, шундыйрак шом аның үз күңеленә дә әкренләп керә башлаган иде инде, тупас кыланмавының бер сәбәбе дә шунда иде булса кирәк.

— Күпне белә башладың син, кызый, — дип мыгырданды ул ачу белән, — кеше арасында юкны-барны уйларга вакытың калмас, җыен кибеткә, күз төбендә бул.

Ләкин кызның да җебеп төшкәнлеге алай сизелми иде.

— Бүгеннән башлап мин синең ул кибетеңә аяк басачак кеше түгел,— диде Гөлчирә, сүзләрен өзек-өзек һәм утә кискенәйтеп,— аннары тагы шуны да белеп торыгыз: мин бу өйдә гел дә торачак кеше түгел.

Бу соңгы сүзләре белән ул атасын да, анасын да берьюлы мең шик-шөбһәгә салды: ходавәндә, нәрсә сөйләгән була бит, кая олагыр өйдә тормыйча.

— Ни әйттем мин сиңа кызыңны кара, гелән-гелән китапка багынып ятмасын, дип. — Карт һәм ырым-шырымга ышанучан могтәбәр сәүдәгәрнең иртәнге сәгатьләрдә үк өйдә тавыш чыгарасы килми иде. — Кыз-хатын корсагына китап төсме соң? Әнә үзең сөйләш кире беткәнең белән.

Ата кеше ишекне яхшы ук каты ябып чыгып киткәннән соң, өйдә байтак вакытка хәтле авыр тынлык хөкем сөрде — ана белән кыз икесе ике якта нинди дә булса шөгыль тапкандай итенәләр, ләкин эшкә чын-чынлап куллары бармый, сөйләшәсе сүз бугазга килеп тыгылган иде.

Ниһаять, ана түзмәде, кулына алган әйберен кире куеп, кызына якынлаша төште.

— Ни дигән сүзең булды ул синең, Гөлчирә? — Аның тавышында хәвефләнү дә, әлжыганлык та, бер үк вакытта аналык җылылыгы да бар иде, — имештер, бу өйдә гел дә торачак кеше түгел. Насыйбы чыкса, анда, алла боерган булса, күз күрер, илла да мәгәр бүген әйткән сүзләрең... җитмәсә, әтиең алдында. Аның болай да борчылып йөргән көннәрендә... Әйтергә генә ансат, никадәр акча биреп җибәрде, алтын тәмәке савыты бирде.

— Әй мин... мин, әни җан кисәгем... — Кыз, сүзен әйтә алмыйча, үксеп әнисенең күкрәгенә капланды. Хакыйкатьне әйтү бик тә авыр иде ана бу минутларда, әмма шул авырлыкны ана күкрәге белән дә бүлешмәсә, ул, бичара кыз, кая барсын соң, — мин акча белән, алтын белән табылмас байлыгымны бирдем. Ник тыясыз сез мине? Минем рәнҗергә хакым юкмыни?

Чынлап та, бусы инде бүген әйтеләчәк һәм бүген ишетеләчәк сүзләрнең иң йөрәк өзгече иде — кочакланышып елаштылар, күзләрендә яшь кипкәнче елаштылар, аннары Гөлчирә әнисе күкрәгеннән кинәт башын алып, йөзен учы белән каплаган хәлдә үз бүлмәсенә атылды, ә ана — мең газапта, мең шөбһәдә күмелеп калган ана — шулай да ходаның рәхим-шәфкатеннән өметен өзмичә, кузгалып киткән булды...

...Җитмәсә, шул көнне төш якынаеп килү алдыннан Мөкатдәснең кибетенә тиречә Хәмзә килеп керде. Сәлам биреп, олылап исәнләште, прилавкага кырын төшеп, бернинди сүзсез, кергәнне-чыкканны тыныч кына күзәтеп тора башлады. Кесәдән червонецлар чыкканда очрашканнан бирле Мөкатдәснең аны күргәне юк иде. Бераз суырылганмы дип әйтергә, күз төпләрендәге капчыклар бушый, асылына төшкән, ә күзләре шул ук: астыртын-хәйләкәр, сөзеп һәм үтәли тишеп карыйлар. Ичмасам, нинди дә булса сүз кушсын, йомышын әйтсен икән. Бер сүз дә әйтми, шул кырын төшкән килеш Мөкатдәстән күзләрен алмыйча, тик текәлеп калган.

Кешеләр керәләр дә чыгалар, арырак ак якасына кара күбәләк «кунаклаткан» приказчик кайнаша, аның бу якка борылыр арасы юк, аның яныннан кешеләр өзелеп тормый: алырдай булсалар да керәләр, алмастайлары да сугыла. Алсалар да, алмасалар да, ичмасам, аларның берме-икеме авыз сүзләре була. Ә тиречә Хәмзәнең бер сүзе дә юк, ул тора да тора, китми дә, китәргә җыенуы да сизелми.

Белә Мөкатдәс, килеп кергәч тә сизде: сүзе бар аның. Әле нинди генә сүз! Әлбәттә, теге эш турында кайгыртып йөреше. Күзләреннән күренеп тора шулай икәнлеге. Ахырда, уңайрак бер форсатны туры китереп, әлбәттә, теш арасындагы канәферен чәйнәп бетергәннән соң, тавышын кыса төшеп кенә пышылдады:

— Бик озакка китте безнең теге эш, азыкай. Синдә соң берәр хәбәрхәтәр юкмы?

Тирече Хәмзә. Үзенекен яканнан борып ала торган Хәмзә. Косарсың, ничек «азыкайлап» сөйләшкән була. Аның бу әдәпле сорашуыннан ток куырып алгандай итте Мөкатдәсне. Үз хәле дә хәл, житмәсә, прилавкага кырын яткан менә бу тиреч Хәмзәгә дә җавап бирергә кирәк. Я хода, тизрәк очын күрсәт муенга элмәк итеп салган бу арканыңның.

18

Китте... китте борчулы көннәр. Хәбәр көтүләр. Искәртмәстән килеп төшүләрен көтүләр... Тиреч Хәмзә дә һич йомышы юкта Мөкатдәснең кибетенә килеп, прилавкага кырын авып төшкән хәлдә, сәгатьләр буена дәшми-тынмый күз көеге булып торудан туктады. Килә, сәлам бирсә бирә, бирмәсә, ансыз да басып керә. Хәл-әхвәл сорашып тору юк, канәфер чәйнәп тору шулай ук юк, өзеп-кистереп әйтә торган бернечә сүзе бар: «Кайчанга хәтле күк капусы ачылганны көтмәкче булабыз?»

Шулай читләтеп-читләтеп кенә Мөкатдәс картның болай да кыршылган җанын кыршып китә. Өенә кайтса хатыны Гөлсара колак төбендә безелди: «Кара әле, сиңайтәм, озаккарак китте түгелме соң? Әйтүен әйтеп үк бетерми, Гөлчирә дә әллә нишләде, сәгатьләр буена авызыннан бер сүз чыкмый».

— Башымны катырмасагызсана, сездән башка да беләм,— дип кенә җибәрә карт, җенләнеп. Белмиме соң! Очкан червонецлар йөрәкне бер тырнаса, алтын портсигар өчен киткән акча икенче тырный, тиреч Хәмзәнең килгән саен телчәләнә төшүе — өченче. Һәм, ниһаять... сүзсез дә күреп тора ата кеше: кызый бөтенләй әкәмәтләнә бара. Олылар үзләре «Мәскәү егете дә Мәскәү егете!» дип бик җәелеп торгач, кыз, беркатлыланып, бөтенләй тугарылып ташламаган булса гына ярый.

Болай пошынулар, күк капусы ачылуны көтеп авыз ачып торулар белән генә чикләнеп калмыйча, ниһаять, бик үк кыюланып булмаса да, практик адымнар ясап карарга булды Мөкатдәс. Егетнең командировка белән Наркомзем системасына килгәнлеге хәтерендә иде. Һич югы, берәр ягы ачыкланмасмы дип, бер көнне Кремльдәге наркоматка китте. Ике нәрсә ачыкланды: моңа хәтле йомышы төшмәгәнлектән һич белми иде — ул Наркомзем дигәннәре иксез-чиксез күп бүлмәләрдән тора икән, бүлмә саен өчәр-дүртәр кеше утыра, бөтенесе кырыс чырайлы, эшкә күмелгәннәр. Язалар, счет төймәсе тарталар, чатыр-чотыр язу машинасында сугалар, телефонда сөйләшәләр. Кайсына барып егылырга белгән юк. Йөри торгач, ниһаять, шул ачыкланды, бусы картны дәррәү айнытып җибәргән икенче хакыйкать булды: июнь башларында да һәм гомумән дә Татнаркомзем аппаратына республика кантоннарында саранчаларга каршы көрәш буенча Мәскәүнең үзеннән чыккан бернинди зур белгеч тә теркәлмәгән.

— Әгәр кирәк булса, безнең үз аппаратыбызда үз белгечләребез дә саранчадан күбрәк, агай кеше,— дип тел шартлатып көлеп калды берсе. Кеше хәлен кеше беләмени, әйтерсең, Мөкатдәс «агай кеше» уйнап йөри.

Татар ягының атаклы кибетчесен кайдандыр танып белә торган икенчесе, тегенең күләгәсе күмелүгә, аптырагандай янындагыларга сүз катарга ашыкты:

— Бу ата нэпманның Наркомземга ни йомышы төшәргә может, һич башыма алмыйм.

Ярый әле, бу репликаны Шәйдуллин үзе ишетмәде, алла сакласын, мондый шикле сораулар белән чека арасындагы сукмакның бөтенләй кыска булуы да мөмкин. Шул кыска юлдан автомобильгә генә утыртып алып китсәләр, тиле...

Үзенең Наркомземда булуын, аннан бөтенләй өмете өзелеп кайтуын ул, әлбәттә, әйтмәде, тирече Хәмзә болай да, бөтен бәлане аннан күреп, Мөкатдәсне тереләй тотып ашарга йөргәндәй йөри. Инде үзләренең җыйнаулашып төп башына утырып калуларын төшенсә дә, беренчедән, Хәмзә белән Ясәви алдында үзен чак кына булса да аклау нияте белән, икенчедән, (бәлки бусы төп сәбәптер!) бердәнбер кызының киләбен чуалтып киткән шома егетнең ничек тә эзенә төшеп булмасмы дигән өмет белән, Мәскәүгә сәфәр чыгарга булды.

— Расходлы булса булыр, өч-дүрт көнгә эшем тукталса тукталыр,— диде ул, Хәмзә белән Ясәвинең икесен бергә туры китереп, — мәгәренки мин бу эшнең очына чыгып кайтачакмын, менә күрерсез, агай-энеләр.

Моның болай җилкенеп тотынуыннан, дөрес, «агай-эне» һәм бигрәк тә өйдәгеләр беркадәр җанлангандай булып калсалар да, бер атнадан бөтенләй төссез-өнсез әйләнеп кайткан Мөкатдәс күп сорашырга урын калдырмады:

— Киләчәк казабыз шул булгандыр, кулның аркасы белән амин тотыйк, җәмәгать. Амин тотыйк та... — Ул, тиз-тиз генә бөтенесен дә түгеп ташларга теләгәндәй, кабалана-кабалана, бутала-бутала сөйли иде. — Эзләмәгән җиребез калмады, Мәскәү фирмалары белән бергәләп йөрдек, Моссовет дигәннәренә хәтле барып җиттек, сигез катлы йортта, кругом пыяла ишекләр... Бөтен Мәскәвендә без булмаган бер адресный стол калмагандыр, юк ул, фик булып чыкты ул улица Трубадуров. Урамы фик икән, үзеннән-үзе аңлашылса кирәк, кешесе дә фик дигән сүз.

— Фик дип әйткәненнәнән әйтәм әле, — дип, бик алай күтәрелеп бәрелмичә генә, Мөкатдәсне бүлдерде тирече Хәмзә. Аның бик яман сүзләр әйтәсе килсә дә, әле генә ерак сәфәрдән арып-талчыгып кайткан һәм үзенә караганда олырак яшьтәге Мөкатдәс картка, бигрәк тә аның кайгыдан коелып төшкән Гөлсарасы алдында, каты бәрелмәскә тырышып үзен ничек тә тыеп торганлыгы күзгә чагыла иде, — бөтен дөнья фик белән тулмагандыр, ул егет фик булып чыкса, менә син фик түгел, хөрмәтле Мөкатдәс азыкаем. Без, сүздән әйтик, сине беләбез, син башладың, алла кушып син үк очларга тиешсең. Шулай түгелме, Ясәви кода?

Ясәви сүзгә-өнгә катнашмыйчарак торуны хәерле санады. Беренчедән, чынлап та Мөкатдәс картның бик йончып кайтканлыгы күз алдында. Икенчедән, барып җитмәде әле аңарга: ничек инде ул — кайчандыр дөньяда булган кеше, аннары дуамал гына фиккә әйләнгән?

Шул ук йортта, шул ук түбә астында Мәскәүдән кайтачак хәбәрне үтә өзелеп көтеп торган бер кеше — фикнең нәрсә икәнлеген, кешенең тора торгач ничек фиккә әверелүен белмәүче, асылда башка сыймаслык шул шурум-бурум арасында иң зур югалтуга дучар булган бер кеше — Гөлчирә бәхетсез бар иде. Ябылып җитмичәрәк калган ишектән олы агайлар арасында барган сүзгә ул кызыксынып колак салып торды һәм коточыргыч тирәнлегендә аңлады: димәк, шулай икән, алданган икән бичара Гөлчирә.

Һәм үз бүлмәсенә кереп бикләнде дә мендәренә капланып елады, күз яшен җәлләмичә елады... Хәер, елаудан гайре тагы нәрсә бар икәнен хәзергә әле ул белми дә иде. Ашарга чакырып, ишек шакыдылар — ачмады. Әнисе килеп әйтеп карады — ачмады. Әтисе килеп өркетергә тырышып карады — ачмады. Хәтта ишетмәгән дә кебек калды. Бу минутларда аның башына бөтенләй бүтән уй төшеп тора. Ул эзли, күңеленнән берәм-берәм кешеләрне уздыра, теге кичне аның белән ялгыз калган егетне китереп бастыра. Нинди чибәр егет, ничек матур итеп сөйли белә, елмая, көлә һәм көлдерә белә иде. Бактың исә, егет булмаган, фик кенә булган икән.

«Тукта әле, тукта, Гөлчирә балакай, бу дөньяда синең өчен елаудан да бүтән берәр юл калмадымы соң?» дигән сорау өзлексез миен бәзләп торды аның.

## 19

Тирече Хәмзәнең көе бөтенләй китте. Соң шулай булмыйча! Червонецлардан колак какканнан соң бер яңа ай туды, тулды, ай тулысында көтмәделәр, эшнең караңгыда башкарылырга тиеш икәнлеге сеңдерелгән. Ул ай бетеп яңа ай туган арада кичләр, төнләр тагын караңгыланып тордылар, Кабанның иң җылынган чагы иде, чум да теләгәнчә актарын Кабан төбендә. Килүче күренмәде Мәскәү ягыннан. Элегрәк әле тирече Хәмзә, Шәйдуллинның ике ишекле магазинына барып, прилавкага кырын төшеп, һич югы, төрпә-төрпә сүзләре белән Мөкатдәс картның җанын үчекләп һәм нәтиҗәдә чак кына булса да ачуын басып китә ала иде. Мөкатдәс Шәйдуллин махсус рәвештә Мәскәүгә барып, дөнья кубарып эзләтеп тә, теге шулер егетнең эзенә төшә алмыйча кайткач, Хәмзә сулагай кулын ук селтәде: юк, Кабан күле төбенә ташланган алтын-көмешне чыгару булмады, киресенчә, «Алтын бәрабәренә йөри» дип өстенә үк язып куелган кып-кызыл червонецларыңны үз кулың белән Кабан күленә ташлау булды. Җитмәсә, кызы Зөһрә ачык авыз кер чайкаганда төшергән алтын беләзек көенече дә күңелдән киткәне юк. Теге шома егеткә тоттырып җибәргән червонецлар хәсрәтенә беләзек көенече дә килеп кушылгач, ачудан нишләсен, үзен-үзе тотып тора алмастан, хатыны Хәдичәбикәнең яңагына менеп төшә. Сүзе гел бер:

— Сиңа нярә килде бу бәлаләр. Суеп тунар нем мин сине, әгәр тиреңөчен бәһа бирә торган булсалар...

Быел тагын чүп өстенә чүмәлә: өязгә чыгып, башка еллардагы кебек нишле итеп корбан тиресе дә төятә алмады. Бөтенесе шул большевиклар коткысы аркасында: халык эссе җәй уртасында корбан дигән булып мал җаны кырудан тыелып тора иде. Җитмәсә тагы, кайтарткан сыер тиреләре партиясеннән егерме тирене «түләмә чиреннән үлгән хайван тиресе, заразный товар. Эшчеләр комитеты болай да гел күзәтеп торганда, синең заразный тиреләреңне производствога кертеп, башымны Себер җибәрәсем юк» дип, завод хуҗасы кире борды. Бу хәтле бәла-казаның ачуын канәфер чәйнәп кенә басып буламы соң! Эчкегә сабышыр иде (яратмый да түгел күләгәдә мыек чылатып утыруны), бердән, теге дөньяга баргач җавап бирүдән курка — әле бит «Яңа бистә» якларына да китәсе бар. Икенчедән, исеме халык арасына таралган тирече Хәмзәне бер дә бер көнне «Исерекбаш Хәмзә» дип мыскыллап йөри башлаулары мөмкин. Ә кемнәндер ачуны аласы килә. Кайтып, хатынына бәйләнә Хәмзә бик тә ачуы чыккан минутларда. Юк сылтауны бар итеп бәйләнә һәм, озак төшендереп тормыйча, кыйный ук башлый. Хәер, хатыны Хәдичәбикәнең бу яктан үз төшенчәсе бар.

— Ир кыйнамый икән, яратмый дигән сүз ул, — ди, чын-чынлап әйтә бу сүзне. — Аннары тагы ишеткәнең бардыр: әтиең-әниең, никахлы хәләл җефетең кыйнаган урын тәмугыда янмый, имеш, Хәсбиҗамал кодагый.

— Ишеткәнем дә юк, ишетәсем дә килми, — ди Хәсби өздереп. — Алайса, минекенең янар җире гүпчи дә калмагандыр инде, берәр шиген сиздемме, атланып кисәм. Хәзерге азгын ирләрне шунсыз тотарсың бар.

Ике кодагый — икесендә ике характер. Бүтән бер кешегә дә сер чыгармый, «кулың сынса — җиң эчендә!» дигән иман белән яшәүче Хәдичәбикә, рәнҗүенә түзә алмыйча, кодагыена якын итеп кенә «тиш-

кән» иде, менә сиңа кирәк булса: Хәсбиҗамал кодагые ничек кенә авызын томалады.

Һәр яклап җыелган ачуы, югалтулары, түләмәле тирене түләмәсез тиредән аера алмавы өчен тәмам эчне киптерү дәрәҗәсенә җиткән үте хатын кыйнау белән генә басылмагач, көннәрдән бер көнне Хәмзә, бер үзенә бер көймә яллап, Кабанның теге ягына — Суконный бистәсенә юл тотты. Дөрес, бу сәфәр вакытында да ачулы икәнлеге үзен сиздерде. Көймәче ишеп чыгарганы өчен биш тиен сорагач:

— Минем, илледән ашкан картның биш тиенлек ниткән авырлыгы калсын, ди. Мә, өч тиен бакырны тот та, авызыңа оҗмах җимеше ике канәфер каптырам, — дип котылмакчы иде дә, көймәче бик үзсүзле кире беткән нәрсә булып чыкты, «оҗмах җимешен» авызына якын да китертмәде — бар бит әле бездә кешенең хәсрәтен аңламый торган таш йөрәкле кешеләр!

Ясәви кибетенә барып кергәндә дә чыгырына утырып җитмәгән иде Хәмзә. Баш кагып кына сәлам биргән булды, шундук тегенең күңелен табарга тырышып булса кирәк:

— Салкынча икән кибетеңдә, сулышка рәхәт булып китте,— дип сөйләнә-сөйләнә, камзул төймәләрен чишеп, киң җиңнәрен җилпеп, җилләнергә тотынды. — Сәүдәләр уңмы соң?

— Булганы белән. Безнең бу Суконный ягында соң җыен мастеровой да сала бәрәңгесе. Акмаса да, тамганны көтеп көн уздырабыз.

— Беләм, беләм ничек тамганын, миннән яшерә алмассың,— дип хихылдап көлгән булды Хәмзә һәм, шундук хихылдавын басып, җитдирәк күренү өчен хәтта тавышын да кыса төшеп, тәкъдим ясады: — Яп әле кибетеңне, әйдә берәр җары кереп, чак кына сүләшеп утырыйк. Хәсбигә ишеттерми генә сүләшә торган сүз бар.

Шундый кызыксыну кузгата торган итеп әйтсен дә, тыңламыйча кара. Бераздан инде алар урамда иделәр.

— Көне дә харап бөркү, тамак та чатнап тора, әйдә кыйшык ишекле менә бу таш подвалга сәлам бирик әле, — диде Хәмзә. Кодасының «ә» дигәнен дә, «җә» дигәнен дә көтмичә, ярым подвалга урнашкан пивнойга алып төшеп китте. Кодасының икеләнүен басар өчен булса кирәк, үзеннәнме, кодасыннанмы көлгәндәй итеп, бусага аша үтешли өстәп куйды:

— Үзем чакырам, расходын да үзем күтәрермен. Нишләптер бетләр котырып тора бүген. Өченче көн түләмә чиреннән үлгән сыер тиресе дип егерме биш тиремне кире бордылар. Котырыр урын бар бетләргә.

Пивнойда кешеләр болай да ике-өч бөртек кенә иде, болар шулай да иң караңгы почмактагы өстәл кырына килеп утырдылар. Бөркүдән кергәч, бу салкынча караңгылыкта җан рәхәте иде, инде иреннәрне салкын сырага да тидергәч, бөтенләй Суконный җәннәте булып китте.

— Нихәл соң, Ясәви, теге егерме червонец янды бит безнең? — дип, бик тә җитди итеп сүз башлады Хәмзә. — Берәр нәрсә уйлыйсыңмы син, әллә шул янган килеш бәхилләргәме исәп?

— Уйлап ни эш кылмак кирәк, — диде тегесе, кыска гына итеп. Күренеп тора: Ясәвинең бу турыда хәтта исенә дә төшерәсе килми иде. — Үзебез җыгылдык, үзебез үк җыламыйча гына тора да белергә тиешбез.

— Дурак син, Ясәви. Хәсбиең зря гена тукмамый икән сине. — Хәмзәнең җенен чыгарды Ясәвинең тыныч һәм тәүфыйклы җавабы. Һәм ул кычкырып җибәргәнен үзе дә сизми калды: — ә мин моны болай гына бәхилләргә уйламыйм. Әндрей казнасы юк миндә.

— Соң нишлибез болай гына калдырмыйча? — Ясәвидә дә кызыксыну кузгалды һәм ул әлегә яртылаш кына эчелгән кружкасын дәррәү күтәреп эчеп җибәрүен үзе дә сизми калды. — Әллә очы-кырые чыгып торамы теге җуликның?

— Миңа аның очы-кырые кирәк тә түгел. Мин Шәйдуллинны беләм. Котҡы салучы кем? Шәйдуллин. Очкан червонецларны да аңардан таптырам. Менә әйткән ие, диярсең.

— Мөкатдәс абзыйны әйтәсеңме? — дип, ышанып җитмәгәндәй сорап куйды Ясәви. — Безнеке кебек үк, аныкы да китте бит егерме червонец. Аныкы әле егерме бер китте, синең өчен дә бирде берне.

— Ә мин аннан егерме итеп таптырам. Судка биреп кайтартам.

— Бу бит сүздә тормау була. Без бит ул эшкә сөйләшеп, ант итешеп керештек. — Ясәви, официантны чакырып, тагын берәр кружка сыра китерергә кушты. Кодасының сүзләре аны бер үк вакытта кызыктыра һәм гаҗәпләндерә иде. — Бу соң көпә-көндез үз мөселманыңны талау була түгелме? Кеше без күргән казаны үк күргән. Өстәвенә, Мәскәвенә барып, ничаклы расход тотып кайтты. Кызы турында да төрле сүзләр йөри.

— Мин ул кызның итәк астына каравылга куелган кеше түгел, — диде Хәмзә, кыза төшеп. Кызуы болай гына басылырдай күренмәгәч, ул канәфер чыгарып кабарга мәҗбүр булды. — Миңа түләмә чире белән үлгән сыер тиресе сатучылар да мөселманнар иде. Мөселманлыкны алыш-биреш эшенә катнаштырма син, кода.

— Мин ни... Мин тегеләй дә, болай да риза. Түлке ни... үз мөселманыңны рәнҗетү килеп чыга.

Ясәвинең болай мәлҗеп торуы Хәмзәнең җенен чыгарды.

— Алайса, синең коең тирәндер, ничек теләсәң, күпме теләсәң шулай чөмереп чыгара торгансыңдыр акчаны, — дип тезеп китте ул, кодасына авыз ачарга да ирек бирмичә, — миндә андый тирән кое юк. Барам да бүген үк кабыргасы белән куям: я теге жуликка тоттырып җибәргән акчадан безгә дүләбезне кайтарып бирә, я эшне чекага җиткезәм. Беләсең килсә бел: контр эшкә сөйрәп кертмәкче булды ул безне. Янәсе, сәвиткә сиздермичә генә Кабан төбендәге байлыкны әрчемәкче.

Ике кеше бер булып эш кылганда, аяк терәбрәк сөйләшергә була, дип ышандыргач, аягы гәрчә бик тартмаса да, Ясәви дә нирде. Ләкин сүзне башлаучы, алып баручы сыйфатында түгел, Хәмзә әйткәнне җуплап торучы сыйфатында гына — бу хәтлесен ул кодасына алдан ук әйтеп куйды.

Хәер, Хәмзә Ясәвигә күп тыгылырга урын да калдырмады.

— Беләсеңме, кем, Мөкатдәс азыкаем, шеш тулгач нишли? Шеш тулгач тишелә, — дип, сүзне бик тә коры тотып кереште Хәмзә. — Ишекләреңне бикләп, кыз-хатын керен-чыгып йөрерлек булмасын.

Һәм ничек турый башлаган — шулай турау аның өчен файдалырак күренде:

— Без сиңа сагыз чәйнәп утыру өчен түгел, без сиңа сүз белән килдек. Сүзебез шул: син безгә теге акчаларны кайчан кайтарып бирергә уйлыйсың?

Төрлесен уйлап соңгы вакытта болай да миңгерәүләнебрәк торган Мөкатдәс Шәйдуллин кинәт аптырап калды — уйнап түгел, чынлап.

— Аңлап бетмәдем: нинди акча турында сүз алып барасың, мөселман?

— Аңламаганга салышып кыланасы юк: ояларга оясы, кунакларга колгасы булмаган теге шома егеткә бирү өчен син менә Ясәви кода белән минем кесәдән егермешәр червонец акча тарттырдыңмы? Тарттырдың. Син бәлкем кызыңны да биреп, аны сразы банкир итмәкче булгансың; ул чаклысында безнең катышыбыз юк. Илла да мәгәр, безнең кесәдән чыккан егермешәр червонецны син тавышсыз-тынсыз гына безгә кире кайтарып бирергә тиешсең.

— Аллаһдан курык, Хәмзә кода, синең кесәдән чыкканы егермегә

тулмады, унтугыз гына булып калды. Тулмаганын синең өчен әнә Мөкатдәс абзый бирде, үзем шаһит.

Сүз җүпләргә дип килгән кодасы Ясәвине кара инде син, башта ук ничек сата.

— Сүләшә белмисең икән, май кап,— дип, күзенең агы белән кодасына усал итеп бер карап куйды Хәмзә һәм, аның саен оятсызлана барып, Мөкатдәс Шәйдуллинга очып кунуын дәвам иттерде.

— Кара әле, Хәмзә туган, акылыңдамы син? Сезнеке киткән кебек минеке дә китте. Минеке әле күбрәк тә китте, уйлап карасаң — Мөкатдәснең күзләренә яшь пәрдәсе бәреп чыкты. Акчадан да бигрәк кызының хурлыкка калуы тетрәтә иде аны.— Кемнән сорыйк, кемнән таптырыйк соң, я, әйтеп кара.

— Мин ни... Мин тегеләй дә, болай да риза... Түлке ни... үз мөселманыбызны рәнҗетү килеп чыкмасын.

Ясәвинең болай икеләнеп торуын, яклау дип, үз файдасына алган Мөкатдәс бераз елаган тавыш белән ялгап алып китте:

— Алланың барлыгын, берлеген белеп торганыбыз хәлдә, коръән үбеп, ни булса — шул, дип керештек ләса, кәбәм. Инде килеп үз җилкәмә төшкән каза-хурлыклар өстенә, сезнең казаны да күтәрергә тиешменме? Иманың бармы синең, Хәмзә туганкай гынам?

— Син минем иманга кагылма, яме. Коръәнгә дә кагылма. Алар икесе дә үз урыннарында.

Бер кызгач Ясәви кодасын да урынына утыртмакчы булып, аңа да тупас кына дәште:

— Ә сиңа, Ясәви кодам, күпме кирәген мин үзем беләм. Итче Гыймади мунчасыннан Мәрүсә тәтәй белән чыгып килгәнеңне Хәсби кодагыйга җиткерсәмме? Белеп тор, ул синнән бише белән чыгарачак.

Шуннан нишләсен инде Ясәви бичара, хәтта сүз дә җүпләмәс булды. Бер читкәрәк китте дә, борын астыннан гына мыгырданып, үзенә үзе сөйләнергә тотынды:

— Бетмәде шул бер Марусә, күреп калган ич, ләгънәт төшкересе. Күренмәгәннәре әнә утә, шито-крыто. Үзебезнең яндагы кызыл фонарьны ябып харап иттеләр, хатын биләмгә киткән арада да кердең-чыктың ие. Бик тәүфыйклы булып кылана бу сәвит дигәннәре дә.

Ул арада Хәмзә белән Мөкатдәс янә бер чукышып аласы иттеләр:

— Алай коръәнең дә, иманың да үз урынында булгач, тәкъсир,— дип җайлап кына сүзне очларга тырышты Мөкатдәс,— болай да кыйналган башыбызга яңадан таяк эзләп йөрмик. Килгән каза икән, тавышсыз-тынсыз гына күтәрик тә алладан икенчесен, өченчесен җибәрмәвен сорый башлыйк.

— Икенче, өченче тагын да шомарак жуликларнымы? — Хәмзә үз тапкырлыгыннан үзе шаркылдап көлде һәм шундук, утә житди тонга күчеп, ялгап алып китте:— Чынлап сөйләшә башласакмы? Миңа, әгәр дә мәгәр чынын әйттемгә керешсәк, кулыбыздан шуып үткән шома егетне дә, әлегә башыбызга төшәргә өлгермәгән таякны да эзлисе юк. Барам да, ни булган — шуны чекага селким дә салам. Безне шулай алдадылар, болай күз буядылар, без томана булганлыктан алдандык, ә чын гаепле кеше, аферистны чакыртып китерүче, аңа кызын сыларга йөрүче чын контр әнә Мөкатдәс Шәйдуллин, мин әйтәм. Алар моңа тиешле статьясын үзләре табачаклар. Уйнама, Сәвиткә каршы контрреволюция оештыру бу. Ике ишекле таш магазиныңның ишекләренә шундук сургучлы йозак салачаклар, бөтен мал-мөлкәтең конфисковать ителәчәк, ә үзеңә, өркетә дип уйлама, Мөкатдәс азыкаем, Себер юлы тап-такыр...

Тирече Хәмзә бик рәхимсез иде бу минутта, аның сүзен җүпләшергә дип килгән Ясәви исә читкә үк китеп утырган, сүзгә бөтенләй катнашмый, болай сүзгә катнашмый утыруы белән үз нәүбәтендә анысы да

күнелгә шик сала, кыскасы, Мөкатдәс Шәйдуллинга уйларга, акыл җыярга бик вакыт иде.

— Чын ирләрчә сөйләшик дисәк, сездә нинди тәкъдим бар? — дип сорады Мөкатдәс, күпмедер вакыт сүзсез күперенеп утырганнан соң.

— Чын ирләрчә сөйләшик дисәк, бездә чека бар,— дип үз туксанын тукыды кире беткән Хәмзә.

— Карагыз әле, мөселман ләбаса сез, ник шулай егылганны түбәлисез?

— Кара әле... ни... мөселман булмасаң, ир бул: үртәмә олы кешене, әйт соңгы сүзеңне, — дип арага кысылды Ясәви.

— Әйтсәм, алайса, әйтим. Анысы да башына кырпак кунган Мөкатдәс азыкайны җәлләп кенә: безнең кесәдән чыккан егермешәр червонецның яртысын ул күтәрә. Тәштите шул: ун червонецны миңа, ун червонецны минем Ясәви кодага чыгарып бирә дә, шуның белән шул вәссәләм! Ул безне белми, без аны белмибез.

— Тагы егерме червонец дигән сүз бит бу, адәм балалары. Тагы минем кесәдән.

Мөкатдәс моны елаган тавыш белән әйтте, чынлыкта исә болай котылудан ул бик канәгать иде. Үзе әйткәнчә, чекага хәтле барып җитүе дә бар бит бу имансыз тиреченең.

Кайтышлый Хәмзә кодасы Ясәвигә шелтә белдерде:

— Син йомшак тордың, син эреп тормасаң, мин ул кан эчүче буржуйдан егермешәр червонецны ике дә уйламыйча суыраием.

## 20

Тычканга — үлем, мәчегә — көлке. Мөкатдәс Шәйдуллиннар гаиләсе болай да парә-парә өзгәләнгән бер вакытта, елан урынына шуышып өйдән-өйгә гайбәт китте. Һәр очракта шулай булганы кебек, монда да күпертеп, күбесен үзләреннән кушып тел чайкый башладылар. Имештер, кызын алса Мөкатдәс күз дә йоммыйча кибетенең яртысын бүлеп бирмәкче, имеш. Тешләп караган бит Мәскәү егете, кызның тәмен ошатмаган. Ошатканмы, ошатмаганмы, борчак бүртә, ди, инде. Ул Мәскәү егете дигәннәре гел Мәскәүнеке түгел, шулай шәһәрдән шәһәргә баерак кешеләрне төрле юллар белән алдап йөрүче мошенник, ди. Бай кешенең коесы тирән, син эчсәң дә, мин эчсәм дә корымас. Әйтмә дә, сөйләмә дә, синең белән миннән ни аллага, ни муллага. Шәйди Мөкатдәсенә бик таман, хөррият дигәннәренә кукиш күрсәтеп, дөнья куа башлаган ие...

Бу имеш-мимеш хәбәрләр Чукрак Зарифка да, әлбәттә, ишетелде. Ләкин ул җүпләп тору белән генә, әлбәттә, канәгать түгел. Моның астында тагын нидер яшеренеп ятарга тиеш, дип уйлый. Чокчына, сораштыра, Мөкатдәсне бер дә бер көнне тотып чекага алып китүләрен бик теләп көтә, әмма хәзергә ишетелгәннән артыгын ишетә алмагач, ачуын эчкә яшереп йөри бирә иде. Теге әллә кайчангы кичне, әйтер сүзен әйтергә бирмичә, ишектән борганга бик тә хәтере калды шул аның. Бөтен Казанга мәгълүм извоз тотучы Зариф белән шулай кылансынчы әле.

Көтеп-көтеп тә Мөкатдәснең тамырын корытырлык, һич югы, аны чекага озатырлык сәбәп килеп чыкмагач (нәрсә ул кыз турында тарал-ган сүзләр?! Нәрсә ул Мөкатдәс тиклем Мөкатдәсне берәр йөзгә утыртып китүләре? Төкерек ул аңа!), Чукрак Зариф тегенең җан җиренә тиярлек итеп берәр «тиатр» кору эшенә кереште. Искечә укып искеләрне шаккатыра алмаган, яңача укып яңаларның олтанына да ярамаган, утыз биш яшькә хәтле өйләнә алмый йөрүче бер карт «шәкерт»не табып алды һәм шул шәкерттән Мөкатдәс байның кызына, аннан да бигрәк

байның үз танавына суктыра торган бәет чыгарып килергә кушты. «Әҗере» мул күренеп торганда, «иске»дән дә, «яңа»дан да авыз иткән карт шәкерт өчен нәрсә ул бәет чыгару. Ике көннән бәет әзер һәм ул Чукрак Зарифның нәкъ үзенә килеп, булдыра алганча көйләп-көйләп, укып та күрсәтте:

...Бисмиллаhи-вәбилләhи житә корбан гаете,
Без әйтәбез, сез тыңлагыз: Гөлчирә туташ бәете.
Мөкатдәс бай кыз үстерде банкадагы гөл сыман,
Кашы кыйгач, бите кояш, язгы якты көн сыман...—

кебек юллар белән башта кызны юри мактап килеп тә, ахырга таба:

Ел килешкән. Дым ирешкән, шытым биргән борчагы,
Нечкә билле Гөлчирәнең үсә хәзер корсагы,—

дип, тупас һәм оятсыз рәвештә хурлый торган юллар белән тәмамланучы бу такмак беренче укудан Чукрак Зарифның күңеленә хуш килгән кебек күренсә дә, алдан вәгъдә ителгән «гонорар»ның муллыгын истә тотып, аннан да бигрәк Мөкатдәс картның үзен дә читтә калдырырга теләмичә, тагы бер-ике куплет өстәргә дип, «автор»ны кире борды.

Өстәмәләре белән китергән соңгы вариантны «шәкерт автор» Зарифның чукрак колагы төбендә аеруча кычкырып укыганлыктан, шул вариантка тукталырга булдылар. Ләкин бер шарт белән: көне-сәгате җиткәч, «шәкерт» үзе чыгарган бәетне, Зарифның үзенә «Мысыр мәкаме» белән, тагын бернечә кеше алдында укыячак, тегеләрнең күңелләренә сеңдергәнче укыячак, бергәләп ятлаячаклар. Аннан соң нишләргә икәнлеге турында Зариф абзыйларыннан яңа фәрман булачак. Хәзергә ул чаклысына ук ачуны Зариф кирәк тапмый, яшерен сер, янәсе. «Шәкерт»нең, әлбәттә, эшләгән эше өчен шундук каерып аласы килгән иде, алырсың каешланып каткан ул чукрактан.

Хәер, алай озак көтәргә дә туры килмәде. Усад заводыннан спирт төяп кайтып, аракы заводына бушатканнан соң мичкәләр чайкаган суны бу юлы «яңадан эшкәртүгә» җибәрмичә, олаучыларны сыйларга булдылар. Моның янына «Кәрванбаш» Бикәйнең тегендәге дуслары белән сөйләшеп, спиртләтә кыстырып кайтканы да бар иде. Зариф закускага бик шәп ат казылыгы алып куйган иде, пәрәмәч-бөккәнне өйдәгеләрдән әзерләтте, юлдан кайткан саен жыелышып утыра торган арт өйдә ярыйсы гына табын әзерләнде. Әлбәттә, казылыгына, кәбестәсенә акча кесәдән чыкты, мичкә чайкаган суны «эшкәртеп» Обжорный рядка чыгармыйча калу да исәптә, ләкин бу юлы ваклашып тормады Зариф. Үзе белә: эше шундый, ак сөяк шагыйрь дә киләсе бар, күзләре тонганчы эчсеннәр.

Олаучылар — барысы да Зарифның үз кешеләре, «Кәрванбаш» Бикәйне әйткән дә юк, үзе кыстыра кайтканны да уртага чыгарып куйгач, бөтенләй хуҗа булып алды, «ирен чатный башлады, кайчан ходка җибәрәбез туйны?» дип, табын тирәли биеп кенә йөри. Моңа хәтле бик ашыктырмыйча, «киләсе кеше бар, чак кына сабыр» дип көттергән Зариф, «Кәрванбаш» бик тәкатьсезләнә башлагач, тегеңә борычны алдан ук сала башлау нияте белән:

— Хәзер туйны көтеп тору юк болай. Әнә Мөкатдәс бай хәтле Мөкатдәс бай... Хажга барып кайткан кеше. Кызы туйны көтеп торуны кирәк дип тә тапмаган,— дип, хәйләкәр рәвештә хихылдаган булды. Дөресен генә әйткәндә, бу бер «Кәрванбаш»ка гына әйтелгән сүз түгел, кызым, сиңа әйтәм, киленем, син тыңла дигән сүз дә иде. Сеңдерә торсыннар, хуҗа болай зурдан купкан икән, кашлары-күзләре матур булганы өчен түгел, кирәкләре чыгачак.

«Шәкерт шагыйрь», ничә әйтсәң дә аксөяк, көттеребрәк килде һәм мондагы чуар өерне күреп, сәлам бирергәме соң боларга, бирмәсәң дә батамы, дигәндәй, ишек төбендә бер мәл тукталып калды.

— Бик көттереп йөрисең, яшь кенә башыңнан, — дип, уйный-көлә шелтәләгән булып каршылады аны хуҗа.

— Яшь дип хурлама, утыз биш белән барабыз, — диде «шәкерт» вәкарь саклап кына. Бу аның мондагыларга барсына берьюлы алдан ук сиздереп куюы иде: янәсе: көттек дип бик аптырамагыз.

Башта шулай тәкәллефле кыланган булсалар да, соңга таба турыдан сиптерә башладылар. Олаучылар «шәкерт»не, тегесе исә олаучыларны әле берсен, әле икенчесен кочакларга, яларга тотынды. Җитмәсә тагы, укымышлы кеше бит, сүзләрен дә табып кына тора. Берсенә сырышканда:

— Син минем мулла абый кебек күренеп киттең, минем мулла абыйның да, аз гына сала башладымы, иң элек колагы кызара торган иде, — дип салам кыстыра. Икенчесенә турыдан-туры:

— Чырай сытып торма, иң яхшысы капылт йотып җибәрү, эчкә кергәч үз урынын таба ул, — дип акыл сата. Үзе шул акыл саткан арада казылык белән пәрәмәчне дә ярыйсы гына сыпырта — күренеп тора: «шәкерт» бүген бөтенләй ашамый килгән иде булса кирәк. Зариф төлке үзе бер читтә күзгә ташланмыйчарак утыру ягын карый, ләкин күзәтүен ачык күзәтә, айнык акыл белән күзәтә. Көне-төне спирт заводы белән шәһәр арасында йөреп, хәрәмләшеп тә, хәләл юлын да табып, спирт белән янган олаучы егетләрне кыставыннан ук сизеп алды, «шәкерт»нең мәлҗүе җитеп бара, каһәр. Хәлбуки, алда бит эш тора, аның бөтенләй сыгылып төшүен көтәргә ярамый иде. Саклык белән генә кылын тартып карарга булды:

— Кара әле, кем, мелла Гаптелхәмит, казылыкны син ипи белән аша, казылык ул ипи белән бара,— дип искәртмәкче иде, «мелла Гаптелхәмит» ашау ягына килгәндә, хуҗадан өнлерәк булып чыкты.

— Борчылма, пәрәмәч белән дә шәп шуа, — дип, кыска гына җавап кайтарды да элеккечә үк кыздыра бирде.

Шулай да Чукрак Зарифның төп максаты алалы-колалы бу әләмәтрәкләрне төн буе тыгындырып утыру түгел иде, ташлары бер чама кызган чак җиткәч, сүздән эшкә күчәргә булды:

— Менә бу Гаптелхәмит шәкерт җыр, бәет чыгарырга бик тә маһир кеше, имеш. Әле дә килеп, бай кеше — бер кирәк булмаса, бер кирәк булыр дип исе китеп тормаган. Мөкатдәс Шәйдуллиннар әкәмәтенә багышлап бер дә харап кислоталы бәет чыгарган, — дип, иң элек мондагылар алдында «шәкерт»кә бер реклама ясады һәм шуның белән теге «Аксөяк»не җилкендереп алгач, тәкъдим дә кертте.— Я әле, кем, мелла Гаптелхәмит, үзең беләнме синең ул мәҗмүгаи-асарың?

Әйтүе булды, «шәкерт»нең ялт торып басуы булды һәм шыңгырдатып укып җибәрде. «Мичкә юган су» да ярыйсы гына дәрт өстәгән иде булса кирәк, гомумән алганда, шәп укыды. Шәп үк булмаса да, гел Казан белән Усад арасын таптап, бер генә дә язма сүз ишетмәгән олаучыларның күңелләрен йомшартырлык чыкты.

— Кызык бу, кызык, — дип, шундук бәһа бирергә ашыкты берсе.

— Гаҗиткә бирсәң, басмаслар, чукынчык. Но ябырылып укырлар ие.

— Көе көйгә, җөе җөйгә ялганып кына бара, тегү машинкасында текердәткән күк.

— Гаҗиткә басмыйлар да басмыйлар, мәгәр Шәйди Мөкатдәсенең өй түренә барып, күмәкләп җырласак, бай абзаң үрле-кырлы сикерәчәк инде.

Нәкъ шул сүзне авыздан тартып алырдай көтеп торган Зариф:

— Бу уй минем башка да килде килүен, чукрак булсам да ишетәм, — дигән булды әлеге сүзне җүпләп. Кызулары житкән, нәрсәдер илдә юк бер тамаша эшлиселәре бик килә иде. Капкага дегет сылыйсың — бүген генә чыккан эшмени. Аннары тагы монда, кала

җирендә анын тәмен беләләрме, сала җирендә генә ул дигет сылау белән авылны дәррәү аякка бастырырга була. Тәрәзә ваттын, ди. Бу да әллә ни шаккатырдай тамаша түгел. Җитмәсә, иясе чыгып, милициягә тотып бирүе бар. Ә менә кешенең тәрәзәсе каршына килеп, күмәкләп бәет әйтү — мондый эшнең моңарчы дөньяда ишетелгәне юк. Үзе тагы шигырь белән язылган. Гаеткә барганда тәкбир әйтеп барган кебек чыгачак. Тамаша шәп килеп чыгачак.

«Тамаша шәп килеп чыксын» өчен, Чукрак Зарифның тәкъдиме буенча, «шәкерт»кә ияреп, бәетне монда чакта ук берничә кат кабатлап бактылар, тавышлар тигезле-тигезсезрәк чыкса да, сүзләре болай җиренә җиткерелеп, чын ихластан әйтелә иде, ул репетициянең шулай да артык озынга китүе хәерле булмаслыгын сизеп, Зариф кәефле кунакларын, әлегә җырлый ала торган чакларында, тизрәк Мало-мещанский ягына алып китү ягын карады.

— Әле бу бер җилләнеп керү генә, әйләнеп кайтып, «пирәшләүне» дәвам иттерербез, — дигән булды ул, табыннан кузгаласы килмичәрәк утырган әрсез кунакларны юатып. Ләкин аларга яңадан кайтып утыру насыйп булмады.

Баруын чынлап та гает намазына баргандагы кебек чамача тигез атлап бардылар. Килеп, тәрәзә каршына корт иледәй укмаштылар. Тамак кыргалап куюлар булды, инде менә «тәкбир»не нәкъ башлап җибәрер чакта «шәкертебез»... сүзләрен онытты. Терсәкне терсәккә төртешү, үзара сүгенешү китте, ул да түгел, соңыннан үз җырын китереп таккан олаучы бер егетнең чыдамлыгы җитмәде, бераз карлыккан тавыш белән шул үз «иҗатын» сузып җибәрде. Ул арада «шәкерт» тә ипкә килде. Ләкин бәетнең соңгы куплетыннан тотынды. Аны җырлап чыкканнан соң, дәррәү бер тавыш белән баштагы куплетларга күчтеләр. Башыннан алып азагынача, әлек җырлаган «азак»ны янә бер кабатлап, җырлап чыктылар, икенче кабат башладылар, ләкин анысын очлап өлгермәделәр, бикле капканың эчке ягында кинәт гөрселдәп мылтык атылды, Мөкатдәснең, капкадан чыгарга ашыкмыйча гына, бар көченә:

— Карав-в-вылл! Талый килгәннәр. Күршеләр! Мөселман кардәшләр, ярдәмгә... ярдәмгә килегез, — дип шырылдап кычкырганы ишетелде. Әле соң түгел, әле күрше-күлән йокларга өлгермәгән иде, аннан да, моннан да бикле капкаларның ачылганы ишетелде, күрше-тирә купты, андый чакта, үзеннән-үзе билгеле, буш кул белән чыкмыйлар, карт-корының ясту намазыннан таралган вакыты иде, иманлы таяклары белән алар да орышка килеп кушылды, китте әүмәкләшү... Кайда монда бәет әйтеп тору, баш исән чакта кайсы кая таю ягын карады, беренче булып һәм, һич хәвеф-хәтәргә тармыйча, әлбәттә, Чукрак Зариф үзе шылды. Әүмәкләшеп бәргәләшкән арада шулай да «Кәрванбаш» Бикәйнең кистән хәтле йодрыгы читекче Галләмнең башына төшеп өлгергән икән, маңгае ярылып кан киткән, сыбызгысын сызгыртып милиционер килеп җиткәндә, таш тумба өстендә канлы маңгаен тотып тик читекче Галләм генә изалана иде. Ул, әлбәттә, тамашаның кайдан, кемнәр тарафыннан башланганын әйтә алмады.

Шулай да бер кешегә бик тә аңлашылды бу кечкә «пәри туе». Бу бер кеше дигәнебез урам-түр өйнең кече ягында, үз бүлмәсендә, көндез кеше күзенә күренүдән хурланып качып ятучы, төнен бар белгән догаларын кат-кат укып та, күзен йокы алмаучы Гөлчирә иде. Әнә кай чиккә җитте бит кешеләр, болай күптерүләре генә аз булган, күрәсең, аның исеменә бәет чыгарып, ул бәетне тәрәзә каршына килеп, күмәкләшеп җырлап бирү дә кирәк булган. Юк, болай мөмкин түгел, хурлыкка калган кыз өчен күз яше түгүләр дә, йокысыз төннәрдән башка да нәрсә булса да бардыр. Булырга тиеш!

Шулай икән, гажизлектән соңгы чиккә житкән намуслы кеше өчен гайбәтләрдән, мыскыллы бәетләрдән, күз яше түгүләрдән, әти-әни күзенә күренеп йөрүдән качу өчен әле бер юл бар икән! Теге саташкан кичне мичкә чайкап эчкән кешеләрнең котырынган «тиатры», Мало-мещанский татарларының аңа каршы күтәрелеп чыгулары шаулап узганнан соң, күп тә үтмәде, иртәләрдән бер иртәне Гөлчирәне үз бүлмәсендә күрмәделәр. Бернинди шиккә дә урын калдырмаган, бөтен әйберләре, китапханәдән алып кайткан китаплары, бер кию белән карават башында эленеп калган челтәрле эчке күлмәкләре берсе дә нинди дә булса нәтижәгә килергә сәбәп була алмый, ләкин кыз юк. Башта бик шауламыйча гына көтеп карадылар, күрше кызларыннан сораштырдылар, ачык кына бер сүз дә әйтүче булмады. Иптәш кызлары Гөлчирәнең соңгы вакытларда гомумән күзгә-башка чалынмыйча, алардан качып йөргәнлеген генә әйтә алдылар. Кунарга да кайтмагач, икенче-өченче көннәрдә дә күренмәгәч, Мөкатдәс картның туган авылына, әтисе ягыннан кардәшләренә кайтып китмәгәнме дип, ашыгыч рәвештә авылга кеше жибәреп тә карадылар, аннан да тынычландырырдай хәбәр кайтмады.

Шулай да ата белән ананың күңелендә тоньк кына булса да бер өмет шәме әлегә янган була иде: янәсе, теге алдакчы егет сихерләп, эзен сиздермичә генә үзе янына чыгып сызарга котыртып калдырмаганмы? Мәскәү каласын, андагы адрес бирү урыннарын житәрлек таптады, Мөкатдәснең Мәскәү ягына инде борылып карыйсы да килми, күп баш вата торгач, кайчандыр Мәкәрҗә ярминкәсендә Мөкатдәс килешкән складны алып, Казан сәүдәгәрен бернichә көнгә урамда калдырган бик тә ертлач Касыйм татары яңадан исенә төште, аның фамилиясе дә Нагиев иде шикелле. Үзе барып эзли-сораштыра башласа, каз-үрдәкне берьюлы куркытуым бар дип, үзе чамалаганча дипломатик ходлар өйрәтеп, урысча-татарча ике яклы пәке саналган приказчигын жибәреп карады, «ике яклы пәке» дә буш кул белән кайтты. «Ул Касыйм якларында Нагиевлар эт көтүе икән, киткәне бар, качканы исәпсез, камчат, каракүл белән сәүдә итүче тукмак борынлы мишәрләрне әйтәсеңме, ишегалды саен кереп йөреп булмый, кайдан табасың төшеп югалган тишекле бер тиенне» дигән сүз булды алып кайтканы. Башка чагы булса, яшертен мыскыл белән әйтелгән бу «тишекле бер тиен» өчен Мөкатдәс — Печән базары короле әлеге егетне баш түбәсендә биетергә дә күп алмас иде. Соңгы вакытларда кеше сүзе ишетеп һәм кызы хәсрәтеннән яхшы ук шиңгән бай кул гына селтәде. Һәм, әйтергә кирәк, бу селтәнү жиленнән аларның күңелендә лепелдәп кенә булса янып торган соңгы өмет шәме дә сүнде...

Боларда сүнде. Ә Кабан өстенә кызның су астында ятып шешенгән-күбенгән, яшәреп-күгәреп танымаслык хәлгә килгән үле гәүдәсе калкып килеп чыкты. Кешеләр беркатлы, алар өстә яткан фактларны гына беләләр, шуның турында гына сүз куерталар иде: «Бичара кыз бөтәнчә кая барсын... хурлыгы бугазын килеп бугач!» «Урысча, французча укыган дилә ие... уку белән генә түгел шул, бәхетең булмаса!» «Мөкатдәс байның башына чукмар бу, борынны бер дә харап чөйгән ие». «Общий зиратка күмдермим, Ослан тавы башына күмдерәм, вакытсыз харап булган бердәнбер кызымнан жәл түгел, көмештән чардуган, алтыннан памятник койдырып куйдырам, дип әйтеп әйтәдер, ди».

Казан татарларының шушы килделе-киттеле сүзләренә каршы мәкерле Кабан, кояш астында ялтырап көлгәндәй булып, эченнән генә алардан гүяки мыскыллап пышылдый кебек иде: «Мин сезгә үз алтынымны бирмәдем, ә сезнең алтынлыгызны тартып алдым, комсыз булмагыз шул хәтле!»

Әлбәттә, имеш-мимеш сүзләр, төрлечә юраулар белән генә эш бетмәде, кеше хәтле кешенең Кабанга ташлануы уен түгел, милиция, тикшерү органнары кызыксына-сораштыра башладылар. Чукрак Зариф оештырган «хор»га да барып җиттеләр, ул үз нәүбәтендә «мичкә юган су» белән коенып акланып калмакчы булды: «Минем эш нәрсә? Минем эш хөкүмәт заказын үтәп Усадтан спирт кайтарту. Калганын мин знать не знаю», — дип барды. Болай ансат ерып чыгарлык булмагач, «Кәрванбаш» Бикәй белән «искечә укып тулмаган, яңача укып уңмаган» мәңгелек шәкертне корбан тәкәсе итеп, үзе читтә калырга исәп тотты. Ләкин бу дорфа беркатлылыгы белән ул читтә кала алмады гына түгел, үзенең арка таянычын—«Кәрванбаш» Бикәйне дә кулдан ычкындырды. Милициягә беренче чакыруда ук бирәсе җавабын биреп, шул ук вакытта Бикәйне бутап та үзе судан коры чыкмакчы булган Зарифка каны каткан Бикәй кайтышлый ук хуҗага кереп, араны өзәсе итте.

— Син, агай-эне, — дип, юри әкрен башлады ул башлаганда. Дарылырак сүзләрен соңгарак калдыру өчен шулай итте, — мине кабып йотып, үзең түбә җирдә теш казып утырырмын дигәнсеңдер инде. Утырмый тор әле, әбиеңә сәлам әйт, бабаң утырмага килсен. Күреп торасың, синең бугаздан үтәрлек түгел мин, гәүдәм алыптай, үзем алты кырлы. Әйтердәй сүзем шул: миңа расчет әзерләп куй, китәм мин синнән. Җыен нипман калдыгы — үзара канга батышып сугышыгыз, ә мин — Дөбъяз сапогы, — сезнең аякка көйләнмәгән. Менә шул.

Чукрак Зариф аптыраудан телгә килергә дә өлгермәде, Бикәй ишеккә борылды. Ләкин әйтәсе сүзе бетмәгән икән, ишеккә җиткәч кире килеп, ишетми калмасын өчен үтә кычкырып әйтте:— ...Бер генә күрдем мин ул кызны, безнең буй җитәрлек түгеллегенә шундук ышандым. Фәрештә ие ул, ә сез җыйнаулашып шул фәрештәнең башына җиттегез. Нипман калдыклары.

Бикәй ишекне каты бәреп чыгып китте. Чынлабрак уйлаганда, бу Чукрак Зариф ишеген бәрү генә түгел, бу — революциянең шул чордагы вакытлы сәясәтеннән исереп, череп баеп калырга исәп тоткан беркатлы яңа буржуаның ишеге гомумән тиздән шулай каты бәрелеп ябылачагына бер ишарә иде.

1973

## Нури Арсланов

### Мин тауларга карыйм

Кайда сез, әй, сабый хыялында
Болытларга менгән кыялар,
Карагайлар явы, кара таштан
Калкан булып баскан коймалар?!.

Каркаралым! Ярты гасырдан соң
Чирәмеңә ятып аунадым.
Әллә инде мин зур үскәнгәме,
Кечерәйгәннәр хәзер тауларың.

Ай-Петриләр, Биштау, Алатаулар
Мәһабәтен күздән кичергәч,
Илләр, юллар йөртеп, сагындырып,
Еллар мине сиңа китергәч,

Мин аптырап калдым... үзгәрешләр
Туса туа икән җаныңда! —
Юкса, шунда алтын кояш белән
Сөйләштем бит сабый чагымда!

Шунда вәхый алдым шигърияттән,
Шунда илһам серен төшендем!
Кабат килдем менә дулкынланып, —
Керфекләрем түбән төшердем...

Һәммәсе дә монда җанга якын,
Узган яшьлек кебек кадерле.
Элеккедәй тик мәһабәт түгел,
Шул, ахрысы, өзде бәгырьне...

Кайчандыр чын мәгъбуд [1] иткәннәрем
Гади булып баскач алдыма,
Тик алданып йөргән икәнмен, дип
Уйладым мин...
Бер көн аңымда

Хәзергем дә шулай гына булып
Гәүдәләнсә... коткар бу хәлдән!
Мин Каркарал тауларына карыйм,
Керфекләрем җиргә төбәлгән...

[1] Мәгъбуд — алла — кумир.

## Онытасым юк

Әллә нигә моңсу иде ул көн,
Ап-ак иде дөнья... Хәтердә,
Үзгәрмәде кум-кук урман гына, —
Төренмичә торды кәфенгә.

Уйнап йөри идек тау башында,
Ак карларга батып кәмәрдән [1].
Айгайлады [2] шунда бер азамат,
Тынып калдык шомлы хәбәрдән:

«Ленин үлгән!..»
Без нардомга.
Сәхнә.
Кызыл постау, кара тасмалы,
Монда икән бүген кара көйгән
Кайгыларның хәттән ашканы...

Яшьләренә буылып ораторлар
Сөйли Ленин ятим иткәнен...
Бу сүз миңа таныш, күптән беләм
Ятимлекнең нәрсә икәнен.

Ләкин, гаҗәп, андый вакытларда
Сабый күңеле сүлпән үзгәрә.
Тик олылар елаганны күргәч,
Бик ямансу булды безгә дә...

Каркаралым! Таулар, кыяларың
Күтәрделәр мине күгемә.
Зур тетрәүләр синдә кичергәнгә
Күрә, ахры,
син гел күңелдә!

Ак кәфендә иде ул көн таулар...
Онытасым юк, айкап томагын [3],
Үзәк өзгеч оран салып тауда
Яшь казакъның басып торганын.

## Тузмый икән

Иртешкә төшмә икән,
Суларын эчмә икән:
Сабый чакның сагышлары
Үзәккә төшкән икән...

Пароход тавышлары...
Мәхәббәт язмышлары:
Чын күңелдән сөйгәннәрнең
Бар микән кавышканы?

Нәфисәм — җан арманым [4],
Бәхеткә саралмадым,
Күзгә сөрмә итәр идем,
Туфрагың табалмадым.

Йөрәкнең кузгалганы,
Күңелнең сызлаулары,
Башларым була дивана,
Уйласам узганнарны.

---

[1] Кәмәр — билбау
[2] Айгайлады — кычкырды (казакъча).
[3] Томак — бүрек.
[4] Арман — теләк, омтылыш.

Узмаса узмый икән,
Вакытлар бозмый икән,
И кадерле хатирәләр!
Таушалмый, тузмый икән.

## Мин табынам сиңа

Мин табынам сиңа!
Синең белән
Шундый рәхәт, шундый күңелле! —
Узган гомер — сары яфрак, диләр,
Ничек диләр калган гомерне?!.

Арабызда аз түгел шул еллар...
Син туганда, менеп атларга,
Бәйге даулап, ерак ярышларда
Мин йөргәнмен егет чакларда.

Кабатланмас яшьлек итеп кенә
Яратма син мине юатып,
Кабатланмас кеше итеп ярат,
Яраталсаң, акылың югалтып!

Күз төсләре иңмәс аңа карап,
Яшел язга — сиңа,
әйдә бер
Буталсынчы дөнья, гомер фаслы, —
Күзләремне язга әйләндер!

Мин табынам сиңа!
Син моңаеп
Кул изисең киек казларга, —
Сарган сине гаҗәп алтын дөнья,
Тылсымлаган күзге манзара...

## Әүпелдәк

«Һауп, һауп!» тавыш бирә иде кемдер күлдән,
Җәйге төндә,
каушый идем мин ул өннән;
Үзе шундый шомлы иде, үзе серле!
Ул сер миңа озак ачылмыйча йөрде,—

Ни икәнен беркем әйтеп биралмады.
Сабый чаклар үтте... Белдем мин аннары,
Баксаң, ул һич тә сер түгел икән байгош,
Булып чыкты сазда яши торган бер кош.

Тормышка да каушый-кызыга кирәбез дә,
Серен вакыт иплəп ачып бирә безгә:
Тәҗрибәләр таудай үскәч,
бара-бара,
Тереклек тә әүпелдәккә [1] охшап кала.

[1] Әүпелдәк — саз кошы күлбоганың казакъча атамасы.

## Тургай һәлакәте

Бер карчыга төште тургай артына,
Тургай мескен котылмакчы, талпына...

Карчыганың килә шул җим аласы,
Ә тургайның килә исән каласы.

Орчык кебек бөтерелә тургаем.
Менә явыз тотып алды корбанын...

Табигать тә явызлыкка корылган,
Үзгәртү тик килә кеше кулыннан!

## Баян-Сылу

Баянаула башыннан болыт китмәс,
Төлкегә кыядагы кошым җитмәс...

*Казакъ халык җыры.*

Баянаула, Баянаула! [1]
Баян-Сылу җырлый тауда.
Моңы килә, сүзе килә,
Тик күренми үзе нигә?
Ташлар миңа сер сөйлиләр:
— Баян-Сылу монда, — диләр, —
Син шикләнмә, ышан безгә,
Табыйм дисәң — таудан эзлә.

Баян-Сылу күзендә яшь:
Сөйгән яры — Кузы-Күрпәш,
Кирәкми, ди, аңа үзгә,
Шуңа күренми, ди, күзгә.
Күлләр миңа сер сөйлиләр:
— Баян-Сылу монда, — диләр, —
Бик тирәндә, төптә ята,
Ташлар юкны сөйли — хата!

Баян-Сылу җырлый, җырлый...
Ярын эзли елый-елый:
Кузы-Күрпәш тауда икән,
Төлке куа — ауда икән.
Карагайлар сер сөйлиләр
Миңа: — Сылу монда, — диләр, —
Ышанма син күлгә, ташка,
Бездән эзләп кара башта...

Бөтен җирдә Баян-Сылу,
Әкиятләрдә хәйран сылу,
Яши һаман күңелләрдә,
Күчеп илләр, гомерләргә!
Думбырада өзә генә, —
Үтә моңы үзегеңә!
Баян-Сылу, Баян-Сылу,
Тик күренми күзгә генә...

Баянаула, Баянаула!
Баян-Сылу йөри тауда,
Син кайларда, Кузы-Күрпәш?!
Баян-Сылу күзендә яшь...

1973—74.

---

[1] Җырларда Баян-Аул шулай җырлана. Шуңа монда да Баянаула дип алынды.

## Гәрәй Рәхим

### Бу дөньяда

Бу дөньяда мин дә бер генә кеше,
Бу дөньяда син дә бер генә кеше.
Бу дөньяда күп түгел без;
Ничә мең генә кеше.
Ничә мең генә кешенең
Ничә мең генә уе...
Уйларны килештералмый
Яшибез гомер буе.

Бу дөньяда мин үземчә хаклы ич,
Бу дөньяда син үзеңчә хаклы ич,
Бу дөньяда мең-мең ирнең
Меңе меңчә хаклы ич.
Мең ирнең мең хаклыгына
Бер урта табып кара.
Шул уртаны әзли-әзли,
Гомерләр үтеп бара.

Бу дөньяга мин дә мәңге килмәгән,
Бу дөньяга син дә мәңге килмәгән.
Бу дөньяга бер адәм дә
Мәңге килдем димәгән.
Мәңге килдем димәсә дә,
Кем үләргә җан ата?!
Яшәү өчен тартышабыз,
Ә гомер агып ята.

Бу дөньяда син дә яшәргә тиеш,
Бу дөньяда мин дә яшәргә тиеш.
Бу дөньяда ничә кем бар
Хет бер яшьнәргә тиеш.
Яшьнәгәндә кемдер янар
Соңгы йолдызлар сыман...
Тик исәннәр Кеше булсын,
Янмасын җирдә иман.

•

Назлы сүзне көчәнмичә әйтәм,
Кычкырамын талларымны кочып.
Явызлыклар күрсәм тыным бетә,
Нәфрәт сүзем чыга тешне кысып.

Назлар безне шундый киңәйтәләр —
Дөнья шулай яраткандыр инде.
Явызлыклар кара ярык сыман —
Үзен-үзе тарайткандыр инде.

Адәм баласының холкы гаҗәп:
Бер-бер наздан җиргә шәрран яра.
Ә башына актарылып төшкән
Явызлыкны эчкә йотып бара.

## Кайчагында...

Кайчагында күңел купшылана,
Гел мактыйсы килә дусларны.
«Үзем артык кырыстырмын», — диеп,
Гафу итәм хәтта дошманны.

Сөйгәнемнең ташлап китүен дә
Мин үземнән күрәм, дивана.
Бүген дуслар мине аңламаса,
Киләчәк бар, диеп юанам.

Як-ягыма сибәм гел юмартлык.
Моны күпләр сизеп торалар.
Кайберәүләр минем изгелектән
Шәхси файда сөзеп торалар.
Шактый файда сөзеп торалар.

Мондый халәт ләкин озак бармый,
Бик тиз кырыслана юмарт җан.
Ах, син, дөнья, алдыйсың бит, дим дә,
Мин усалланам.

•

Көннәр үткән саен
Дуслар киңәш бирә:
— Син яздай яшь әле,
Гел алга бар, — диләр.
«Бик ашыкма, дустым,
Өлгерерсең кышка,
Син язда кал әле!» — димиләр.

Еллар үткән саен
Дуслар киңәш бирә:
— Инде җаең җитте,
Тукта, уйлан, — диләр.
«Еллар узып бара,
Көчең бар чагында
Язга чыгып өлгер!» — димиләр.

Гомер үткән саен
Дуслар киңәш бирә:
— Гомер көзең җитте,
Инде ялга чыгып
Тыныч кына яшә син, — диләр.
«Картаясың, дустым,
Дулап язга чык та
Мәңге язда кал син!» — димиләр.

●

Монда апрель...
Анда син...
Сез никадәр пар килгәнсез —
Икегез тиң.
Тамчылар кабатлый:
— Тиң... тиң...
Гөрләвек челтери:
— Тиң... тиң....
Бозлы тупыл ботаклары
Чеңгелдиләр:
— Тиң... тиң...

Менә апрель узып китте.
Тамчылар да туктадылар.
Гөрләвекләр челтерәми.
Тупыллар да шау яфракта —
Ботаклары чеңгелдәми.

Китте инде, китте апрель,
Ә син, иркәм, кил миңа,
Кил!
Тамчылардан башка гына,
Гөрләвектән башка гына,
Тупыллардан башка гына
Чакырамын:
Кил миңа,
Кил!

## Мин бүген дә сине сагындым

Язның моңсулыгын сылтау итеп,
Мин бүген дә сине сагындым.
Җилләр булып иссте хатирәләр —
Җилдә учак булып кабындым.

Ул көннәргә инде чыклар төшкән,
Чык астында яна чәчәкләр.
Бүген инде тәрәз каршысында
Шаулап үсә яңа чәчәкләр.

Язның моңсулыгы сылтау гына —
Мин сагынам узган кышларны.
Узган җәйләр, көзләр сагындыра —
Сагынулар никтер ешлады.

Бу моңлану бәлки кыендыр да,
Тик теләгем минем саф, әйбәт —
Күңелләрдә булсын моңлану да,
Киләчәккә барсын мәхәббәт.

●

Аланнарда үсә гел балан,
Аланнарга кереп югалам.
Туган җирем, мин бит сине сөеп
Аланыңда үскән бер балан.

●

*Мәхтүмколыйга*

Әйткән идең: мин бу җирдә
Бары тик кунак кына.
Дөрес әйттең! Син — кунак, тик
Мәңгелек кунак монда.

●

Замана, кырыс замана,
Якадан тота-тота,
Өйрәтә мине ныклыкка,
Назларны йота-йота.

●

Шартлатып бер әйтер сүзең булса,
Җирдә яшәү әле ярап тора.
Бер юньле сүз әйтче, дигән сыман,
Дөнья минем күзгә карап тора.

•

Ялгызлык ямьсез икән.
Ялгыз эчкәч, хәтта туган
Як суы тәмсез икән.

•

Гамьсезлекне начар гадәт диеп,
Ачулана мине дусларым.
Гамьсезлеккә ләкин өйрәндем мин
Гамьсезлеген күреп дусларның.

•

Безнең әле үсмер чагыбыз,
Безнең әле үткер чагыбыз.
Кайгыларны салып сандалга,
Шатлык итеп чүкер чагыбыз.

•

Мин әлегә сөю тезгеннәрен
Сабыр агачына бәйләп торам.
Тик түзмәс ат,
        өзәр бу тезгенне,
Шуны шәйләп торам.

1973

**Үзбәк Саттаров**

# АЙЛЫ ТӨНДӘ

**хикәя**

Таң ата башлады... Зәй суының аръягындагы урман артыннан күтәрелгән тулы ай җир өстен көмешләнде. Галимә апа җиңелчә салкынлык сизеп, иңбашына юка мамык шәлен бөркәнде дә тәрәзә янына килеп басты. Тәрәзә ачык иде. Борыннарын кытыклап кергән иртәнге саф һава күкрәкләрен тутырды. Ул, көрсенеп, тирән итеп сулап алды да, ияге белән таянып, тәрәзә төбенә килеп ятты.

Әнә кулыңны сузсаң буй җитәрлек ераклыкта алма агачының ботаклары. Әмма ул ботаклар да Галимә апа сыман башларын аска игәннәр кебек. Галимә апа аларга күзләрен тутырып карады. Тулы ай яктысында аларның ботаклары гына түгел, хәтта яфрак аслары да күренеп торырлык булса да, ул берни дә күрмәде, — үз уен уйлады.

Уйланырсың да шул, көн дә вакытында кайтып йокларга ята торган бердәнбер җитеп беткән кызың таң аткан вакытта да өйдә булмасын әле!

Аның сул кулы, ирексез, тышкы якка асылынып төште. Ни эшләгәнен дә белмичә, ул бармак очлары белән кулына беренче очраган үлән яфракларын эләктерде. Аның бармаклары ихтыярсыз ул үләнне учына кысып уа башлады. Аның борынына әрем исе килеп бәрелде. Ул учы белән әрем сабагын сындырып алып, әрем яфракларын һәм чәчәкләрен бергә изеп, борыны астына ук китерде. Аның башында кайнаган фикерләр арасына тагын бер фикер кереп кысылды:

«Нинди яхшы ис бу чәчәк ата торган әрем исе, гомер буе иснәп канга сеңгән хуш ис! Әремне гел ачы гына диләр, әмма аның борыннарны кытыкландырган хуш исен мактап бер генә сүз дә әйткән кеше юк. Болыннарда, басуларда, авылларда әрем булмаса, әллә нинди җитди нәрсә җитмәгән кебек булыр иде».

Галимә апа аңын җыеп, бер алма агачына, бер әрем сабагына карады. Әрем сабаклары нигез буйлап үскәннәр. Кызы Сәйдә эше инде,— ул аларны тигезләп кыркып чыккан. Әремнәр кырыеннан тар гына сукмак бара. Сукмакны капларга теләгәндәй, бәбкә үләне сукмак өстенә чыга. Сукмакның икенче ягында ук чәчәк түтәле. Никтер, соңгы вакытта Сәйдә бик ярата башлады шул чәчәкләрне. Иртән торгач, беренче эше — бакчага йөгерү. Кичтән әзерләп куйган җылы суы белән ул аларны коендыра-юа. Кайсы куакның кайчан чәчәк атканын гына түгел, кайчан ата-

чагына чаклы ук алдан белеп тора. Балалар ата-анасына охшаган була, диләр. Һич дөрес түгел. Мин үзем гомерем буе бер чәчәк тә утыртып үстермәдем... Бәлки әтисеннән алгандыр ул бу сыйфатын... әтисе бит мине һәр вакыт сирень, шомырт чәчәкләренә чумдыра иде, кыңгырау чәчәкнең, я булмаса басуны басып бетергән зәңгәр чәчәкләрнең матурлыгына сокланып, шуларны минем өчен җыеп вакытын әрәм итә иде.

Тынлык. Әнә уң як күршеләрнең әтәче, сузып-сузып, матур итеп ике тапкыр кычкырды. Аңа җавап биргән кебек Уртакуш болыны ягыннан тартайның кычкыруы авыл өстеннән тәгәрәп үтеп, Зәй буендагы таулар арасына кереп югалды.

Стенада сәгать сугуы Галимә апаны уйларыннан айнытып җибәрде. Үзе дә сизмәстән, ул тәрәзә төбеннән торды, кулындагы әрем яфракларын кая куярга белмичә, бераз уйланып торды да, аннары аларны тәрәзә аша бакчага ташлады. Ирексездән ул иснәп җибәрде. Кангa сеңгән гадәт бит — янында аңа карап торучы бер генә җан иясе булмаса да, сул кулы белән авызын каплады. Иснәп бетерүгә, кулын авызы янынннан алганда баш бармагы белән иреннәренең сул ягын, имән һәм урта бармаклары белән авызының уң ягын сыпырып алды. Аның авызына бармакларыннан әрем ачысы тулды.

— Күңелемдәге ачы җитмәгән, авызыма да ачы тулды тагы,— дип зарланып алды да, ни эшләгәнен аңламаган кеше сыман, юынгыч янына килеп, ашыга-ашыга кулларын-битләрен юа башлады.

Су Галимә апаның йокысын тәмам качырды. Аның башына келт итеп, «Болай Сәйдәнең кайтуын көтеп тик ятуның файдасы аз, чыгып эзләп керим әле!» — дигән уй килде.

Күлмәген кигәч, автоматлашып беткән гадәте буенча, стенага элгән көзгесе алдына килеп, бармаклары-куллары белән генә чәчләрен сыйпап алды да ишек ягына юнәлде. Ишек тоткасына кулы тигәч кенә күңеленә:

— Аны эзләп кая барырга соң? — дигән сорау килде.

Кирәргә-чыгарга теләгән кешеләргә еллар буе хезмәт итеп шомарып беткән ишек тоткасын учлап, Галимә апа тагы уйга батты:

— Кая барырга?..

Сәйдә бит Галимәападан бер генә серен дә яшерми иде кебек. Галимә апа Сәйдәнең барлык дусларын да, танышларын да яхшы беләм дип исәпли иде. Шул Рәшит белән микәнни? Алай дисәң, Рәшитне яратуымны-яратмавымны үзем дә белмим әле, — ди иде бит Сәйдә! Әллә кайбер серләрен миннән яшерә торган начар гадәткә өйрәндеме икән? Тиз генә кайтмаслык җиргә киткәч, нигә өстәл өстендә печтек кенә язу булса да калдырып китмәскә?

Күрше әтәченең ачы аваз белән кычкырып җибәрүе Галимә апаның барлык фикерләрен кинәт өзде. Ул тәвәккәллек белән ишекне ачты да ишегалдына чыкты.

Яктылык тышта тагы да көчәйгән. Үләннәргә чык төшә башлаган. Галимә апа өй ишеге белән капка арасына моннан егерме ел элек ире белән бергә тезгән яссы шома ташлар өстеннән китмәде, ә үлән өстеннән китте. Ул ике-өч адым ясарга өлгермәде, аяк буйлап тәнгә рәхәт итеп чык салкыны йөгерде, үләннәрдән күтәрелгән алма исе сулышны каплады. Әллә рәхәтлеген озаграк тояр өченме, әллә инде ирен искә төшерепме, Галимә апа шул юлга карап тагы уйга калды.

Әнә ул чирәмнәр арасында матур таңда ялтырап ята торган ак таш юл. Галимә апа ул ташларның ничек җәелгәнен генә түгел, һәрбер ташны аерым-аерым кайдан һәм ничек алып кайтканнарына кадәр хәтерли. Гомер буе бергә йөрергә дип тезделәр алар ул ташларны һәм ишегалларына тәмле алма исе тарата торган ромашка да чәчтеләр. Анысын да гомер буе бергә иснәргә дип. Әмма... бу юлдан алар бергә озак йөри алмадылар. Дөньяда иренең мәңгелек җанлы хәтирәсе булып Сәйдә генә калды.

Әтисез Сәйдә, ирсез Галимә апа икәү генә калсалар да, күп йөреп шулай ялтыратып бетерделәр ул ташларны!

Бу гади таш юл түгел, хасиятле таш юл бу. Аның хасиятләре бик күп: мисал өчен, ул юлдан капкага табан да, ишеккә табан да вакытында гына үтәргә кирәк; ул юлга юньсезләрнең аяк басуы һич кирәкми; ул юлга үзенә дә, башкаларга да саф күңел, керсез намус белән генә басарга кирәк.

— Их, кызым, аякларың бу юл буйлап капкадан ишеккә таба вакытында атлаган булса соң, — дип уфтанып алды Галимә апа.

Барып җитеп капка келәсенә тотынуга, күршеләрнең этләре тавыш куптарды. Янәсе, кем ул анда вакытсыз йөри. Галимә апа тавышын тану белән эт тынычланып, урынына барып ятты да, «йөри шунда безне борчып» дигән сыман итеп, ыңгырашып куйды.

Галимә апа урам буйлап югары очка менеп китте. Бар кеше йоклый. Таң яктысы ай яктысыннан күп көчле: төньяк-көнчыгыштагы алсу-ак кызыллык шактый югары күтәрелде инде.

Табигать уянып килә, менә тиздән авыл да уяныр. Чык көчәйде, йөргәндә чирәмнән чыксаң, табан астына ябыша, чирәмнән барсаң, аяк юешләнә.

Гамьсез казлар, сарыклар һәм кәҗәләр өйләренә кайтмыйча, урамда куналар. Аларны беркем дә эзләми. Аларга теләсә кайда кунарга ярый. Ә менә Сәйдәгә теләсә кайда куну түгел, соңгарак калып кайтырга да ярамый. Шулай уйлана-уйлана бара торгач, Галимә апа авылның читенә җитүен сизми дә калды. Борылып, күрше урамга чыкты, менә фермалар янына җитте, анда да тынлык. Урамның икенче башыннан әйләнеп, өйләренә кайтып керде, ышанычын, тәрәген югалткан кеше кебек өметсезләнеп, киенгән килеш койкасына ауды да, тавышсыз гына, нигә икәнен үзе дә белмичә елый башлады. Бераз шулай яткач, күңеленә ниндидер шом төште, чөнки тирә-як шундый тынычланды ки, хәтта стенадагы сәгатьнең йөрүе аның колагына барабан каккан кебек, ә мич астындагы чикерткәнең чырлап куюы скрипка кылын сызган кебек ишетелә башлады. Менә шунда ишегалдындагы таш юл буйлап ишеккә таба килүче таныш тавыш ишетелде. Сәйдә кайтып керде.

Галимә апа шунда ук урыныннан сикереп торды да, кызын баштан-аяк карап чыкты. Нидер әйтергә теләде, әмма сүз таба алмады.

Сәйдә дә әнисенә бик озак карап тик торды, шулай да ул аның өске күлмәген салмаган икәнен дә, елаган икәнен дә күрми дә торгандыр әле. Шулай да сүзне Галимә апа башлады:

— Кызым, сиңа ни булды?

Сәйдә ни дип җавап бирергә аптырап калды. «Берни дә булмады» дисә, дөрес түгел, чөнки аның өчен бүген кызлар гомерендә бер генә тапкыр була торган вакыйга булды. Ә ни булганын бер сүз белән ничек аңлатасың, әнисенең башкача аңлавы бар.

— Син кайда булдың?

Бу сорауга җавап бирү җиңелрәк, әмма туп-туры кая булганлыкны әйтсәң, аңлашылмау чыгуы бар.

Галимә апа акрын гына кызы янына килә башлады.

Сәйдә аптырашка төште — чигенергәме, әллә басып торган урында калыргамы?

— Кем белән булдың?

Галимә апа соравын әйтеп өлгермәде, Сәйдә кулларын җәеп әнисенең кочагына ташланды.

— Әнием!

Галимә апаның кызын этеп җибәрергә батырчылыгы җитмәде. Алар икесе кочакланышып дәррәү елый башладылар. Озак еладылар. Кайсының ни уйлап, ни өчен елаганын аларны үз күзе белән карап торган кеше дә әйтә алмас иде, әлбәттә.

Галимә апа, әле һаман елый-елый, көрсенеп җибәрде.
Сүзне ул башлады:
— Кем белән?
— Беләсең ич — Рәшит белән...
— Кайда булдыгыз?
— Уртакуш урманында...
— Анда ничек бардыгыз?
— Җәяү бардык, җәяү кайттык, шуңа күрә соңга калдык.
Сәйдә сөйләвеннән туктады, уйга калды. Әнисе туп-туры итеп аның күзләренә карады. Нинди матур күзләр! Нәкь этисенең күзләре! Тирән, саф, намуслы күзләр. Андый күзләр алдамыйлар! Әнисе Сәйдәне күкрәгенә кысты. Алар бик озак берсенең йөрәге ничек типкәнен икенчесе тоеп утырдылар.
— Әнием дим, Рәшит матур да, батыр да...
— Уртакуш урманында түгәрәк күлне күрдегезме соң?
— Күрдек...
— Аңа таш ыргыттыгызмы?
— Ыргыттык...
— Су өстенә син җәелдергән дулкыннар үзәгенә Рәшит таш аттымы?
— Атты, һәр вакыт нәкъ үзәгенә генә төшерә алды!
— Улаклы чишмәдән су эчтегезме?
— Эчтек...
— Җиргә ятыпмы?
— Әйе, әнием, җиргә ятып.
— Карт юкә төбендә утырдыгызмы?
— Утырдык...
— Ул сине үптеме?
— Үпте...
— Аннан соң умарталык тирәсен ничә кат әйләндегез?
— Өч кат... Син, әнием, боларның барысын да каян беләсең?
Галимә апа бераз уйланып торды да:
— Кызым, быел көз көне туегыз булачак икән, — дип, бик катгый нәтиҗә ясады.
— Әнием, нигә алай дисең?
— Соң, кызым, без дә шулай этиең белән бер җәйне Уртакушка җәяү барып, җәяү кайттык та көзен туй ясадык. Умарталыкны без ике генә кат әйләнгән идек. Калган барысы да нәкь син сөйләгәнчә!

Әнәс Камал

# ОЛЫ ӘКБӘРНЕҢ КЕЧЕ ӘСГАРЕ

*«Галиәсгар Камал турында хикәяләр» китабыннан*

Эңгер-меңгеррәк таң алды булса да, күк йөзе аяз.

Мәчет манарасында, түбә кыегы астында гөр килгән күгәрченнәр өши торган зыкы салкын. Тротуарларда ялварулы кара тәпиләрен тырпайтып туңып яткан чыпчыклар да очрый. Ялгыш кына тышка чыккан мәчеләрнең дә күзләренә ак-кара күренми: җан-фәрманга атыла-бәрелә элдертәләр генә!.. Үсеп утырган юан агачларга кадәр, телеграмм баганаларына кадәр чатнап ярыла. Су китерүче хатын-кызларның чиләк авызларында су өсте мөлдерәмә килеш ката, таеп егылсаң да, түгелерлек түгел. Түкерсәң, төкерегең җирдә борчак булып тәгәри. Зәмһәрир салкыннары шушыдыр, күрәсең!

Болакның бирге ягында, Иске бистәдәге янтык йортларның кыйшык морҗаларыннан һавага тып-туры төтен баганалары күтәрелә. Бу иске бистәдә өчәр-икешәр катлы таш пулатлар да бар. Аларның морҗалары күренмәсә дә, төтеннәре, ярлы йортларыныкы шикелле үк, багана булып өскә күтәрелә икән.

Тихвинский чиркәвендә төнозын кыңгырау кагып чыктылар. Бүген Рождество — урысларның тәре мана торган бәйрәме. Шунлыктан, Казанның бүтән чиркәүләре дә, берсеннән-берсе уздырырга теләгәндәй, чаң-чаң, даң-доң килеп, колакларны тондыралар... «Шушы салкында ничек чишенеп суга кермәк кирәк?» — дип уйланды иртәнге намазга ашыккан Галиәкбәр абзый.

Чиркәү тыкрыгына каршы чатта Кызыл мәчет. Манарада мәзин азан әйтә. Колак каккан саен ялан кулларын тизрәк төшереп, тун җиңнәре эченә тыгып алырга ашыга. Галиәкбәр абзыйга үз мәхәлләсендәге мөэмин-мөселманнарны шундый салкында, шул кадәр югарыга менеп, намазга өндәүче мәзин дә кызганыч тоелды. «Көненә биш тапкыр шунда менеп-төшеп йөр инде... Я хода, үзең савабын иңдер! Ярлыка без гөнаһлы бәндәләреңне!»

Урамнан үрәчәле чаналарга утын, тире-яры, чыпта-мунчала төягән, чикмән-толып якаларын күтәргән, чыбыркыларын өстерәгән олаучылар уза. Алҗыган атларның да сыртлары, керфекләре ап-ак. Авыр, зур башларын түбән салындырып, абына-сөртенә генә атлыйлар. Дагасыз атларның хәлләре бигрәк тә мөшкел.

Йөкчеләрнең кайсылары Кабан күленә — Печән базарына таба, кайсылары вокзалга — Агач базарына таба уза. Агач базары чатындагы каравыл будкасыннан башына соры постау башлык, өстенә толып, аягына чуар кызыл киез итек кигән бутышник туп шикелле атылып чыга да, утынчыларга тупас акырып, будка янындагы гөрләп янган учакка төртеп кенә күрсәтә. Янәсе, сезнең өчен шушы салкында тәртип саклап торучыга бурычыгызны калдырып китегез! Тегеләре авыр сулап кына йөкләреннән берәр пүләнне учакка ыргытып китеп баралар. Бутышникның җирән мыекларына боз каткан. Тула оек өстеннән кыска куныччлы киез ката яки агач башмак өстерәгән карт-коры мәчеткә ашыга. Зыкы салкыннан болай да шаңгырдап торган аяк асты, лыштырдык кәвеш, шыпылдык башмак тавышларыннан тагын да ныграк яңгырый. Әйтерсең лә тормышның бәгыренә суык үтәли сеңгән дә, ул шулай туң бозга әверелгән!..

Мәчет чатыннан тирес башына — ике бистә арасына төшеп китә торган тыкрыкны Аркылы Тихвинский урамы[1] дип йөртәләр. Иртә намазын укып чыккач, Галиәкбәр абзый шул тыкрыкның түбән очына таба атлады. Бу тыкрыкта өч катлы бер яшел пулат бар. Ямшекләр йөртүче, двор ие тотучы Субор Хәйрулла йорты ул.

Болак артының бу бистәсендә күбесенчә һөнәрчеләр, читек-кәвешчеләр, ломовой ямшеклар, крушниклар, иске-москычылар, ялчылар, хәерчеләр яши. Йомран Җамалый, Кәвешче Садыйк, Сая Ибрай, Маҗар Фазлый, Суксу Ярулла, Битаман Зариф кебек үз йортлары, кибетләре булган хәлле кешеләр — байлар да юк түгел. Мондыйларның исемнәренә туган авылларының исемнәре генә кушымта итеп тагыла. Болар үз товарлары белән Мәкәрҗә, Эрбет, Минзәлә ярминкәләренә дә йөри алучылар. Үзләре берни эшләмәсәләр дә: «Бөтен ярлыябагайларны без тукландырып, без яшәтеп киләбез»,— дип күкрәк кагучылар. Алар көн-төн бил бөгүче, тир түгүче һөнәрчеләр исәбенә корсак симертәләр һәм үз кул асларындагы барлык эшче кешеләрне «вак халык» дип кенә йөртәләр. Аларга: зимагур Сиби, Дәһри-Мәһди, чүпрәкче Гыйльмулла, корымчы Корбай, йомыркачы Шәрәфи, кәләвәче Нурый, күмерче Ибни, күмәчче Гатаулла, гармунчы Садыйк, ташъяк Исмәгыйл, имансыз Иманай кебек кимсетүле кушаматлар тагалар.

Шундый вак халыклардан саналган «камчатчы Галиәкбәр» абзый да, сузан гәүдәсен дугадай бөгеп, Субор Хәйрулла пулатының[2] таш капкасы аша ишегалдына үтте. Ул өченче катта, өч тәрәзәле фатир биләп гомер итә. Аның кәсебе — чүпкә чыккан вак мех кисәкләрен эшкә кертү. Андыйларны скорняк дип атыйлар. Ул вак мех кыйпылчыкларын төсен төскә китереп ялгый. Камчат, кама, каракүл кисәкләреннән бүрек кырпулары, тун әйләнәләре, тун эчлекләре оештыра. Иске мехларны яңага әйләндерә: буйый, кырка, тарап шомарта. Ул эшкәрткән якалар елкылдап, тоташ мех сыман булып тора. Ул теккән тире бияләй эчендә кулларың майда гына йөри. Әгәр дә читегеңне эт тиресе белән эчләп бирә икән, Кукмара киез итекләре бер якта торсын, һәм синең аякларың гомер-гомергә зәңгелә зәхмәтен күрмәячәк!

---

[1] Соңрак Фуксовская, хәзер Г. Камал урамы — автор.
[2] Хәзерге Г. Камал урамы, 29 нчы йорт.

Ул үзе Арча ягыныкы, тирә-якта киез итек басучылары белән танылган Сикертән авылыннан. Балалары күплектән иза чиккән атасы Камалетдин аны, һич югында, бер кашык ким булыр дип, унике яшеннән үк Казанга, байга асрамга китереп тапшырган. Башта Галиәкбәр йорт-кибет арасында йомышка-юлга йөри торган булса, торабара байның мастеровойлары арасында скорняклык һөнәренә өйрәнә һәм үз тырышлыгы аркасында шушы эшнең остасына әйләнә.

Хәзер аңа егерме тугыз яшь. Ләкин сирәк булса да чал бөртекләре күренгән кызгылт-көрән сакалына, коелган чәчләренә һәм куе салынкы кашларына караганда, ул инде шактый олы яшьтә булып күренә. Алгарак чыгып торган киң маңгае өстендәге тирән җыерчыклар, бигрәк тә төбәлсә өтеп ала торган күз карашлары, бу кешенең шактый кырыс һәм зур ихтыяр көченә ия булганлыгын раслап тора. Гәүдәгә сузан булса да, гел утырып эшләүдән җилкәләре тәмам бөкрәйгән. Хәрәкәтләре саллы, салмак. Колаклары дәү, имән яфрагын хәтерләтә. Колак димәктән, аны атасы Казанга ялчылыкка китергән чактагы бер хәлне искә төшереп үтик.

Күрер күзгә сыек, сузан һәм кирәгеннән артык арык булган бу малайны бер генә сәүдәгәр дә ошатмый. Аны кайсы гына байга күрсәтмәсеннәр, әрәмтамак булыр бу, дип кенә карыйлар. Байдан байга йөри торгач, ата белән улы Захарский дигән урамга[1] барып чыгалар һәм Кушлавыч Мифти атлы бер сәүдәгәрнең йортына керәләр. Мифти бай Галиәкбәрне сынарга, адәм мәсхәрәсе ясап калдырырга чамалый. Аның алдына бер табак кайнар ясмык өйрәсе һәм бер бөтен ипи китереп куйдырта да:

— Яле, малай актыгы, эшкә ураклымы, юкмы икәнлегеңне ашавың белән исбат ит! — ди.

Галиәкбәр исә аптырап-куркып калмый, иң әүвәл ипләп кенә теге бер бөтен ипине пычак белән урталайга кисеп, яртысын читкәрәк этеп куя да «эшкә» керешә.

Мифти бай малайның башта ук шүрләвеннән кәефләнеп:

— Әһә, котың алындымыни? Нигә дип бер бөтенен үк ашап ташламаска?! — дип көләргә тотына.

— Мин әлегә үзем дә яртылаш кына кеше! — ди аңа Галиәкбәр. — Иртәгәгә дигәнне бүгеннән үк ашап бетерсәң, гомергә икмәк чырае күрмәвең бар.

Байга баланың тапкыр җавабы ошый, ләкин аңа сиздермәскә тырышып, эченнән тына һәм, монысын ни эшләтер икән бу йолкыш дип, тизрәк кайнар өйрәне ашарга кыстый.

Галиәкбәр һич тә ашыкмыйча гына әлеге ярты бөтен ипине телемнәргә турый, аннан соң ашъяулык өстендәге ипи валчыкларын чүпләргә керешә. Мифти байга малайның болай мыштырдавы ошамый башлый.

— Әйдә, әйдә, Әкбәр атлы икәнсең, аминыңны тотарга ашык — атыңны җәһәтрәк куала! — дип ашыктыра.

— Хәзер, хәзер, бай абзый,— ди малай, валчыклар чүпләвен дәвам итеп. — Икмәкнең валчыгын да әрәм итәргә ярамый — ул зур гөнаһ!..

Шуннан соң ул ипине зур итеп, ә өйрәне авызын пешермәс өчен аз-азлап кына кабып ашарга керешә.

Такыр, йоп-йомры башның як-ягыннан имән яфрагыдай тырпаеп торган ике колак, бер артка, бер алга кыймылдый һәм кызуланган-

[1] Хәзерге Каюм Насыйри урамы.

нан-кызулана барып, тегермән канатларыдай әйләнергә тотына... Малайның тегермәне шәп тарта — ипи телемнәре бер-бер артлы авызга кереп югала, ә зур агач табактагы өйрә күзгә күренеп кими бара. Озак та көтәргә туры килми — табак төбе ялт итә. Малай хәтта табак кырыйларын да сыпырып, ялап куя. Ярты ипидән дә җилләр исә.

— Аллаһы әкбәр! — дип аминын тота да, бусага төбенә барып, үрә ката малай.

— Бәрәкалла! Инсафлы балага охшый,— ди бай, бу юлы хәйран калуын яшерә алмыйча. — Ярар, калдырып торыгыз, башта тамак ялына хезмәт итәр, өс-башын юнәтүне дә үзем карармын. Рәнҗетмәм. Ашаганда колагы селкенгәннең эшкә йөрәге җилкенгән, диләрме? Шаять, бу малайдан берәр мәгънә чыгар. Зиһенсез дә түгел шикелле.

Шулай итеп, Галиәкбәр шәһәр кешесе булып китә. Нинди генә кыенлыклар күрсә дә, түзеп, байга хезмәт итеп үсә, буйга җитә. Егерме биш яшькә җитеп, өйләнеп туй итәрлек хәле булмауга да карамастан, сер бирми: «Бәхетле чебен ат койрыгы астына яшеренеп булса да шәһәргә керә!» — дип, үзен-үзе юатып йөргән була.

Ниһаять, аңа кыз димлиләр. Масра авылының волость старшинасы, Хәбибулла бай кызы Мәүгыйзә була ул. Масра Галиәкбәрнең туган авылы Сикертәннән өч-дүрт чакрымда гына. «Казан кияве» бай кызына өйләнүнең шактый зур расходларга бәйләнгәнен белсә дә, сынатмаска тырыша, кызны яучылап алырга була. Мәһәр, бирнә мәсьәләләрендә шактый тарткалашулар-сатулашулардан соң, кыз ягыннан да, егет ягыннан да төрле ташламалар ясала һәм килешүгә ирешелә.

Туй расходларын волость старшинасы Хәбибулла үз өстенә ала һәм туйны бик шәп итеп үткәрә. Туйдан соң Галиәкбәр Мәүгыйзәне Сикертәнгә — ата-анасы өенә алып кайта, ләкин үзе Казанга алып барырга һич кенә дә җай таба алмый. Чөнки ул өйләнү мәшәкатьләре белән муеннан бурычка баткан, өстәвенә, аның әле Казанда юньле фатиры да юк. Кыскасы, тормышын азрак җайга салыр өчен аңа яңадан өч-дүрт ел чиләнергә туры килә. Менә шуңа күрә ул үзенең ярты җанын — Мәүгыйзәсен дүрт ел буена авылда, болай да ярлылыктан йөдәгән атасы өендә калдырып торырга мәҗбүр була.

Аның Мәүгыйзәсен үз янына шәһәргә алдыртып яши башлавына бүген нәкъ бер ел. Бүген Галиәкбәр агай өчен тагын бер зур вакыйга булды: бүген, 1878 елның 25 декабрендә, аның Мәүгыйзәсе малай китерде.

Намаздан кайтып кергән Галиәкбәр абзый бусагада кәвешләрен салып калдырып, читекчән генә йомшак басып, беркемгә бер сүз катмыйча гына кече бүлмәгә узды. Нафталин, сумала һәм әчкелт тиреяры исе аңкып торган, ярым караңгы ике тәрәзәле олы якта әбиләр, хатын-кызлар ыгы-зыгы килә. Чуар чаршау белән бүленгән агач караватлы почмактан әледән-әле бәби елаган тавыш ишетелә. Бу тавыш шактый көр булганлыктан, хатын-кызларны каушарга, пышылдап сөйләшергә, җәһәтрәк йөрергә мәҗбүр итә. Аларның толымнарындагы чулпылар да, изү хәситәләрендәге тәңкәләр дә, җиз ләгәнкомганнар да тонык кына чыңлаган сыман тоела. Кулыңны күтәрсәң, түшәменә бармагың тиярлек тәбәнәк һәм озынча бүлмә эченә кайнаган су пары тулган. Ишек ачылып ябылганда тыштан кергән зәһәр салкыннан ул пар тагын да куерып, берни күрә алмаслык хәлгә китерә.

Галиәкбәр абзый кырпулы бүреген, билле тунын салып куйды да төпсез тәпәнгә тире тарттырып ясалган урындыкка утырды. Монда аның мех эшкәртү өстәле. Өстәлдә җеп сыдырта торган балавыз кисәк-

ләре, сумала йомарламнар, яргакланып беткән мех кисү тактасы, күгәргән-тишкәләнгән уймаклар, төрле зурлыктагы энәләр, безләр, өлгеләр. Ишек буенда мех чүбе тутырылган капчыклар. Стенага тун эчлекләре эленгән, киерелгән тиреләр кадакланган...

Галиәкбәр абзый бүреген салып тез өстенә куйды да, кайракланып беткән кәләпүшен маңгаена табарак этәреп, тирән муен чокырын кашыгандай итте. Менә аның улы да булды, менә инде ул чын мәгънәсендә гаилә башлыгы. Аңа хәзер җиңне тагын да ныграк сызганырга, билне тагы да ныграк бөгә төшәргә туры киләчәк. Ай саен Сикертәнгә, фәкыйрьлектән гаҗиз әти-әниләренә җибәрә торган ярдәмне дә кысмыйча булмас... Нишләмәк кирәк соң, үзләрендә дә кытлык. Җитми, җитми... Камчатчының эше — энә белән баз казу! Хәер, эш дигәне өелеп торганда бер хәл. Уймаклар тишкәләнеп, бармаклар уелып каннар тамса да, өчле лампа яктысында төннәр буе утырырга туры килсә дә, баш күтәрмичә эшләргә риза ул. Ләкин заказ китерүче хуҗалар эш хакын киметкәннән-киметә торалар шул. Мәкәрҗә, Эрбет ярминкәләрендә җиңгәчиләрдә типтереп, бөлеп кайталар да шул мутлыклары аркасында әрәм-шәрәм иткән чыгымнарын болай да мохтаҗлыкта интегүче мастеровойлар җилкәсенә салалар. Җитмәсә тагы зарланалар: «Сәүдәләрнең рәте-чираты китте, базар-ярминкәләрне Себер байлары, чит ил сәүдәгәрләре килеп басты, кызыл малны гына түгел, үз малыбызны үзебезгә биш бәягә сата башладылар. Баржа-баржа, вагон-вагон мал төяп, Мәскәвенә дә, Ташкентына да алар йөри. Безнең таварга әйләнеп караучы да юк!» — дип аһ иткән булалар. Шунысы гаҗәп, бу сүзләрне Казанның шактый зур байлары, Җиңги Садыйклар, Фәтхулла Мамаевлар сөйли бит...

Галиәкбәр абзыйның кыяфәте балтасы суга төшкәч аптырашта калган утынчыларныкы сыман. Шулай да бу кырыс табигатьле оста765ның кәефе бүген бераз күтәренке. Калын иреннәрендә бераз елмаю да бар шикелле. Баласы, ир баласы туды бит аның! Мохтаҗлыкка төшеп авылга кайтып торасы булган тәкъдирдә дә ир балага имана бирелә бит! Галиәкбәр абзыйның күгелҗем-кара күзләрендә өмет чаткылары чагыла, кипшергән иреннәре дерелди: «Бәхете-тәүфыйгы белән килсен инде үзе, картлык көннәремдә кул арасына кирәрлек булышчым булсын», — дип пышылдый ул...

Аңа яңа гына коендырылган, биләүгә биләгән улын кертеп күрсәттеләр. Ул бәләкәй генә гәүдәле, җыерчык тәнле, зур башлы, кысык күзле һәм почык борынлы иде. Беренче күрүдә Галиәкбәргә бала бигүк ошап бетмәде. «Шушындый мәхлуктан юньле адәм заты оешыр микән, ходайның хикмәте! Шуны мин «улым» дип тә йөрергә тиешме?» — дип уйлап алды ул. Ләкин кендек әбисе алдында сер бирмәде:

— Карасана, карасана, минем нинди баһадир улым булган!.. һайт, сине, кечкентәй Галиәкбәр! — дигән булды. Нәзек калдырып кырылган мыекларын тырпайтып, авызын чөмәкләндереп чөңгереп, баланы көлдерергә иткән булды. Аннары баланы кулына алып берике тапкыр «үчтеки» иттереп карады. Ләкин бала көләсе урынга, кып-кызыл тешсез утрларын күрсәтеп, кычкырып еларга тотынды. Яшь ата каушап калды һәм баланы кендек әбисенә бирергә мәҗбүр булды.

Галиәкбәр баласына нинди исем кушу хакында уйлана башлады. Башта үз атасы Камалетдин исемен охшатып Җамалетдин дип кушмакчы булган иде, ләкин соңыннан ул уеннан кире кайтты. Бабасының исеме Җомагылга охшашлы исем эзләргә керешә — таба алмады. Шуннан үз исеменә кайтып төште: ул үз исеменең мәгънәсен белә һәм шуңа бик канәгать кеше иде. Үз исеменең мәгънәсен ул

авылда бер мәҗлестә ишеткән иде. Ул бер елны кайнаталарына кунакка кайтты. Аны кияү кеше итеп, зурлап, табын түренә, хәзрәткә янәшәрәк утырттылар. Аш, бәлеш, ит кебек сыйлардан соң, савыт-сабаларны җыеп, чәй хәзерләгән арада, кунаклар хәзрәткә төрле сораулар бирә башладылар. Мулла үзе белгән мәсьәләләр буенча халык телендә җавап биреп, белмәгәннәре хакында башкалар аңламый торган гарәп, фарсы телләрдә сөйләп утырды. Кунакларның күбесе хәзрәт сөйләгәннәргә төшенеп бетмәсәләр дә:

— Бик дөрес аңлаттың, хәзрәт, зур рәхмәт! — дигән булып утырдылар.

Волость старшинасының кияве буларак, Галиәкбәр абзыйга да олылар арасында олыларча булырга кирәк иде — шуңа ул үзенең чи надан икәнлеген белдермәс өчен сүзгә кысылды:

— Хәзрәт, — диде ул, — Галиәкбәр исеменең мәгънәсе ни булыр? — «Булыр?» дип ул укымышлы кешеләргә охшатып әйтергә тырышты. Югыйсә, ул бу соравын «ничек» дип кенә биргән булыр иде. — Шуны тәфсир итеп бирмәссез микән? (Аның «тәфсир», «тәкъсир» кебек гарәпчә сүзләрне ишеткәләгәне бар иде.)

Мулла бу исемнең мәгънәсен белә икән, бик җиңел генә җавап кайтарды:

— Галиәкбәрнең мәгънәсе, менла Галиәкбәр, олы Гали дигән сүз буладыр, — диде ул. Һәм үзенең белемен күрсәтү өчен: — Әгәр дә мәгәр, мәсәлән, Галиәсгар дигән исем булса, аның мәгънәсе кече Гали дигән сүз булыр иде, — дип тә өстәп куйды.

Галиәкбәр хәзер менә шул мәҗлесне исенә төшерде. Һәм бик куанып: «Галиәкбәр-Галиәсгар, — яхшы бит бу! Галиәкбәр малае икәнлеген әллә каян күрсәтеп тора!» — дип, үзалдына сөйләнеп, олы бүлмәгә чыкты.

— Мәүгыйзә, безнең баланың исеме Галиәсгар булыр! — дип кычкырды. — Әйе, әйе, бик мөселманча! Шулай, тәвәккәлләдек!

## Әнгам Атнабаев

### Горурлык

Туган илем! Син бит минем өчен
Хәтта җанын фида кылырлык
Туган анам кебек якын дисәм,
Бу — төчелек түгел, — горурлык!

Туган илем, минем җылы өем,
Башка җирдә миңа урын юк,
Дип шатлансам синдә яшәвемә,
Бу — төчелек түгел, — горурлык!

Туган илем — минем туган телем,
Шушы телдән башка җырым юк,
Дип җырласам әгәр җырларымда,
Бу — төчелек түгел, — горурлык!

Туган илем, синең үткән юлың —
Минем юлым, башка юлым юк,
Дип соклансам барыр юлларыңа,
Бу — төчелек түгел, — горурлык!

Туган илем, синең исемеңне
Йөртүемә лаек булырлык
Гомер итсәм, мин үкенмәс идем...
Бу — төчелек түгел, — горурлык!

### Без—егерме сигезенчеләр!

Тыныч заманнарда тумадык без,
Тудык сыйнфый көрәш кызганда,
Шәхси милекчелек межаларын
Тәү «Фордзон»нар сөреп узганда.

Тыныч заманнарда үсмәдек без,
Үстек бишьеллыклар чорында,
Магниткалар, ГЭСлар тәэсире бар
Бала чакның гамьсез җырында.

Сугыш безне колаклардан тартып,
Вакытыннан иртә өлгертте:
Кичтән егет итеп йоклатты да,
Таң атуга инде ир итте.

Сөйгән ярлар белән саубуллашып,
Без тутырган идек токсайны [1],
Хәле бетеп тынган дулкын сыман,
Сугыш безгә килеп тукталды.

Атайларсыз үткән замананың
Патшасы да идек, колы да,
Кирәгеннән артык бәләкәй дә,
Кирәгеннән артык олы да!..

Тыныч заманнарда тумадык без
Һәм үсмәдек тыныч заманда.
Тыныч замана дип йөртелсә дә,
Тыныч түгел әле һаман да.

Бу тормышның чияләнеп беткән
Төеннәрен чишә кулыбыз,
Җәмгыятьне тартып бара торган
Арканнарны ишә кулыбыз.

Сугыш чоры белән тыныч чорның
Уртасына туры килгәнгә,
Тормыш безне чүкеп җитештерде,
Үзе таләп иткән кимәлгә.

Кирәгәннән артык мактана дип,
Әйтсә әйтер бары көнчеләр.
Көнләшәләр икән — көнләшсеннәр! —
Без — егерме сигезенчеләр!

●

Йолдызларга карап җирдә ятам...
Йолдызларга җитә уйларым!..
Бер уйласам, мин югары кебек,
Бер уйласам, алар югары...

«Кеше туса, күктә йолдыз туа»,
Дип сөйлиләр; бәлки ул хактыр?
Ни дисәң дә, бар бит йолдыз белән
Кеше арасында уртаклык.

[1] Токсай — капчык

Алар да бит без барлыкка килгән
Материядән үсә яралып;
Кайберләре яралырдан элек
Тузан булып оча таралып...

Аларның да яхшылары була,
Яктылары була, тоныгы...
Венерасы, Марслары була...
Балалары була, оныгы...

Һәрберсенең юлы үзенә башка...
Теле башка... гореф-гадәте...
Үзенә башка янар сәгатьләре,
Таң алдыннан сүнәр сәгате...

Берәүләре иплә генә яшәп,
Ипле генә дөнья куялар...
Икенчесе вата, кыра, җимерә...
Дер селкенеп куя дөньялар...

Кайсылары, кара янар булып,
Якты янганнардан көнләшә...
Кайсылары читтән җылы эзли,
Кайсылары үзе өләшә...

Кайсы — үлгәч яна...
Кайсылары —
Тере булсалар да салкыннар...
Йолдызлармы кешеләргә охшаш,
Кешеләрме йолдыз затыннан?

●

Дус югала сугыш яланында,
Утта янып, дөрләп югала.
Йөрәгеңдә еллар буе сүнмәс
Көйрәп ята торган куз кала.
Бик авыр!

Дус югала үлем түшәгендә,
Күз алдында эреп югала.
Йөрәгеңдә еллар буе тынмас
Елатырлык моңлы җыр кала.
Бик авыр!

Дус югала үзе тере килеш;
Дәрәҗәгә үрләп югала.
Йөрәгеңдә еллар буе сызлап
Интектерә торган җөй кала.
Аһ, авыр!

●

*Динис Исламовка*

Һәрбер үлем үкенечле,
Һәрбер үлем көтмәгәндә.

Нигә көтмәгәндә китеп бардың? —
Озак утыра торган идек лә,
Үзең һаман китми торган идең,
«Хәзер китәм, китәм» диеп тә.

Нигә көтмәгәндә китеп бардың? —
Яз башланды... Җәйләр... Көзләр бар...
Языласы күпме хикәятләр,
Сөйләнәсе күпме сүзләр бар!

Нигә көтмәгәндә китеп бардың? —
Тукталмаган идек төшкә дә,
Чәчләреңә көмеш кар төшсә дә,
Йөрәгеңә кырау төшмәгән.

Нигә көтмәгәндә китеп бардың? —
Анда барып була соңлап та,
Барып була, ләкин кайтып булмый,
Бөтенләйгә түгел, сорап та.

Нигә көтмәгәндә китеп бардың? —
Кадереңне белеп бетмәдек;
Син әкият кебек кызык идең,
Кызганычын, ахры, көтмәдек.

Нигә көтмәгәндә китеп бардың? —
Озак утыра торган идек лә,
Үзең һаман китми торган идең,
«Хәзер китәм, китәм» диеп тә.

Нигә көтмәгәндә китеп бардың?..

1973

●

Н. Н. гә

Таңнарда гармун уйнадың,
Тирә-як тынып калды.
Гармун моңына тирбәлеп
Гөлләрдән чыклар тамды.

Гөлләрдән чыклар тамдылар,
Әйтерсең күз яшьләре.
Ишетелеп китте сыман
Әнкәңнең эндәшкәне:

— Таңнарда гармун уйнама,
Моңлы булырсың, балам.
Бу дөньяда моңсызлар күп,
Ниләр кылырсың, балам?

Таңнарда гармун уйнадың,
Әнкәңне тыңламадың,
Күрекләрен сузып суздың,
Телләрен моңга манып.

Тирә-якка моң түгелә...
Еласын — елаганнар.
Йоклар йокыларын бүлеп,
Сөйгәнен уйлаганнар,

Сөйгәненнән сөелеп тә
Сөелеп туймаганнар,
Мең газаплы мәхәббәттән
Өметен җуймаганнар...
Еласын — елаганнар!

Гармунчыны тиргәмәгез,
Гармуны елатадыр!
Бәлки үзенең гомерен
Елатып уйнатадыр?

Гармун телләре исәпсез,
Гомерләр тик бер генә,
Гармун күреге сузыла,
Сузылмый гомер генә.

Моңлы гомерләр җитешми,
Моңсызлар күбрәк әле,
Моңсызларны уятырга
Гармуннар кирәк әле!
Гармуннар кирәк әле!

●

Көзләр үтеп, кышлар башлануын
Хәбәр итә кара каргалар —
Беренче кар җиргә төшү белән
Очып китә кара каргалар.

Ураллардан Африкага тиклем,
Ай-һай, ерак инде юллары!
Талмасын ла инде канатлары,
Өзелмәсен инде җырлары.

Кышлар үтеп, язлар башлануын
Хәбәр итә кара каргалар,
Иң беренче тамчы таму белән
Кайтып җитә кара каргалар.

Беренче кар... һәм беренче тамчы...
Ай-һай, ерак мизгел арасы!
Кошлар булып кошлар түзәлгәнне
Түзмәс микән адәм баласы?
Түзәр әле!

## Кайталар

Шауласын авыллар, калалар,
Шатлансын олылар, балалар,
Шатлансын аналар, аталар! —
Егетләр солдаттан кайталар.

Сөенсен сөйгәнен көткәннәр,
Кызлары үсеп буй җиткәннәр,
Онтылсын хәвефләр-хафалар! —
Егетләр солдаттан кайталар.

Симерткән тәкәләр суелсын,
Табында шәраблар коелсын,
Йөгереп йөрсеннәр апалар! —
Егетләр солдаттан кайталар.

Кайталар хезмәтен тутырып,
Акылга, тәртипкә утырып,
Һәм татып дөньяның ачысын,
Аерып яманнан яхшысын.

Кайталар җирләрен сагынып,
Погонлы шинельләр ябынып...
Төп-төгәл, исән-сау көллесе —
Заманның иминлек билгесе!

Егетләр солдаттан кайталар...

◆ ◆ ◆ ◆

Саҗидә Сөләйманова

# ӘС-СӘЛЯМИ, СУФИЯТ[1]

## Ташу кайтыр, ташы калыр



Ай ураклы манаралар мөсафирлар артыннан үрелеп карап калдылар. Сау бул, шәрык шәһәре!

Шәһәр читен сәләмә алачыклар, алачыкларны тагын да сәләмәрәк кешеләр сырып алган. Качаклар бу. Израил басып алган җирләрдән качып, Дәмәшкъ тирәсенә сыенганнар. Совет «Кызыл Хач» җәмгыяте Сүрия хөкүмәтенә качакларны урнаштыруда ярдәм күрсәтә. Ә алар бик күп. Туристлар йөртә торган автобуста кем утырганын белепмебелмичәме, елмаеп кул болгыйлар.

Яшел бакчалар артта калды. Басу-кырлар башланды. Күмәкләп, кул белән урак уралар. Беренче кооперативлар болар. Машиналар, күрәсең, җитешми әле.

Берәм-берәм сукачылар күренә. Май ахырында уракчысын да, сукачысын да очратасың. Кояш юмарт монда, елына өч тапкыр уңыш җыеп алучылардан нурын кызганмый.

— Иминлектә, муллыкта яшәгез, тырыш игенчеләр!

Әнә анда совет эшчеләре нефть эшкәртү заводы салганнар. Совет белгечләре шунда эшләп, гарәп инженерларын өйрәтәләр.

Йөзләрчә чакрымга нефть кудыру торбалары сузыла. Монысы да Совет хөкүмәте ярдәме белән салынган.

— Игелеген күреп яшәгез!

Очсыз-кырыйсыз чүл-сахра башланды. Хуҗаларын җәйләүгә озаткан балчык кышлаклар моңаеп утыра. Ком өстендә нинди азык табалардыр — сарык-кәҗә көтүләре йөри.

Күңелне биләгән ямансулыкны автобус җиле белән сахрага очыртырга теләгәндәй, Суфия озын җыр сузып җибәрә.

Һай, әле бик еракта идек бе-е-з,
Җиде илнең чиген үттек бе-е-ез,
Ак калфакның табылган чагы.

Илһам Шакиров яңарткан борынгы җырны сәфәрчеләр күтәреп ала:

Ак калфакның табылган чагы-ы-ы-ы...
Туганнарның сагынган чагы.

Юлда каршы очраучы да, узып китүче дә юк. Җан иясе күренми, ком да таш. Шундый чакта җырдан да әйбәт юлдаш бармы?

[1] Ахыры. Башы журналыбызның бишенче санында.

Ком сахраларына җыр белән Идел дулкыннары сулкылдавы, кошлар сайравы килә. Гид Хәсән юл ритмына салынган җырны бик тиз отып ала.

Ай, былбылым, вай, былбылым,
Агыйделдә таң ата...

Белеме белән Хәсән музыкант икән. Һөнәре буенча эш таба алмагач, гид булып урнашкан. Туристлар арасында да музыкантлар барлыгы беленде. Сахраны арияләр яңгыратты. Менә кайчан сәләтләр ачыла! Немецча әйбәт белүчеләр дә бар икән, ул телдә дә Хәсәнгә кушылып җырладылар. Аңа ук кушылып русча «Катюша»ны әйттерделәр. Хәсән ялгызы гына сагышлы гарәп җыры сузды. Күңелләрәкне җырлавын үтенгәннәр иде, тагын да сагышлыракны башлады. Иксез-чиксез чүлдә элек-электән күңелле җырлар тумагандыр шул. Ә татарда шук җырлар, шат җырлар күп. Авылча, кичке уендагыча кара-каршы җырлашып алдылар.

Кара бөдрә чәчләремне
Сибелдереп таратам.
Уйларыңны белмим әле,
Буйларыңны яратам.

Абайламый гына барганда, чүл өстендә әкияттәге сыман таш кала калкып чыкты. Кунак капкасының ак баганалары күккә ашкан. Якъякта тугры сакчылардай мәһабәт колонналар баскан. Кояш аяусыз кыздыра. Тирә-юньдә җан иясе күренми. Мең еллар эченнән гаҗәпсенеп карап торган хәрабә Пальмирага тиктормас туристларның гына юлы төшә. Җимерек шәһәр янына салынган бер катлы җиңелчә кунак өе дә туристлар өчен.

Озын юлдан соң тамак ялгагач, ял итәргә куштылар. Шәһәр хәрабәләрен карау көн бераз сүрелгәч, өйләдән соң булачак. Әсседән куркып, Сүриядәге соңгы көнне ничек йоклап үткәрәсең? Мең еллык тарих махсус сине көтеп, каршыңда басып тора бит! Тау башында бик ерак та түгел борынгы кирмән күренә. Сукмагы да ярылып ята. Суфия белән Матура шунда барырга ниятләделәр. Ләкин Вероника Сергеевна катгый каршы төште. Анда еланнар, чаяннар... Таш ишелүе мөмкин, крепость иске. Туристлар үзсүзләнеп маташтылар. Гел иске крепостьларда йөриләр бит әле, ишелми. Аннары еланны шомлы әкияттә, чаянны журнал тышында гына күрәләр, чыннарын күреп кайту үзе бер бәхет булыр иде... Җитәкче даманың үгете үтмәгәч, мондагы хуҗаларның берсе күргәзмә дәлилләр китерергә булды:

— Әнә, күрәсезме?

Тау ягыннан килгән юлдан хәрбиләр төялгән йөк машинасы узып бара иде. Шуңа күрсәтте хуҗа. Шул чак баш өстеннән генә карлыгач канатлы самолет борыны белән күкне ярып менеп китте. Хуҗа кеше аңа ымлады:

— Әнә, күрәсезме? Ярамый.

Каршы сүз дәшәргә урын калмады. Бу тирәдә хәрби зона булырга тиеш. Сугыш бара. Басып алу һәм азат итү сугышлары. Башта искиткеч тын күренгән шәһәр өстенә шом салып, әледән-әле самолетлар оча. Тынлык юк. Тынгылык юк. Кеше күңеле бервакытта да тынгылык күрмәс. Мең еллар элек сугыш корбаны булган җимерек шәһәр шаһит моңа.

Кояш бераз сүрелгәндәй иткәч, туристлар таш шәһәр эченә керделәр. Кәрван-сарайлы Пальмира шәһәре өч материк арасында барган сәүдәнең үзәге булган. Азия, Африка, Европа товарлары шушында очрашкан. Ике дәвер тоташкан чорда Пальмира — югары культуралы

мөстәкыйль дәүләт. Дәвер башында ул Рим империясенең хакимлеген танырга мәҗбүр була, ләкин мөстәкыйльлеген югалтмый. Өченче гасырда, Зиновия (гарәп дөньясында аны Зәйнәб дип йөртәләр икән) патшалык иткән чорда Пальмира шул чаклы көчәя, Рим хакимлеген бөтенләй алып ташламакчы була. Һай, ул чибәр шәһрәтле Зәйнәб алдында кемнәр генә баш ими! Аның ихтыярына буйсынып, илчеләр шымчыга, сәүдәгәрләр солдатка әйләнә. Ләкин һәр заманда, һәр илдә булган кебек сатлык җаннар монда да була. Иң ышанып дип сөйләнелгән сүз серне белмәскә тиешле кешегә иң әүвәл барып ирешә. Баш күтәрергә әзерлек барганда Рим императоры бөтен кодрәте белән фетнәче дәүләт өстенә ташлана. Мөстәкыйльлек теләгән башлар гәүдәләрдән аерылып, колгаларга эленә. Азатлыкка омтылган йөрәкләр күкрәк читлегеннән суырылып, сөңге очларына кадала. Бары тик Зәйнәбнең горур башы гәүдәсеннән аерылмый, аның үзен иленнән аерып, диңгез арьягына олактыралар. Фетнә оясы Пальмираның асты өскә китерелә.

Суфия хәрабәләр арасыннан озын кара чәчле Зәйнәбнең сылу сыны күтәрелгәнен күргәндәй була. Хатын-кызны юкка гына буйсынучан зат дип уйлыйлар. Гомер буе буйсынып яшәгәнгә дә иреккә омтылу аңарда көчле була. Ирекне татып караган хатын-кызда бу тойгы тыелгысыз омтылышка әйләнә. Чөнки мәхәббәттә дә, нәфрәттә дә хатын-кыз урталыкны белми.

Туристлар тын гына хәрабәләр арасында йөриләр. Хәзерге техника баш иярдәй гигант корылмалар. Алар астында ничәмә мең кол сөяге ята. Шөһрәт һәм мәрхәмәтсезлек һәр вакыт янәшә яшәгән.

Рим стилендәге амфитеатр. Сәфәрчеләр, һәрберсе үз уйларына бирелеп, баскыч-баскыч күтәрелгән эскәмияләрдә утыралар. Бер уй берсен дә читләтеп узмый: шушы сәхнәдә борынгы дөнья әдәбияты һәм сәнгатенең корифейлары чыгыш ясаган. Аристофан, Софоклның үлмәс әсәрләре куелган. Шушында ук бугазга-бугаз килеп гладиаторлар кан коешкан. Иң югары сәнгать һәм иң түбән вәхшилек...

Ком-сахра уртасында гөлбакча булып утырган шәһәрнең таш өеменә әйләнүе үзе вәхшилек түгелмени! Шушы җинаятьне туар буыннарга бөтен фаҗигасе белән күрсәтү өчендер, канлы вакыйгалардан соң Пальмирада җир тетри. Челтерәп аккан көмеш елга җир астына китеп югала. Су китә, тереклек бетә. Бөтен нәрсә тораташ булып ката. Кешелек җинаятен хәтта табигать күтәрә алмый. Кешеләргә сабак булып, үле шәһәр һаман шулай тора.

Оешкан төстәге экскурсия күптән тәмам, ә мөсафирлар таш сыннар тылсымыннан аерыла алмыйлар.

Ауган колонналарның таш чәчәкләрен көз нурлары белән терелтердәй булып Суфия йөри. Җимерек биналар өстенә менеп, караңгы базларга төшеп йөргәндә, аның күз алдына Иделдәге Болгар хәрабәләре килә. Журналистлар анда узган җәй экскурсиягә барганнар иде. Бер-берсен белмәгән халыклар бер үк язмышка дучар булганнар. Идел буйлап сәүдә кораблары узган. Шәрык илләре белән көнбатыш арасындагы сәүдә ачкычын Болгар үз кулында тоткан. Ул чакта дөньяны дер селкеткән Батый яуларын кире кагарлык көчле дәүләт булган Болгар. Ләкин ул заманнар — ата улны, ана кызны танымый торган заманнар. Тирә-якка диңгез ташкынындай яулар ябырыла. Болгар кабиләләрендә бердәмлек бетә. Баскынчылар яңадан килеп, үзеге какшаган дәүләтне көл итеп китәләр.

Шәһри Болгарда экскурсантлар йортлары янган кешеләрдәй уйга батып йөрделәр. Таш өстендә таш, таш астында баш.

Бүген дә Суфия, нәкъ Болгардагы сыман, юлдашларының барлыгын-юклыгын да сизми. Ташлар белән аңлаша, ташлар белән сөйләшә.

Үле шәһәрдән кайткач, Фәрит янәшәдәге авылны карап килергә тәкъдим итте. Җиде-сигез турист балчык йортлар ягына юнәлделәр. Бу нәни экскурсиядән алар олы хис белән кайттылар.

Авыл урамы шәһәрнеке кебек тар түгел, ярыйсы гына киң. Акка буялган өйләр. Күп өйләрнең ишеге урам якка чыга. Ишегаллары таш коймa артыннан күренми, анда тагын бер ишек чыга торгандыр. Урамда берсеннән-берсе кече биш-алты бала иярткән (кулга күтәргәне дә бар) пәрәнҗәсез хатыннар күренгәли. Авыл халкы бер-берсеннән ятсынмый, койма буена чыгып утырган хатын-кызларның да йөзләре ачык. Монда туристларга да күнеккәннәр, артык гаҗәпләнми генә, ләкин үтәли күрердәй булып карыйлар.

Авылның икенче очына җитеп, бакчалар ягына борылабыз дигәндә Габделбәр абыйлары берничә баланы рәсемгә төшермәкче булды. Аларны тезеп маташкан арада күзгә күренмәс тыкрыклардан төркем-төркем малайлар чабышып чыкты. Һәммәсенең рәсемгә төшәсе килә, әле берсе, әле икенчесе алга чыгып, кабат-кабат төшерүне таләп итәләр. Нигә генә бәйләнде болар белән Габделбәр! Йөзләрчә малай-шалай колак тондыргыч итеп кычкырыша, алардан һич арынып булмас кебек. «Фотограф» янында иптәшләрнең берсен калдырып, Фәрит ханымнарны алып китте, болай гына котылу юк икән әле. Матура да аппаратын асып чыккан, җитмәсә. Теге төркемнән кубып, дистәләрчә малай шау-гөр килеп, болар артыннан килә башлады. Туристлардан алар сувенир алып гадәтләнгәннәр, әллә берни бирмәгәнгә ачуланалармы?

Бу тамаша яудан ничек котылырга белми барганда, унбиш-уналты яшьлек үсмер егет малайларның каршына төшеп, нидер әйтә башлады. Сәфәрчеләр «яудан» ераграк китәргә ашыктылар.

Авыл артында җимеш бакчалары урнашкан. Алар берничә урамлы авыл шикелле рәт-рәт булып тезелгәннәр, урамнары тыкрыклар белән тоташкан. Бакчалар янына җиткәч, фотографларны көтеп алдылар. Артларында койрыклары өзелеп җитмәгән икән, сәфәрчеләрне тагын бер төркем малай-шалай куып җитте. Ләкин хәзер тәртипсез шауламыйлар, җыр ритмына салып, беравыздан кычкыралар:

— Әс-сәләми! Әс-сәләми!

— Әс-сәләми, Суфият!

— Сиңа нидер әйтәләр бит алар, Суфия, — диде Матура.

Габделбәр абыйлары аңлатып бирде:

— Советлар илен алар «Суфият» диләр. Көнбатышлар «Совиет» дигән шикелле. «Мәга-әс-сәләми» — иминлек белән, исәнлек белән дигән сүз.

— Әс-сәләми, әс-сәләми!

— Әс-сәләми, Суфият!

Сәфәрчеләрнең йөзләре яктырды. Тәбрикләүләре, сәламләүләре шул икән сөйкемле гарәп малайларының. Советлар иленең даны әйбәт бу якларда. Моның белән безнең туристлар Сүриядә эшләгән белгечләргә, врачларга, укытучыларга бурычлы.

Сәфәрчеләрнең җавап тәбриген бакчаларны сугаручы су кудыргыч станцияләр, авыл-шәһәрләрне яктыртучы плотиналар, чик буенда очкан йолдызлы самолетлар раслый:

— Иминлектә яшәгез, гарәп дуслар!

— Әс-сәләми!

## Чылбырлы сәгатьнең сере

Картада Гарәбстан ярым утравына күз салсаң, елан сыман бөргәләнып диңгез ярында яткан бер ил күрәсең. Гарәпләр аны үзләре Лүблән дип йөртәләр, безнең карталарда ул Ливан дип исемләнә.

Буе ике йөз илле чакрымга сузыла, иңе кырык чакрымга да җитми. Азия материгы Африкага якынайган бу җирдә Европа гадәтләре хөкем сөрә. Сүрия җиренә чиктәш, Сүрия халкына кардәш исәпләнсә дә, мөсафирларга Ливан бөтенләй башка дөнья булып ачылды.

Чик буенда туристларны озын кара күлмәкле, ап-ак чәчле, башына кара челтәр шарф ураган дама — гид каршы алды.

— Әһлә вә сәһалән! [1] Җилфердәп торган юка гәүдәле карчыкның үсмер малайларча калын тавыш белән сөйләшүе сәеррәк тоелды. Анна-ры гид русчага күчте:

— Гарәпчә бераз өйрәнгәнсездер инде? Әйдәгез, рәхим итегез.

Эче-тышы ялт итеп торган йомшак автобус кузгалып киткәч, гид үз вазифасын микрофон аша үти башлады.

— Таныш булыйк: минем исемем Раиса Давыдовна.

Турыдан-туры русча сөйләве белән яңа гид шундук туристларның игътибарын җәлеп итте. Шәхес буларак та карчык кызыклы кеше: бала чагында ук ата-аналары белән Россиядән киткән эмигрантка икән ул. Түгәрәк йөзе вак кына җыерчыклар белән капланган кечкенә гәүдәле бу карчык бик тере, бик хәрәкәтчән. Йөгерек коңгырт күзләре шактый сулган йөзенә көләчлек биреп тора. Елмайганда алар шомырт кара булып күренәләр.

Юлда күргән һәр нәрсә турында гид сөйләп бара.

Ялан кырда егерме-утыз чатырдан торган авыл. Бу бәдәвиләр авылы. Бәдәвиләрне чегәннәр белән бутарга ярамый. (Чегәннәр монда да бар икән!) Кыяфәтләре белән охшашсалар да, аларны торакларыннан ук аерып була. Чегәннәрнең чатырлары кара, бәдәвиләрнеке соры, кәҗә тиресеннән ясыйлар. Бик борын заманнарда бәдәвиләр ниндидер җинаять эшләп үз кабиләләреннән куылганнар, ди. «Гарәб» — якын дигән сүз, «бәдәви» исә ерак дигәнне аңлата. Шуннан бирле бәдәвиләр дала буйлап күченеп йөриләр. Мал-туар үрчетәләр. Телләре гарәп теле, чөнки алар шул ук гарәпләр. Ике кардәш кабиләнең тормыш шартлары төрле булган кебек, көнкүрешләрендә дә аерма бар. Гарәп дүрт хатынга өйләнә ала, ә бәдәви икегә генә. Бәдәвиләрдә хатыннар ирекле, битләрен ачык йөртәләр. Хуҗалыкта бөтен эш хатын белән киңәшеп эшләнә. Гарәпләрдә исә ир хәл итә.

Юл диңгезгә таба алып бара. Ком сахраларын артык күрсәтмәс өчен гүя яшел чаршау кордылар: урманнар, бакчалар башланды.

— Олы юллар монда бетоннан салына, бер салынса, — мәңгелек.

Ливанның башкаласы Бәйрүт тирәсенә күп санда шәһәрчекләр урнашкан. Биек-биек йортлары, бай архитектурасы белән алар олы шәһәрләрдән аерылмыйлар. Раиса Давыдовнаның тонында Суфия мактану сыман нәрсә сизә:

— Бу яңа кварталларда аена 60—70 лирага [2] өч бүлмәле квартира алып була. Ике балконлы, ванналы, ике туалетлы.

Монда андый квартирны мөмкинлеге булган кеше үзе теләгән вакытта ала икән. Шуның белән масая да гид. Бәлки масаймыйдыр да, Суфияга гына шулай тоеладыр. Әнә бит, кире якларын да сөйли:

— Врачка беренче күренү — егерме биш лира тора. Бала мәктәпкә бара — өч йөз лира. Өстәвенә, китаплар кыйммәт. Махсус өс киеме, юл йөрү хакларын исәпләсәң, ярыйсы сумма җыела.

— Башлангыч классларда да уку түләүлеме?

— Хосуси мәктәпләрдә, әйе. Дәүләт мәктәпләре түләүсез, ләкин аларда укыту сыйфаты түбән. Түләп укытырга хәле җитмәгән кеше генә баласын андый мәктәпкә бирә.

---

[1] Әһлә вә сәһалән! — Рәхим итегез! (Гар.)

[2] Бер лира безнең өч сумга туры килә. Бер лирада йөз пиастр.

— Бала биш яшеннән укый башлый. Беренче сыйныфларда, башлыча, тел өйрәнү дәресләре керә. — Раиса Давыдовнаның тавышында тагын эчке киная. — Биш яшьлек бала инглизчә һәм французча сөйләшә. Туган телне дә исәпләсәң, уку өч телдә бара.

«Безнең тел белмәүгә төрттерә бу», — дип уйлый Суфия. Бүтәннәр ничектер, ул бәләкәй карчыкка чит итеп, үзенчә әйтсәң, бәдәви итеп карый. Кояш кызуында чүл буйлап йөзләрчә чакрым юл арыткандай, гидның ил турында тулы белешмәләр бирүе дә Суфияның җанын эретми.

Автобус диңгез буеннан бара. Баеп килгән кояш нурлары астында вак дулкыннар җемелди. Бу җирләрдә антик культурага нигез салучы Финикия халкы яшәгән. Ливанлылар әле хәзер дә үзләрен гарәпләр дип түгел, финикиялеләр дип йөртәләр.

Ливанның башкаласы — Бәйрүт. Урта диңгез яры буендагы кечкенә яшел шәһәр. Бизәкле-сырлы бер яки ике катлы биналар белән аралаш шома итеп эшләнгән заманча биек йортлар. Курортлар шәһәре, туристлар шәһәре, сәүдәгәрләр шәһәре. Миллионерлар шушы өч чыганак исәбенә байыйлар. Монда хәтта миллиардерлар да бар икән. Наркотик ише тыелган товарлар белән сәүдә итү дә миллион туплауда төп чыганакларның берсе. Дөньяның төрле почмакларыннан агылган туристлар һәм курортчылар да бу эштә сәүдәгәрләрдән калышмыйлар икән.

Шәһәрдә тормышның кайнап торган чагы — кичке җидедән иртәнге бишкә чаклы. Рестораннар, барлар, төнге йортларның эш сәгате шушы вакытка туры килә. Көндез кояш кыздырганда шәһәр ял итә. Шул сыйфатлы өчен Бәйрүтне «нәни Париж» дип йөртәләр.

Безнең туристлар кергәндә шәһәрдә кичке хәрәкәт башланган иде. Урамнарда машина ташкыны. Дәмәшкъ урамнары белән чагыштырганда җәяүлеләр сирәк. Пәрәнҗә бөркәнгән хатын-кыз юк. Кызлар, яшь хатыннар зәвык белән тегелгән озын чалбарлы җиңел костюмнан. Тез өстеннән яки «мини» күлмәкләр күренми. Өлкән ханымнар тездән түбән «миди» күлмәк кия. Ирләрнең исә һәммә җирдә, һәммә вакытта бер кием — костюм яки куртка. Эссе як дип, ярым шәрә йөрүче юк, барысы да безнең салкынча җәйдәге кебек киенгән. Гарәп кызлары тән аклыгының кадерен беләләр.

Юлчыларны яңа стильдә салынган алты этажлы һотельгә урнаштырдылар. Мөсафир кеше монда чемодан күтәреп йөрми икән. Вероника Сергеевна бу хакта алдан ук кисәткән иде. Юлчының әйберен һотельдә махсус йомышчылар ташый. Чемодан иясе аңа «бахшиш», безнеңчә әйтсәң, хаер бирергә тиеш. Кулдан сумканы алып, лифт ишеген ачып-ябып һәм башка йомышлар үтәп йөрүче берсеннән-берсе чибәр унбиш-уналты яшьлек егетләргә Матураның ачуы килде.

— Тапмаганнар үзләренә лаеклырак эш! Үз эшебезне кешедән эшләтергә өйрәнмәгән без. Ишек төбендә хәер көтеп тора бит өрлектәй егет!

Ике кешелек кечкенә бүлмә үтә пөхтә җыештырылган. Ванна стеналары күз чагылдырырлык ак кафельдан. Сөлге, җәймә ише әйберләр дә сөттәй ак. Бүлмәдә күзгә күренми торган электр җылыткеч. Бер сәдәфкә басасың, шундук салкынча, җиләс булып китә. Тахта янындагы тумбочкада шундый берничә сәдәф. Суфия юынып маташкан арада Матура аларны тикшереп чыкты. Берсе радио, берсе төнге лампочка. Ә бусы нәрсә? Билгесез сәдәфкә бер-ике баскач, бүлмәгә ак алъяпкычлы горничная килеп керде, чакыру сигналы биргән икән теге сәдәф.

— Гафу итегез, мадам, ялгышлык, — дигән булды Матура.

Горничная сүзсез генә елмаеп, чыгып китте. Дәмәшкъ һотелендә хатын-кыздан хезмәткәрләр юк, урын-җирне дә ирләр карый иде. Бәйрүттә хатыннар эшли, күрәсең.

Ашау-эчүне такы-токырак әзерләгәннәр. Күбрәк үләнле азык, ирләр сөйми торган пирожное, кесәл ише татлы әйберләр. Дәмәшкътәге оҗмах сыйларын сагынырсың монда. Һотельнең югары класслы булу исәбенә азык-төлек киселә дип аңлатты Вероника Сергеевна.

Дәмәшкътән соң мондагы официантларның тәҗрибәсезлеге дә сизелә. Өстәлгә савыт-сабаны шалтыр-шолтыр куялар, чәнечке-кашыкны идәнгә төшерәләр. Андый чакта үсмерләр куркынып як-якка карана.

Ут алынгач, мөсафирлар шәһәр күрергә чыктылар. Һотель төнге йортлар тирәсенә урнашкан икән, һәркайда кызыл утлар җем-җем итә. Тәрәзә-витриналарда утлы сызыклар белән ярым шәрә биюче кызларның силуэтлары ясала. Бер югалып, бер балкып торган шәүләләр узып баручыларны кызгылт эңгер-меңгергә чакыралар.

Арырак киткәч, туристлар бөтенләй башка күренешкә тап булдылар. Урам-тыкрыкларга тартмалар, иске мичкәләр өелгән, төрле чүпчардан баррикадалар корылган. Малай-шалай, яшүсмерләр колак тондыргыч итеп кычкырышалар, йөгерешәләр. Урам чатына йөге белән чүп китереп аударганнар. Икенче җирдә шундый чүпкә ут төрткәннәр, тирә-як күз ачкысыз төтен. Өченче шау-шулы төркемдә өлкәннәр дә күренә. Яшьләр бер-берсе өстенә очып-кунып кычкырыша, ызгышалар. Кай арададыр фотоаппаратлы, киноаппаратлы кешеләр килеп җиткән, әле алларына, әле артларына төшеп, ызгышучыларны объективка алалар. Мондый хәлләрне чит ил тормышыннан телевизорларда гына күрергә мөмкин. Гадәти булмаган күренеш безнең туристларны ифрат кызыксындырса да, озак күзәтергә туры килмәде. Кемнең кемлеген белә торган урын түгел бу, күзәтчедән катнашучыга әверелүең бар. Сабыррак туристлар һәр нәрсәгә борыннарын тыгарга әзер газетчыларны көчләп диярлек алып киттеләр. Болай да тынгысыз шартларда эшләүче Совет илчелегенә мәшәкать арттырмау яхшы.

Икенче көнне университетка планлаштырылган экскурсия булмады, студентлар баш күтәргән, диләр. Туристлар тап булган төнге күренеш — шул забастовканың шаукымы икән. Бер төркем студент хөкүмәткә экономик һәм политик таләпләр куйган, икенчеләре аларга каршы чыккан. Ливанда ике дистәгә якын партия булган кебек, яшьләр оешмасы да күп санда, кичә төнлә шуларның берничәсе бәрелешкән. Урамда җыелган халыкны полиция килеп тараткан, атышлар, хәтта корбаннар булган. Бу илдә һәркем кораллы икән. Аерым кешеләр кулында пистолетлардан алып автоматларга чаклы бар, ди. «Сүз иреге» «забастовкалар ирегеңнең кечкенә бер нәтиҗәсе... Тау араларында хөкүмәт тарафыннан тыелган исерткеч үсемлек плантацияләре пушкалар белән саклана, имеш...

Ливанда совет туристларына бераз салкын мөнәсәбәт сизелде. Әллә курку, әллә читсенү — нәрсәдер бар инде Ливан кешеләрендә.

Тимер рәшәткәле кече капкадан хәрабә гыйбадәтханәгә кертеп торучы милли киемдәге гарәпләр туристларга юлны куллары белән сүзсез генә күрсәттеләр. Нәкъ телсезләр кебек. Руслар белән сүзгә кермәскә кушылганмы аларга. Әллә совет туристлары берниндидә тел белми дип уйлыйлармы? Шуны ачыкларга теләп, Суфия «телсезләргә» сәлам бирде:

— Әс-сәлям-мәгаләйкум! Сабах әл хәйер! [1]

Гарәпләрнең йөзләре яктырды, телгә килеп, хор белән җавап кайтардылар:

---

[1] Әс-сәлям-мәгаләйкум! Сабах әл хәйер! — Исәнлеккә, иминлеккә! Хәерле иртә! (Гар.)

— Вәгалейкум-әс-сәлям!

Суфия дәвам итте:

— Кәйф халәкә? [1]

Түбәнчелекле гарәпләр тагын бергәләп җавап бирделәр:

— Шөкран, мәбсут. Иншалла, мәбсут [2].

Узып киткәч, Суфия капка төбендә торучыларның үзара сөйләшүләрен ишетеп калды:

— Бәррәкалла, бәррәкалла...

Исәнлек-саулык сорашканга да ачылып китә бит кеше.

Агач башын җил борыр, кеше башын сүз борыр, ди.

Антик культураның иң зур корылмаларыннан саналган Баалбәк. Баал — борынгы семит кабиләләренең уңыш алласы булган. Шәһәр һәм борынгы корылмалар шул алла исемендә йөртелә. Гыйбадәтханәләр исә моннан ике мең еллар элек грек-рим стилендә салынган, җирле архитектура белән һич охшашлыгы юк. Гүяки искиткеч корылмалар ниндидер могҗиза белән монда бүтән җирдән күчеп утырган.

Раиса Давыдовнаның сөйләвендә могҗизаларга бик ышанасы килүе сизелә. Баалбәк буенча белгечләрнең фикерләре бер булмау да төрле юрауларга киң юл ача.

Кайчандыр искиткеч архитектура ансамблен тәшкил иткән храмнар хәзер бер квартал мәйданны биләп торган җимерекләрдән гыйбарәт. Кайда түшәмсез таш идән, кайда идәнсез бизәкле-рәсемле түшәм сакланган. Пар атлар белән керерлек мәрмәр яңаклы ишек бар, стеналар юк. Билгесез рәссамның картиналары белән стена бар, ә тәрәзәләр — өч яктагы офык. Шул хәрабәләрдә дә ул заманның көчен, кодрәтен тоясың, нәфислек, гүзәллек чалымнарын күрәсең. Баалбәк хәрабәләренең даны — дөнья могҗизасы булырдай колонналар сафы бик ерактан күренеп тора. Тетрәүләр, сугышлар, гарасатлардан исән калып, мең еллар янәшә басып торган алты мәһабәт колонна. Һәр колонның биеклеге егерме метр, аларны өстә бергә тоташтыручы иң нәфис челтәргә охшатып ясалган аркаың биеклеге алты метр. Кеше иҗатына тарих үзе куйган һәйкәл. Бүтән рәттә шундый ике колонна башыннан тетрәү вакытында берничә таш җиргә төшкән. Ул ташларның авырлыгы әллә ничә тонна, ди.

Раиса Давыдовна һәр ауган баганаың, һәр мүкләнгән ташның, һәр мәйданчыкның тарихын белә, учтагы сызыкларга карап сөйләгән күрәзәчедәй, борынгының җанлы күренешләрен күз алдына китерә.

Бик шәп акустикалы җимерек залга бөтен дөньяның сәнгать корифейлары ел саен «Баалбәк фестивале» дигән халыкара җыенга җыелалар икән. Баалбәк күгендәге йолдызлар Җир шарының барлык төре йолдызларын күргән. Очлары күккә тигән колонналар Шаляпинны таң калып тыңлаган, Клиберннның тылсымлы музыкасын ишеткән.

Шулай да үз хисләреңә бирелеп, ишеткән-күргәннәреңне үз йөрәгең аша үткәреп йөрер җир түгел Баалбәк. Безнең Кара диңгез яр буйларындагы истәлекле урыннар кебек күп халыклы җир. Янәшәңдә үк башка төркем туристлар, бүтән телдә сөйләгән гид тавышы. Яратмый Суфия халык мыжгып торган экскурсияләрне. Табигать садәлеге, сәнгать матурлыгы меңләгән күз алдында ачылып җитми, йомылып каладыр шикелле. Гасырлар түреннән бүгенге көнгә килеп җиткән архитектура һәм сәнгатьнең иң югары өлгесе Суфия күңеленә тирән үтеп керә алмады. Акыл белән һәммәсен кабул итәсең, ә йөрәк битараф кала.

---

[1] Кәйф халәкә? — Нихәлдә яшисез?

[2] Шөкран, мәбсут. Иншалла, мәбсут. — Рәхмәт, канәгатьбез. Алла теләсә, канәгатьбез.

Экскурсия буена Суфия гид янындарак йөрде. Карчык аны нәрсәсе беләндер үзенә тартты. Тавышы утырып җитмәгән үсмер малайларча сөйләшүе, көйдергеч кояшта яргаланган җир өсте кебек бите җанга бик ятышлы түгел, югыйсә. Күз-авыз тирәләрендә татар карчыклары нда була торган мөлаем сызыклармы, елмайганда шомырт кара булып күренгән көләч күзләрме — Суфияны әледән-әле гидның йөзенә карарга мәҗбүр итте. Юк, тәгәрәп торган тере күзләргә Суфия якын итеп түгел, киресенчә, ят итеп, шомланыбрак карый. Күлмәк өстеннән тагылган озын көмеш чылбырлы, ахак кашлы, пальто төймәсе зурлыгындагы медальонга да сәфәрче ханымның карашы еш төште. Әллә шул карашны сизеп, әллә күзлеген кияргә иренеп, гид медальонны кулына алды да Суфияга күрсәтте:

— Карагызчы, вакыт күпме?

Кай арададыр ахак каш күтәрелде, аның астында нәни сәгать күренде. Рим саннары төшерелгән цифрблатка карап, Суфия вакытны әйтте. Шул чак аның игътибарын ахак кашлы капкачның аскы ягына язылган гарәп хәрефләре җәлеп итте: «Кантимер.»

Суфия каяндыр йөрәк турысыннан бөтен тәненә таралган салкынның тамак төбенә килеп җиткәнен тойды. Теш суырткандa ясаган уколдан тел өшегән хис белән сорады:

— Нәрсә бу?

— Язуны әйтәсезме? Безнең фамилия. Гаилә реликвиясе бу, ата-анамнан калган истәлек.

Сәгать капкачы «челт» итеп ябылды.

Гарәп язуының һәр сызыгы, һәр ноктасы Суфияның исендә. Авыру кайнанасы бүләк иткән алтын балдакта шул ук язу иде. Ул чакта урта мәктәпне генә бетергән Суфия гарәпчә танымый иде. Менә хәзер сәгать капкачындагы язу белән чагыштырып, хәтерендә уелган хәрефләрне укыды: «Кантимер». Аерылган ире Фуатның фамилиясе Кантимеров бит! Тик фамилия нечкә «к» кебек әйтелә, ә балдакта калын«к» белән язылган. Эмигрантка Раиса Давыдовнаның гаилә реликвиясендә дә шул ук гарәп билгеләре. Уң яктан беренче «Кан», «т»нең башында сызык, иң ахырда гарәпчә «м»не аңлаткан кечкенә түңгәләк һәм «р» өтере.

«Сез Ленинградныкымы?» димәкче булды Суфия. «Анда туганнарыгыз бармы?» дигән сорау да тел очына килде. Сораулар ыргак булып тел очында эленеп калдылар. Хан заманындагы карчыкның Ленинград белән нинди уртаклыгы булсын? «Петербургныкымы» дию тагын да урынсызрак. Теш суырткандагы кебек хис Суфияның авызын өшетеп, телен әйләндерә алмаслык хәлгә китерде. Хәер, тел әйләнсә дә, мондый ыгы-зыгыда четерекле темага сөйләшеп булмас иде. Йөгерек күзле карчык инде бүтән туристларның сорауларына җавап бирә.

Автобуста кайтканда да, кичке аш, кичке прогулка вакытында да шомлы гарәп язуы Суфияның исеннән чыкмады. Кайнанасының сугышта хәбәрсез югалган ире Якуп, Якупның революция чорында бөтен гаиләсе белән юкка чыккан агасы Даут... Раиса Давыдовна... Өзелгән чылбырның сибелгән боҗралары түгелме алар? Шул боҗраларның берсенә Суфияның гомер түңгәләге дә ялгана язып калмадымы?

Кыршылып беткән кара хәтфә тышлы альбомдагы борынгы бер рәсем башка фотолардан аерылып тора. Ярым хәрби киемле, кырык яшьләрдәге ыспай ир белән янәшә гармун якалы озын күлмәк кигән, биек прическалы чибәр хатын утыра. Күлмәк өстеннән озын чылбырлы медальон таккан. Ыспай ирнең артына Фуатның бәләкәй чагына охшаган үсмер малай баскан. Хатын янында зур түгәрәк күзле кызчык. Кантемировлар гаиләсе бу. Фуатка охшаган үсмер малай — аның әтисе Якуп. Ыспай ир — Якупның агасы Даут, тегеләре Даутның

хатыны һәм кызы. Якуп шушы гаилә тәрбиясендә үскән. Данлыклы сәүдәгәрләр нәселеннән истәлек булып Фуат Кантемировка әлеге рәсем генә калган... Суфияның күңелен иренең соңгы сүзләре озак еллар өшетеп торды.

— Балдакны бир әле.

Яшь бала белән юлга җыенган хатынына Фуатның әйткән сүзе шул булды. Аңламый торган Суфияга «нинди «миңгерәү» дигәндәй, бер карап алды да тагын кабатлады:

— Балдакны дим! Әни истәлеге! — Кәнәфидә утырган килеш кулын сузды, үзе икенче кулындагы журналга текәлде.

Аһ, менә нәрсә икән... Кайнана түшәккә егылгач, үзен караган килененә рәхмәт йөзеннән хәрәкәтсез кулындагы алтын балдагын салдырып алырга кушты. «Иремнең бүләге иде, сиңа Фуат бүләге итеп бирәм», — диде. Читләре югарып беткән балдакны мәеттән салдырган-дай булды Суфия. Шулай да авыру кешенең хәтере калмасын дип, үз бармагына киде. Кайнана балдакны килененең кулында күрмәсә, шундук таптыра иде:

— Бармагыңнан салма. Улымны чит иткән кебек буласың...

Шул балдакны сорый икән Фуат...

Юлга әзерләнгәндә идән-кер юып куллар җилсенгән, тиз генә салып та булмый бит әле. Суфия, үзен-үзе белештермичә, бармагын суйдырып, балдагын йолкып алды да Фуатның сузылган учына ташлады.

Язмыш аларны тагын бер-ике тапкыр очраштырды. Фуат һаман шул «танылмаган даһи». Аның каравы, Суфия башка. Район журналисткасы. Гейнены яттан белә, Поль Элюарны укыган. Русча тәрҗемәдә, әлбәттә. Һаман үзенеке дип санаган хатыны белән Фуатның бер түбә астында яшәргә нияте бар. Теге чакта ул аны наданлыгы өчен санламаган лабаса! Бу ачышны икесе берьюлы ясадылар. Суфия Фуатка уңай җавап бирмәсә дә, шактый уйланып, икеләнеп йөрде. Суфия аңа үзенчә тәэсир ясый алмас идеме? «Кем белән каралангансың, шуның белән аклан диләрме әле?» Фуатның уңай яклары да күп иде бит. Әниләре үлгәч, Суфияны кочаклап: «Синнән башка минем беркемем дә калмады», дип елавы... Суфия авырганда, тәҗрибәсез атаның бала чүпрәкләре юып киптерүе... Бер-береңнең киләчәге өчен җаваплылык хисе дә булырга тиештер...

Соңгы очрашуларына ел да тулмый әле. Теге «Чайльд Гарольд» һаман ялгыз. Суфия аны кызганыпмы, әллә үз итепме, үгет-нәсихәт кебек нәрсә әйткәләгән иде, тегесе француз шагыйренең юлларын китерде:

> Яраталар безне дуслар,
> Сөяркәләр, кандалалар.
> Сөйгәннәрдән сак булыгыз —
> Алар безгә кадалалар,
> Башны ашыйлар...

Суфияча түгел ул, чит. Фуаттагы нигилизмның төп сәбәбе — хәтфә альбомдагы рәсемгә бәйле икәнлеген Суфия әлек үк эчке сиземләү белән тоя иде. Әмма соңгы очрашулардан соң, бер җәмгыятьтә яшәгән, бер тәрбия алган ике кешенең бер-берсен бөтенләй аңламаулары мөмкин түгел дигәнрәк фикердә йөрде. Бәлки Суфияның үзендә дә гаеп булгандыр? Бәлки ул иренә артык каты таләп куядыр?

Чит илдә көтелмәгән очрашу Суфияның күз алдында иске рәсемне җанландырды. Рәсемдәге гаилә кайчандыр чит илләр белән сәүдә итүче кодрәтле байлар нәселеннән булган. Фуатка ул байлыктан өлеш чыкмаган. Даһи әсәрләр язу хыялы да тормышка ашмаган. Хәзер кеше кулъязмаларын теркәп утыра. Шуңа ул барысына да үчле сыман.

Менә тагын шул Кантимерлар шаукымы... Рәсемдәге кызчыкның зур түгәрәк күзләре тере карчыкның җыерчыклы йөзеннән карый.

Чибәр хатынның күкрәгендәге медальон-сәгать карчык түшендә. Бетмәгәнмени әле ул нәсел? Авырткан җирләргә төртеп-төртеп алган кинаяле сүзләр...

Иртәгесен Раиса Давыдовна туристлар янына килмәде. Гаиләсендә бәхетсезлек диделәр. Ике-өч сәгать көттергәннән соң, катлы-катлы киенгән яшь гарәпне алып килделәр дә гид дип тәкъдим иттеләр.

Сәяхәтчеләрне Гомернең «Илиада»сында телгә алынган бик борынгы Сәйдә шәһәре, җиде мең яшьлек кедр урманы, Мисыр-Рим культурасы аралашкан музейлар, хәрабәләр көтә иде.

Раиса Давыдовна килмәүгә башка туристлар пошынса да, Суфия сөенде генә. Карчык аңа шомлы чылбыр бөҗрәсы булып күренә, ялганырга үз ишләрен эзли кебек тоела. Яисә карчыкның түгәрәк күзләре журнал тышындагы чаянга күчә. Күзләрен тәгәрәтеп чаян таш арасыннан килеп чыга да туристларның әле берсен, әле икенчесен чага башлый...

Суфия төне буе шундый төшләр күреп саташты. Иртәгесен карчыкның үзен тере килеш күрү бер дә күңелле булмас иде.

Яшь гид сөйләгәннәрнең тәрҗемәсен тыңлау да кызык түгел түгелен. Сәяхәтнең калган ике көнен тагын ничек тә үткәрерләр.

Суфия өчен иң авыр үткәне нәкъ шул ике көн булды. Үзәк өзелеп кайтасы килә башлады. Ахак капкач астындагы гарәпчә язу Суфияны чит илгә чыккач беренче тапкыр айнытып җибәргәндәй булды. Кантимерларны качарга яки үзгәрергә мәҗбүр иткән хәлләрне уйлады ул. Ал байрак җилфердәтеп дошманга ташланган кызыл гаскәрләр, мәтәлчек атып егылган атлар, яралы солдатлар, салкын Сиваш сазлыгы аша үтеп, ут өермәсенә ыргылган кешеләр күз алдына килде. Дөньяга кабынган утны шулай гына сүндереп, кешелек теләгән тынычлыкны шулай гына яулап була. Азатлык өчен үләргә әзер батырлар булса гына халык коллыктан котыла ала. Шул батырлар токымыннан икәненне бераз онытып җибәрдеңме әллә, Суфия?

Ерак экскурсиядән кайтып килгәндә автобус шау-шулы урам чатына туктады. Көн кызу иде, җылы киенгән гид су эчәргә уйлады. Автобус ишеге ачылуга резин сагызлар салган нәни капларын күтәреп, гарәп малае килеп керде. Гид аны тамак төбе белән кычкырып куып төшерде:

— Изһаб! Изһаб! Рус! Лә гиндәкум нукуд! [1]

Яшь гид, әлбәттә, рус туристлары гарәпчә белми дип уйлаган. Кызганычка каршы, аны барысы да аңлады.

Акча тотуга ифрат сак Матура икенче бер тукталышта сумка тутырып әфлисун алып керде. Гидны, шоферны, шоферның нәни кызын кыстап-кыстап сыйлады. Үгетләп, бүтән юлчылардан да җимеш алдыртты. Акчалары юкка руслар сагыз алмый, имеш! Бик чәйнисе килә ди сезнең ялтыравык кәгазьгә төргән сеңерләрегезне!

Төп кәсеп сәүдә булган җирдә бөтен нәрсә акча белән бәһаләнә. Бүтән ил туристлары борынгы культура истәлекләрен карау белән генә чикләнми, алыш-биреш белән дә шөгыльләнә. Һотельгә тукталган мөсафирларның сандык чаклы йөк-йөк чемоданнары моңа дәлил. Америка долларлары, Франция франклары монда шул килеш, алмаштырмыйча йөри. Чөнки бу илнең һәр күзәнәгенә Европа капиталы үтеп кергән: банклар, сәүдә компанияләре, курортлар аларныкы. Совет туристларына кесәлек, сувенир алырлык кына акча алмаштыралар. Шулай булуы бер караганда әйбәт тә. Югыйсә, фикер башкага юнәлер, сәяхәтнең төп максаты артка чигенер иде. Совет кешесенең бервакытта да, акчасы булмаганда да хәерче хәленә төшмәячәген долларга табынган гид аңлый алыр микән?

[1] Кит, кит! Болар руслар! Аларның акчалары юк!

Кояш кыздыра. Юл ерак. Офык та, күк тә күренми, бөтен дөнья күз камаштыргыч нурлар белән тулган. Ул нурлар чәнчеп, көйдереп алалар. Кояшның шундый ят сыйфатларын Суфияның моңарчы сизгәне юк иде. Автобустагылар җырламый да, сөйләшми дә, һәркайсы үз уйлары белән мәшгуль. Диңгез ярыннан барган олы юл буенда әледән-әле чатыр-кибетләр очрый. Йон свитер өстеннән вельвет куртка кигән гид чакрым саен диярлек төшеп су эчә. Тукталышның берсендә ул юлчыларга да лимонад эчәргә тәкъдим итте. Сары эчемлекле стаканнар тезелгән подносларны тотып, берсе олырак, берсе кечерәк ике малай автобуска керде. Унбиш пиастр түләп, бозлы җимеш суы эчтеләр. Бушаган стаканнарны кечерәге җыя бара. Сатучыларның икесе дә урамда сәүдә итүче малайлар кебек кеше алдына сәйлән булып сибелмиләр, кулаяклары кием эченә тыккан уклау сыман хәрәкәтсез. Үзләренә азрак җан кермәсме дип, җиде-сигез яшьлек кара малайга Суфия сүз катып карады:

— Кәйфә халәкә? [1] — Ягымлы сөйләшкән ят апага малай коты очып карап кына куйды.

— Шу исмак? [2]

— Каддеш әмрак? [3]

Сораулар җавапсыз калды, малайның тавышын да ишетеп булмады. «Болар руслар», дип, гид кисәткән, күрәсең. Куркынган күзле кечкенә малай кинәт подносын төшереп, стаканнарны чәлпәрәмә китерде. Үзе баскан урынында агарып катты. Малай күргән казаны каплаарга юлчылар тиз генә пиастрлар җыеп бирделәр. Шунда гына олысының йөзенә елмаю әсәре чыкты. Ул да юлчыларга карап түгел, учына көмеш тәңкәләр йомарлаган энесенә карап. Кечкенәсе исә күзен күтәреп карарга да курка. «Рус» дип котларын алып бетергәннәр икән сабыйларның. Ничек аңлатырга аларга русның кем икәнлеген? Ватылган стаканнар хакын кайтарып кына исбатлый торган нәрсә түгел шул бу. Чылбыр өзелеп бетмәгән әле. Фикерләрне зынҗырлап, кешеләр хәтерендә ул Россиянең канлы-тимерле чагын сакламакчы.

Соңгы елларда Суфияның вөҗданын газаплап торган сораулар һәм күп нокталар артына ныклы нокта куелды. Фуат белән алар бервакытта да икесе бер җан булып яшәячәк түгелләр. Суфия бер җылы сүзгә мохтаҗ чакта алтын балдак таләп итеп сузылган учны күз алдыннан җуеп буламыни!

## Мәңгелек шах

Ливанга килгәннән бирле туристлар диңгез буенда йөриләр, ләкин бер тапкыр да диңгезгә чумып караганнары юк. Программа буенча су коену сәяхәтнең соңгы ике көненә туры килә иде. Бу көннәрне Матура рәхәткә чумып ял итәсе көннәр итеп көтте. Көньяк кояшында берьюлы янмас өчен акрынлап күнегергә булдылар. Озын юлларның берсендә агачлыклар янында туктап ял иткәндә дүрт-биш минут кояшка күренергә исәпләп, берничә хатын-кыз төркемнән читкә китте. Бу эш алдан уйланылган, пляж костюмнары киелгән иде. Күлмәк салырга да өлгермәделәр, артларыннан Вероника Сергеевна килеп җитте.

— Өстегезгә таш ыргыта башласалар, мин сезне яклап калырмын дип ышандыра алмыйм!

---

[1] Кәйфә халәкә? — Хәлләр ничек? (Гар.)
[2] Шу исмак? — Исемең ничек?
[3] Каддеш әмрак? — Син ничә яшьтә?

Кояштан туймас сәфәрчеләр күндәмлек күрсәткәч, җитәкче ханым тынычлангандай өстәп куйды:

— Шәрә тәннән күренү монда коточкыч әдәпсезлек санала, халыкның милли хисләрен рәнҗетү була.

Юлчылар тирә-якка каранып алдылар. Агачлык дигәннәре әфлисун, мандарин, хөрмә агачлары икән, кайсысының җимеше әле өлгермәгән, кайсысының җыеп алынган, бакча икәнлеге шуңа күзгә ташланмый. Яхшылап йомшартылган кызгылт туфрак комга охшап тора. Ләкин комда агач үсми. Ташланып каткан җирдә кеше кулы бакча ясаган. Үзләренең белексезлекләренә хәйран калып, җиргә карап торган сәфәрчеләрнең уйларын куәтләгәндәй, Вероника Сергеевна тагын да тынычрак итеп әйтте:

— Бу шәхси бакчалар, монда керергә, гомумән, ярамый.

Тәнне кинәт яндырудан куркасы булмаган, пляжга барырга туры килмәде: җил чыкты, диңгез дулкынлана, диделәр. Туристларның коенырга билгеләнгән вакытлары буш иде, болай гына диңгез буена төшәргә уйладылар. Мөсафирлар яшәгән һотель диңгездән ерак түгел.

Суфиялар бүлмәләреннән төшкәндә каршыларына Габделбәр абыйлары очрады. Хатыны белән кызына беренче тапкыр үзе сайлап бүләкләр алган да, шуңа бик канәгать булып, авызын ерып килә. «Яшь аермасын истә тотарга иде, хатынызга тынычрак төс сайларга иде» дип, ханымнар тел тибрәтәсе иткәннәр иде, галим абзый колагына да элмәде: әйтеп карасыннар аны хәзер гаиләгә игътибарсыз дип! «Хуҗалыклы» дигән яңа сыйфатын тагын бер күрсәтер өченме, һотель янындагы карадан ялт иткән җиңел машинага ым кагып, яннарына килгән Фәриткә сүз катты:

— Әллә машина алып җибәрергә инде? Хатын янына шуып кына кайтып төшәргә, ә!

Фәрит кәефсез иде, дәшмәде. Хановның күңел көрлеге ханымнарга күчте, ахры, соңгы көннәрдә гел борчулы йөргән Суфия шаярып җавап кайтарды:

— Я машина, я хатын, Габделбәр абый. Һәркайсы игътибарны үзенә генә таләп итә.

— Алай сайлауга калса, хатын мәшәкатьсезрәк булыр минем өчен...— Ханов сөйләнә-сөйләнә әйберләрен куярга бүлмәсенә кереп китте. Аны көтеп алгач, сәфәрчеләр төркеме диңгезгә таба юл тотты. Фәрит Суфия белән янәшә бара. Тын гына баралар, берсе дә сүз башламый. Ханов белән әнә ничек ачылып сөйләшә. Фәриткә — ләм-мим.

— Сез Клеопатра кебек мәкерле...

Суфияга шулай әйтүенә Фәрит үзе дә гаҗәпләнде, чөнки мондый уй аның башына да килгәне юк иде.

Суфияның әллә хәтере калды, тавышы калтырабрак чыкты:

— Беркатлы чакларым да бар иде.

— Кәбестә кебек димәкче буласызмы? — Бер башлаган тонын Фәрит үзгәртә алмады.

— Нигә, язын бакчага утыртканда кәбестәнең дә ике нәфис яфрагы гына була. Дөнья киендерә, туган. Кәбестә бит көзге кырауларны бакчада каршылый.

Фәрит тагын күңелендә булмаган сүзләр әйтте:

— Мондый анализдан соң ул кәбестәне ашказанына салган кеше миңа Алып батыр булып күренәчәк.

Суфия да шаян дулкынга күчте:

— Минем нәкъ шундый батыр эзләп йөрүем инде!..

Шәһәр эчендә бушлай гына диңгез күрермен димә: яр буйлары тоташ ябык пляжлар. Анда керү хакы хатын-кызга ике лира, ир-

атка өч лира. Мондый аерманың сәбәбен тәгаен генә белә алмадылар, җәмәгать урыннарына хатын-кыз аз йөргәнлектән, кызыксындыру чарасыдыр дип фараз калдылар. Ләкин бүген пляжлар бүтән мәгънәдә дә ябык булып чыкты — диңгез тынычсыз, коенырга рөхсәт юк.

Дәмәшкътә мөсафирлар урамдагы сатучылардан гаҗиз иделәр, монда таксистлар бәгырьгә төшеп, үз хезмәтләрен тәкъдим итәләр, ун адым да тыныч кына җәяү атлап булмый. Бу юлы мөсафирлар сәхнәгә чыгарга әзерләнгән җырчы төсле пөхтә киемле шоферның тәкъдимен кабул итеп, шәһәр читенә киттеләр.

Диңгездә чыннан да давыл икән. Су ташкыны ярга килеп җитәрәк махсус дулкын кайтаргычларга бәрелеп сына да стена булып күтәрелә. Стенаның югары өлеше пыяла кебек үтә күренә. Пыяла кыя ярга ава да чәлпәрәмә килә, күбекләнеп, кире диңгезгә шуыша. Ухылдап, дулап, аның өстенә бүтән дулкыннар ябырыла. Тынгысыз хисләр ташкынын кемнәр генә үз йөрәкләренә тиңләмәгән. Бунтарь кеше күңеле ярларына кайтып төшкән дулкыннарга карап монда тынычлык тапкан.

Дулкыннар шаулавын тыңлап, мөсафирлар тын калган.

Суфиянның битенә су тамчылары килеп бәрелә. Ыргыласы иде шушы дулкыннарга каршы! Беләкләр талганчы колачлап йөзәсе иде! Сәяхәтнең беренче көннәрендә күзгә һәм күңелгә ят нәрсәләр белән мавыгу, хискә бирелү сизелә иде. Бер ел эштән соң ял алгач була торган бушанганлык хәзер бетте, күңел кыллары киерелде, аларга ни белән кагылсаң да, патетик марш яңгырар төсле.

Ярсыган дулкыннарның тамчылары чәчрәп йөзгә бәрелә.

Яр астында ике-өч гарәп малае кайнаша. Үрә басып ярга һөҗүм иткән дулкын кыясын алар башлары белән тишеп керәләр дә стенаның теге ягындагы бушлыкта торып калалар. Дулкын авып чәлпәрәмә килгәч, кире диңгезгә шуышкан ак күбекләр эчендә сикерешәләр. Тагын икенче, өченче дулкынны шулай башлары белән тишәләр. Ике олырак малай эчкәрәк, упкын-упкын булып тирбәлгән дулкыннар арасына, диңгезгә кереп китте. Анда куркынычсызрак та: дулкын үрә басмый, йөзүчене үзе белән әле күтәреп, әле төшереп тирбәлдерә генә. Малайлар күздән югалганда куркышып, күренгәндә сөенешеп, мөсафирлар яр башыннан күзәтеп торалар. Диңгез буенда үскән балалар гына болай шаярырга җөрьәт итә ала.

Соңгы кичә. Совет илчелегенең Культура үзәгендә очрашу бөтен сәяхәтне йомгаклау кебек булды. Туристлар анда киносеанс арасында чыгыш ясадылар. Алдан сөйләшеп куелганча, сүз фән һәм журналистикага бирелде. Мәскәү журналисты сөйләде. Кыска гына шигъри чыгышын тәгәлләп, ул болай диде:

— Безнең иң зур байлыгыбыз — алтмыш төрле милләтнең бердәм, дус булып яшәве. Революция җимеше булган бу байлыкны без күз карасы кебек саклыйбыз.

Үз илебездә колак күнеп беткән, купшы булып тоелган бу сүзләргә зал дәррәү кул чапты. Тыңлаучыларның ихлас мөнәсәбәтеннәнме, Матура да ул сүзләрне беренче ишеткәндәй дулкынланып тыңлый.

— Тагын олы байлыгыбыз — иртәге көнгә ышаныч,— диде оратор, алкышлаулар тына төшкәч.— Совет иле үткәргән тынычлык политикасын бөтен дөнья хезмәт ияләренең яклавы әлеге ышанычны икеләтә көчәйтә.

Гадәти сүзләр нинди сихри көчкә ия, залдагыларны аягүрә бастырды. Сәхнәдәгеләр ватаннары өчен, ил теләген әйтеп бирә алган оратор өчен сөенеп, зал белән бергә кул чабалар.

Советларга теләктәш кешеләр йөри булыр бу клубка. Өч йөзләп кеше сыешлы залның яртысыннан артыгы тулы. Чәчләренә чал кергән олы ирләр дә, кара мыеклары яңа сызылып килгән яшьләр дә бар. Җитди, сабыр, очкынлы күзләр...

Габделбәр Ханов татар әдәбияты, сәнгате турында сөйләде. Уникенче-унөченче гасыр поэмаларының, шулай ук аннан соңгы татар әсәрләренең гарәп хәрефе белән язылуын ишетү залдагыларга искиткеч яңа ачыш булды.

— Борын-борыннан югары культура иҗат иткән гарәп халкына ихтирамыбыз ифрат зур. Сезнең хәзерге әдәбият белән дә танышып барабыз. Муса Җәлил әсәрләренең гарәп телендә чыгуы татар һәм гарәп халкының күңел байлыгын күрсәтә торган әйбер: һәр ике халык чын поэзияне һәм чын батырлыкны таный белә!

Зал тагын тоташ алкышка әверелде. Һәммәсе тынычлангач, ораторларны тәрҗемә итеп торучы кечкенә буйлы, юка гәүдәле яшь гарәп кыюсыз гына әйтеп куйды:

— Бүген мин Муса Җәлил иҗаты белән очрашуның икенче шатлыгын кичерәм: герой шагыйрьне гарәпчә тәрҗемә итүчеләрнең берсе мин фәкыйрегез, Никола Тавил.

Тәрҗемәче туристларга карап баш иде. Яңадан башланган алкышларны кул хәрәкәте белән туктатты да сүзен сабыр гына дәвам иттерде:

— Илегезгә кайткач, шундый турылыклы ул үстергән халыкка минем халкым исеменнән баш иегез.

Ханов сәхнә алдына чыгып, Никола Тавилнең кулын кысты, аннан, болай гына аз дигәндәй, тәрҗемәчене олы кочагына алып, баласын сөйгән сыман аркасыннан сөйде. Алкышлаучылар арасында күзләрен сөртүчеләр күренде. Матура да атылып чыгарга әзер күз яшьләрен чак тыеп утырды.

Залдан тавышлар яңгырады.

— Татарча сөйләгез!

— Сезнең сөйләмне ишетәсебез килә.

Сәхнәдәгеләр үзара киңәшеп алдылар. Урыннан Суфия күтәрелде.

— Мин сезгә революциягә чаклы утыз яшенә дә җитми балкып сүнгән бөек шагыйрь Габдулла Тукай шигырен сөйлим. Шигырьгә чаклы бер-ике генә сүзем бар. Сез белгән чит телләрдә безнең йөгерек сөйләшә алмавыбыз кайберәүләргә гаҗәп булып, хәтта наданлык булып тоеладыр. Аклану дип уйлыйсызмы, аңлату дип уйлыйсызмы, шуны әйтәсем килә: киң илебезнең кайсы тарафына ничә мең чакрым китсәк тә, безгә анда французлар да, немецлар да, американлылар да очрамый. Алар телен белмичә дә һәркем белән күзгә-күз карашып, туганнарча сөйләшә алабыз.

Чак кына паузадан соң кабынып киткән алкышларны Суфия тәрҗемәче үрнәгендә кул хәрәкәте белән туктатырга теләде, ләкин залны алай гына тыярлык түгел иде.

Уңайсызланып кына әйтелгән сүзләрнең асылын залда утыручылар шундук аңлап алдылар. Юк, чит телләрне күп белүләре белән масаймыйлар гарәпләр. Илләрендә чит телне бөтенләй ишетмәсәләр дә, үкенәчәк түгелләр.

Йөрәктән кайнап чыккан сүз һәр халыкның күңеленә үтеп керә икән:

И туган тел, и матур тел,
Әткәм-әнкәмнең теле...

Аягүрә басып кул чабучы гарәпләр ни кичерәдер, ә Матураның күз алдында Бәйрүт читендәге алачыклар, баласын сәләмәгә төреп,

кукрәгенә кыскан гарәп хатыны... Алъяпкыч итәген биленә кыстырып, уң кулын маңгай өстенә куеп, сәфәрчегә капка ачарга килүче үз әнкәсе... Туганнары, дуслары, ватаны...

«Ил-18» Гарәбстан җиреннән аерылып, зәңгәр киңлеккә очты. Совет туристлары утырган бүлемгә иң соңыннан уртача буйлы, заманча киенгән утыз биш яшьләрдәге бер гарәп керде. Вероника Сергеевна аны сәяхәтчеләргә тәкъдим итте:

— Безнең яңа юлдашыбыз Рәфикъ Сидон, Мәскәү аша Монголиягә, журналистларның халыкара киңәшмәсенә бара.

Яңа юлдаш Суфия янындагы буш урынга утырды. Уң як канатта өчәр кәнәфи. Матура тәрәзә янында, Суфия уртада. Фәрит килгәндәгечә Габделбәр янында, ханымнарның артына урнашты. Хәзер Суфияның гарәп белән сөйләшүенә колак салып бара. Сөйләшүләре рәсми, гүя безнең журналист чит ил кешесеннән интервью ала.

— Русча каян беләсез?

— Ленин телен белмичә коммунист булуы кыен.

Яңа юлдаш журналист, Ливан коммунистларының җитәкчеләреннән берсе икән. Ничек тиз сөйләшеп китә ала Суфия таныш булмаган кеше белән? Аның юлчыга өзлексез сораулар бирүен Фәрит өнәп бетерми. Газетчы икәнеңне беразга онытып торырга да мөмкиндер бит: юлчы арган кыяфәтле күренә. Менә алар алларындагы җыелма өстәлне корып, шахмат уйный башладылар. Фәрит боларның уенын теләсә-теләмәсә дә күзәтеп бара башлады. Суфия бер-бер артлы ике фигурасын оттыргач, Фәрит сөмсере коелып, читкә борылды. Көрәшчеләр тиң булганда гына күзәтүе кызык.

Ә Суфия самолетта түгел, гүя үзе канатланып оча. Хыял түгел, чынбарлык аны җир шарының өстенә, чиксез зәңгәрлеккә күтәрде. Ул чит ил коммунисты белән, кешелек бәхете өчен көрәшчеләрнең берсе белән янәшә утыра.

Журналистканың тактикасын гарәп башта аңламады. Үзеген пешкалар белән ныгытып алган кызый фигураларын аямыйча һөҗүмгә күчте. Шахмат тактасына артык әһәмият бирмәгәндәй, «интервью»сен дәвам иттерә:

— Ничә хатыныгыз бар?

Рәфикъ Суфияга сагаюлы-сынаулы караш ташлады. Кызның соравын ул: «Хатыннар белән күп мавыгасыз, шуңа эшегез алга бармый», дигән кебек кабул итте. Шахмат тактасы өстенә иелгән кайгысыз алсу-ак йөз. Маңгай, күз тирәләре соклангыч ак. Бит алмалары, ияк тирәләре азрак кояшта янган. Каралмаган, алсуланган гына. Хәсрәтсез тормыш алсулыгыдыр бу. Әхсәнәне белсә икән бу ваемсыз кызый! Бит алмалары караеп эчкә баткан Әхсәнәне бер генә күрсә дә, аның иренә мондый сорау бирмәс иде. Өйләнешүләренең беренче төнендә үк Рәфикъ кулга алынып, алты ел төрмәдә утырды. Әхсәнәнең алты ел буе тыелган газетаны чыгаруда һәм таратуда ярдәм итүен Суфия кайдан белсен? Аларда күптән инде бу хәсрәт юк. Унике елга утырган ирен төрмәдән качырып, чит илгә озаткан Әхсәнәнең михнәтләре таныш түгел Суфияга. Тугыз ел ирлехатынлы исәпләнеп, әле бер генә ел, партия подпольедан чыккачкына бергә яшәүгә ирешүнең ни икәнен кайдан белсен Суфият-Суфия? Әнә ул, давылдан соң диңгез төсен хәтерләткән күзләрен тутырып, җавапсыз утыручы Рәфикъка карап алды. Карашлар очрашудан кыенсынып, яңадан тактага иелде.

Арттан үрелеп, Фәрит тә тактага карады: көчләр тигез диярлек, ләкин Суфия акларының позициясе отышлы. Уйлап уйнаганда Суфияның җиңүе мөмкин.

Рәфикъның күз карашы Суфияны сискәнергә мәҗбүр итте. Коңгырт кара күзләр тирәнлегеннән килгән ниндидер ут көйдереп алгандай булды. Очкын да, чаткы да, ялкын да түгел. Кара төтен аралаш дөрләүгә охшаган сагышлы ут...

Суфияның ничек кире алырга белмәгән соравын Рәфикъ җавапсыз калдырмады.

— Сез журналист бит, күзәтүчән булырга тиеш.

Суфия башта ук күршесенең кулында ярәшү балдагы күргән иде, уңайсызлыктан чыгар өчен генә булса да, күзәтүчәнлеген белдерергә ашыкты:

— Хатын саен бер балдак, димәк. Әйтәм лә гарәпләр алтын балдакны күпләп кия. Сезнең бер генә...

Мәгънәсе шул ук булса да, әйтелеше бүтән: гафу үтенгәндәй, гаепле елмаеп әйтелде бу сүзләр. Рәфикъка кинәт күңелле булып китте. Күбрәк сөйләсен иде кызый шундый юк-бар сүзләрне.

Шул чак ак ферзь очты, журналистканың күзәтүчәнлеге җитенкерәми икән. Гарәпнең күзендә бая чагылып калган сагышлы ут тәэсиреннән Суфия айный алмый утыра. Ирешелмәгән теләкләре бар Рәфикъның. Ике каш арасына сызылган тирән буразнада какшамас көч яшеренеп ята шикелле. Ә үзенең очлары өскә бөгелеп торган озын кара керфекләренә иң шөһрәтле артистка көнләшерлек. Гаҗәп. Какшамас көч һәм артистка көнләшерлек керфек. Суфияның гарәп турында күбрәк беләсе килә. Нинди булалар алар Суфия белән бер исемдәге партиядә торып, чит җирдә яшәүчеләр?

Шахматта ул Суфия кебек үк таркау, мавыгучан. Сорауларга артык сизгер. Җаваплар, сораулар кебек үк, эш арасында әйтелгән сүз булып тәкъдим ителә. Янәсе, махсус тукталып сөйләшкән сүз түгел, килешмәгән җире булса төзәтү мөмкинлеге кала.

— Иң явыз дошманыгыз кем?

— Маочылар.

— Алар сезгә дә кагыламыни?

— Сезгә кагылган һәр нәрсә безгә дә кагыла.

Фәрит уенның ахыры белән кызыксынды. Канәгатьсезлек белән тезенә сугып, зыян эшләгән балага дәшкәндәй, Суфияга әйтте:

— Ферзеңне кая куйдың?

Суфия үзендә артык гаеп сизми генә «булды инде» дигән ишарә белән кулын селтәде. Аннары «дөньяда ферзьдән мөһимрәк әйберләр бар әле» дигәндәй, гарәп белән әңгәмәсен дәвам иттерде:

— Халык көнкүрешен яхшыртуны безнең хөкүмәтнең төп экономик бурыч итеп куюына сез ничек карыйсыз?

— Уңай карыйбыз.

— Моны идея көрәшен йомшарту дип аңлаучылар булмасмы?

Рәфикъ уйга калды. Әллә сорау турында, әллә шахмат фронтындагы хәл турында. Контрһөҗүм белән мавыгылган, ахры, кара ферзь шәһит китә. Бер карарга килеп, Рәфикъ сорауга җавап бирә:

— Безнең илдә шагыйрьләр һәм политикларга караганда сәүдәгәрләр күбрәк. Нинди система кешегә әйбәтрәк тормыш шартлары тудыра — аларны шул мәсьәлә кызыксындыра.

Чү, ферзьне Суфия алмады, корольгә «шах» бирде. Гел куылып торган королен әле анда, әле монда качырып, Рәфикъ сүзен дәвам иттерде:

— Ә идея көрәшенә килгәндә, сез моны бер минутка да онытмыйсыздыр дип уйлыйм.

Өзлексез «шах» бирүче аклардан кара король ычкына алмады, үтерми дә, яшәтми дә торган куркыныч астында калды.

— Шәхси дошманыгыз бармы?

— Әйе,— диде Рәфикъ, елмаеп,— мәңгелек шаһ.

«Мәңгелек шах» шахматтагы хәлгә туры килсә дә, Суфия бу сүзләрне үз соравына җавап дип кабул итте.

— Ничек аңларга?

— Алыш-биреш, табыш кешенең аңын биләп алды.— Гарәпнең күзләрендә төтен аралаш ут тагын дөрләп китте.— Кеше үлми дә, яшәми дә, ул акча әсире, аның һәр хәрәкәте бәйле. Табигатьтән килгән бөтен гүзәл сыйфатларын ул үзенең хөкемдарына корбан итә.

Суфия күптәнге танышын очратып та, аны хәзер генә таныган кебек, Рәфикъка гаҗәпсенеп, сокланып, шул ук вакытта мәкерле «шаһ»тан котылу юлы эзләшкәндәй, борчылып карый. Менә нинди ул! Кешелек дошманы — аның шәхси дошманы. Суфияның да уйларын әйтеп бирде түгелме Рәфикъ?

Аларның күзләре очрашты. Ике каш арасындагы буразна язылган, анда яшеренгән ихтыяр көче гарәпнең күз карашына, тавышына күчкән:

— Сезнең халык өстеннән «шаһ» алай хакимлек итә алмый.

Фәрит, «дошманнар» арасындагы көрәш тәмамланганын күреп, тактага күз салды:

— Бер-берегезне җиңә алмадыгыз? Ничья?

Суфия Фәриткә ниндидер тәвәккәллек белән борылып карады. Кайгыртучанлык өчен рәхмәт тә белдерде зәңгәр каймалы соры күзләрнең карашы. Фәриткә аңлашылмаган хәвеф тә бар иде анда. Сүзсез Суфия тыныч кына, «әле син күп нәрсәне белеп бетермисең» дигән кебек әйтте:

— Дуслык җиңде, Фәрит.

«Ил-18» Туган җиргә төште.

— Әс-сәлями, Суфият!

— Хәерле юлга, Рәфикъ!

Ниһаять, туган туфрак, туган җир. Монда сине һәркем аңлый. Син монда һәркемне аңлыйсың.

Иң изге теләкләрне әйтеп бирә алган тел...

Иң кыю хыялларны тормышка ашыра алган ил.

Дәмәшкъ — Бәйрут — Әлмәт.

# КамАЗ ЕЛЪЯЗМАСЫ

**ИЮНЬ, 1973 ел**

«Лихачев исемендәге заводның баш конструкторы, профессор, Дәүләт премиясе лауреаты Анатолий Маврикиевич Кригерның эш бүлмәсендә стенага терәп куелган озын өстәл өстендә һәр вакыт тышларына «КамАЗ» дип язылган калын папкалар яткан булыр.

Илебез буйлап сәяхәт итүче машиналарга да «КамАЗ-75» дип язылган ялтыравык металл беркетелгән.

Һәр атна саен А. М. Кригер һәм ЗИЛның башка конструкторлары машинаның үз-үзен тотышы турындагы сводканы өйрәнәләр. Ике атна саен сводкалар Автомобиль промышленносте министрлыгы һәм Дәүләт комиссиясе членнарына да җибәрелә.

Кама елгасының сул ягында, Чаллыда, экскаватор беренче чүмеч җир казып алып, грандиоз төзелешне башлап җибәрүдән ел ярым элек ЗИЛ конструкторларына авыр йөк күтәрешле автомобиль проектлау буенча техник задание бирелде.

Кәгазьгә беренче төшерелгән сызыктан башлап ЗИЛның эксперименталь цехыннан зур алкышлар астында юлга чыккан «КамАЗ» тамгалы беренче машинага кадәр тагын ел ярым вакыт үтте. Дөньяда моннан да тизрәк барлыкка килгән машина юк әле. Аннан соңгы өч ел ярым дәвамында ЗИЛның конструкторлары, галимнәре һәм эшчеләре «КамАЗ»ның өч төрен, унике модификациясен эшләделәр.

ЗИЛ конструкторлары уенча, Мәскәү елгасы буенда туган, Кама елгасы буенда ясалып чыгачак йөк машиналары озак гомерле булырга тиеш: сиксәненче елларда да әле аларда мораль картаю кětелми. «КамАЗ» бик күп сыйфатлары буенча хәзерге заман совет һәм дөнья автомобиль төзү таләпләренә җавап бирә...»

**«МОСКОВСКАЯ ПРАВДА».**

«Шушы елның январь аенда КамАЗда олимпия уеннарына катнашучылар булды. Автогигант төзүче яшьләр белән очрашуларда алар Саппоро һәм Мюнхендәге спорт ярышлары турында сөйләделәр, камазлылар белән бергә спорт ярышларына катнаштылар һәм төзелештә эшләделәр.

Олимпиячеләр КамАЗ яшьләренә олимпия байрагы, хрусталь кубок бүләк иттеләр, бөтен Союз удар комсомол төзелешенә катнашучыларга мөрәҗәгать һәм рапорт тапшырдылар.

«Советский спорт» газетасы хәбәрчесе КамАЗ коллективында спорт тормышы яңалыклары турында сөйләвен үтенеп, ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре Илгиз Рахманкуловка мөрәҗәгать итте.

— Яшь эшчеләр,— диде ул,— үзләренең хатларында илебезнең җыелма командасына бригадаларның олимпия маркасын югары тотулары турында рапорт бирәләр. Кою заводы төзүчеләре Н. Шемякин, А. Новолодский, И. Караманешту,

Д. Загребальный бригадалары хөрмәтенә күп тапкырлар хезмәт даны флагы күтәрелде. Н. Шемякин бригадасы егетләре кыен шартларда 100—130 тонна бетон салып, смена заданиесен арттырып үтиләр...

Ярыштa әйдәүчеләр, кагыйдә буларак, спорт белән шөгыльләнүчеләр, чыныккан егетләр: чаңгы буенча спорт мастерлыгына кандидат В. Степачев, җиңел атлетика буенча «Металлургстрой» чемпионы М. Шевцов, хоккей буенча җыелма команда члены А. Зайкин һ. б. лар. Бу егетләр тәкъдиме буенча, һәр спортчы комсомолец үзенең буш вакытында шәһәр спорт комплексы төзелешендә 60 ар сәгать эшләргә алынды».

**«СОВЕТСКИЙ СПОРТ», МӘСКӘҮ.**

«Француз фотографы Картье-Брессон исеме безнең илебездә күптәннән билгеле. Советлар Союзына ул беренче тапкыр 1954 елда килә һәм «Мәскәү» дигән фотоальбом әзерли. Бу альбом Франциядә, Америка Кушма Штатларында һәм Германия Федератив Республикасында басылып чыга. Соңрак аның фотолары күргәзмәсе Луврга куела.

Күптән түгел Картье-Брессон тагын Советлар Союзына килде. Ул Кама автомобиль комплексы төзелешендә дә булды, двигатель, җыю, ремонт-инструменталь заводларында, Чаллының төньяк-көнчыгыш ягындагы яңа шәһәрдә уннарча рәсем төшерде.

**«СОЦИАЛИСТИЧЕСКАЯ ИНДУСТРИЯ»**
**НА СТРОИТЕЛЬСТВЕ КАМСКОГО АВТОЗАВОДА».**

«Берничә ел элек кенә әле Чаллы шәһәрен белүчеләр аз иде. Гигант төзелеше белән ул хәзер бөтен илебезгә атаклы. Билгеле, шәһәр, архитекторлар иҗаты буларак, заманга, гасырга ятышлы булырга тиеш.

Безгә сөйләделәр: Чаллы шәһәрен төзү тәмамлангач, анда күп катлы зур биналар башкаларыннан аерылып торачак. Алар — культура учаклары. Советлар Союзындагы яңа төзелешләрнең үзенчәлеге дә шул: зур урамнар кисешкән урыннарда, үзәк мәйдан урталарында культура сарайлары, театрлар, китапханәләр, күргәзмә заллары үсеп чыга...

Чаллы шәһәренең үз төзү индустриясе бар, аның мөмкинлекләре үскәннәнүсә бара, корыла торган биналар, корпуслар камилләшкәннән-камилләшә.

Шәһәрнең баш архитекторы Р. Насыйров — ул яшь кенә кеше — бирелә ярты гына ел эшли әле. Аңа үз эшендә ныклык, шәһәр төзү буенча һәр көн үз максатына ирешүне телибез. Чөнки яңа төзелешнең йөзе күбесенчә аның эшчәнлегенә бәйле.

Әмма шәһәрнең язмышы бер кеше җилкәсендә генә түгел. Аны бары тик шәһәр төзү буенча зур архитектура советы гына хәл итә ала. Һәм мондый совет Чаллыда бар. Аның члennары — бөтен илебезгә билгеле кешеләр. Төзелеш барышында бу зур абруйлы оешманың йогынтысы никадәр көчлерәк булса, шул кадәр яхшырак.

РСФСР Министрлар Советы Чаллы шәһәренең 2000 елга кадәр үсешен планлаштырды. Шәһәрнең киләчәктәге үсешен күз алдына китерсәң, эшче сыйныфының удар эшләренә Ватаныбыз юнәлткән зур игътибар белән горурланмый мөмкин түгел...»

**«СОВЕТСКАЯ КУЛЬТУРА», МӘСКӘҮ.**

«Чаллы шәһәренә килеп төшү белән үзеңне Мәскәүнең бер яңа районында итеп хис итәсең. Күп катлы йортлар төзелеп киткән кварталлар, киң проспектлар, хәрәкәт, ыгы-зыгы.

КамАЗның үзен әле күрмибез, ул кайдадыр якында гына, әмма монда барысы да аңа бәйле: сөйләшүләр дә, йорт түбәләрендәге лозунглар да. КамАЗга бару өчен беренче автобуска утырырга, бетон юл буйлап озак-озак барырга кирәк.

Завод идарәсендә тәэсирләр кенәгәсе бар. Анда Көнбатыш Германиядәге «Даймлер-Бенц» фирмасы президенты Г. Цаан болай дип язып калдырган: «...безнең өчен мондый масштаблар әлегә ачылмаган «яңа җир». Сезнең мондый комплексны төзү планы Көнбатыш Германиядәге барлык йөк машиналары заводларын узып китә. Моңа охшашлы нәрсә АКШта да юк».

Әлбәттә, масштабы белән бөтен дөньяны шаккаттырган эшне үтәп чыгу күңелле. Әмма бирedә колач — үзмаксат түгел. Илебезгә андый йөк машиналары бик кирәк. Аларны авыллар, төзелешләр, азык промышленносте таләп итә. Бик кыска срокта җитештерелергә тиеш алар. Менә шуңа күрә дә куелган максат үтәләчәк».

**«ТРУД», МӘСКӘҮ.**

«Сәлимә Җамалетдинова ялтырап торган, спираль рәвешендә бөтеркәләнгән металл йомычкасын тоткан килеш, бәхетле елмая. Комсомол оешмасы секретаре бу тар металл боҗраны — КамАЗның беренче заводында, ремонт-инструменталь заводында, үзе ясаган беренче деталь йомычкасын — барысы да күрсен өчен югары күтәрде. Яшь эшчеләрнең дулкынланудан күзләре дымланды, әйтерсең лә алар алдына үзләре китаплардан укыган бөек төзелеш күренешләре: Днепрогэс турбиналары, Магнитканың төнге утлы шәүләсе, кайнар сулышлы Турксиб килеп басты.

Әйе, хәзер үткәндәге шул зур хисләрнең, дулкынландыргыч күренешләрнең кабатлануы иде бу...».

**«КРАСНАЯ ЗВЕЗДА», МӘСКӘҮ.**

«Төзүчеләр кабул иткән социалистик йөкләмәләрдә хезмәттә югары күрсәткечләргә ирешү генә каралмаган. Алар удар төзелештә прогулчыларга, эчкечеләргә, хезмәт дисциплинасын бозучыларга урын булмаска тиеш, дип хәл иттеләр. Закон тәртипләрен саклау өчен көрәш — милиция, суд, прокуратура эше генә түгел. Бу өлкәдә җәмәгатьчелек оешмалары да зур эш башкаралар.

...Кама буендагы бөтен Союз комсомол удар төзелешендә без очраткан кешеләр дөньяда иң зур завод салалар. Алар кулы белән гаҗәеп матур кала — Чаллы шәһәре төзелә. Бу шәһәр һәр тармак буенча да үрнәк булырга тиеш — төзүчеләрнең омтылышы шул. Менә шуның өчен дә алар үзләренең гражданлык һәм җәмәгатьчелек бурычларын да намус белән үтиләр».

**«ЧЕЛОВЕК И ЗАКОН» ЖУРНАЛЫ, МӘСКӘҮ.**

«Чаллы шәһәрендә Ленин комсомолы премиясе лауреатлары — Зур театр солисты Евгений Райков, шагыйрь Роберт Рождественский, скрипкачы Виктор Третьяков, композитор Тукмаковлар булып киттеләр, төзелеш мәйданнарында, «Чулпан» кинотеатрында, «Гренада» концерт залында автогигант төзүче яшьләр белән очраштылар, концертлар бирделәр».

**«СОЦИАЛИСТИЧЕСКАЯ ИНДУСТРИЯ»**
**НА СТРОИТЕЛЬСТВЕ КАМСКОГО АВТОЗАВОДА.**

Фәләх Насыйров

# БӘЙРӘМ АЛДЫННАН...



Октябрь бәйрәменә әзерләнеп йөргән көннәрнең берсендә колхозга кинәт кенә район партия комитеты инструкторы килеп төште.

— Бик вакытлы килдегез, иптәш Мөбәракшин, — дип каршылады аны колхоз председателе Дамир Габдрахманов, чын күңелдән сөенеп. — Бәйрәм тантанасында алдынгыларга бүләкләр тапшырырга да уйлый идек. Җыелышта сезнең дә катнашу бик күңелле булыр.

Мөбәракшин пальтосын салып, өстәл янына утырды да, председательнең ачык йөзенә сынаулы карап, беравык сүзсез торды.

— Сезнең колхозга килүемнең максаты башка иде шул, иптәш Габдрахманов.—Ул, портфелен ачып, аннан бер хат алды.—Менә, танышыгыз әле, синең өстән жалоба.

— Жалоба?! — Председатель, гаҗәпләнеп, конвертны алды. — Укырга мөмкинме?

— Укыгыз, укы...

Берничә минуттан председательнең болай да чандыр гәүдәсе тагын да кечерәеп калгандай булды.

Ул маңгаена төшкән аксыл чәчен ашыкмый гына кулы белән артка сыпырып куйды, бераздан тагын хатка иелде.

«Габдрахманов, җитәкче буларак, бик юньсез администратор. Кешеләргә игътибарсыз. Аларның гозерләренә колак салмый. Тупас, эш урыныннан үз максатларында файдалана. Төзек булмаган машиналарны рейска чыгарга мәҗбүр итә. Мәсәлән, шофер Харис Галләмовны тормозлары эшләмәгән машинага утыртып, эшкә чыгарды. Бу машина ашлык ташыганда кеше таптатты. Тапталган кеше үлсә дә, председатель шоферга: «Син бер дә борчылма, мин сине төрмәгә утыртмам, алып калырмын», — диде. Тикшерү вакытында шаһит итеп җинаятьне ябып калырдай кешеләр чакыртты. Алар бу эшне яптылар. Председательнең кеше үтерүдә турыдан-туры катнашы юк микән? Мондый кеше колхоз белән җитәкчелек итә аламы?..»

Председатель өстенә бик авыр гаепләү ташланган иде.

Бүлмәдә урнашкан тынлыкны беренче булып район вәкиле бозды.

— Я, иптәш Габдрахманов, ни әйтерсез? — диде ул.

— Мондый очракта мин ни әйтим инде?.. — Дамирның тавышы баздан чыккандай тонык яңгырады. — Мин гаепләнүче. Бердәнбер үтенеч: хатның авторы, шушында язылганнарны идарәгә килеп, сезнең алда минем күзләремә карап әйтсен иде!

— Хатның авторы бар белән юк арасында. Үзегез күрәсез, имзасын танырлык түгел.

— Ачыкларга тырышырбыз...

Председатель шулай диде диюен дә, әмма башын бер борчулы уй бораулады: «Бәлки мин чыннан да хуҗалык белән җитәкчелек итә белмимдер?» Дөрес, ВЛКСМ райкомы секретаре, «Кама», «Правда», «Алга» колхозларында партия комитеты секретаре постларында эшләп, ул байтак кына тәҗрибә туплады туплавын. Үзенә калса, хуҗалык эшләре белән дә танышты кебек. Чапаев исемендәге колхозга председатель итеп куелгач, хуҗалыкны алдынгылар сафына чыгару теләге анда бик зур иде.

Егерме биш ел буе хуҗалык белән җитәкчелек иткән, авыру сәбәпле эшеннән киткән тәҗрибәле председатель Хөрмәт агадан соң яшь кенә килеш нәтиҗәле эшли алырмынмы дип, Дамир аз борчылмады. Ни әйтсәң дә, ул чакта әле утызны гына тутырган иде. Җитәкчелек итә башлавының беренче көннәреннән үк ул, иң элек, үзалдына кешеләрнең ышанычын, аларның ихтирамын яулау бурычын куйды. Моның өчен игенчелек һәм терлекчелек тармакларын күтәрү буенча нинди дә булса адым ясарга, инициатива күрсәтергә, яңалык кертергә кирәк иде. Кешеләр өчәр ай хезмәт хакы алмаганнар, колхозның финанс хәле бик авыр, экономикасы түбән. Колхоз председателе булып 1968 елның декабрь урталарында сайланды. Терлекләргә ашатырга саламга хәтле чамалы иде. Кышы да бик әшәке салкын килде. Февраль аенда фермада су торбасы шартлады. Кыш буе суны елгадан ташып интектеләр. Терлек азыгы эзләп чабарга да председательгә күп туры килде. Анысын ничек кирәк алай ерып чыктылар.

Ул елдагы кичерешләрен Дамир үзе генә белә! Борнак авылына килгәндә таза гына күренгән председатель ярты елдан соң, чәчү беткәндә, бөтенләй ябыгып калды. Шулай да Дамирның күңеле шат иде. Барлык терлекләр исән-сау кыш чыгып, яшь үләнгә аяк бастылар. Чәчүне дә хуҗалык вакытында бетерә алды. Бу, үз чиратында, яңа председательгә карата халыкта акрынлап ышаныч уятты.

Игеннәр ул елны бик әйбәт уңды. Мул уңыш көтелде. Әмма... Куанычлы ук булып бетә алмады. 500 гектар арышны боз сукты. Эшли башлавының беренче елында ук табигать тарафыннан шундый кыһәрләнүне Габдрахманов бик авыр кичерде. Аның өстенә урып-җыю чорында тагын бер бәла килеп чыкты. Балаларның шырпы белән уйнаулары аркасында авылда унбер хуҗалык янды.

Утны сүндергән чакта ук: «Колхозда барлык төзелеш эшләрен туктатып, бу кешеләргә йорт салыргамы инде?.. Моның өчен никадәр төзү материалы, транспорт, эшче көче кирәк булачак», — дип баш ватып торганда, аның янына «Маяк» колхозы председателе Әхәт Гарипов килде.

— Син бик артык борчылма, Дамир, — диде ул аталарча кайгыртучанлык белән. — Янган хуҗалыкларның берсенә безнең колхоз бушлай йорт салып бирер. Юкса, сезнең үзегезгә генә бу хәлдән чыгуы кыенрак булачак.

Аның бу фикерен КПССның район комитеты һәм хезмәт иялəре депутатларының район Советы башкарма комитетында да бик хуп күрделәр. Шунда ук маяклылар үрнәгенә күрше колхозлар кушылды. Барлык янган хуҗалыкка да районның унбер колхозы бер ай эчендә өй салырга вәгъдә итте. Бу — янган хуҗалыклар өчен генә түгел, колхоз председателе өчен дә һич уйламаган, көтелмәгән ярдәм иде. Әлеге минутта йорт-җирсез калучыларга караганда, мөгаен, Дамир күбрәк сөенгәндер.

Күрше колхоз җитәкчеләре исә Габдрахмановның яшьлеген, кайбер председательләр кебек шапырынырга яратмавын, киңәшмәләрдә

үзен һәрчак тыйнак тотуын, сүзен уйлап, үлчәп сөйләшүен һәм бу хуҗалыкның экономикасы йомшак булуын искә алдылар, ахры. Ә Дамир алар каршында үзен чиксез бурычлы санады, һәм үзенә, ул житәкчелек итә торган колхоз члennарына күрсәтелгән шундый ышаныч һәм ярдәмне аклар өчен тапшырылган эшен тагын да тырышыбрак эшләргә кереште. Күршеләрендәге һәр яңалык белән танышып, аларны үз колхозларына кертергә омтылды. Югары уңыш бирә торган сортлы орлыклар булдыру, терлекләрнең нәселен яхшырту, жиргә ашлама салу, терлек азыгы базасын ныгыту кебек мәсьәләләрдә ул күршеләреннән күп нәрсәләргә өйрәнде. Хуҗалык акрынлап үсә, экономикасы ныгый башлады. Колхозчыларның хезмәт хакларын түләүдәге тоткарлыклар бетерелде. Ярышта жиңүчеләр һәм осталыкка ирешкән өчен материаль һәм мораль кызыксындыру чаралары кертелде. Болар барысы да авыл эшчәннәренең инициативасын, аларның иҗади активлыгын бик нык үстерде. Өч ел эчендә сөрүлек жирләренең һәр йөз гектарына житештерелгән сөт — 37, ит — 26 центнерга, йомырка — 1.200 данәгә артты. Иген уңышын күтәрүдә дә сизелерлек борылыш ясалды. Терлек продуктлары житештерү һәм хәзерләү буенча Чапаев исемендәге колхоз район күләмендә алдынгылар сафына чыкты. Яңа эшләр, иҗади эзләнүләр белән янып йөргәндә, әлеге жалоба Дамирның дөньясын әйләндереп ташлады. «Әллә мин үз эшемдә ялгышлыклар жибәрдемме?» — дигән сорау бертуктаусыз аның миен игәүләде...

— Син бүген ашарга кайтырга уйлыйсыңмы?..

Габдрахманов салмак кына башын күтәрде. Ул хатыны Әлфинурның бүлмәгә ничек керүен сизми калган икән. Аның ни дип әйтүен дә ул башта төшенеп житмәде.

— Син нәрсә, яңа йокыдан уянган кешедәй, шаккаттың? — диде хатыны, ире янына килеп.—Ашарга кайтыгыз. Әнә кунагың да бар икән.

Дамир бары тик хәзер генә тәрәзә артындагы куе караңгылыкны абайлап алды. Хатынына карап торганнан соң, нидер исенә төшергәндәй тиз генә өстәлдә яткан хатка үрелде.

— Әлфинур, кара әле, — диде конверттан хат алып. — Бу кем имзасы булыр?..

— Бәй, Рая кулы бит! Әйе, Борнак кибете мөдире Нургалиева имзасы.— Аннан ул райком инструкторына карап:— Мин сәүдә берләшмәсенең бухгалтериясендә эшлим. Һәр сатучының язуы таныш, — дип өстәде.

Председатель, урыныннан торып, ишекле-түрле йөри башлады. Күз күне бәрәңге казыганда булган бер вакыйга аның исенә төште. Раяның ире Рәфкат Хәнәфиев тә кибеттә хәзерләүче булып эшли иде. Шулай бер көнне колхоз председателе урынбасары Васил Төхфәтуллин:

— Бәрәңге төягән бер автомашина үлчәүгә кермичә узды, — дип, Габдрахмановка килеп әйтте.

Ул шунда ук телефоннан:

— Борнак авылыннан килүче ЗИЛ автомашинасын туктатыгыз! — дип, Янгул почтасына хәбәр итте.

Берничә минуттан Рәфкат аңа Янгулдан шалтыратты.

— Ни өчен безнең машинаны туктатырга куштыгыз? Мин бит бәрәңгене хуҗалыклардан җыйдым, — диде.

— Кайбер нәрсәләрне ачыкларга кирәк. Хәзер үк Борнакка кайтыгыз! — диде аңа председатель.

— Вакыт әрәм була бит! — дип карышты хәзерләүче.

— Карагыз аны, әгәр кайтмасагыз, артыгыздан Шәмәрдән станциясенә чыгам, — дип кисәтте Дамир.

Хәзерләүчегә колхозга кире борылып кайтудан башка чара калмады. Идарә каршына машина килеп туктау белән аның янына председатель чыкты.

— Нинди бәрәңге алып барасыз? Каян алдыгыз?

— Соң, үзебезнең авыл Советы территориясенә кергән Карык-Серма авылыннан җыйдым. Җитмәгәнен Борнак хуҗалыкларыннан алдым, — диде Хәнәфиев, шикләнергә урын калдырмыйча.

Шулчак бәрәңге ташу өчен колхозга ярдәмгә район «Сельхозтехника» берләшмәсеннән килгән шофер сүзгә кушылды:

— Нигә хуҗалыклардан булсын?! — диде ул гаҗәпләнеп. — Колхоздан төядем бит мин бу бәрәңгене. Син үзең әйттең бит: «Председатель алырга кушты», — дип.

Хәзерләүче машинада утырган шоферга күзләрен әйләндереп, усал итеп карады. Боргаланып маташуның инде файдасы юк иде. Өч ярым тонна бәрәңге урланган. Габдрахманов шундук тикшерү органнарына хәбәр итте. Алар Хәнәфиевнең моннан башка махинацияләрен дә ачтылар. Һәм ул суд җаваплылыгына тартылды.

Менә шушы эшкә тикшерү барганда, Әлфинур беркөнне өенә кайткач:

— Карале, Дамир, — дип сүз башлады. — Рая миннән бик үтенә: «Дамирга әйт әле, иремне алып кала алмасмы икән?» — ди.

— Аның ире колхоз члены түгел бит! — диде аңа каршы Габдрахманов. — Ул бит сезнең коллективта эшли, сәүдә берләшмәсендә. Андый мәсьәләне сез үзегез хәл итегез. Минем монда нинди катнашым бар?..

Ир белән хатын арасында бу турыда бүтән сүз кабатланмады. Суд булып, Хәнәфиевне төрмәгә алып киткәч, Әлфинур елардай булып өенә кайтты. Рая аны:

— Синең ирең кеше үтерүче... Ул минем иремне дә төрмәгә тыкты, — дип сүккән.

Габдрахманов моңа башта артык игътибар итмәгән иде. Ә менә хәзер, шундый эчтәлекле жалоба да язылгач, бу хәл аны уйланырга мәҗбүр итте.

Вакыт соң иде инде. Жалобада язылган гаепләүләр турында Раяның үзе белән сөйләшүне икенче көнгә калдырып, таралыштылар. Өенә кайтып ашарга утырса да, Дамирның тамагыннан аш үтмәде. Урынга яткач, йокысы кермәде. Арлы-бирле әйләнгәләп, шактый вакыт узды. Ахырда ул урыныннан торып өстенә киенде. Балалары караваты янына килеп, изрәп йоклап яткан сабыйларының өстен япты да урамга чыкты. Әле узган ел гына төзеп бетергән зур культура йорты тирәякка ямь биреп тора. Аның янында гына типовой колхоз идарәсе бинасы. Илле урынлы балалар бакчасы да күптән түгел файдалануга тапшырылды. Фермадагы типовой терлек абзарларының да күбесе Дамир эшли башлагач салынды. Хәзер анда барлык авыр эшләр машинага көйләнгән. Ферма елдан ел үсә, киңәя, яңара бара. Терлекчелектә үз эшенең чын осталары булган хезмәт маяклары үсеп чыкты. Тавык караучы Миңнегөл Нәҗипова хөкүмәтебезнең иң югары бүләге — Ленин орденына лаек булды. «Почет билгесе» ордены кавалеры механизатор, коммунист Наил Нәҗипов үзен район күләмендә бәрәңге үстерү остасы итеп танытты. Соңгы елларда хуҗалыкта булган үзгәрешләр, беренче чиратта, әнә шундыйларның хезмәт нәтиҗәсе. Әмма алда башкарасы эшләр дә аз түгел әле. Ремонт мастерское, типовой гараж бик кирәк. Председательнең башыннан тормышка ашырасы планнар бер-бер артлы йөгереп узды. Һәм никтер аның йөрәге сыкрап куйды. Беркайчан да ул үзенә карата шундый коточкыч гаепләү ташларлар дип уйламаган иде.

Тып-тын авыл урамнары буйлап озак йөрде Дамир. Туңа башлагач, идарәгә кереп, кабинетында ут яндырды. Өстәлдәге бүләкләнергә тиешле кешеләрнең исемлегенә, Почет грамоталарына күзе төште. Бу

минутта аның башыннан бәйрәм уе качкан, күңелен үпкә катыш әрнү хисе биләгән иде.

Шулай уйга батып утырганда, бүлмәгә ревизия комиссиясе председателе, заманында озак еллар партия оешмасы секретаре булып эшләгән пенсионер Гарифулла ага Хәбибуллин килеп керде.

— Күрәм, йокың качкан синең, Дамир... Инде кайчаннан бирле бүлмәңдә ут яна, — дип, ул председатель каршына килеп утырды. Җавап та көтмәстән, сүзен дәвам иттерде: — Ишеттем, Дамир. Барысын да ишеттем. Теге... ни... жалобаны әйтәм. Авыл җирендә хәбәр тиз тарала бит ул...

— Башыма күсәк белән суккан кебек булды әле бу, Гарифулла абзый. Күңел бик төште...

— А, юк! Минә анысы ярамый. Хәсрәтләнерлек нинди гаебең бар? Я, әйт әле, нинди гаебең бар? Берәр нәрсә үзләштердеңме, әллә берәр яманлык эшләдеңме? Киресенчә, безнең авылга син килгәннән соң колхоз гөрләп үсә, ныгый башлады. Эшләгән кеше ай саен уч тутырып акчасын ала, мал-туарына печәне, саламы бирелә. Аның өстенә, өстәмә түләүләр, бәйрәм саен бүләкләр... Безнең аны элек күргән бар идемени! Боларны авыл халкы белми дисеңме?!

Пенсионер карт башыннан бүреген салып куйды да, бармакларын җәеп, уң кулын алга сузды:

— Авылда йокысыннан иң иртә кем тора? Председатель. Бер булды. Иң соңыннан кем ята? Председатель. Ике. Төзү материаллары, минераль ашламалар артыннан көн-төн чапкан кеше дә шул ук. Техника алу, аларны ремонтлау, кадрлар хәзерләү, терлекләрнең нәселен яхшырту, баш санын арттыру, продуктлылыгын күтәрү — юк, һәммәсен дә санап бетерергә мөмкин түгел, куллардагы бармак җитми. Боларның барысы да иң элек председательгә, аның кешеләрне оештыра белү сәләтенә, җитәкчелек итү осталыгына бәйләнгән бит. Әйтик, менә шушында, синең урында бер юньсез кеше утырсын әле, колхоз хәзер артка тәгәри башлый. Менә шулай, Дамир, син башыңдагы икеләнүләреңне чыгарып ташла. Уйлаган планнарыңны тормышка ашыр. Халык сине ярата, хөрмәт итә. Жалоба язуда кемнәрнең кулы уйнаганны белән мин. Шабашниклар эше бу. Синең өстеңнән жалоба язарга намуслы кешенең кулы һич күтәрелмәс...

Гарифулла аганың сүзләреннән Дамирның күңеле тынычланып, йөзе яктырып китте.

Иртәгесен идарәгә жалобаның авторы Рая Нургалиеваны чакырттылар.

— Бу хатны сез яздыгызмы?

— Әйе, мин. Әллә дөрес түгелме? — диде сатучы чая гына.

— Сез колхоз председателен кеше таптауда гаеплисез, бу нахак бит,—диде аңа партия оешмасы секретаре.

— Соң, Мәйсәрә апаның үлүе хакмы, әллә юкмы?..

— Ә монда председательнең ни катнашы бар? Мәйсәрә апа бит кырдагы салам эскерте арасыннан машина каршына үзе кинәт чабып чыккан. Шофер машинасын борып өлгерә алмаган. — Бераз сүзсез торганнан соң, Муллагалиев дәвам итте: — Ул көнне иптәш Габдрахманов авылда да түгел, Казанда, командировкада иде. Аңа хатыны хәбәр итте: «Кеше таптаттылар, кайт», — дип. Ул кайтып җиткәндә инде тикшерү дә беткән иде бит.

— Ә колхозчыларны җәберләве? Печәннәрен алу, штрафлар салу кирәкме? Бакчаларын кисү дисеңме... — дип тезеп китте сатучы.

Председательдән кала бүлмәдәгеләрнең барысының да йөзләренә елмаю чыкты.

— Болай булгач, сез, — диде партоешма секретаре сабыр гына. — колхоз идарәсе рөхсәтеннән башка шабашниклыкта йөргән кешеләр турында сөйлисез. Әйе, устав нигезендә бакчаларның аларга тигәннән артык өлеше чыннан да киселде. Колхоздан бирелгән терлек азыклары да алынды, өзлексез эш стажлары да сакланмады. Әмма боларның берсен дә ул үз белдеге белән генә хәл итмәде бит! Колхозчылар таләбе буенча, гомуми җыелышка куелып, бу турыда махсус карар чыгарылды. Ул бары тик шул карарны тормышка гына ашырды. Монысын да сез, Рая, бик яхшы беләсез. Теләсәгез, менә җыелыш протоколларын укырга мөмкин.

— Ник сез кәгазьгә карап эш итәсез? Булган фактларны күрергә кирәк, — дип карышты Рая.

Моңарчы сүзсез генә тыңлап утырган район партия комитеты инструкторы Мөбәрәкшин әңгәмәгә кушылды. Кичә кич, председатель кайтып киткәч, ул бу турыда авыл коммунистлары, идарә членнары, җирле Совет депутатлары белән дә сөйләшкән, киңәшкән иде. Барысы да бер фикер әйттеләр:

— Дамирның гаебе юк. Халык белән эшли, уртак тел таба белә. Тыйнак. Эш өчен бөтен барлыгын бирә.

Моны Мөбәрәкшин үзе дә яхшы белә иде. Әмма жалоба кергәч, аны объектив рәвештә тикшерергә кирәк.

— Председательнең тагын нинди гаепләре бар дип саныйсыз? Барысын да әйтеп бетерегез, — диде ул Раяга.

— Язганнары да җитеп торыр...

— Язганнары расланмый бит. Гаепсез кешегә яла ягу закон нигезендә тыела. Моның өчен сезне суд җаваплылыгына тартырга туры килер...

Ә суд жалобаның авторын гаепле дип тапты...

Бөек Октябрь бәйрәме алдыннан Балтач районының Чапаев исемендәге колхозында булган бу вакыйганың финалы шулай тәмамланды. Бу күңелсез вакыйга бәйрәм тантанасын күләгәли алмады. Бу хәлдән соң авыл халкының Дамир Габдрахмановка карата мөнәсәбәте тагын да якыная, ихтирам һәм ышанычы тагын да үсә төште. Алда торган бурычларны хәл итү өчен хезмәт киеренкелеге артты, ярыш ялкыны тагын да киңрәк колач алды.

# СӨЙКЕМЛЕ СӨЯГЕ БАР

Беренче тапкыр аны кайда күреп, кайда тыңлаганны хәтерләмибез. Безнең буын кешеләре өчен ул һаман да бар, һаман да булган кебек. Йомышың төшеп тирә-күрше өлкәләргә, чит-ят шәһәрләргә китәсеңме—кайда да ачык буяулы афишалардан ул елмая. Бер күргәндә ул Мәскәү, Ленинград сәхнәләреннән торып кешеләргә үзенең йөрәк жылысын өләшә, икенче карасаң, Урал-тау итәкләренә, ерак Себер якларына, үзбәк янсә казакъ дусларыбыз янына барып чыга. Ул да түгел, үзебезнең Татарстан җирендәге культура сарайларына яки вак-вак авылларның үч төбе кадәрле генә клуб сәхнәләренә кайтып төшкән була. Кунар өчен купшы ботак сайлап, урын талымлап изаланмый бу сайрар кош, каршысында тик кешеләр булсын да, теленнән тамган хак сүзләрен сеңдерерлек пакь күңелләр булсын. Кайда да моңлы, кайда да шук, дәртле яңгырый аның көр тавышы. Аны һәр җирдә беләләр, көтәләр, һәр җирдә таныйлар, яраталар.

Сайрар кошка тыңлап сүз башлагач, болар инде атаклы бер җырчы турында сөйләргә җыеналар дип уйларсыз. Юк, җырчы түгел, тик алай да җырчыларга, шагыйрьләргә юлдаш, әдипләргә кулдаш кеше ул.

Шулай бервакытны, әдәби очрашулар үткәрергә дип, аның белән без өчәүләп Биектау районына чыгып киттек. Юлдашыбыз һәр икебезнең күңелен инде бала чактан ук биләп алган, бик якын күргән кешебез булса да, ничектер шүрләбрәк кузгалган идек бу сәфәргә. Ләкин юкка шүрләгәнбез. Үзара да шундый ук гади, нәкъ сәхнәдә күргәнебезчә сөйкемле, кече күңелле икән ул. «Я, киттекме, егетләр? Әйдә бер җилләнеп кайтыйк әле, электриккә утырып...» — булды аның беренче сүзләре. Поезд кузгалу белән чемоданыннан кып-кызыл әнис алмалары чыгарды да: «Үз бакчамның хәләл җимешләре, юл сәдакасы булсын, бисмиллагызны әйтеп ашагыз», — дип, безгә тоттырды. Шуннан соң әлеге алмаларга ялгап, инде күптәнге танышлар шикелле, көлдерә-көлдерә берничә мәзәк сөйләп ташлады. Аннары, сүз җаена китереп, безне башыннан кичкән яки ишетеп белгән гыйбрәтле истәлекләр дөньясына алып кереп китте. Әдәбиятыбызда һәм сәнгатебездә якты эз калдырган, әле бик күп еллар сагынып сөйләрлек олы шәхесләр турында иде бу истәлекләр. Һади Такташ, Салих Сәйдәшев, Галиәсгар һәм Шәриф Камаллар, Кәрим Тинчурин, Бари Тарханов, Мөхтәр Мутин һәм тагын, тагын бик күпләр...

Авыз ачып тыңлый-тыңлый, көлә-көлә бара торгач, үзебез төшәсе станцияне дә узып киткәнбез.

— Сәдака кабул булмады бит болайга киткәч, — дибез моңа.

— Җиде-сигез чакрымны гына пешкомобильгә утырып та барабыз аны, кайгырмагыз, — ди бу.



Станциядән аз гына китеп, олы юлга аяк басуыбыз булды, безнең янга тузанга батып беткән йөк машинасы килеп туктады. Шоферы кабина тәрәзәсеннән башын чыгарды да:

— Фәйзи абый, исәнмесез! Кая барышыгыз? — дип кычкырды.

— Биектауга ла,— ди Фәйзи ага шаяртып.

— Шулаймыни... Миңа бераз әйләнеч тә инде... Әйдә, ярар, илтеп куйыйммы соң?

— Шәп булыр иде дә... Кем дип әйтим соң үзеңне?

— Белмисез сез мине, Фәйзи абый...

— Ярый, алайса, рәхмәт, энекәш...

Фәйзи ага, кабина ишеген ачып, бер аягын баскычка куйгач, безгә таба борылды да хәйләкәр генә елмайгандай итте. Аннары:

— Менә бит ул юл сәдакасы... Ә сез, имансызлар...— дип көлә-көлә иплән кенә шофер янына кереп утырды. Ә без, ике «имансыз», югарыга, машина кузовына менеп кунакладык...

*

* *

Биектау райкомында барысы да ачыкланган, колхоз җитәкчеләре белән дә алдан ук сөйләшеп-килешеп куелган булып чыкты. Маршрут кәгазен кулга тоттырдылар да, хәерле юл теләп, безне Киров исемендәге колхозга озаттылар.

Чыршы авылына килеп кергәндә, өйлә инде күптән авышкан иде. Хәзергедәй урак өстендә гадәттә авыл урамнары бик тын, кешесез була торган иде. Ә монда кибет тирәсендә дә, капка төпләрендә дә халык байтак күренә. Фәйзи ага бу хәлдән никтер сагаеп калды: «Карагыз әле, егетләр, ник сүрән бу халык, нигә җыелышкан болар?».

Сораша торгач, шуны белеп алдык: моннан берничә көн генә элек колхозның унлап салам эскерте янган. Шундый корылыклы елда әле монысы да зур байлык, дип торган ул кадәр саламнан колак кагу игенче өчен, әлбәттә, бик күңелле хәл түгел. Шуның өстенә тагын кинәт кенә авылның бер егете үлеп киткән — җирлисе көннәре икән.

Ул арада, әллә без килгәнне ишетеп, әллә инде үзенә шулай кирәк булыпмы, идарәгә колхоз председателе Шамил иптәш Гыйльманов кайтып керде. Ул бик хафалы күренә иде. Шулай булмый ни, хуҗалыкны кабул итеп эшли башлавына әле икенче генә ае, әнә бит нинди казага тарганнар. Күрешеп-танышудан соң сүзебез дә шуннан башланды:

— Уңайсыз вакытка туры килгәнбез икән, иптәш Гыйльманов, бик борчулы чагыгыз бит, — дибез.

— Шулайрак шул. Малай-шалайлар инде, ут ягып уйнаганнар. Башка вакытта булса әле бер хәер иде, быел бит... Үзегез беләсез. Егет тә бик жәл... Сез, иптәшләр, артык хафаланмагыз. Сөйләшенгән булгач, үткәрербез инде ул кичәне. Башка җирдә бүген көтмиләр бит сезне, — ди.

Күренеп тора, алай да вай, болай да вай иде председательгә. Сүзгә Фәйзи ага кушылды:

— Юк, энекәш, алай түгел ул. Без ничек тә җайларбыз үз эшебезне. Соңыннан, кайтышлый сугылырбыз әле. Хәзер әнә халыкның күңелен табарга тырыш инде син. Кеше күңеле бит ул...

Без икенче колхозга киттек.

*
* *

Фәйзи ага бик моңаеп, сүрәнләнеп калган иде. Авылны чыгып байтак киткәч кенә телгә килеп:

— Өч баласы калды диделәрме әле теге егетнең? — дип сорап куйды. Аннары, шофер белән янәшә утырган җиреннән безгә таба борыла төшеп, сүзен дәвам итте:

— Миндә дә шул кайгы бит әле, егетләр. Сезнең белән шаяртып сөйләшәм, көлгән булам, ә үземнең эчем тулы ут. Йөрәк сыкрана. Узган атнада гына киленебез вафат булды. Биш оныгым ятим калды... Шул кайгыларымны да таратыйм дип чыгуым иде бу юлы... Ә ятимлек ул... — дип, кабат башлаган сүзен төгәлләмичә, Фәйзи ага тагын тынып калды.

Ятимлек, ятимлек... Белә бит ул аның ничек ачы булуын! Үз башыннан кичкән — җиде ятка да теләми ул андый язмышны.

Алар унбер малай, бер кыз үскәннәр. Бөек вакыйгалардан, олы тетрәнүләрдән соң кысыр һәм рәхимсез 1921 ел килә. Ачлык Чистай якларындагы Яуширмә кешеләренә дә күпме күз яше, күпме бәхетсезлек китергән. Унбер яшьлек Фәйзине дә ул әнисеннән мәхрүм иткән. Арада иң нечкә күңеллесе булгангамы, бу вакыйга аның соңгы канатларын каергандай, соңгы шатлыкларын тартып алгандай була. Хәзер инде беркем дә аның башыннан шундый якын итеп сыйпамас, әнисенең моңлы тавыш белән мөнәҗәт әйтүләрен, җыр сузуларын ул инде беркайчан да ишетмәс. Югыйсә, шул кадәр әйбәт иде бит бу мәңге көләч кояш астында, бик түгәрәк иде бит дөньясы...

Тормыш куып шыр сөяккә калган Сәйяр агайның да балаларының сынык күңелен күрер чагы түгел. Озакламый ул үзе дә дөнья куя. Гаилә өелешеп ятим кала. Олыраклар әнә кайсы кая таралыша да башладылар. Бөтенесенең якасыннан үлем карачкысы кысып тоткан. Һәркемнең үз кайгысы кайгы. Кайчакта гел җор сүзле мишәр карты Катәй бабай гына моңаеп утырган малайны юатып үткәли:

> О чем думать, безгә ни булган
> Безнең кебек белән ил тулган, —

ди ул, үзе дә хәсрәтләреннән бушанырга теләгәндәй.

Ярата аны Фәйзи. Кече күңелле, мәңге шат чырайлы булганы өчен, кешеләргә ярдәмчел булганы өчен ярата. Әле моннан өч ел элек авылга китап сатучы килгәч тә, Катәй бабай аңа Тукай шигырьләрен бүләк иткән иде. Инде һәфтиякне шартлатып укый белгән малайның түбәсе күккә тиде.

— Укы, ятла, күләп сулә, Тукай абзаң күләп язган, — дип киңәш итте мишәр карты. Ятламыймы соң Фәйзи, ятлады ул аны, шуның белән теле ачылды ич аның, Тукай шигырьләрен оста көйләве өчен авылдашлары арасында матур сөйләүче малай дигән ат та алды. Ә аннан соң...

Кара инде, алай ук өметсез түгел икән ич Фәйзинең хәле, яңарган, сафланган иле бар икән ләбаса аның! Казандагы үксезләр йорты... Мәктәп... Педагогия техникумы... Ә менә соңгысына никтер күңеле утырмады Фәйзинең. Касыйм Шамил дигән артист балалар театры оештырып җибәргән бит әнә. Шунда тартыла бит әле бу күңел дигәнең, шунда йөри малай. Җитмәсә тагын, Галиәсгар абзасы да шәйләп алган үзен.

Болай килеп чыга бу. Балалар театры урнашкан мәдәният йортында еш кына әдәбият кичәләре үткәрелә. Шундый кичәләрнең берсендә Фәйзи Һади Такташның «Нәни разбойник» дигән шигырен укый. Шигырь укылып беткәч, дулкынланудан колак яфракларына чаклы кызарган малайны Һади Такташ үз янына дәшеп ала һәм:

— Әйбәт сөйләдең, егет икәнсең, — дип башыннан сыйпый.

Такташ яныннан китәргә дә өлгерми, Галиәсгар абзасы тотып ала.

— Малай, синең тавышың бик көр икән, үзең бөдрә дә икәнсең, сиңа артист булырга кирәк, педтехникумнан театр техникумына күч, — ди ул Фәйзигә.

— Нургали абый җибәрмәс шул, — ди малай, тартынып кына.

— Әйт директорыңа, Галиәсгар Камал шулай кушты диген, җибәрер...

Хәзер инде, педагогия техникумында бер ел укыгач, малаең театр техникумына күчәсе. Әмма анда керү өчен имтихан тотасы бар. Тавыш та көр Фәйзинең, сөйли дә белә, тик буй дигәне генә бик бәләкәй икән. Имтихан алучыларның кайберләре моны бик өнәп бетермиләр, үсә төшсен мәллә бераз дип, кире кагарга чамалыйлар. Ярый әле, комиссия председателе Кәрим абзасы Тинчурин мәрхәмәтле була.

— Яле, бас, урындыкка баскач үсә ул, — дип, Фәйзине урындыкка бастырып сөйләтә...

Театр техникумының икенче курсында укып йөргән көннәрнең берендә ул чагында Академүзәктә эшләгән Шәриф Камал чакыртып ала Фәйзине.

— Менә нәрсә, — ди ул егеткә, — башка халыкларда цирк артистлары, сатирик-юмористлар, клоуннар бар. Ни өчен бездә дә булмаска тиеш. Әйдәгез, Кәрим Морзаханов белән икегезне парлыйбыз да Фәйзи-Морзи дигән исем белән циркка чыгарабыз. Репуртуар белән үзем тәэмин итәрмен...

Шулай итеп, бу ике егет җәйге каникул вакытларында сатирик-юморист булып циркта эшли башлыйлар. Ул чактагы яшь, икесе дә бәләкәй буйлы, җор телле бу шаян артистларны өлкән буын кешеләре бәлки әле хәзер дә хәтерлиләрдер. Шул чорда (1927—29 еллар) Казан циркында берничә ел рәттән СССРның халык артисты Михаил Румянцев — «Карандаш» та эшли. Күп вакытта аларга рус һәм татар телендә өчәүләп чыгыш ясарга туры килә. Аренада башта Румянцев күренә. Шуннан соң ул Фәйзи-Морзиларны каршылый һәм:

— Фәйзи — Көдрәбаш, Морзи — Каракаш, мин — Карандаш, — дип үзләрен тамашачылар белән таныштыра торган була...

Әнә шулай укып та, уйнап та йөри торгач, техникум тәмамлана. Фәйзи Юсупов Казан театрында эшли башлый. Зәйни Солтанов, Мохтар Мутин, Нәгыймә Таҗдарова, Фатыйма Ильская, Гөлсем Болгарская, Шакир Шамильский кебек күренекле артистларның уйнауларын хәйран калып күзәтә.

Озак та үтми, 1931 елны, Фәйзи армия сафларына алына. Беренче укчы татар полкында хезмәт иткәндә дә ул сәхнәне ташламый, үзешчән сәнгать көчләре белән җитәкчелек итә, чагышлар ясый.

Гаскәри хезмәттән кайткач, ике ел Мәскәү эстрадасында эшли. Анда ул рус эстрадасы осталары Смирнов-Сокольский, Илья Набатов, Аркадий Райкин, Ирма Яунзем иҗатлары белән якыннан таныша, данлыклы сүз остасы Владимир Яхонтовны тыңлый.

Мәскәү эстрадасында эшләгәндә Фәйзи Юсуповка талантлы җырчылар Наилә Рәхмәтуллина, Асия Измайлова, гармунчы Фәйзулла Туишевлар белән гастрольләргә йөрергә, беренче профессиональ җырчыбыз Фәттах Латыйпов биргән концертларда катнашырга, атаклы җырчыларыбыз Ситдыйк Айдаров, Галия Кайбицкая, Гөлсем Сөләйманова, Рәшит Ваһапов, Сара Садыйкова концертларын алып барырга туры килә.

Әйе, язмыш аны татар культурасының бик күп күренекле вәкилләре белән очраштырды. Аларның таланты Фәйзи ага күз алдында чәчәк атты. Бүген дә афишаларда аның исеме белән рәттән бик күп сәнгать осталарының исеме ялтырый. Соңгы елларда РСФСРның атказанган, ТАССРның халык артисты, Тукай бүләге лауреаты Илһам Шакиров-

ның елдан-ел күркәмрәк, аһәнлерәк, колачлырак була барган халыкчан иҗатына юлдаш ул. Алар, илебезнең төрле почмакларында бер үк сәхнәдән торып, хезмәт сөюче кешеләребезгә рухи байлык, шатлык һәм бәхет өләшәләр.

Фәйзи аганың тамашачылар алдына ничек килеп чыгуына игътибар иткәнегез бардыр. Җитез хәрәкәтләр белән сәхнә түренә чыгып басар да кешеләрнең алкышларына тыйнак кына баш ия-ия уйланып калыр. Нәрсәдән башларга соң әле? Менә шушында аның яңа тормышы, иҗади тормышы башлана лабаса. Үзен тыңларга килгән бу кешеләргә нәрсә әйтер ул? Ниләр белән сөендерер, ниләр белән дулкынланырга мәҗбүр итәр? Фәйзи ага репертуарындагы әсәрләрне бергә тупласаң, калын-калын томнар җыелыр иде. Тормышның һәр очрагына ярардай, теләсә кайсы сорауга җавап булырдай алар. Ара-тирә ул залга күз төшереп ала. Ә анда — игенчеләр янсә эшчеләр, төрле хезмәт, төрле профессия кешеләре, һәммәсе дә бизәнеп, киенеп-ясанып килгән. Көнкүрешләре җитеш, күңелләре шат, күрәсең. Әйе, бүген нәкъ менә тормышыбызның матурлыгы, илебезнең олы казанышлары, республикабызның тату халыклар гаиләсендә көннән-көн чәчәк атуы хакында сөйләргә кирәк. Һәм ул Нәкый Исәнбәтнең «Татарстан сәламе»н башлый.

Әсәр озын, җитди, аны бертөрле генә тавыш белән укысаң, тамашачыны ялыктырып бетерергә мөмкин. Әмма залда чебен очканын ишетерлек тынлык. Алгы рәтләргә тезелешкән бала-чага, дөньяларын онытып, авызларын ачып артистка текәлгәннәр. Ара-тирә көлгән авазлар яңгырап куя. Ә Фәйзи ага, тылсымлы карт сыман, һәммәбезне Татарстан җире буйлап сәяхәт иттерә, аның данлы тарихы белән таныштыра. Сөйләгәндә ул каударланмый, кабаланмый. Кул хәрәкәтләре соң дәрәҗәдә саран. Интонацион көчешләр табигый, артист үз тавышы белән бөтен нечкәлекләрнең, бөтен тибрәнешләрнең чамасын белеп идарә итә.

Бер шигырьгә икенчесе, өченчесе ялгана. Габдулла Тукай, Һади Такташ, Муса Җәлил, Әхмәт Фәйзи, Зыя Мансур, Әнгам Атнабаев... Туган ил туфрагы, таңнан торып халык байлыгын ишәйтү өчен кырга ашыгучы авыл кешеләре, яшьлек, яшәү һәм үлем, тормыш мәгънәсе турында шигырьләр. Кайсылары лирик җылылыгы белән күңел кылларын тибрәтә, икенчеләре тормышыбыздагы ямьсез күренешләрне сатира утында көйдерә, өченчеләре җиңелчә елмаю уята, уйларны, хыялларны кытыклап ала. Төрле пландагы, төрле югарылыктагы әсәрләр. Татарстанның атказанган артисты Фәйзи Юсупов башкаруында алар яңача яши башлыйлар, чын сәнгатьчә яңгыраш алалар. Кул чабулар, дәррәү көлүләр, хуплау авазлары белән аралашып, минутлар артыннан минутлар үтә. Ләкин берәү дә залны ташлап чыкмый. Шул ук тынлык, шул ук игътибар. Халык аны кабат-кабат чакыра, сәхнәгә үтенеч язылган кәгазьләр ява...

Менә ул, ниһаять, йөрәгеннән ташкан хисләрдән әсәрләнеп, чиксез бәхетле кыяфәттә сәхнә артына чыга. Шактый ардырган. Олы яшьтә бит инде. Ә күңел аны беләмени?! Һаман яшь, һаман тынгысыз, һаман эзләнүчән ул. Кешеләргә аның тагын, тагын сүз кушасы килә. Авыр һәм катлаулы, дәһшәтле һәм истәлекле елларның әманәтен ышанычлы кулларга тапшырасы килә. «Катык ашап, ертык бишмәт киеп» йөргән егерменче, утызынчы еллар малайларының гыйбрәтле язмышлары хакында сөйлисе, бүгенге яшь буынны алар яулаган матур тормышның кадерен белергә чакырасы килә. Моның өчен форсат та чыгып тора бит — залда утырганнарның күбесе яшьләр. Һәм ул, җаен туры китереп, чамасын белеп кенә заманнар элемтәсе, буыннар эстафетасы турында чын сәнгать чаралары белән әңгәмә башлый. Репликаларын конкрет тыңлаучыларга адреслый, аның күзләренә туры карап: «Менә

шулай, энем». «Әйе бит, сеңелем», — дип куя, яки дустанә ишарә ясап, кордашларына, чордашларына мөрәҗәгать итә. Тамашачы белән артист арасында ниндидер күренмәгән җепләр сузыла. Бу бәйләнеш кай арада монологтан бигрәк диалог төсен ала. Менә ул яшәү белән үлем турында сөйләп килә да:

Үлем хәтле үлем башың белән,
Дәрәҗәсен төшереп данының,
Син башкача миңа килеп йөрмә,
Вакыт җиткәч... —

дип, бәләкәй генә пауза ясап ала. Залдан шигъри юлларны тәгәлләүче:

— Үзем барырмын! — дигән сүзләр яңгырый.

Тыңлаучының башкарылган әсәргә әнә шундый актив мөнәсәбәте, иҗади процесста битараф калмавы ике арадагы ышанычны ныгыта, сөйләшү-аңлашуда бөтенлек һәм гармония тудыра. Бу инде нәфис сүз остасы үз һөнәренең бөтен нечкәлекләрен белә, тамашачының психологиясен аңлый һәм сәхнә түрендә чын сәнгать әсәре иҗат итә дигән сүз. Ул халык авыз иҗатыннан да бик иркен һәм оста файдалана. Аның иҗатында такмак-такмаза шуклыклары, мөнәҗәт моңнары, заманча югары публицистика, драма элементлары бергә үрелеп бара.

Шулай бер арада, эстрада алымнары турында сүз чыккач, Фәйзи ага бу турыда үзе шундый бер фикер әйткән иде: «Шигырьме ул, прозамы, куплет яисә такмакмы, хәтта буффонада һәм клоунада әсәреме, әгәр алар кешене ышандырырлык итеп башкарылса, эстрада өчен берсе дә хилаф эш түгел. Бары тик чынбарлыктан читкә китмәсеннәр дә якты киләчәгебезгә хезмәт итсеннәр. Шул чагында эстрада жанрының бу төре әйбәт, тегесе начар дип әйтергә урын калмый».

Мөгаен, шулайдыр. Ләкин моңа ирешү өчен әсәренне, иҗатыңны тәкъдим итәсе халыкның рухи байлыгын, рух мирасын армый-талмый өйрәнү һәм үзләштерү, халык кайгысы белән кайгырып, шатлыгы белән шатланып яши белү дә кирәктер. Фәйзи ага моны яшьтән үк аңлаган, гомере буена шуңа омтылган. Артист ирешкән уңышларның сере бәлки нәкъ менә шундадыр да. Моңа ул газаплы эзләнүләр, абынусөртенүләр аша килде, зур тормыш тәҗрибәсе, бай биографиясе бәрабәренә иреште. Ә биографиясе аның чыннан да бик бай, күп кенә чордашларыныкы кебек гыйбрәтле, эчтәлекле. Ул ил язмышын, аның шатлыкларын да, кайгысын да уртаклашып яши. Ватаныбызга яу килгәч, кулына корал тотып, Фәйзи ага да башта ак финнарга каршы китә, ә соңрак немец фашистлары белән сугыша.

Әгәр кеше тормышта чын гражданин икән, димәк, ул, артист буларак та гражданин булып кала. Әгәр ул чын артист икән, тормышта да үзе пропагандалаган, үзе байрак итеп күтәргән идеалларга инанып яши. Фәйзи ага әнә шул ике башлангычны үзендә органик төстә берләштергән шәхес. Ул башкалар күңелендә сәхнә түреннән дә, урамда очраганда да бердәй мөлаем тәэсир калдыра. «Сөйкемле сөяге бардыр бу Фәйзи абыйның», диләр аның турында.

Бу язмабыз белән без күренекле артистның иҗатына һәр яклап бәя бирүне бурыч итеп куймадык. Анысы белгечләр эше. Безнең теләк, кешеләргә бик күп шатлыклар, бик күп дулкынландыргыч минутлар бүләк иткәне өчен, бала чагыбыздан ук яраткан, хөрмәт иткән өлкән агабызга рәхмәт сүзләре генә ирештерү иде. Безнең бу теләккә Фәйзи ага Юсуповның Галиәсгар һәм Шәриф Камаллар, Һади Такташ һәм Кәрим Тинчуриннар фатихасы белән киткән юлдан илле ел буена миллионнарча чакрым җир йөреп тапкан миллионнарча дуслары да кушылыр дип өметләнәбез.

**ӘХМӘТ РӘШИТОВ,**
**ГАБДУЛЛА ШӘРӘФЕТДИНОВ.**

Ләлә Мәхсүмова

# ТАТАР-ҮЗБӘК ӘДӘБИ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ

*СССРда яшәүче төрле халыклар әдәбиятлары арасындагы мөнәсәбәтләр тарихын төгәл һәм тирән яктырту — совет филологлары алдында торган актуаль мәсьәләләрнең берсе. Телләре, гореф-гадәтләре ягыннан бер-берсенә якын булган халыклар арасындагы әдәби багланышларны җентекләп өйрәнү исә аерата игътибарга лаек. Менә шуны искә алып, татар филологлары әледән-әле башка халыкларның әдәбиятлары тарихына мөрәҗәгать итәләр. Кардәш халыкларның галимнәре дә татар әдәбияты хәзинәләреннән үз әдәбиятларының үсү, ныгу сәбәпләрен эзлиләр. Бу юнәлештә махсус тикшеренүләр языла, диссертацион хезмәтләр башкарыла. Мондый эзләнүләрнең кайберләре хакында «Казан утлары» моңарчы да материаллар бирә килгән иде. Журналның бу санында укучылар игътибарына Ташкент университетының үзбәк әдәбияты кафедрасы аспиранты Ләлә Мәхсүмованың кайбер күзәтүләре тәкъдим ителә.*

*РЕДАКЦИЯ.*

### ЭЛЕМТӘЛӘР ТАРИХИ ЕРАКТАН БАШЛАНА

Үзбәк һәм татар халыкларының тормышында, гореф-гадәтләрендә матди һәм рухи уртаклык зур. Ике кардәш халык арасында элек-электән экономик, иҗтимагый мөнәсәбәтләр хөкем сөргән. Бу исә аларның әдәбиятлары арасындагы элемтәләрнең үсү һәм ныгуына да җирлек тудырган. Моның шулай икәнлеген бик күп дәлилләр ярдәмендә исбатларга мөмкин. Мәсәлән, төрки халыкларның күпчелеге өчен уртак дип танылган борынгы язма истәлекләр безнең халыкларыбыз өчен дә бер дәрәҗәдә кадерле. Җөмләдән Мәхмүд Кашгариның «Диваны лөгат-ит-төрек» әсәрен күрсәтергә мөмкин: үзбәкләрнең дә, татарларның да борынгы телләрен, халык авыз иҗатын, гореф-гадәтләрен өйрәнү өчен әйтеп бетергесез дәрәҗәдә мөһим бер истәлек ул. Шулай ук Йосыф Хас Хаҗибның «Котадгу билик», Әхмәт Югнәкинең «Һибәт-ел-хәкаикъ» әсәрләре дә, үзбәкләр белән бергә, мәгълүм дәрәҗәдә татар халкының да әдәби мирасыннан санала.

Әдәбиятларыбыз арасындагы мөнәсәбәтләрнең тарихын тикшергәндә бөек үзбәк шагыйре, олуг фикер иясе Галишир Нәваиның роле аерата зур булуын күрәбез. Башка төрки әдәбиятлар белән бергә, татар әдәбияты классикларыннан Мөхәммәдъяр, Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри, Дәрдмәнд, Габдулла Тукай иҗатларына да Нәваи поэзиясе, аның тирән фәлсәфәсе көчле тәэсир ясаган. Моның шулай икәнлеген әле генә телгә алынган атаклы татар галиме Ш. Мәрҗаниның үз сүзләре күрсәтә. Мәгълүм булганча, аның «Вафият-ел-әслаф вә тәхият-ел-әхлаф» исемле зур-

зур җиде томнан торган био-библиографик хезмәте бар. Анда меңнән артык төрле ил, төрле чор шәрык әдипләре, галимнәре хакында материаллар тупланган. Менә шул китапта Галишир Нәваига да киң урын бирелеп, аның шигъри маһирлыгына, гуманизмына дан җырлана. Күренекле мәгърифәтче Каюм Насыйри үзенең әдәби, гыйльми хезмәтләрендә Нәваи иҗатына мөрәҗәгать иткән, бигрәк тә аның «Мәхбүбел колуб» әсәреннән нык файдаланган. Заманында Нәваи күтәреп чыккан гомум гуманистик мотивларның соңрак Г. Тукай иҗатында тагы да үстерелә төшүен күрәбез.

Галимҗан Ибраһимов сүзләре белән әйткәндә, борынгы чыгтай (иске үзбәк) әдәбияты «Урта Азиядәге олуг бер мәдәниятнең җимеше булып, безгә дә (ягъни татарларга да — Л. М.), госманлыларга да, әзербәйҗан әдәбиятына да зур тәэсир ясады. Моның алтын дәверендә җитешкән шагыйрьләреннән Нәваи кебекләре, Төркстанда ничаклы кадерле булса», башка төрки төбәкләрдә дә шул дәрәҗәдә популяр иде[1].

Ниһаять, Нәваи әсәрләреннән «Ләйлә һәм Мәҗнүн», «Фәрһад һәм Ширин» кебек поэмаларның, тагы башка бик күп аерым шигырьләрнең татар халкы тарафыннан һаман яратылып укылуын онытмаска кирәк[2].

Шул ук вакытта, элекке чор татар әдәбиятына Нәваи һәм башка үзбәк әдипләре зур тәэсир ясаган булса, соңгы дәвер үзбәк әдәбиятына Габдулла Тукай һәм аннан гайре күп кенә татар язучыларының тәэсире көчле булган. Гомумән, XIX йөзнең ахыры һәм XX гасырның башында, мәгълүм иҗтимагый сәбәпләр аркасында, элек күрелмәгән казанышларга ирешкән татар әдәбияты төрки дөньяда иң алдынгы әдәбиятларның берсенә әверелә һәм теге яки бу күләмдә алар өчен өлге хезмәтен үти. Күптән түгел Мәскәүдә чыккан «Милли әдәбиятларның үзара мөнәсәбәтләре һәм тәэсирләре» исемле китапта бу мәсьәлә буенча төрки телле әдәбиятлар белгече М. И. Богданова түбәндәгеләрне яза: «Урта Азия һәм Казагыстан язучылары татар әдибе Галимҗан Ибраһимовның хикәя һәм романнарын, татар-башкорт классигы Мәҗит Гафури шигырьләрен, татар драматургларыннан Галиәсгар Камал, Фатих Әмирхан драмаларын сөеп укыдылар, шулар аркылы милли традицияләр нигезендә рус әдәбияты тәҗрибәсен үзләштерделәр. Бу алар өчен нәфис прозада повесть, роман кебек жанрлар һәм драматургия барлыкка килүгә мөмкинлек тудырды» (319—320 битләр).

1905 елдан соң татарлар ирешкән зур казанышларның берсе вакытлы матбугатның үсүе иде. Татарлар чыгарган «Вакыт», «Йолдыз», «Казан мөхбире», «Нур», «Тормыш», «Халык», «Әл-ислах» кебек газеталар һәм «Ак юл», «Акмулла», «Аң», «Кармак», «Шура», «Ялт-йолт», «Яшен» кебек журналлар Казагыстан, Үзбәкстан һәм Кавказ халыкларының игътибар үзәгендә була киләләр. Төркстанда исә аерата «Вакыт» газетасы һәм «Шура» журналы күп тарала. Үз нәүбәтендә, әлеге газета һәм журнал битләрендә Төркстан укымышлыларының да күп кенә әсәрләре басылып килгән. Мәсәлән, «Шура» журналының 1908—1917 елгы саннарында, казакъ авторлары белән бергә, үзбәк язучыларының, шагыйрьләренең әсәрләрен бик күп очратырга була. Мисал өчендә үзбәк әдипләреннән Мөхәммәтшәриф Суфизадәнең «Мәктәптән кайтканда», «Ханымнар исемендә», «Мөслимәләр» исемле, Чулпанның «Өмет», Габделхәбир Абдуллаевның «Бармы?», «Мин нигә елыйм?», «Үзе өчен яшәүчеләргә» исемле, Мөэминҗан Мөхәммәтҗановның «Рижа вә нияз», «Тәрҗигъ бәнд» һәм Лотфулла Галиминең «Туран кызларына» исемле шигырьләрен күрсәтергә мөмкин. Шулай ук Мирмөхсин Ширмөхәммәдовның «Егерменче гасырда Төркстан бабай», «Динчеләр вә тәрәкъкыйчеләр», «Төркстанның ысулы идарәсе хакында», «Сәяхь Нәүширван әфәнде» исемле мәкаләләре, моннан тыш, Чулпан, Фитрәт, Бәһбуди, Габделвәһап Моради, Мирзаҗан Камали һәм башка бик күпләрнең чәчмә әсәрләре «Шура»да дөнья күргәннәр. Җыеп әйткәндә, өч революция дәверендә татар һәм үзбәк әдәбиятлары арасындагы хезмәттәшлек аерата җанлы, нәтиҗәле булган. Шушы чорда Төркстанга күпләгән татар сәяхәтчеләре килә. Алар җирле халыкларның тормышы, көнкүреше,

[1] Г. Ибраһимов. Әдәбият мәсьәләләре. Казан. 1960. 137 бит.

[2] Археографик экспедицияләр вакытында татар халкы арасында Нәваи һәм башка үзбәк шагыйрьләре әсәрләренең кулъязма күчермәләре һаман табыла торуы бу фикерне тагын да куәтли төшә.— Ред.

гореф-гадәтләре, борынгы мәдәниятләре, тарихлары белән танышалар; күргән-белгәннәре хакында, «Шура» журналында, «Йолдыз», «Тормыш» газеталарында мәкаләләр бастырып, татар укучыларына хәбәр итә торалар. Шулар арасында татар сәяхәтчесе, журналист Нәүширван Яушевның эшчәнлеге аерата игътибарга лаек. Ул, мәсәлән, Төркстанның бик күп җирләрендә, төрле шәһәрләрендә була, аның тарихы, җирле халыкның бүгенгесе белән кызыксына. Узган дәверләр тарихын җентекләп өйрәнер өчен, ул өч-дүрт ел Сәмәрканд шәһәрендә яши, борынгы язма чыганакларга керер өчен фарсы телен өйрәнә. Моннан тыш, Уфадагы «Галия» мәдрәсәсендә тәрбияләнгән Н. Яушев җирле халык арасында аң-белем таратырга тырыша, күп санлы мәкаләләр белән «Сәмәрканд», «Айна», «Садаи Төркстан», «Садаи Фәрганә» газеталарында чыгыш ясап, тиз арада бөтен Төркстан җәмәгатьчелеге тарафыннан танылып өлгерә. Аның «Бохарада яңа ел», «Сәмәрканд мәдрәсәләре хакында», «Төркстан», «Төркстан голямасы», «Төркстан мәктүбләре» һәм тагы башка күп кенә әһәмиятле хезмәтләрен махсус билгеләп узарга кирәк [1].

Шушы елларда Төркстанга килеп, үзбәк халкының тормышы, мәдәнияте белән танышкан татар укымышлыларыннан һәм журналистлардан шулай ук Камил Мотыйгый, Борһан Шәрәф, Шакир Мохтари, Шакир Мөхәммәдьяров, Әхмәтҗан Биктимеров, Ф. Солтанбековларны күрсәтергә кирәк. Мөгаллим һәм мөгаллимәләрдән Зариф Мозаффаров, Шакирҗан Ибраһимов, Фатыйма, Зөһрә Сәйфуловалар һәм башкалар шушы чорда үзбәк халкының аяныч хәле хакында чын күңелдән ачынып мәкаләләр язалар, төркстанлы кардәшләрен армый-талмый мәгърифәт юлына чакыралар.

Төрле юллар белән Төркстанга килгән беренче татар драма әсәрләреннән Ф. Халидиның «Рәдде бичара кыз»ы, Ильясиның «Бичара кыз»ы, Г. Камалның «Бәхетсез егет»еннән соңрак безгә Гафур Коләхметовның «Яшь гомер» драмасы да килә. Шулай ук 1911—1912 елларда Урта Азия шәһәрләрендә, җөмләдән Ташкент, Сәмәрканд, Бохара, Кукандларда «Сәйяр», «Нур» труппалары төрле сәхнә әсәрләре күрсәтеп йөри. Боларның барысы үзбәк әдәбиятында яңа жанрлар туурга этәргеч булалар. Мәсәлән, Хәмзә Хәкимзадәнең «Яңа сәгадәт яки милли руман», «Агулы хәят», «Бидгатьме, мәҗүсиятме?», «Фәкыйрьлек нәрсәдән?» кебек әйберләрен, Абдулла Кадыйриның «Бәхетсез егет», «Уйнаш» («Жувонбоз») шикелле сәхнә әсәрләрен, һичшиксез, шушындый дәвамлы тәэсир нәтиҗәсендә туган әсәрләр дип карарга ярый.

Әмма революциягә кадәрге әдәби мөнәсәбәтләребез хакында сөйләгәндә, бу югарыда әйтелгәннәрнең барысы да гомуми фон гына булуын истән чыгармаска кирәк. Чынлыкта бу зур һәм катлаулы процессның үзәген бөек татар шагыйре Габдулла Тукай иҗаты тәшкил итә иде.

## ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ҺӘМ ҮЗБӘК ӘДӘБИЯТЫ

Г. Тукайның ялкынлы поэзиясе, бу иҗатның халык язмышыннан аерылгысыз булуы, шуңа күрә татар әдәбиятын аннан башка күз алдына китерүе мөмкин түгеллеге хакында озак сөйләп торуның хаҗәте юк, әлбәттә. Әмма Тукай поэзиясенең үзбәк әдәбиятына ни дәрәҗәдә тәэсир ясавын дөрес аңлар өчен, XX гасыр башында йөз борган кайбер мөһим үзгәрешләргә махсус тукталып узу зарури.

Иң элек XX йөз башында, капиталистик мөнәсәбәтләрнең үсү нәтиҗәсе буларак, татар һәм үзбәк дөньясындагы иҗтимагый интересларның якынаюына уңайлы җирлек тууны күрсәтергә кирәк. Аннары, 1905 елгы революция тәэсирендә революцион рухтагы рус әдәбиятының формалашуын, шул әдәбиятның илебездәге башка халыкларның да аңнары үсүгә ярдәм итүен истән чыгармаска кирәк. Ниһаять, татар әдәбиятының, югарыда әйтелгәнчә, кызу темплар белән үсеп, төрки дөньяда алдынгы әдәбият-

---

[1] 1913—1917 еллар арасында үз тырышлыгы белән хәзерге Үзбәкстан, Таҗикстан җирләренә, шулай ук Кытай Төркстанына (уйгурлар арасына) сәяхәт ясаган, сәфәрләре хакында төрле матбугат органнарында дистәләгән кызыклы очерклар бастырган сәләтле журналист Нәүширван Яушевның катлаулы эшчәнлеге әле тикшерелмәгән. Ул 1917 елда Кашгар якларыннан ерак Һиндстанга сәяхәткә әзерләнә, тик, Февраль революциясеннән соң, Россиягә кайтуны дөрес таба, сәяхәтен соңрак дәвам иттерергә җыена. Әмма бу теләгенә ирешә алмый: 1917 елның көзендә Ташкент шәһәрендә үпкә авыруыннан үлә. Аның бай һәм каршылыклы мирасы махсус өйрәнүне көтә.— Ред.

ларның берсенә әверелүен истә тотарга кирәк. Нәтиҗәдә моңарчы да өзлексез аралашып яшәгән халыкларыбыз өчен мөнәсәбәтләрне янә дә ныгытырлык мөмкинлекләр туа. Һәм менә шушы объектив сәбәпләр Тукай иҗатын теге яки бу дәрәҗәдә уртак хәзинәгә әверелдерә дә. Мәсьәләнең шулай тирән, катлаулы булуына ишарә ясап, Үзбәкстанның халык шагыйре Гафур Голәм болай язган иде: «Габдулла Тукайны искә алабыз икән, безнең күз алдыбызга татар әдәбияты белән үзбәк әдәбияты, гомумән татар халкы белән үзбәк халкы арасындагы тарихи мөнәсәбәтләр килеп баса» [1].

Бу зур мөнәсәбәтне тегәл яктырту өчен, тормышны әтрафлы анализлаган кебек, әдәбиятларны да, җөмләдән Тукай иҗатын да төрле яктан тикшерү кирәк булыр иде. Әмма без бу кечкенә күзәтүдә нибары ике мәсьәләгә — Тукай сатирасы һәм ул күтәреп чыккан хатын-кыз тематикасының үзбәк әдәбиятында яңгыраш табу фактларына гына кагылабыз.

Мәгълүм булганча, Габдулла Тукай иҗатында сатира төп урыннарның берсен биләп тора. Бу аңлашыла да, тормыштагы искелеккә каршы сугыш ачып, халыкны якты киләчәк өчен көрәшкә чакыручы шагыйрьгә чынбарлыктагы бөтен тискәре күренешләрне көлү аша фаш итү, укучыларда шуларга карата нәфрәт хисе тәрбияләү зарури иде. Ислам динен тотучы халыклардагы хатын-кызларның аерата кыерсытылуы әле әйтелгән тормыш искелекләренең бер өлеше булган. Шуңа күрә хатын-кыз азатлыгы мәсьәләсе дә әлеге әдәбиятларның үзәгендә торган. Белгәнебезчә, Тукай да бу мәсьәләгә зур игътибар биргән.

XX йөз башы үзбәк әдәбиятының алдынгы вәкилләре өчен дә нигездә шундый ук сыйфатлар хас була. Моны атаклы үзбәк шагыйре Хәмзә Хәкимзадә һәм мәшһүр үзбәк-таҗик әдибе Садретдин Айни иҗатларында ачык күрергә мөмкин. Бу планда бигрәк тә Хәмзә Хәкимзадә иҗаты игътибарга лаек. Алай гына да түгел, яңа чор татар әдәбиятын Тукайсыз күз алдына китерү мөмкин булмаган кебек, үзбәк әдәбиятын да Хәмзәсез таный алмас идек. Ике шагыйрьнең иҗатына тематик уртаклык та, халыкчан гадилек тә хас булган. Чөнки Хәмзә, нәкъ Тукай кебек, үз шигырьләрен халык телендә, фольклор әсәрләре формасында язган. Моның сәбәпләрен, шул елларда Төркстанда барган үзгәрешләр белән бергә, әлбәттә, татар мәгърифәт фикеренең, татар әдәбиятының хосусиятларыннан да эзләргә кирәк. Хәмзә үзе дә бу хакта бик ачык язып калдырган:

«1908 елны Нәмәнгән шәһәренә барып җиде-сигез ай укыган чакта хәзерге Нәмәнгән мәгариф эшләре җитәкчесе Габдулла Тукмуллин белән очрашып, аның файдалы тәэсиренә элэктем. Ул минем кулымдагы үз каләмем белән иске формада язылган йөз биттән артык шигъри язмаларымны күреп, минем тәрбиям белән шөгыльләнә башлады. 1905 елгы эшчеләр революциясе хакында да шунда мәгълүмат алдым.

Ул (Габдулла Тукмуллин — ред.) кул матбагасы белән кечкенә күләмле китаплар, игъланнар бастырып торучы бер татар егете иде; аның белән мин атна саен ике-өч мәртәбә очраша, әңгәмәләшә торган идем. Ул мине шактый дәртләндергән булса кирәк, шул вакытларда ук иске падишалар тормышыннан «Хакыйкать кемдә?» дигән бер роман язарга тотынган идем... Аннан соң шигырьләрем дә милли һәм революцион төс ала башладылар».

Бу китерелгән фактлар Хәмзәнең татар әдәбияты, татар мәдәнияте тәэсирен яшьтән үк сизә башлавын расласа кирәк. (Шагыйрьнең замандашы Хәбибинең әйтүенә караганда, ул бик яшьли Каюм Насыйриның Әбугалисина хакындагы хикәяләрен гаять яратып укыган.) Шушы чорларда ук Тукай әсәрләре белән дә таныша башлаган дип уйларга мөмкин. Аның иҗатында Тукай күтәреп чыккан тематиканың яңгыраш табуы да шуны раслый. Моңа исә татар вакытлы матбугаты, татарча китаплар белән танышып бару сәбәп булган. Хәер, бу хакта шагыйрь Сабир Абдуллинның истәлекләрендә дә беркадәре материал табарга мөмкин: «Хәмзә бик яшьли үк гыйлемгә бирелеп, укуга хирыслы кеше иде. Ул көнбатыштагы хәлләр белән аерата кызыксынды. Шушы вакытларда ук «Тәрҗеман», «Вакыт» газеталарын вә башка төрле журналларны калдырмыйча укып бара иде [2].

---

[1] «Шәрык йолдызы» журналы. 1964. 4 сан.
[2] «Үзбәкстан мәдәнияте» газетасы. 1964 ел. 4 март саны.

Г. Тукай кебек үк, Хәмзә дә үз поэзиясендә гражданлык мотивларын беренче планга куеп, хезмәт ияләренең интересларын яклап чыга, аларның киләчәге өчен кайгырып, халыкны азатлык өчен көрәшкә чакыра. Һәр ике шагыйрьгә дә халыкка хезмәт итү, халык бәхете өчен көрәшү хисе уртак.

Мәгълүм ки, татар әдәбиятында Г. Тукай беренчеләрдән булып руханиларны, ике йөзле буржуаз милләтчеләрне сатира уты астына ала, татар поэзиясендә иҗтимагый сатира жанрын үстереп җибәрә. Тукайның бу юнәлештәге осталыгы аерата реакция елларында ачыла. Шул ук вакытта Тукай өчен югары гражданлык лирикасы да хас иде. Хәмзә иҗатында да нәкъ шундый ук хәлләрне күзәтәбез. Хәтта аның әсәрләре стиль, форма ягыннан да Тукайга бик якын. Әлбәттә, бу уртаклыкларны механик күчерү нәтиҗәсе генә дип карарга һич тә ярамый. Чынлыкта мондый якынлык эчке тематик уртаклыктан, идея, максат уртаклыгыннан килә. Чөнки татарларда да, бездә дә руханилар бер дәрәҗәдә реакция таянычы булганнар, мәгърифәткә, тәрәккыяткә каршы торучы кара көчләрнең башында торганнар.

Фикеребезне дәлилләр өчен, кайбер мисаллар китерик. Мәсәлән, Хәмзәнең «Бер ишанның үпкәсе» исемле шигыре төп эчтәлеге, хәтта поэтик алымнары белән дә Тукайның мәшһүр «Мулланың зары» дигән сатирасын хәтерләтә.

Тукайда:

**И ходаем! Бәндәңә әүвәлдә хөрмәт бар иде,**
**Бер заманнар чалмалыга кадер, гыйззәт бар иде.**

**Кайда аусам мин, халык шул якны куәтләр иде,**
**Җир йөзе җәннәт иде, дәүләт вә нигъмәт бар иде.**

Хәмзәдә:

**Инде, җүләр, узган көннәр кайда ул!**
**Ханәкә [1] һәм котү-маллар кайда ул.**
**Хәлвә, зикер дигән шайтан кайда ул!..**
**Фатихама карап күпме хайваннар —**
**Малым көткән кышлакларда чабаннар —**
**Белмәс иде серемне ул наданнар,**
**Инде андый шәп дәверләр кайда ул!..**

Хәмзә шигыреннән бер өзекне укыгач, ихтимал, мондый мотивларның элгәрәк Тукайда да күп тапкырлар яңгыраган булуы искә төшәр:

**...Хәзрәт ничек, кардәшләр,**
**Күзне ачыйк, диндәшләр,**
**Гафләт белән үтмәсен**
**Инде безнең җәй-кышлар.**
**Ишаннарның хәленнән**
**Сүз ачма әхвәленнән! —**
**Һаман нәфес итмәктә**
**Башкаларның малыннан...**

Әсәрләренең сыйнфый юнәлешләре, изелгән халык мәнфәгатен яклап, изүчеләргә каршы төбәлгән булулары белән дә Тукай һәм Хәмзә иҗатларында уртаклык көчле иде. Шагыйрьләрнең һәр икесе дә үз әсәрләрендә патша колонизаторларының милли политикасына нәфрәт белдерәләр.

Г. Тукай үз иҗатында хатын-кыз мәсьәләсенә зур әһәмият биргән, гүзәл табигатьле, мәгәр авыр язмышлы татар хатыннарының кабатланмас образларын тудырган, шунысы белән татар әдәбиятына тагы бер әһәмиятле яңалык китергән шагыйрь. Хатын-кызларга багышланган шигырьләрендә Тукай иң элек мәгърифәтчелек позициясеннән чыгып фикер йөртә. Шуңа күрә демократик мәгърифәтчелек рухында иҗат иткән төрки телле шагыйрьләрнең күпчелеге бу мәсьәләдә Тукай тәэсиреннән читтә кала алмаганнар. Моның шулай икәнлеген Хәмзә мисалында бигрәк тә ачык

[1] Ханәкә — ишаннар резиденциясе.

күрәбез. Фикеребезне дәлилләр өчен Хәмзә шигырьләреннән бер генә өзек китерү дә җитәр кебек:

**Их, кызларыбыз безнең саф-саф булып,**
**Мәктәптә йөрсәләр иде урам тулып;**
**Шулай йөрүләрен бер генә күрсәм,**
**Үкенеч калмас иде көтсәм дә үлем!**

Әлбәттә, Хәмзә бары ияреп язучы гына түгел, бәлки иң элек үзбәк халык авыз иҗатына таянып, аннары Тукай кебек олы остазларыннан иҗади өйрәнеп мөстәкыйль әсәрләр тудырган оригиналь шагыйрь, чын көрәшче, талантлы художник иде.

Үзенең кыска вакыт дәвам иткән иҗат чорыннан бай сатирик мирас калдырган Мөхәммәтшәриф Суфизадә дә татар әдәбиятын, татар мәдәниятен якыннан белүчеләрдән иде. Ул Төркстан шәһәрләрендә чыккан газета-журналлардан тыш, Казан, Баку, Тифлислардан килгән вакытлы матбугат органнарын даими рәвештә күзәтеп бара. Аның берничә әсәре Оренбургта нәшер ителгән «Шура» журналында басылып чыгуын югарыда әйтеп узган идек инде. Суфизадә дә Тукай кебек, мәгърифәтчелек позициясеннән торып, беренче планга халык массалары интересын куеп иҗат иткән шагыйрь була. Аның хөкем сөргән социаль төзелештән ризасызлыгы, халык исәбенә яшәүче паразитлардан ачы көлүдә Тукай алымнарыннан файдалануы «Чуст казые Аббасхан Хаҗимөхәммәт угылына җавап», «Борчалар, хәлләрегез ничек?» исемле сатирасында бигрәк тә ачык күренә.

Бөек татар шагыйре кебек, Суфизадә дә хатын-кыз тематикасына җитди игътибар биргән. Феодаль кыргыйлык, дини фанатизм, томаналык нәтиҗәсендә социаль һәм рухи коллыкка төшерелгән үзбәк хатын-кызларын чын азатлык өчен көрәшкә чакырып, аларның хөр, мәгърифәтле булуын теләгән:

**Алып ташла пәрәнҗәңне — синең богау ул,**
**Кара пәрдә йөзеңдә — рухыңны буган ул...**

Шагыйрь шулай ук «Укыгыз, аналар», «Ханым», «Ханымнар исемендә» дип аталган шигырьләрендә дә, Тукай эзләреннән барып, хатын-кызлар дөньясында хөкем сөргән наданлыкны, чикләнгәнлекне тәнкыйтьли.

Өч революция дәверендә зур иҗади активлык күрсәткән үзбәк әдипләреннән Мирмөхсин эшчәнлегенә дә махсус тукталырга кирәк. Чөнки аның мисалында үзбәк-татар язучылары арасындагы идея-эчтәлек якынлыгының яңа мисалларын күрергә мөмкин.

Мирмөхсин 1913—1915 елларда әдәбиятка шагыйрь буларак килгән кеше. Төркстанда чыккан газеталардан тыш, ул «Шура» журналында да әсәрләрен бастырган. Аның әсәрләрендә дә Тукай иҗатының тәэсире ярылып ята: шул ук социаль-иҗтимагый тематика, шул ук гражданлык мотивлары, шул ук милли аң үсүе, милли изүгә протест. Әгәр Г. Тукай үзенең:

**Җөмлә фикерем кичә-көндез сезгә гаид [1], милләтем,**
**Сыйххәтеңдер — сыйххәтем һәм гыйлләтеңдер — гыйлләтем [2],**

— дип башлаган «Милләтә» исемле шигырендә үзенең бөтен булган барлыгын туган халкы өчен көрәшкә багышлавын әйтеп, халкына олы мәхәббәт белдерсә, Мирмөхсин дә, аның фикерләрен үстереп, үз халкына карата чын сөю, турылык, фидакарь хезмәт вәгъдә итә:

**Әгәр милләт булса бер гөл, фикеремнән булып былбыл,**
**Таң-сәхәрләр аһ орармын аның гамендә, әй, дуслар!**

Туган халкының никадәр изелгән, таланган, кыерсытылган икәнлеген күрә торса да, Тукай, мәгълүм булганча, халыкның олылыгы, көчлелеге, моңлылыгы, әдиплеге, шагыйрьлеге хакында зур трибунадан горурланып сөйләгән, димәк, аның киләчәгенә өмет баглаган булуын ачык игълан иткән иде. Моның белән Тукайның хезмәт ияләрен «кара халык» дип хурлаучы тәкәббер иске интеллигенция вәкилләренә каршы чыгуы

[1] Гаид — биредә: баглы.
[2] Сыйххәт — саулык; гыйлләт — чир, авыру.

бәхәссездер. Мирмөхсин дә нәкъ шулай үзбәк халык массаларын «надан, мокыт» дип кыерсытучы карагруһ «укымышлыларга» кискен отпор бирә:

**Кайберәүләр акыл сата, имеш, милләт гөмраһ [1] дип,**
**Бу сүзләргә ышанма, дус, милләтем дип аһ ит!**

Боларның барысы да, әлбәттә, элек иҗтимагый фикердә, аның бер формасы булган әдәбиятта хөкем сөргән тар кавым-кабиләчелек яисә үтә киң «мөселманлык» идеяләре урынына бер конкрет халык-милләт дигән төшенчә килүне, милли аң тәгәл формалашуны, аның әдәбиятта да элекке абстракт «хак мөселманлык»ның позицияләрен яулап ала баруын күрсәтә. Димәк, Габдулла Тукай милли аңның әдәбиятта гәүдәләнешендә дә үзбәк әдәбиятына теге яки бу күләмдә тәэсир ясаган булып чыга. Моның шулай икәнлеген дәлилли торган янә бер фактка мөрәҗәгать итик. Мәсәлән, шул ук дәвердә иҗат иткән шагыйрьләрдән Әүлани Г. Тукайның мәшһүр «Туган тел» шигырен үзбәкчә тәрҗемә итеп, аны үзе төзегән мәктәп дәреслекләренә кертә.

Габдулла Тукай вакытсыз вафат булгач, аның иҗаты белән кызыксыну, аны олылау Төркстанда бигрәк тә көчәеп китә. 1913—1917 еллар арасында бездә Тукай истәлегенә, аның иҗатына багышланган махсус әдәби кичәләр уздырылып тора. Мондый күп санлы кичәләрдә, шагыйрьнең иҗаты турында махсус докладлар тыңлану белән бергә, үзбәк шагыйрьләре тарафыннан аның әсәрләренә ияреп язылган төрле формадагы тәхмис, тәзмин кебек шигырьләр укылган. Шуңа күрә бу дәвердә иҗат иткән үзбәк авторларына Тукайның бәрәкәтле тәэсире аерата көчле булган.

## ТРАДИЦИЯЛӘР ДӘВАМ ИТӘ

Үзбәк-татар әдәби мөнәсәбәтләре Бөек Октябрь революциясеннән соң тагы да киң колач җәя. Шул ук вакытта бу өлкәдә принципиаль яңалыклар да пәйда була: файдалы, самими хезмәттәшлеккә социалистик идея өстәлә.

Мондый яңа рух белән баетылган иҗтимагый хезмәттәшлекнең мисалларын без гражданнар сугышы чорыннан күп табабыз. Мәсәлән, күпләгән татар егетләре басмачыларга каршы сугышалар; татар укымышлыларының зур төркеме җиң сызганып идеология фронтында көрәшәләр. Күренекле үзбәк галиме, филология фәннәре докторы Иззат Солтанов ул еллар хакында түбәндәгеләрне искә төшерә:

«1919 ел. Гражданнар сугышының иң кызган чагы; миңа нибары 9 яшь. Без яши торган Ош шәһәре халкын басмачылар эзәрлекли иде. Шәһәргә «Мөселман татар бригадасы» дип исемләнгән хәрби татар отряды килеп, басмачыларга каршы көрәш башлый. Татар кардәшләребез Халхуҗа башлык басмачылар өерен туздырып, шәһәрне юлбасарлардан азат итә. Урамнарда ярым татарча, ярым үзбәкчә «аман, аман» дип эндәшеп, шәһәрнең басмачылардан азат ителүен игълан кылып йөриләр».

Кыскасы, Үзбәкстанда совет власте ныгуга татарлар да шактый зур өлеш керттеләр.

Бөек Октябрь революциясеннән соң чыга башлаган «Иштиракиюн», «Михнәткәшләр авазы», «Инкыйлаб», «Кызыл байрак», «Җир йөзе», «Мәгариф вә укытучы» кебек газета-журналларны оештыру, ныгытуда татар укымышлыларының өлеше шактый зур. Үзбәк журналистикасы тарихында Мәхмүт Хәсән һәм Вәли Галләмовларның эшчәнлеге аерата тәкъдиргә лаек. Шулардан, мәсәлән, Мәхмүт Хәсән шактый вакыт «Кызыл Үзбәкстан» (хәзерге «Совет Үзбәкстаны») һәм «Правда Востока» газеталарының редакторы булган.

Революциядән соң татар һәм үзбәк язучылары арасындагы хезмәттәшлекнең формалары да күбәя, эчтәлеге дә баена. Күпләгән татар әдипләре Үзбәкстанда кунакта булалар. Кояшлы өлкә һәм аның кунакчыл халкының яңа тормышы, бөек төзелешләре белән танышалар; күреп-белгәннәре хакында үз әсәрләрендә тәфсилләп язып, татар укучыларына җиткерәләр. Шулай ук үзбәк әдипләре дә Татарстанга кунакка бару бәхетенә ирешәләр, гүзәл Татарстан җире, аның тырыш халкы белән

[1] Гөмраһ — юлдан язган (аңгыра, мокыт мәгънәсендә).

якыннан танышалар, алар хакында үз илләренә кайтып тулы мәгълүмат бирәләр. Оешкан рәвештә әдәбият алмашу, ягъни иң әйбәт әдәби әсәрләрне тәрҗемә итү, төрле җыентыклар оештыру эше тәртипкә салына.

Әлбәттә, яңа шартларда болай колач җәеп үскән хезмәттәшлекнең тарихи тамырлары турында да онытырга ярамый. Чөнки узганның тәҗрибәсенә таяну киләчәкнең перспективасын тагы да ачыграк күзалларга ярдәм итә. Нәкъ менә шуларны истә тоткан кебек, татар культурасына, татар әдәбиятына һәр вакыт тирән ихтирам саклаган Гафур Голәм, үзе дә яңа дәвер әдәби мөнәсәбәтләргә зур өлеш керткән хәлдә, элекке дуслык традицияләрен өзлексез пропагандалап, әзлекле рәвештә аларның тарихи әһәмиятләрен аңлатып килде. Габдулла Тукайның 80 еллыгына багышланган мәкаләсендә ул болай дип язган иде: «Тукай фәкать бер милләт даирәсенә генә чикләнмичә, бер татар шагыйре генә булып калмыйча, башка халыклар арасында, җөмләдән үзбәкләр арасында да мәгълүм вә мәшһүр иде» [1].

Муса Җәлил истәлегенә багышланган «Шагыйрьнең мәңгелеге» исемле мәкаләсендә Гафур Голәм, татар-үзбәк мөнәсәбәтләре тарихына тагы мөрәҗәгать итеп, түбәндәгеләрне исенә төшерә:

«Минем сөеп укыган китапларым Казан, Оренбург, Бакуда басылганнар иде. Казан китапларын бигрәк тә күп укыдым мин. Габдулла Тукай, Мәҗит Гафури, Фатих Әмирхан, Риза Фәхретдин, Галимҗан Ибраһимов вә башкаларны шул заманнарда да укып чыккан идем» [2].

Әдәбиятларыбыз мөнәсәбәте тарихы өчен шагыйрьнең түбәндәге истәлеге бигрәк тә мөһим: «Һади Такташ белән без 1919 елларда Ташкентта танышкан идек. Зәңгәр күзле, ак чырайлы, чандыр гына, миннән бер-ике яшькә яшьрәк бер татар малае иде ул. Икебезнең дә тиеп киткән кешеләрнең табаннарын пешерерлек дәрәҗәдә утлы күз кебек кайнар чакларыбыз иде...

...Озак еллар дәвам иткән теләгем, ниһаять, 1928 елны гына тормышка ашты: Зыя Сәеди белән икебез Татарстанга юнәлдек. Безне кадер-гыйззәт белән көтеп алдылар. Монда мин кадерданым Такташны очраттым. Ул безне Казан һәм Казан тирәләре белән таныштырып йөрде».

Остаз шагыйрьнең бу сүзләреннән без яңа дәвердә татар-үзбәк мөнәсәбәтләренең тагы да ныгый, самимиләшә төшүенә дәлилләр табабыз.

Революциядән соңгы мөнәсәбәтләрнең оешкан төс алуына түбәндәге фактларны китерергә мөмкин: татар әдәбиятының иң күренекле вәкилләреннән Габдулла Тукай, Галимҗан Ибраһимов, Фатих Әмирхан, Гадел Кутуй, Гомәр Бәширов һәм башкаларның әсәрләре сыйфатлы тәрҗемәләрдә аерым-аерым китап булып, үзбәк укучыларына җиткерелде. Ленин премиясе лауреаты герой шагыйрь Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәре» дә тулысынча үзбәкчә яңгырап, киң җәмәгатьчелекнең мәхәббәтен казанды.

Шулай ук үзбәк язучылары һәм шагыйрьләреннән Айбек, Гафур Голәм, Абдулла Кадыйри, Хәмид Алимҗан, Миртимер, Шәрәф Рәшидов, Зөлфия, Әсгат Мохтар һәм тагын бик күпләрнең әсәрләре дә татар укучыларына тәкъдим ителделәр инде.

Кыскасы, ике халык арасындагы әдәби мөнәсәбәтләр көннән-көн колач җәеп үсмәктә. Соңгы еллардагы элемтәләрнең үзенчәлекләре турында исә киләчәктә — процесс нәтиҗәләре азмы-күпме чарланып, чын мәгънәсендә тарихка әверелгәч, объективрак фикер йөртергә мөмкинлек туачак.

**Ташкент, 1973 ел.**

---

[1] «Шәрык йолдызы». 1964 ел. 4 сан.
[2] «Шәрык йолдызы». 1966. 7 сан.

◆ ◆ ◆ ◆

# ЯШЬ РӘССАМ

*(Яшь рәссамнарны тәрбияләү һәм аларның хезмәтен оештыру проблемалары)*

Профессиональ рәссамның формалашуы балалар художество мәктәбендә башлана һәм югары уку йортында тәмамлана. Талантның дөрес, закончалыклы һәм нормаль үсешен күздә тотканда мондый формалашу художество белеменең барлык баскычларын да — мәктәп — училище — институт — эзлекле рәвештә үтүне таләп итә. Хәзерге совет художество сәнгате культурасында эш нигездә менә шулайрак тора.

Ләкин элек бу мәсьәләдә хәл башкачарак иде. Әллә ни ерак китмичә, мисал өчен совет властеның беренче елларына гына күз салыйк. Октябрь революциясеннән соң безнең сынлы сәнгатькә килгән яшь рәссамнарыбыз, бигрәк тә революциягә кадәр аеруча нык изелеп яшәгән ваграк милләт вәкилләре, нигездә барысы да эшче, авыл һәм Кызыл Армия рәсем студияләрендә, төрле түгәрәкләрдә уку белән генә чикләнгән кешеләр булып, аларның төпле профессиональ белемнәре юк иде. Шуңа аларга кинәт зур сикереш ясарга — үзешчән студияләрдән туп-туры художество институтларына укырга кирәргә туры килде. Егерменче еллардагы татар совет милли рәссамнарының формалашу юлы да әнә шулай булды.

Ә бүгенге Татарстан рәссамнарының урта һәм өлкән буын вәкилләрен алып карасак монда эшләр бүтәнчәрәк тора: аларның күбесе профессиональ белем алган — Казан художество училищесын тәмамлаган кешеләр. Аларның югары белемнәре юк. Әмма алар инде халык ихтирамын казанырга өлгергән, зур тәҗрибә туплаган осталар.

Ләкин менә шушы хәлне мисал итеп алып, таланты булган яшь рәссамнар художество мәктәпләрендә, училищеларда, институтларда укып вакыт әрәм итеп тормыйча да урта һәм өлкән буын вәкилләре Х. Якупов, Л. Фәттахов, В. Кудελькин, К. Максимов, Н. Кузнецов, М. Усманов, С. Лывин, Б. Альменовлар шикелле зур осталар, атаклы рәссамнар була ала икән дип уйлау һич тә дөрес булмас. Тарихи процессның диалектикасын дөрес аңламау, тормыш шартлары, заман таләпләре үзгәрүен күрмәү булыр иде бу.

Ә заман һәм тормыш шартлары соңгы елларда танымаслык булып үзгәрде. Татарстанда хәзерге көндә җиде балалар художество мәктәбе һәм ике (Казанда һәм Лениногорскида) художество училищесы эшләп тора. Художество уку йортлары арту белән бергә, ул уку йортларына керүчеләргә таләпләр дә бик нык артты. Әйтик, яшь рәссам Бакый Урманче Казан художество мәктәбендә нибары бер ел укыганнан соң 1921 елда Мәскәүдәге ВХУТЕМАСка (Югары Художество-Техника Остаханәләренә) укырга керә. Шул ук уку йортына 1925 елда республика комсомол путевкасы белән яшь график Фаик Таһиров кабул ителә. Аның да белеме әллә ни зурдан булмый. Ләкин аларны укырга алалар. Чөнки заман шундый, таләпләр шундый — мөмкин кадәр тизрәк татар совет милли рәссамнарын үстерергә кирәк була. Ә менә хәзер, республикада байтак кына художество уку йортлары оештырылгач һәм эшли башлагач, хезмәтләре бөтен Союз күргәзмәләрендә күрсәтелеп, югары бәя алган татар совет рәссамнары үсеп җиткәч исә Мәскәүдәге В. И. Суриков исемендәге художество институтына керергә теләүчеләргә дә, Ленинградтагы И. Е. Репин исемендәге рәсем,

скульптура һәм архитектура институтында укырга омтылучыларга да таләпләр бик нык арттырылды. Ул уку йортларында уку бәхетенә ирешү өчен һәр яктан бик яхшы әзерлекле булырга кирәк. Безнең заманда башлангыч һәм урта художество белеме алмыйча торып, югары уку йортында уку бөтенләй мөмкин түгел. Ә югары художество белеме булмаган рәссамга һаман үсеп бара торган культура һәм сәнгать таләпләренә тиешенчә җавап бирерлек әсәрләр иҗат итү гел авырлаша бара.

Заман үзгәреше белән исәпләшмичә мөмкин түгел. 1946—1948 елларда бары тик Казан художество училищесында алган белем белән дә (хәтта аны тулысынча тәмамламаган килеш тә) СССР Художниклар союзы члены булырга мөмкин иде. Хәзер андый белем белән генә Союз члены булуга ирешү кыен.

Моннан егерме биш еллар элек кенә бу мәсьәләдә эшләр бөтенләй башкача тора иде әле. Беренчедән, рәссамнар, бигрәк тә милли кадрлар, бик аз иде. Чөнки күп кенә рәссамнар фашистларга каршы сугышта үлеп калды. Республика Художниклар союзы һәм Казан художество училищесы биналарына куелган мемориаль такталарга вакытсыз һәлак булган рәссамнарның исемнәре язылган. Ләкин бу урында анда исемнәре язылганнарны гына түгел, Союз члены булырга өлгермичә, талантлары ачылып җитәргә өлгермичә үк әлеге шул сугыш кырында үлеп калганнарын да искә алырга кирәк. Кем белә, әнә шулар арасында бәлки исемнәре илебездә танылып китәрдәй талантлылары да булгандыр. Ләкин алар, кызганычка каршы, кайта алмыйча калдылар. Алар башкарачак эшләр сугыш мәхшәреннән исән-имин кайткannar җилкәсенә төште. Ә алар күп түгел иде. Шуңа алар бик кадерле булдылар. Һәм алар җиң сызганып эшкә тотындылар. Аларга сугыш елларында өзелеп торган эшләрен эшләргә дә, һәлак булып калган иптәшләре өчен тырышырга да кирәк иде. Бу хәл, билгеле, эшнең сыйфат ягына, таләпчәнлекне беркадәр киметүгә дә китерде. (Бер Татарстанда гына түгел, Россия Федерациясенең барлык өлкәләрендә һәм автономияле республикаларында да бу хәл шулай булды.) Ләкин шунсыз мөмкин түгел, чөнки, инде әйткәнебезчә, рәссамнар бик аз, ә эшлисе эшләр чамасыз күп: күргәзмәләр оештырырга, декадалар үткәрергә, китапларга иллюстрацияләр ясарга, республиканың атаклы кешеләренә һәйкәлләр куярга кирәк иде.

Бүгенге белән элекке хәлнең төп аермасы менә шунда. Ләкин тагын бер нәрсәне онытмаска кирәк. Казан художество училищесын сугышка кадәр тәмамлаган рәссам белән шул училищены узган ел тәмамлаган рәссам үзләренең профессиональ әзерлекләре һәм квалификацияләре буенча бер-береннән шактый нык аерылып торалар. Бу очракта өстенлек училищены сугышка кадәр тәмамлаучылар ягында. Моннан чыгып, хәзер Казан училищесында укытуның сыйфаты кимегән икән дип уйлый күрмәгез. Киресенчә, Россия Федерациясендәге шундый ук училищелар арасында ул иң алдынгылардан санала. Хикмәт шунда, бу училищеның хәзер тоткан бурычы башка. Ул хәзер үзенең укучыларына махсус урта белем бирә: урта мәктәпләр өчен рәсем, сызым укытучылары, театр өчен декораторлар, оформительләр хәзерли. Ә югары белем бирү бурычы художество институтлары өстенә йөкләтелгән. Казан училищесын тәмамлаучыларның аеруча сәләтлеләре әнә шул институтларга укырга җибәрелә. Ә егерменче елларда Казан училищесы үзе югары уку йорты булып саналган һәм 1921—1923 елларда хәтта Казан художество институты дип аталып та йөртелгән иде. Һәм ул чакта аның исеме җисеменә тәңгәл дә килгән. Соңыннан институт үзгәртелеп, берничә мәртәбә исемен алыштыргач та (1923—1927 елларда ул Казан художество техникумы дип, 1927—1931 елларда художество-театр техникумы дип, 1931—1938 елларда татар сәнгать техникумы дип атала һәм тик 1939 елдан гына Казан художество училищесы дип атала башлый) анда югары уку йорты традицияләре сакланып кала. Уку срогы, югары уку йортларындагы кебек, биш ел дәвам итә. Укыту алымнары, бигрәк тә В. К. Тимофеев, П. Т. Сперанский кебек осталарның укытуы вузлардагы профессура укытуы формасына тартым була. Анда укып чыгучылар да хәзерге училищены тәмамлаучыларга караганда профессиональ яктан әзерлеклерәк һәм тәҗрибәлерәк булулары белән аерылып торалар.

Ә хәзерге яшь рәссамнар һәм аларның югары профессиональ белем алулары мәсьәләсе буенча республикада эшләр башкачарак тора. Иң элек статик отчетлардан алынган ике белешмәне карап үтик. Беренче белешмә: «1973 елның 1 ноябренә Татарстан АССР художниклар союзындагы (барлыгы 50 член) яшь рәссамнар (35 яшь-

кә кадәргеләр) — бер кеше». Икенче белешмә: «Казан художество училищесы ун ел эчендә (1962—1972 ел) ел саен уртача 40 лап кешене укытып чыгарган. Училищеда яңа оештырылган оформление бүлеген тәмамлаучыларның беренче чыгарылышы хисабына 1973 елда училищены тәмамлаучыларның саны 18 кешегә артыграк булды».

Беренче карашка гаҗәп булып тоелырга мөмкин. Кая китеп югала соң ул кешеләр? Ун ел эчендә республика художество училищелары (мин монда Лениногорскиныкын да күз алдында тотып әйтәм) биш йөздән артык яшь рәссамнар укытып чыгарган, ә Художниклар союзына нибары бер генә кеше кабул ителгән!

Ләкин монда бер дә алай шаккатарлык нәрсә юк. Ни өчен дигәндә, училищеларның максаты Художниклар союзы членнары әзерләү түгел. Аларның максаты республикага культура хезмәткәрләре — башлангыч мәктәпләр өчен рәсем укытучылары, театрлар өчен декораторлар әзерләү. Сүз уңаенда шунысын да искәртеп үтәргә кирәк, Казан художество училищесы театр декораторларын Татарстан һәм Идел буе республикалары өчен генә түгел, бәлки бөтен Россия Федерациясе өчен дә әзерли. 1965—1970 елларда училищеның театр-декорация бүлеген тәмамлап чыккан яшь белгечләр хәзер Владивосток, Чита, Уфа, Пермь, Мурманск, Сыктывкар шәһәрләрендә, Мари, Мордва, Дагстан АССРларда, Алтай һәм Калининград өлкәләрендә эшлиләр. Ә училищены аеруча яхшы укып тәмамлаган һәм иҗат эшенә сәләтләре булган яшь рәссамнарга илебезнең югары художество уку йортларына керү өчен рекомендацияләр бирелгән. Мәсәлән, 1966 елгы чыгарылыштан 5 кеше (Л. Якубович, Ю. Артемьев, Г. Эйдинов, Г. Ларионова, Г. Зотов), 1971 елгы чыгарылыштан 4 кеше (И. Әхмәтҗанов, Г. Немчинов, И. Ефимов, Ю. Бахрин), 1973 елгы чыгарылыштан 4 кеше — Ш. Гимаев, Ф. Габделисламов, А. Якупов һәм С. Хөснетдиноваларга югары уку йортларына керү өчен училищеның рекомендацияләре бирелде.

Рекомендация алган кешеләрнең бөтенесе дә институтка керә алмый, әлбәттә. Керә алганнарының да тәмамламыйча калганнары һәм укып бетергәннән соң Казанга әйләнеп кайтмаганнары да була. Шулай итеп, художество институтын тәмамлап Татарстанга эшкә кайтучыларның саны ел саен бер-ике кешедән артмый. Әмма кайтканнары начар эшли дип әйтеп булмый. Алар югары квалификацияле белгечләр, үзләренә тапшырылган эшләрне күбесе яратып, белеп эшли. Бу җәһәттән караганда Илдар Зарипов аеруча характерлы. 1961 елда Казан художество училищесын тәмамлагач ул Мәскәүнең В. И. Суриков исемендәге художество институтында укыды. Аны 1968 елда тәмамлап Казанга кайтты, әйбәт кенә эшләде һәм 1971 елда Татарстан художниклар союзына член итеп алынды. Ә РСФСР художниклар союзының III съездына (1972) исә РСФСР художниклар союзының идарә члены итеп сайланды.

Ленинградның И. Е. Репин исемендәге рәсем, скульптура һәм архитектура институтын тәмамлаган Тавил Хаҗиәхмәтов, Виктор Федоров, Валерий Скобеев, Варис Хәсәнов, В. И. Суриков исемендәге Мәскәү художество институтын тәмамлаган Абрек Абзгилдин, Рәшит Имашев, Ташкент театр-художество институтын тәмамлаган Азат Садыйков, Хәнәфи Нәфиков, Александр Иванцев һәм Львов полиграфия институтын тәмамлаган Эрот Зариповлар да республиканың перспективалы яшь рәссамнары булып саналалар һәм художество сәнгатенең төрле жанрларында уңышлы гына эшләп киләләр.

Татарстан художниклар коллективы акрын, әмма системалы рәвештә художество югары уку йортларын тәмамлаган яшь көчләр белән тулылана бара. Хәзерге көндә Казан һәм Лениногорск художество училищеларын тәмамлаган 17 кеше Ленинград художество институтларында (шуларның унысы И. В. Репин исемендәге рәсем, скульптура һәм архитектура институтында, җидесе — В. И. Мухина исемендәге югары художество-промышленность училищесында) укыйлар. Башка шәһәрләрдә укучылар да бар.

Димәк, Татарстанда яшь рәссамнар тәрбияләүнең хәзерге төп тенденциясе художество белеменең барлык баскычларын да эзлекле рәвештә үтүгә — башлангыч, урта һәм югары белем алуга кайтып кала икән. Безнеңчә, әйбәт һәм шулай булырга тиешле тенденция бу. Ләкин бу баскыч ныкмы соң? Йомшак, өзелеп китәрдәй буыннары юкмы аның? Шул хакта бераз уйланып карыйк әле.

Сүзне балалар художество мәктәбеннән башлыйк. Ул мәктәпләрдә укыту методологиясенә махсус тукталып тормыйбыз. Чөнки бу бик катлаулы, бер Татарстан алдын-

да гына түгел, бөтен Россия Федерациясе масштабында торган зур мәсьәлә. Моның шулай икәнлеге әле күптән түгел генә Горький өлкәсенең Дзержинск шәһәрендә үткәрелгән РСФСР художество мәктәпләре директорларының бөтен Россия киңәшмәсендә бик ачык күренде: балаларның стихияле иҗатын ничек итеп аңлы рәвештә натурадан реалистик иҗатка юнәлтү мәсьәләсе хәзергәчә ачыкланмаган килеш кала килә әле. Шуңа күрә мәсьәләнең бу ягына — укытуның сыйфатына тукталып тормастан, сан ягына гына игътибар итик. Хәзерге көндә республикада 7 художество мәктәбе бар диган идек. Бу, әлбәттә, элек бер мәктәп тә булмаган заман белән чагыштырганда шактый зур алга китеш булса да, бүгенге көн бурычларыннан чыгып караганда — бик аз. Хәзер Татарстанда 3383 гомуми белем мәктәбе бар. Әлеге 7 не 3383 белән чагыштырып карасак һәр мең баланың нибары икаве генә художество мәктәбенә йөри булып чыга. Мәсьәлә ачык: ул җиде мәктәп кенә барлык художество эшенә сәләтле балаларны һич тә җыйнап һәм сыйдырып бетерә алмый. Авыл җирендәге балалар бу яктан аеруча уңайсыз хәлдә.

Димәк, художество белеме баскычының беренче басмасы шактый йомшак: рәссам булырга теләүчеләрнең барысы да эшне балалар художество мәктәбеннән башлый алмый икән. Шуңа күрә дә училищега укырга килгән сәләтле яшүсмерләрнең күбесе, гәрчә сигез-ун класс тәмамлаган булсалар да, художество ягыннан өзерлексез килә. Андый яшьләргә художество мәктәбен тәмамлаган кешеләр белән уку кыен, чөнки алар үз белгечлекләренә өйрәнергә тиешле вакытның күп кенә өлешен художество белеменең мәктәптә үтелә торган элементар нигезләрен үзләштерүгә сарыф итәргә мәҗбүрләр. Тагын шул ягы да бар: ул элементар нәрсәләрнең кайберләрен бары тик бала чакта гына үзләштерергә мөмкин, олыгая төшкәч, аларны теләсәң дә өйрәнеп булмый.

Баскычның икенче басмасы — училище. Бу яктан Казан художество училищесында эшләр ничегрәк тора соң?

Сүз дә юк, анда укырга эләккән яшьләрнең хәле яхшы. Казан училищесының күптәннән килә торган бай традициясе бар. Ул 1895 елдан бирле эшләп килә. Россиянең иң өлкән художество уку йортларыннан санала. Совет Татарстанының сынлы сәнгать тарихы нәкъ менә шушы училище белән аерылгысыз бәйләнгән. Аңа И. Е. Репин исемендәге рәсем, скульптура һәм архитектура институты шефлык итеп килә. Ул В. И. Кудельжин, Ә. И. Тумашев, Б. И. Майоров, Л. М. Кальюранд кебек тәҗрибәле һәм талантлы укытучылары, В. К. Федоров, А. С. Иванцев, Х. А. Нәфиков, И. И. Еникеев кебек үз эшләрен яратып башкаручы яшь педагоглары булган училище. Художество-педагогик, театраль-декоратив һәм оформление бүлекләре булган киң профильле училище. Тормыш белән тыгыз бәйләнеш тота: студентларының уку һәм диплом алды практикасын яңа зур төзелешләрдә (соңгы елларда КамАЗда), нефть һәм химия районнарында, колхоз кырларында һәм үсеп килә торган яшь шәһәрләрдә үткәрә торган училище. Ниһаять, ул РСФСРдагы югары художество уку йортларына бүтән теләсә кайсы училищега караганда да студентларны күбрәк бирә торган училище.

Ләкин аның эшенә комачаулый торган җитешсезлекләр дә бар. Ул җитешсезлекләрнең берсе — училищеның материаль базасы тиешенчә тәэмин ителмәү һәм, барыннан да элек, аның бинасының кечкенәлеге. Икенче җитешсезлеге — уку срогы кыска, нибары дүрт кенә елдан гыйбарәт булу. Сәләтле яшьләргә югары художество уку йортларына кереп укый алырлык һәм училищены тәмамлаганнан соң театрларда, оформление мастерскойларында заман таләпләренә җавап бирердәй итеп эшли алырлык тәрбия бирү өчен дүрт кенә ел укыту аз. Менә шушы ике җитлеккән мәсьәләне хәл итәргә: Казан художество училищесына элек махсус шуның өчен төзелгән, хәзерге көндә Казан авиация институты биләп торган үз бинасын кире кайтарырга һәм училищеда уку срогын тагын бер елга озайтырга — биш ел итәргә кирәк.

Инде баскычның өченче басмасы — югары уку йортында уку мәсьәләсенә килеп карыйк. Татарстанга югары квалификацияле рәссамнарны хәзер Мәскәү, Ленинград, Ташкент институтлары әзерли. Моннан бернича ел элек унөч рәссам Украина, Эстония, Латвия художество институтларын тәмамлап кайтканнар иде. Кыскасы, моңа кадәр югары белемле рәссамнарга кытлык әллә ни сизелми килде. Ә менә хәзер Татарстанның үзендә югары художество уку йорты булмавы һәм аның кирәк икәнлеге

көннән-көн ачыграк күренә башлады. Һич югында, югары квалификацияле педагоглар әзерли торган художество-графика факультеты гына булса да оештырасы иде. Әгәр шушы нәрсә уңай хәл ителсә, Татарстан мәктәпләрендә рәсем дәресләрен югары белемле белгечләр укыта башлар иде һәм бу хәл яшь буынны эстетик тәрбияләүнең сыйфатын күтәрүгә китерер иде.

Чувашиядә һәм Удмуртиядә моннан берничә ел элек җирле педагогия институтлары каршында художество-графика факультетлары ачылган иде. «Зур Идел» дип аталган зональ күргәзмә нәтиҗәләренә караганда бу тәҗрибә әлеге республикаларга шактый зур нәрсә биргән: аларда яшь көчләрнең сәнгатькә актив килүе, яшь рәссамнарның профессиональ квалификациясе үсүе сизелеп тора. Әлеге факультетларда тәҗрибәле педагоглар коллективы туплану, үз чиратында, шулай ук уңай нәтиҗә бирәчәк. Дөресен әйткәндә, ул нәтиҗәләр күренә дә башлады инде. Моңарчы Идел буе автономияле республикаларына һәм өлкәләренә рәссамнарны Казан бирел торган булса, хәзер, киресенчә, ул республикалар үзләре Татарстанга рәссамнар җибәрә башладылар. Чабаксар педагогия институты каршындагы художество-графика факультетын тәмамлап кайтып, Зеленодольск шәһәрендә эшли башлаган Әмир Заһиров, Ижевск педагогия институты каршындагы художество-графика факультетын тәмамлап кайтып, көнкүреш сәнгате рәссамы булып эшләүче Татьяна Федоровалар мисалыннан күренгәнчә, ул факультетлар әйбәт кенә кадрлар әзерләп чыгаралар икән.

Әнә шундый художество-графика факультетын Казанда да оештыру өчен бөтен мөмкинлекләр бар. Мәсәлән, республика культура институты каршында художество-графика факультеты ачып, шунда мәктәпләр өчен югары белемле рәсем укытучылары, художество студияләре, клублар, пионерлар йортларындагы һәм культура сарайларындагы түгәрәкләргә җитәкчеләр һәм иҗат кадрлары тәрбияли башлаганда бик әйбәт булыр иде. Хәл итүне көтә торган мөһим мәсьәләләрнең берсе әнә шул.

Тагын бер нәрсәне онытмаска кирәк: Казан училищесын тәмамлаган сәләтле яшьләрнең барысы да Мәскәү, Ленинград, Ташкент югары уку йортларында укый алмыйлар. Кайсылары тормыш шартлары аркасында, ә кайберләре исә — монысын да исәптән чыгарып ташларга ярамый — институтка керү кыенлыклары һәм укытуларның туган телдә алып барылмавы нәтиҗәсендә югары белем алмыйча калалар. Шулай итеп, булачак югары белемле рәссамнарның, бигрәк тә булачак милли кадрларның, күпмедер проценты янә бер мәртәбә кимеп бара.

Алда әйтеп үтелгән тенденция (мәктәп — училище — институт) көчендә булуга да карамастан, әле хәзергәчә Татарстанның күп кенә яшь рәссамнары училищены тәмамлауга иҗат эшенә керешеп китәләр дә югары белем алмыйча калалар. Ә бу хәл аларның эш сыйфатына кире йогынты ясый. Чөнки алар югары мәктәп бирә торган осталыкка ия булмау нәтиҗәсендә шактый гомерләрен үзлекләреннән укып үткәрергә мәҗбүр булалар. Ә укымыйча заман куйган югары таләпләргә җавап бирерлек дәрәҗәдә иҗат итү һич мөмкин түгел. Никадәр генә талантлы булса да, югары белемгә ия булмаган рәссамның хәзерге заман күргәзмәләрендә уңыш казанырлык әсәрләр тудыра алуы бик чикле.

Бу яктан караганда, графикларның һәм бигрәк тә карикатурачыларның хәле яхшырак. Аларга заман таләпләре югарылыгында тору ансатрак. Бу хәл сатирик рәсемнең үзенчәлегенә бәйле. Сатирик рәсем ясау өчен рәссамның хыялга, экспромтка ия булуы, сатирик фикер йөртә белүе кирәк. Ә моңа күп укып кына ирешеп булмый. Моңа, барыннан да бигрәк, табигать тарафыннан бирелгән сәләт кирәк. Сәләте булган рәссам училище белеме белән дә бу өлкәдә уңышлы гына эшли алырга мөмкин. Совет сатира графикасының атаклы осталары Борис Ефимов, Дементий Шмариновларның эш практикасы әнә шул хакта сөйли. Алар икесе дә махсус мәктәптә укымыйча, практика нәтиҗәсендә генә сәнгатькә килгән кешеләр.

Шушы ук хәлне «Чаян» журналында эшләүче сәләтле яшь рәссамнар мисалында да күреп була. И. Әхмәдиев, Л. Насыйров, Ю. Денисов, С. Насырова, Э. Дышаевлар махсус югары белемнәре булмаса да, сатирик рәсем өлкәсендә әйбәт кенә эшләп киләләр.

Ләкин, кабатлап әйтәм, бу хәл художество сәнгатенең бары тик сатирик рәсем жанрында эшләүчеләргә генә хас. Ә ул сәнгатьнең бүтән төрләре, бигрәк тә тематик картина һәм скульптура, бүгенге рәссамнардан бик зур һәм җитди профессиональ

әзерлекле булуны таләп итә. Талантлы булуларына да карамастан, махсус югары белемгә ия булмаган рәссамнарга бу өлкәләрдә эшләү шактый читен. Мәсәлән, скульптор Альфред Әбдрәшитов хәзер менә шундыйрак хәлдә. Сүз дә юк, ул табигать тарафыннан бирелгән пластик сәләткә, материалның декоратив мөмкинлекләрен тиз сизенеп алу һәвәслегенә ия кеше. Бар нәрсәгә аның кулы ябышып тора. Хыялга бай, эзләнүчән иҗади фикерле һәм тормыш белән бик нык кызыксынучан скульптор ул. Ләкин кайчак ул әнә шул хыялы тудырган нәрсәләрне тиешенчә художестволы итеп тормышка ашырып җиткерә алмый, композицияләрендә ялгышлар һәм төгәлсезлекләр җибәрә. Кыскасы — скульптор профессиональ нечкәлекләрне тиешенчә белеп бетерми. Әгәр дә ул табигать тарафыннан бирелгән шушы таланты өстенә югары профессиональ белем дә алган булса, композицияләрендә күзгә күренеп торган төгәлсезлекләрне җибәрмәс һәм зуррак уңышка ирешер иде. Югары белемнең булмавы яшь рәссамнарның да иҗат диапазонын чикләүгә китерә. Илдар Әхмәдиев, мәсәлән, 1955 елда Казан художество училищесын тәмамлаганнан соң күп еллар буена бары тик сатирик рәсем өлкәсендә генә диярлек эшләп килде. Бик сирәк очракларда гына бүтән өлкәләргә (акварель, китапларга иллюстрация, декоратив афиша һәм плакат жанрларына) мөрәҗәгать итеп, иҗат мөмкинлеге күп кырлы икәнлеген сиздергәләп ала иде. Зуррак күләмле әсәрләр язу белән ул тик соңгы елларда, КамАЗда башланган зур төзелешләр белән рухлану нәтиҗәсендә генә шөгыльләнә башлады. «Скреперчылар», «Эштән соң», «Апрель» исемле әйбәт кенә картиналар да тудырды. Аның ул хезмәтләре күргәзмәләргә куелып, җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп итте. Ләкин ул бу өлкәгә соңгарак калып килде. Художниклар союзында яшь булып саналып йөри торган чикне — утыз биш яшен тутырганнан соң, яшьлек ялкыны инде сүрелә башлагач килде. Шунысын да искә алып китмичә булмый: И. Әхмәдиевнең уңышлы эшләнгән һәм күргәзмәләргә куелып йөри торган әлеге картиналарында да профессиональ күзлектән караганда байтак кына кимчелекләр булуы, димәк, монда да рәссамның югары махсус мәктәптә укымаганлыгы бик ачык сизелә. Татарстанның үзендә югары белемле рәссамнар әзерләү мөмкин булса, яшь рәссамнарның иҗади сәләтләре тизрәк ачылыр һәм алар күп мәртәбә нәтиҗәлерәк эшли алырлар иде, дигән фикернең дөреслеген менә бу мисал тагын бер тапкыр раслап тора.

Ләкин, ничек кенә булмасын, бүгенге көндә Татарстан рәссамнары арасында югары белемнәре булмаган яшь рәссамнарның саны шактый зур әле. 1969 елда Татарстан художниклар союзы каршында яшьләр белән эшләү өчен махсус комиссия төзелгән иде. Ул комиссия шактый зур оештыру эше башкарды. Казанда һәм Татарстан районнарында иҗади эшләрдә актив катнашып килә торган җитмеш яшь рәссамны исәпкә алып, аларга һәртөрле ярдәм күрсәтә башлады. Ләкин шул җитмешләп яшь рәссамның тик унбише генә махсус югары белемгә ия. Узган елның көзендә яшь рәссамнар иҗатының VI республика күргәзмәсендә катнашкан алтмыш кешенең дә тик унысы гына югары белемле иде. (Җәяләр эчендә шунысын да әйтеп үтик, күргәзмәгә куелган әсәрләр арасында нәкъ әнә шул югары белемле иптәшләрнең — И. Зарипов, В. Скобеев, В. Федоров, Р. Имашев, Ю. Вургафт, Э. Зариповларның картиналары тамашачыларның игътибарына лаек булды, чөнки алар художество сәнгате кануннарын белеп эшләнгәннәр иде.) Татарстан художество фондының районнардагы бүлекләрендә хәл аеруча борчу тудыра. Мәсәлән, Бөгелмә бүлегендәге егерме худфонд членының нибары берсе (1973 елның 1 ноябрендагы мәгълүмат), Түбән Камада ундүрт кешенең икесе, Чаллыда егерме биш кешенең өчесе, Лениногорскида егерме җиде кешенең тик дүртәве генә югары белемлеләр. Алары да, кызганычка каршы, яшьләр түгел, күбесе өлкән буын вәкилләре. Районнардагы яшь рәссамнар нигездә Казан һәм Лениногорск училищеларын тәмамлау белән генә чикләнгән иптәшләр.

Республика профессиональ сынлы сәнгатенең төп резервын әнә шул яшьләр тәшкил итеп тора. Шуңа күрә аларны исәптән чыгарып ташлау һәм алар иҗатына ниндидер икенче дәрәҗәдәге иҗат итеп кенә карау һич тә дөрес булмас иде. Республиканың бүгенге художество тормышында бу яшьләр зур урын билэп тора: шәһәрләрне, җәмәгать интерьерларын формалаштыруда, нәшрият практикасында һәм яшьләр күргәзмәләрендә алар актив катнашып килә.

Ләкин училище тәмамлаган яшь рәссамнар белән системалы эш алып барырга кирәк. Монда художниклар союзының яшьләр комиссиясе башкара торган эшләр белән генә канәгатьләнергә ярамый. Яшьләр белән эшләүне художниклар союзының иҗат секцияләрендә (рәсем, графика, скульптура) дә дәвам итәргә кирәк. Ул секцияләр белән җитәкчелек итүче тәҗрибәле өлкән рәссамнар яшьләрнең эшләрен тикшереп, аларга консультацияләр биреп барсалар — моның файдасы зур булыр иде. Өлкәннәр ярдәме белән осталыкларын арттыра барып, яшь рәссамнар Художниклар союзының рекомендациясе белән югары художество уку йортларына укырга да керә алырлар иде.

Республикада югары типтагы рәсем студиясе оештыру мәсьәләсе дә бик актуаль мәсьәләләрнең берсе булып тора. Әгәр андый студия оештырылса, ул да яшьләрне осталыкка өйрәтү мәктәбе булыр иде. Монда сүз яшь рәссамнарны училище тәмамлаганнан соң иҗат процессында өйрәтү-укыту турында бара. Ә Казанда аларны укытырлык зур тәҗрибәле һәм талантлы педагоглар бар.

Бу мөһим мәсьәләне үз агымына куюу белән генә чикләнмәскә, бәлки сынлы сәнгать осталарының квалификациясен күтәрү буенча республика студиясе оештырырга кирәк. Ул студиянең үз бинасы, график, скульптура һәм декоратив эшләрне башкару өчен материаллары һәм станоклары, шуларны урнаштырырлык бүлмәләре булырга тиеш. Менә шул чакта ул студия иҗади көчләрне үстерү һәм иҗади тәҗрибә уртаклашуның җитди базасына әверелер иде.

Яшь иҗат көчләрен туплау һәм үстерү өчен яшьләрнең республика күргәзмәсен оештыру бик зур әһәмияткә ия. РСФСРның автономияле республикалары һәм өлкәләре арасында беренче булып, Татарстан художниклар союзы 1967 елда яшь рәссамнарның республика күргәзмәсен оештырган иде. Шуннан бирле бу эш традициягә әйләнеп китте һәм соңгы алты ел эчендә алты күргәзмә оештырылды инде. Тәҗрибә шуны күрсәтә: күргәзмәдә катнашучы яшьләрнең саны елдан-ел арта, күргәзмәгә куелган әсәрләрнең сыйфаты һаман яхшыра килә. Ләкин яшьләр күргәзмәсен оештыру мәсьәләсендә эшне тагын да яхшыртасы бар әле. Мәсәлән, күргәзмәләрне оештыру моңа кадәр стихияле төстәрәк үткәрелә: күргәзмәгә яшьләр үзләре тәкъдим иткән материаллар гына куела килде.

Киләчәктә бу эшне алдан уйлап, планлы рәвештә алып бара башларга: яшьләргә алдан ук конкрет бурычлар куярга, темалар бирергә, аларны яңа төзелешләргә иҗат командировкаларына җибәрергә, кыскасы, күргәзмәләрнең характерын алдан ук билгеләп куярга кирәк. Аннары яшьләр, өлкәннәр һәм үзешчәннәр хезмәтләрен янәшә куеп күрсәтү очраклары да булгалый. Болай эшләүне уңышлы дип әйтеп булмый. Киләчәктә күргәзмәгә материаллар сайлап алу принцибын да камилләштерергә, үзешчәннәр һәм халык иҗаты әсәрләрен үзенә аерым, курс һәм диплом эшләрен үзенә аерым күрсәтергә кирәктер. Болай эшләү яшьләрнең җаваплылыгын арттырыр, үз иҗатларына җитдирәк карарга мәҗбүр итәр иде.

Эшлисе эшләр күп. Уңышлар арткан саен, алда яңа бурычлар да килеп чыга тора. Ул бурычлар нигездә бер нәрсәгә — яшь рәссамнарны тәрбияләү һәм аларның хезмәтен оештыру чараларын камилләштерүгә кайтып кала. Ә моңа республиканың дәүләт, партия һәм комсомол оешмалары, культура учреждениеләре һәм Татарстан художниклар союзы бергәләп ныклы эш алып барганда гына ирешергә мөмкин. Шул ук вакытта бу мәсьәләнең уңышлы хәл ителүе яшь рәссамнарның үзләренә — аларның осталыкларына, иҗади ачышларга омтылышларына, белемнәренә, идея ныклыгына, гражданлык сыйфатларына һәм үз иҗатларына ни дәрәҗәдә җаваплы карауларына да бик нык бәйле.

**Светлана ЧЕРВОННАЯ,**
**сәнгать белеме фәннәре кандидаты.**

## Луиза Шәйдуллина

# ИСЛАМ ДИНЕНДӘ ИЗГЕ ХАТЫННАР КУЛЬТЫ

Болгар хәрабәләре арасында изгеләр кабере дип йөртелгән урыннар бар. Алар бик борынгыдан калган легендалар белән бәйле. Мәсәлән, шундый урыннарның берсенә христиан динен кабул итәргә теләмичә үз-үзләрен үтергән җиде изге кыз күмелгән дип сөйлиләр.

Икенче бер легенда ул изге кызларның башта җылы яклардан очып килгән гүзәл аккошлар булуы, үлемнәре алдыннан, әфсен өреп сихерләрен бетергәннән соң, җиде бертуган кызларга әверелүләре турында әйтә.

Андый хикәятләрне мин шактый җыйдым, язып бардым. Аннары төрле китаплардан шуңа охшашлы легендалар белән кызыксынырга керештем. Билгеле булганча, коръәндә мөселман хатын-кызларының тормыштагы роле аермачык әйтелгән.

Ислам динендә күчмә халык — гарәпләрнең варварлыктан югарырак культурага үсеш чорындагы сыйнфый мөнәсәбәтләре чагыла. Бик табигый: коръәндә мөселман хатын-кызларының үз-үзләрен тотышлары өчен кануннар да билгеләнгән. Колбиләүчелек, аннан феодаль җәмгыять шартларында кулланылган хатын-кызларның хокук нормалары күп кенә көнчыгыш илләрендә бүгенге көнгә тикле хакимлек итә. Корьәндә ислам диненең патриархатны ныгытуга юнәлтелгән булуы турыдан-туры әйтелә. Ир кеше башка кабиләләрдән хатын сатып ала. Үз кабиләсеннән хатын алу ярамый, чөнки балалары сәламәт тумаска мөмкин. Хатын кеше сатып алынган икән, димәк, ул хуҗасына турылыклы хезмәт итәргә тиеш. Хатын-кыз үзе ир сайларга, аның өчен мәһәр яки калым түләп сатып алырга хокуклы түгел.

Никахны бозу, аерылышу кануннары да корьәндә бик катгый куелган. Монда да инициатива ир кулында, ә хатын-кыз ирен яратса-яратмаса да, хәтта аңа нәфрәт белән караса да, үз язмышына риза булырга, буйсынырга тиеш. Әгәр ире өч мәртәбә «талак» әйтсә, ул ире өендә өч ай гына яшәргә хаклы. Бу шуны белү өчен: хатын балага узмаганмы?.. Әгәр йөкле булса, ире талак кылган очракта да хатыны белән килешә ала. Ә инде йөкле түгел икән, ул балаларын иренә калдырып китәргә тиеш. Дөрес, ике яшькә кадәр аңа баласын тәрбияләргә рөхсәт ителә. Әмма ике яшь тулу белән баласын иренә кайтарырга тиеш.

Әгәр ир кеше ачудан гына, алдын-артын уйламыйча гына хатынын талак кыла һәм ахырдан, ачуы бетеп, хатыны белән килешергә уйлый икән,— моның да үз кагыйдәсе бар: хатын мөхәллилә вазифасын үтәргә, икенче иргә чыгып кайтырга мәҗбүр.

Кырым алпавыты Исмәгыйль Гаспринский чыгарган «Тәрҗемән» газетасында шундый бер вакыйга турында хәбәр басылып чыккан.

Казан шәһәренең бер бай мөселманы, мәҗлестән кәефе китеп кайткач, вак-төяк гаеп табып, хатынына бәйләнә һәм аны талак кыла. Иртәгесен бик үкенә, хатыны белән килешергә дә тели — әмма соң инде, мөхәллилә вазифасын үтәргә кирәк. Моңа

да барып идең — бөтен шәһәргә фаш буласың. Һәм бай муллага киңәшкә китә.

Мулла бик игътибар белән тыңлый да, мөхәллилгә үзен тәкъдим итә. Килешәләр, өйдәге хезмәтчеләрне шаһит итеп чакыралар да никах укыйлар. Хатын мулла өендә кала.

Икенче көнне бай хатынын алырга дип килә. Ә мулланың хатынны иренә кире кайтару уенда да юк: үз хатыны карт, күптән биздереп бетергән, ә бай хатыны яшь, чибәр. Хәзрәткә бик озак ялына бай, илле сум акча бәрабәренә генә, ниһаять, үз хатынын өенә алып кайта.

Ислам диненең берничә хатын алуга рөхсәт итүе һәркемгә билгеле. Бу нәрсә хатын-кызларның мораль һәм экономик яктан барлык хокуклардан мәхрүм булуларын ачык чагылдыра. Мөселман легендалары бу гадәтне уңай күренеш итеп күрсәтәләр. Мәсәлән, Мөхәммәт пәйгамбәр, янәсе, алла-тәгалә юлында корбан булган мөселман ирләрнең балалары ятим калмасын өчен, ирсез калган хатыннарны кызганып, аларны үз хатыннары иткән. Шунысын да әйтергә кирәк: берничә хатын һәм җәһирәләр белән байлар һәм түрәләр генә тора алган. Ә ярлыларга өйләнеп тормыш корырга мөмкинлек бөтенләй булмаган. Мондый хәл көнчыгыштагы мөселман илләрендә хәзер дә еш очрый.

Дөрес, коръән буенча, туган белән туганга, бер-берсенә чит булып та, бер ана сөтен имеп үскәннәргә өйләнешү, яңа туган баланы үтерү, дүрттән артык хатын алу рөхсәт ителми. Хәзерге заманда дингә аңлатма бирүчеләр боларны уңай, прогрессив күренеш итеп бәялиләр. Чыннан да, алар гарәпләрнең варварлыктан югарырак культура мөнәсәбәтләренә чыкканда туган яңа сыйнфый күренешләр.

Нәкъ менә хатын-кызның барлык кешелек сыйфатлары, аның теләкләре һәм хисләре аяк астына салып тапталганга, ислам динендә аерым бер юнәлештә изге хатын-кызлар культын алга сөрү тенденциясе барлыкка килә. Бу юнәлешне, тенденцияне калку итеп тасвирлаган күп кенә легендалар тарала, алар турында китаплар басылып чыга. Ул легендалар хатын-кызларның күңелен тынычландырырга, аларда өмет тудырырга юнәлдерелгән булалар.

Шунысы кызыклы: ислам дине башта изге хатын-кызлар культына каршы чыга. Ирләр дә, хатын-кызлар да теге дөньяда, җәннәттә рәхәт күрү өмете белән генә яшәргә, дөнья рәхәтеннән ваз кичәргә тиеш булалар: бу дөньяда алар бернәрсәне дә үзбаш хәл итмәсен (бар нәрсә алла-тәгалә иркендә), рәхәт тормыш, ярдәм көтмәсен, хакимлеккә, хәрәкәткә омтылмасын.

Ислам дине киң таралгач, мөселманнарда изгеләргә табыну, аларга ярдәм сорап мөрәҗәгать итү башлана. Моның нигезендә, мөгаен, гарәпләр яулап алган җирләрдәге халыкларда яшәгән, электән калган мәҗүсилекнең тәэсире ятадыр. Нәкъ менә шуңа күрә дә ислам диненә кергән изгеләр культына охшашлы чыганакларны һинд һәм фарсы әдәбиятларында күп очратырга мөмкин.

Чыннан да: хатын-кызның кешелек дәрәҗәсе, барлык хокуклары аяк астына салып тапталган коръән кануннарыннан аларны изге итеп күтәрүне көтү һич мөмкин түгел. Көнбатыш Европада ислам дине белгечләренең берсе Перрон болай яза: «Ислам динендә хатын-кызлардан изгеләр бик аз. Алар өчен изгеләр юлы бик кыен... Иң башта ирләр. Мактау да, хөрмәт тә бары тик алар өчен. Алар хәтта изгелекне дә, җәннәтне дә үзләренә үзләштергән».

Рәсми исламда хатын-кызларның күбесе «тәмуг кешеләре» дип күрсәтелә, чөнки алар, янәсе, сафлыклары белән дә, аң үсешләре белән дә камил түгелләр.

Әмма, икенче яктан, классик гарәп әдәбиятында яу вакытында ирләр белән бер дәрәҗәдә сугышучы каһарман хатын-кыз, политик тормышка актив катнашучы хатын-кыз образлары да бар. Мәсәлән, Мөхәммәт хатыннарының берсе — Гайшә шундый булган. Ул кабиләләр арасындагы төрле талашлар вакытында актив роль уйнаган.

Хатын-кызларның ирләр белән бергә намаз укулары да билгеле.

Безгә кадәр килеп җиткән легендаларның берсендә шиитлар белән сөннитлар арасында Гарәп хәлифәтендә Гали властен урнаштыру өчен көрәштә хатын-кызларның актив катнашуы турында әйтелә. Гали яраннарыннан берсенең хатыны тирмә казыгын суырып ала да, ире янына килеп, мөрәҗәгать итә. «Атам һәм анам исеме белән ялварам: пәйгамбәремез Мөхәммәт вә Гали варислары хакына сугышка чык»,— ди. Ирләр эшенә тыгылмаска, хатын-кызлар ягына барырга кушылгач, ул иренең күлмәк итәгенә ябыша. «Мин синнән калмыйм»,— ди. Ире сугышта һәлак була. «Урының җәннәттә булсын!» — ди аның мәете өстендә хатыны.

Әсма исемле икенче бер хатын — Мөхәммәтнең абыйсы, Мөхәммәт үлгәннән соң беренче хәлиф Әбу-Бәкер кызы — улының сугышка керер алдыннан көбә киюен ошатмый. Янәсе, хак эш өчен сугышканда саклану чаралары куру ирлек түгел.

Әслам кабиләсеннән Куләйбә Бәнат Сәет дигән бер хатын Хәйбәрә янындагы сугыш вакытында мәчеттә иң беренче шифаханә оештыра, шунда авыруларны һәм яраланучыларны дәвалый.

Ислам диненең башлангыч чорында да булачак сугышчылар анасы — хатын-кызга ихтирам бөтенләй юк түгел. 33 нче сүрәнең 35 шигырендә аллага инанучы һәм намуслы кешеләргә — җәннәткә карамастан — теге дөньяда җәннәт вәгъдә ителә. Шулай ук Гайсә пәйгамбәрнең анасын — Мәрьям ананы, Мөхәммәт пәйгамбәрнең анасын — Әминәне, кызын Фатыйманы изгеләр итеп күрсәтү изге хатыннар культын җәелдерүгә нигез булып тора.

Изге кеше — дингә ышанучылар өчен алла-тәгалә илчесе. Исламда хатын-кызларның изгелеге изге ир кешеләр күрсәткән могҗизалардан бер дә ким түгел.

Урта гасырларда кайбер мөселман илләрендә хатын-кызлар өчен рабәтләр (монастырьлар) ачыла. Ә бит мондый монастырьлар ислам өчен бөтенләй чит нәрсә. Гарәп тарихчылары корьән уку, дин кануннарын өйрәнү, гыйбадәт кылу белән бергә, хатын-кызларның фән өйрәнүләре турында да язып калдырганнар. Күп кенә хатын-кызлар язучы һәм галим булып киң танылa.

Рабәтләргә ирләре куган хатыннар да урнаша алган. Алар бүтән иргә чыкканчы, намусларын саклап, шунда яшәгәннәр.

Мөгаен, изге хатыннар культының үсешенә һәм рабәтләр барлыкка килүгә суфизм йогынты ясагандыр. Җирдәге бар нәрсәдән ваз кичүгә, аскетизмга корылган бу агым ислам динендә IX—X гасырларда барлыкка килә. Аның барлыкка килүе көнчыгышка тәре йөртүчеләрнең тәэсире белән бәйле. Алар мөселманнарны үзләрендәге монахлар, төрле орден оешмалары белән таныштыралар.

Көнчыгыш илләрендә феодализмның ныгуы һәм үсеше белән бәйле рәвештә изге хатыннар турындагы карашлар, легендалар билгеле бер тәртипкә салына, алар югары катлау сыйныфы өчен түбән катлауларны эксплуатацияләүдә аерым бер иҗтимагый роль уйный башлыйлар.

Изгеләргә галим булу, динне, аның кануннарын, нечкәлекләрен тирәнтен белү хас. Мөхәммәт әйткән, янәсе, һәр мөселман һәм һәр мөселман хатын-кыз гыйлемгә омтылырга тиеш, дигән. Пәйгамбәрнең шул әйткәнен үтәгән кеше могҗиза тудырырга сәләтле изге кеше булып әверелә икән.

Каһирәдә Ситта-Нәфисә дигән хатынның кабере бар икән. Мөселман руханилары аны чын изге хатын булган диләр. Ул Хәсән хәлиф оныгының кызы һәм Имам Җафар ас-Садикъның килене икән. Нәфисә саф намуслы, дини йолаларны җиренә җиткереп үтәве белән данлыклы булган; утыз мәртәбә Мәккәгә хаҗ кылырга барган. Ул бик күп ураза тоткан, өч көнгә бер ашаган, төннәр буе гыйбадәт кылган. Корьәнне, аның аңлатмаларын күңелдән белгән, хәтта имам Әш-Шәфи (Шәфи мәзһәбенә нигез салучы) аның гыйлемлеге алдында баш игән. Үләр алдыннан үзенә үзе кабер казыган һәм, кабер эченә утырып, йөз дә туксан тапкыр корьән чыккан.

Ул тудырган могҗизалар исәпсез. Шуларның берсе. Гарәбстаннан Мисырга күчеп килгәч, ул күршесендә яшәүче башка диндәге кол белән таныша. Колның кызы кулаягын хәрәкәтләндерә алмый икән. Атасы белән анасы, Нәфисәне авыру кызны карап торырга күндереп, базарга китә. Ә Нәфисә тәһарәт ала да гыйбадәт кылырга керешә, алла-тәгаләдән кызны терелтүен сорый. Бер заман кем күрсен: кыз аягүрә баса һәм әти-әнисен каршыларга йөгерә. Ә әтисе белән әнисе шуннан соң ислам динен кабул итәләр.

Икенче бер могҗиза. Бер елны корылык була. Нил елгасы ул елны бөтенләй ярларыннан чыкмый. Җирләр эсседән ярганып бетә. Корылык белән бергә ачлык башлана. Кешеләр өметсезлеккә бирелә. Гыйбадәт тә, йолалар да ярдәм итми. Шул вакыт изге Нәфисә кешеләргә үзенең чадрасын салып бирә. Чадраны Нил елгасына корбан итәләр. Син күр дә мин күр: елга ярларыннан чыга, барлык басуларны сугара. Ул елны уңышның иге-чиге булмый...

Мәккә шәһәрендә изгеләр каберләре аеруча күп. Кәгъбәдәге кара таш белән Зәмзәм чишмәсе арасында гына да туксан тугыз изге кеше кабере бар, диләр. Мөхәммәт утырып ял иткән таш, Әбу-Бәкер өендә пәйгамбәр галәйссәламне сәламләп каршы алган таш — барысы да изгеләрдән санала. Ә Мәдинә шәһәрендә Мөхәммәт атланган дөянең чүмәкләгән

урынны, шулай ук пәйгамбәр үзенең беренче рикәгать намазын башкарган мигъраәбне мөселманнар бик изге итеп исәпләгәннәр. Пәйгамбәр өшкерүе нәтиҗәсендә саф сулы булып әверелгән күлвек тә зур хөрмәт казана.

Кешеләр изгеләр каберенә барып хаҗ кылуны, анда бүләкләр калдыруны бәла-казадан, авырулардан саклый дип уйлаганнар. Табигать көчләреннән курку, үлгән кеше рухына табыну кебек мәҗүсилек калдыклары изгеләр культы турындагы дини тәгълиматка яңа көч өсти. Җирле мөселман руханилары өчен изге урыннар, бер яктан, матди файдалы булса, икенче яктан, динне тагы да киңрәк җәелдерү, хаким сыйныф властен көчәйтү, халыкны бөлгенлектә тоту өчен хезмәт иткән. Әлбәттә, изге дип исемләнгән каберлекләр, чынлыкта, күбесенчә, мәҗүсилек заманыннан калган зиратлар булган.

Изгеләр каберенә һәркем — гадел кешеме ул, җинаятьчеме — зират кылырга хокуклы булган. Соңрак хәтта изгеләр каберенә килеп дога кылу хаҗга бару белән бер саналган. Хәзер дә әле изге дип исәпләнгән каберләр тирәсе төрле тукыма кисәкләре белән чуарланган була: диндар кешеләр аларны теләкләренең үтәлүен өмет итеп кабер тирәсенә бәйлиләр.

Төньяк Африка халыклары арасында Тәүҗә дигән бер ярлы хатын турында легенда таралган. Имеш, аның иң зур теләге — үләр алдыннан Мәккәгә хаҗга бару булган. Әмма ярлылыгы аркасында бу теләген ул берничек тә тормышка ашыра алмаган. Аның хәтта дисбе алырга да акчасы булмаган. Шуннан ул хөрмә төшләрен җепкә тезеп дисбе ясаган, ди. Шул дисбе белән ул гыйбадәт кылган, аллатәгаләдән ярлылыгын гөнаһ санамауны, изге Габдел Кадыйр каберенә зират кылуын хаҗга бару дип исәпләүне сораган. Бу хатын вафат булганнан соң, бердәнбер байлыгы — дисбе генә калган. Дисбене кабере өстенә салганнар. Пәйгамбәр бу хәерче хатынның гаҗәеп гадел, диндар булуын ишеткәч, аның кабере янына килә, кабер өстенә яшьләре тама һәм шуннан дисбедәге хөрмә төшләре шытып бирә. Хөрмәнең иң баллы сорты шуннан башланган, ди.

Бу легенда борынгы Грециядә һәм христиан динендә изгеләрнең, мифик шәхесләрнең күз яшеннән яки каныннан җимешләр үсеп чыгу турындагы әкиятләрне хәтерләтә.

Шунысы кызыклы: мөселманнар өчен генә түгел, христиан, яһүд динендәге кешеләр өчен дә уртак изге саналган урыннар шактый еш очрый. Андый урыннар каберлекләр генә түгел, ә кизләү чыганагы яки үсеп утырган агач булырга да мөмкин.

Ислам дине үзенең башлангыч чорында мәҗүсилек йолаларын, потка табынуларны бетерергә тырышса да, тулысынча максатына ирешә алмаган, алар халык күңелендә калган. Алай гына да түгел, ислам үзе бу йолаларга яраклашкан һәм аларны үз максатлары өчен файдаланган.

Изгеләр турындагы хикәятләрдә еш кына изгеләрнең түземлелеге, хөкемдарлар, түрәләр алдында баш июләре гади халыкка гыйбрәт итеп китерелә. Мәсәлән, үзенең китабында Л. И. Климович китергән изге Разия турындагы хикәятне алып карыйк [1].

Бик гадел, намуслы Разия исемле бер тол карчык булган, ди. Бер заман бу карчык ай яктысында җеп эрләп утыра һәм айны болыт каплаганчы күбрәк эрләп калыйм дип ашыга икән. Менә айны болыт каплаган. Шул вакыт кулына фонарь тоткан хәлиф узып бара, ди. Карчык, шул фонарь яктысында бер генә саплам булса да җеп эрләп калыйм, дип, тагын эшкә тотынган. Хәлиф күздән югалганчы ике саплам эрләп ташлаган бу. Әмма эченә пошаман кергән: чит кеше фонаре яктысында эрләде бит әле ул бу ике саплам җепне. Димәк, бу җепләр аныкы түгел! Киңәшкә имам Әхмәт ибне Хәнбәлгә китә бу. Имам Разия карчыкның гаделлегенә зур бәя бирә, әмма ике саплам җеп аның өчен хәрәм дип хөкем чыгара. Чөнки карчык законсыз рәвештә чит кеше милкеннән — хәлиф фонаре яктысыннан файдаланган.

Әлбәттә, урта гасырлар чорында мондый хикәятләрнең сыйнфый максаты бер булган: феодаллар, түрәләр каршында ярлы халык калтырап торсын! — югары сыйныфларның төп идеологиясе булган дин менә шуңа хезмәт иткән.

Димәк, бу хикәятләрдә күбесенчә ярлы хатын-кызларның сурәтләнүе тикмәгә генә түгел. Ә бай хатын-кызларына түземле булу, язмышка буйсыну кирәкми, алар тамак өчен тир түкмиләр бит.

Ә халык авыз иҗатында барлык мөселман халыкларында хатын-кызлар ана булу-

---

[1] Л. И. Климович. Ислам. Рус телендә. 2 басма, 1965. 308—309 битләр.

лары, якты акыллы, сәләтле, хезмәтчән булулары өчен зур ихтирам белән телгә алына. Алар еш кына, алдынгы замандашлары белән бергәләп, хокуксызлыкка, мыскыллауга каршы чыгалар.

Хәзерге заманда мөселман хатын-кызлары, ирләр белән бергә, милли-азатлык хәрәкәтенә катнашалар. Россиядә Бөек Октябрь революциясенең җиңеп чыгуы, элек артта калган өлкәләрдә социализм төзү тәҗрибәсе, күп милләтле дәүләт төзү үрнәге, мәгариф һәм культура үсеше, хезмәткә, ял итүгә, белем алуга хатын-кызларның ирләр белән бер дәрәҗәдә хокук алуы, аларның политик һәм иҗтимагый тормышка актив катнашулары — болар барысы да капитал илләрендә хатын-кыз проблемасын хәл итү өчен маяк булып тора.

Хатын-кызларның яшь буынны тәрбияләүдәге иҗтимагый әһәмиятен яхшы белгән мөселман руханилары аларны дини мораль рамкаларыннан чыгармау өчен зур көч куя. Шуңа күрә хатын-кызларның аңына һәм хисләренә реакцион традицияләр белән, ата-бабалар йолаларын илаһи итеп күрсәтү, изге хатын-кыз культын пропагандалау юлы белән йогынты ясарга тырыша. Урта гасырларда барлыкка килгән, югары сыйныфларга хезмәт иткән изге хатыннар турындагы хикәятләр, әлбәттә, хәзерге заман өчен кулай түгел. Шуңа күрә хәзерге мөселман руханилары, электәге йолаларны идеаллаштыру белән бергә, ислам диненә хас булмаганча, хатын-кызга ихтирам турында вәгазь укыйлар. Янәсе, ирләр, сез хатыннарыгызны ихтирам итегез, алар сезнең балаларыгызның анасы, балаларыгызның кем булуы аналарына бәйле.

Әмма бездә хатын-кыз икейөзле дини йолалардан азат. Бары тик иҗтимагый тормышта да, семьяда да тигез хокуклы, үзендә кешелек дәрәҗәсен горур йөрткән, һәм дини гореф-гадәтләрдән азат хатын-кыз гына коммунизм төзүче кешене тәрбияли ала.

# ОНЫТЫЛГАН БЕР ӘСӘР ТУРЫНДА

Унтугызынчы йөзнең икенче яртысы һәм егерменче йөз башы әдәбиятын өйрәнү өлкәсендә әдәбият фәнебезнең зур гына уңышлары бар. Әмма шулай да әдәбият фәнебез бу чор әдәби процессын тулы, тәфсилле аңлатудан шактый ерак әле. Унтугызынчы йөзнең икенче яртысына һәм егерменче йөз башына караган күп кенә әдәби чыганаклар әле һаман игътибардан читтә калып килә. Бу еллар татар әдәбиятында, мәсәлән, «Идел буе», «Нуретдин хикәясе», «Ялтыравыклы күз», «Хатыннар», «Кылаф белән Диләрә» кебек билгеле бер әдәби-эстетик кыйммәткә ия булган әсәрләр бар. Киләчәктә аларны өйрәнү һәм фәнни әйләнешкә кертү, һичшиксез, тарихи-әдәби процессны тулырак аңлауга мөмкинлек тудырачак.

Ленинградтагы Салтыков-Щедрин исемендәге китапханәдә саклана торган «Бичара Галия яки михнәттән соң рәхәт» китабы да — шундый әсәрләрнең берсе. Хәлбуки, әдәбият тарихы буенча язылган хезмәтләрдә бу әсәр турында бер сүз дә әйтелми.

«Бичара Галия» әсәре Әхмәтҗан Биктимеров дигән кеше тарафыннан язылган һәм 1906 елда Оренбургта, Кәримовлар типографиясендә басылып чыккан. Язучы әсәрен роман дип билгеләгән, һәм ул күләме белән дә, эчтәлеге белән дә М. Акъегет, З. Бигиев тарафыннан язылган беренче татар романнарыннан әллә ни калышмый.

«Бичара Галия»дә сурәтләнгән вакыйгалар егерменче йөз башы татар тормышын чагылдыра. Романның үзәгенә бу чор әдәбияты өчен традицион булган мәхәббәт, гаилә бәхете, хатын-кыз азатлыгы кебек мәсьәләләр куела. Бу мәсьәләләр әсәрнең төп образларында, аеруча Галия образында калку булып гәүдәләнә.

Галия — шәһәр бае, зур сәүдәгәр кызы. Аның әтисе Насыйр әсәрдә байлык яратучы, гаять комсыз кеше итеп тасвирлана. Ул мөмкин булган һәр урында алдарга, табыш алырга омтыла. Гаять надан, иске фикерле булса да, бу чор татар әдәбиятында сурәтләнгән бик күп татар байлары кебек, Насыйр яңалыктан, модадан артта калмаска тырыша. Өен җиһазлау, кием сайлау мәсьәләләрендә, язучы әйткәнчә, ул «бөтенләй дәртсез кеше түгел». Шулай ук кызы Галияне гимназиягә укырга бирүе дә аның бүтәннәрдән калмаска тырышуын күрсәтә. Әмма шул ук вакытта Насыйр үз өендә элек-электән килгән кырыс гадәтләрне, иске йолаларны да нык саклый.

Галия әнә шундый семьяда үсә. Ләкин шуңа да карамастан, ул — нечкә хисле, акыллы һәм зиһенле кыз. Галия әлегә гимназиядә укып йөри һәм еш кына эчке, яшертен борчылу белән алдагы тормышы турында уйлана. Ул үз киләчәгенең ата-анасы теләкләренә, яшәп килгән гореф-гадәтләргә бәйле икәнен яхшы аңлый һәм шулардан җиңел генә котыла алмаячагын да сизенә. «Мин үземезне, кызларны, әсирләр дип беләмен,— ди ул ачынып дус кызы Ләтифәгә.— Бәхет вә сәгадәтемезне ата-анамыздан көтеп, күп вакытта ата-аналарымызның корбаны уламыз. Алар безне хаксыз, ихтыярсыз йорт хайваннары диеп йөриләр... бәхет сәгадәтемезне тикшермиләр» (21 бит).

Ләтифә исә Галияне борчылмаска, ата-ана сүзен тыңларга һәм язмышы белән килешергә үгетли.

«Галия җаным, мин бу сүзеңә разыймын. Безнең иргә бару... турысында һич ихтыярымыз юк. Әмма, минемчә, синең иргә бару хосусында хәсрәтең бер дә булмаска кирәк иде. Әлхәмде лилля, дәүләтеңез бар. Сине бер картка яки хатын өстендән бирү ихтималлары юк. Дәүләт үз кулыңда булачак. Дәүләт берлән гомер итү дәүләтсез гомер итүдән артыграк булса кирәк. Бар сөештерә, юк орыштыра диләр».

Аңа каршы төшеп, Галия болай ди: «Ләтифә туганым... син эшне малга китереп терәдең. Әмма мәхәббәт, ихтыяр... инсаният, тәүфыйк, әдәп, инсаф, мәгърифәт кайда калды? Синеңчә булганда, бу күркәм сыйфатлар бәхет, сәгадәт өчен бер дә хаҗәт түгел, мал гына кирәк... Юк, Ләтифә җаным. Болай булса, фикереңхата... мал, дәүләт, алтын, көмеш һәм зиннәткә кызыккан кешене мин ахмаклар җөмләсендән саныймын».

Яшь кыз хатын-кыз бәхетен чикли торган иске кануннары җимереп ташларга тели. Ул үз бәхетен мәхәббәттә, хезмәттә табарга омтыла. Галиянең әнә шул идеалы әсәрдә җанлы итеп, романтик буяулар белән сурәтләнә.

Менә Галия этисе белән авылга бара. Төш вакыты җиткәч, әтисе кырда атын туктатып, намаз укырга керешә. Галия исә, сусавына түзә алмыйча, эчәргә су эзләп китә һәм уракчылар янына килеп чыга. Яшь ир белән яшь хатын төшке ялга туктаганнар, табын көйләп гөрләшә-гөрләшә чәй эчәләр. Яннарында яшь балалары да бар. Ир белән хатын алмаштилмәш тупырдатып шуны сөяләр, берберсенә карап, бәхетле елмаеп шатлыкларын уртаклашалар. Крестьяннарның табигать кочагындагы эшләре, яллары, берберсенә карата җылы мөнәсәбәтләре Галиянең күңеленә чиксез якын, кадерле булып тоела. Аңарда көнләшү хисләре уяна. Ул үз тормышын да әнә шундый тигез, нык мәхәббәткә, хезмәткә нигезләп төзергә хыяллана.

Әмма бөтен бәхетне акчада, байлыкта күргән буржуаз семья Галиянең омтылышларын исәпкә алмый. Насыйрның үз исәбе бар. Ул «Мәскәүне ике-өч мәртәбә алдаган» дәрәҗәле бай Гыйззәт семьясы белән туганлашырга омтыла. Шул максатына ирешү өчен ул Галияне Гыйззәт байның эчкече һәм фахиш малае Баһауга кияүгә бирмәкче була.

Ләкин, күргәнебезчә, Галия дә канунйолаларга, байлык-дәрәҗәгә сукыр рәвештә баш ия торган кыз түгел. Ул көрәшергә карар бирә һәм сөйгән егете Габдрахманнан үзенә ярдәм итүен сорый. Ләкин Габдрахман аңа ярдәм итү түгел, бөтенләй Галиянең уйларына каршы төшә. Чөнки әти-әнисенең сүзеннән чыкса, Галия мал-мөлкәтсез калачак. Ә Габдрахманның һич тә андый кызга өйләнәсе килми. Шуңа күрә ул Галиягә язмышы белән килешергә, ата-анасының сүзеннән чыкмаска куша.

«Галия җаным! Мин сезне... җаным-тәнем белән яратам. Әмма ярату белән генә эш бетми, җаным. Бу сүз генә дөнья өчен җитми. Көн уткәрер өчен сәрмая да кирәк. Мәхәббәт дәрте белән генә бәхтияр була алмыйбыз... Авырлык булса да аталарыңның сүзенә итагать тиеш»,— ди Габдрахман кыз белән саубуллашканда.

Габдрахманда да яклау таба алмагач, Галия тәмам төшенкелеккә бирелә. Ул юлын дәвам итәр өчен үзендә көч тә, мөмкинлек тә күрми һәм, ахыр чиктә, Баһауның хатыны булырга ризалаша.

Ә Габдрахман исә университетны тәмамлап доктор була һәм көньяктагы шәһәрләрнең берсенә китеп, шунда эшли башлый. Ләкин ул Галияне оныта алмый, аның турында еш уйлана. Галиягә карата мәрхәмәтсезлек күрсәтүе өчен торган саен көчлерәк газаплана. Һәм, ниһаять, анда Галияне эзләп табарга, тормышы, яшәве белән кызыксынырга, үткәннәр өчен гафу үтенергә дигән теләк туа. Ул Галияне эзләп юлга чыга.

Бер шәһәргә килеп төшкәч, Габдрахман көтмәгәндә җәнҗаллы вакыйгага юлыга: исерек ир револьвер белән баласын атып үтергән, хатынын авыр яралаган һәм соңыннан үзенә дә аткан. Врач икәнен белгәч, Габдрахманны фаҗигагә юлыгучыларга ярдәм күрсәтергә чакыралар. Шул вакытта исерек ирнең Баһау булуы ачыклана. Ул өйдәге бөтен нәрсәләрне сатып эчкән, шуннан соң тагын хатынынннан акча даулаган, ә тегесе бирмәгәч, котырынып китеп, револьверга ябышкан икән. Очраклы төстә Галия исән кала. Ул әле һаман Габдрахманны сөя икән. Габдрахман да хәзер инде Галияне ташламый. Әсәр алар-

ның бергә тормыш коруларын сурәтләү белән тәмамлана.

«Бичара Галия» әсәренең сәнгатьчә эшләнеше дә шактый югары. Ул нәфис, аңлаешлы тел белән язылган. Анда уңышлы, оста тасвирланган образ-сурәтләр, лирик төстә хикәяләнгән эпизодлар күп.

Инде әсәрнең авторы хакында да берничә сүз.

Әхмәтҗан Биктимеров — әдәбиятка Беренче рус революциясе чорында килгән язучы. 1905—1907 елларда ул, әлеге әсәрдән тыш, «Закирә илә Фатыйма» (1905), «Үткән мәхәббәтем» (1905) һәм «Ятим Сабир яхуд бай кызы» исемле хикәяләр язган. Ләкин «Бичара Галия» идеясе һәм сәнгатьтә эшләнеше белән ул әсәрләрдән нык аерылып тора. Моның сәбәбе — «Бичара Галия»нең немец әдәбияты йогынтысында язылган булуында. Романга чит әсәр тәэсире барлыгын бер урында безгә язучы үзе дә күрсәтә. Галия Габдрахман янына килгәч, егет аңа болай ди: «Әйе, Галия, хәзер безнең хәлемез «Графиня Нищая» дигән романның вакыйгаларына охшыйдыр». Без «Бичара Галия»нең немец әдәбиятының русчага тәрҗемә ителгән әсәре «Графиня Нищая»дан (авторы күрсәтелмәгән) иҗади төстә файдаланып язылган булуын ачыкладык. Ул әсәрнең романга тәэсире Баһау образында аеруча ачык күренә.

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә кирәк, Ә. Биктимеровның «Бичара Галия» егерменче йөз башы татар әдәбиятының гаять характерлы һәм шактый гына уңышлы эшләнгән әсәре. Фикеребезчә, ул тарихи әдәби процессны өйрәнүдә билгеле бер әһәмияткә ия булыр.

**С. ХАФИЗОВ.**

Мансур Вәлиев

# БЕЗГӘ АК БОЛЫТ БУЛЫРГА ЯЗМАГАН ШУЛ...

*(Равил Фәйзуллинның яңа китабы чыгу уңае белән)*

Михаил Юрьевич Лермонтов турында язылган истәлекләрдән бер эпизод хәтергә нык сеңеп калган. Патша хөкүмәте ерак Кавказга сөрергә булгач, китәр алдыннан саубуллашып чыгу өчен, шагыйрь иптәшләре янына керә. Тиздән, бик тиздән авыр аерылышу минутлары җитәчәк. Таныш җирдән, җан дуслардан аерылу. Тиздән шагыйрь үзе теләмәгән күңелсез сәфәргә кузгалырга тиеш. Ямансу һәм авыр. Бу тойгыны дусларның эчкерсез теләктәшлеге дә, танышларның гадәттән тыш ягымлылыгы да баса алмый. Беркайчан булмаганча җан әрни, йөрәк сыза. Шагыйрь, эчендәге ялкынга түзә алмыйча, тәрәзә янына килә. Ә тышта салкын болытлар агыла. Болытлар... Аларны да каядыр куалармы соң әллә? Югыйсә, ник болай ашыгалар икән? Чит җирләрдә нәрсә бар дип уйлыйлар икән? Әгәр ихтыярында булса, ул менә шуннан беркая да китмәс, үз иленнән беркайчан да аерылмас иде... Ләкин, юк шул, аны бу җирдән куучылар бар. Чөнки аның талантыннан куркучылар бар. Шагыйрь җанын шул тираннар куа туган илдән... Лермонтов иптәшләренә таба борыла. Аның күзләрендә яшь, ә йөзендә — иксез-чиксез сагыш. Күпмедер шул хәлдә басып торгач, ул, ашыгып, бер почмакка китә һәм туктаусыз яза башлый. Бераздан иптәшләре шагыйрьнең атаклы «Болытлар» шигырен ишетәләр:

Вечно холодные, вечно свободные,
Нет у вас родины, нет вам изгнания...

Әйе, туган ил — һәр чын шагыйрьнең иң зур байлыгы. Ил — шагыйрь җанының тормыштагы иң ныклы таянычы. Илдән аерылу, ил һавасыннан ераклашу — шагыйрь өчен иң каты җәза. Шуңа күрә патша хөкүмәте шагыйрьләрне илдән куган, аларны изге нигездән — үскән туфрактан аерган, шул юл белән корытырга, сүндерергә уйлаган.

Совет әдәбиятының нигезендә туган илне ярату хисе ята. Безнең шагыйрьләр иҗатының матур ягы шунда: поэзиянең көче — шагыйрь йөрәгенең ил, халык тормышына береккән булуында. Моны без Сибгат Хәким шигырьләрендә аеруча ачык күрәбез. Аның иҗаты белән туып-үскән җирләрдән еракка киткәч кенә ныклап танышырга туры килде. Шагыйрь язган әсәрләрнең көченә шунда гына төшендем. Чит җирләрдә яшәгәндә туып-үскән җирең, андагы тормыш синең күз алдыңа яңа бер халәттә — һәр күренеше гаҗәеп матур картина булып, аермачык булып, бик нык тирәнәеп һәм олаеп килеп баса икән.

Ул хатирә-күренешләргә карап туеп булмый икән. Хисләр ташый, ургыла икән аларга карагач! Һәм әнә шунда укылган Сибгат Хәким шигырьләрен мин әлеге хисләрнең иң нык сөелгәне, иң куе һәм иң кайнар ялкын катламы булып йөрәккә утырып калганы итеп тойдым. Аларда — безнең өчен кадерле ядкарь булган туган авылыбыз һавасы, әниләребезнең йомшак күңеле һәм әтиләребезнең акылы. Шагыйрь үз буыны кешеләренең тормыштан алган иң зур сабакларын салган икән ул җырларына. Шуңа күрә ул җырлар көчле һәм нык икән. Шуңа күрә шагыйрь җыры ил җаны турында шул кадәр хисне, шул кадәр моңны әйтеп бирә ала икән!

Р. Фәйзуллин шигырьләре дә, беренче чиратта, мине әнә шул сыйфатлары белән үзенә тартты.

Бала чактан туры
без көрәшкә кердек...

Равил Фәйзуллинның иҗат юлы әнә шулай башланып киткән иде. Күптән түгел «Наз» исеме белән чыккан шигырьләр җыентыгы[1] аның шул идеалларга турылыклы булып калуы хакында сөйли. Менә шуннан бер шигырь — «Мич тулып шигырьләр яна...» Анда шагыйрь тормышының бер күренеше — аның үз шигырьләрен утка ягуы:

Дәрт — ялкын-тел!
Хис — үкерә, үкси!
Фикер — чарт-чорт!
. . . . . . . . . . . .
Мич тулып шигырьләр яна.
Күгем яна,
йолдызларым,
аем яна...
. . . . . . . . . . . .
...Колларым яна,
иреннәрем,
бәбәкләрем...
Карындагы бала кебек
бөкрәеп, мин янам...

Моңарчы үзем укыган әсәрләр арасында шагыйрь күңелен бу кадәр көч белән сурәтләгән шигырь очратканым булмады шикелле. Поэзияне көрәш мәйданы, шигырьне дөнья матурлыгы, җан пакьлеге, кеше күңеленең бөеклеге өчен көрәш коралы дип ышанып яшәүче шагыйрь генә шигырьләрнең шундый көчен аңлый һәм алар белән бергә утта да яна ала.

Равил Фәйзуллинның бөтен поэзиясенә әнә шундый ялкын, тормыштагы иң кайнар хисләрне үзенә җыеп яну хас. Шагыйрь өчен андый хисләр чыганагы — беренче чиратта, аның үз буыны язмышы. Шагыйрь йөрәге буын язмышындагы һәр тибрәнешкә, аның яшәвендәге һәрбер үзгәрешкә искиткеч сизгер.

Равил Фәйзуллин шигырьләрен күбрәк укыган саен, без бүгенге яшьлекнең рухын, аның идеалларын, борчылулы уй-хисләрен тулырак күз алдына китерә барабыз. Һәр шигырь «яшьлек» дигән мозаик панораманың матур бер кисәге кебек. Күләме ягыннан бик кечкенә булган әнә шул кисәкләрдә тормышның, дөньяның бик күп хикмәтләре тупланып, көчәеп күренә. Менә «Бер дуска» дигән шигырьдән берничә строфа:

. . . . . . . . . . . .
Бездә әзрәк дуамаллык,
бераз баламишкинлык.
Аңа да риза. Алмасын тик
мушкасына — мескенлек.

---

[1] Р. Фәйзуллин. Наз. Лирик шигырьләр. Татарстан китап нәшрияты. 1973 ел. Редакторы Ф. Гайнанова.

. . . . . . . . . . . .

Һаман төшенеп җитеп булмый
яшәү хәйләләренә.
Куллардан бигрәк, җан белән
нык бәйләнгән бала чакның
әйлән-бәйләннәренә!
Син, әлбәттә, бездән акыллырак,
Миеңдә бар хөкемчең.
Безнең исә — шашкынлы хис
генеральный йөртүче...

Мөгаен, хис белән акылның беркайчан да безнең замандагы кебек шулай нык «дошманлашканы» булмагандыр. Ни өчен шулай? Моның сәбәпләрен тормышның үзеннән эзләргә кирәктер. Бүгенге тормыш агымы бер яктан, саф акылны, бар нәрсәдән элек исәп-хисапны, практицизмны нык көчәйтсә, икенче яктан, шул ук тормыш саф акылның һәм исәп-хисапның гына Кеше өчен никадәр мескенлек һәм бәла дә була алганын күрсәтә. Бу мисалларның икесе дә бүгенге тормышта шактый еш һәм типик күренешләрдә очрый. Югарыдагы шигырьдә дә шагыйрьнең йөрәге дустының, кешелек гүзәллеген, намус һәм эчкерсезлеген югалту бәрабәренә, дан һәм югары дәрәҗә яуларга маташуына карап әрни. Шул ук вакытта шагыйрь мәсьәләнең башка ягын да күрә, бу күренешне дә бик реаль аңлый. Шигырьдәге «Син, әлбәттә, бездән акыллырак. Бәлки үзең дә беләсеңдер», дигән юллар шуңа ишарәли. Ләкин шагыйрь мондый дәрәҗәгә кызыкмый, аның идеалы башка. Шагыйрьнең идеалы — намус белән, эчкерсез күңел белән яшәү. Кеше бәхете, намуслы тормыш, яшәү сөенече турында уйлану «Бер мәҗлестә» дигән шигырьдә тагын да көчәя, тирәнәя. Конкретрак әйткәндә, тормышта ике төрле яшәү үрнәгенең бер күңелле мәҗлестә күзгә-күз очрашуын күрәбез без ул шигырьдә.

Шагыйрь фикере шулай шигырьдән шигырьгә үсеп, көчәеп укучыны җитди, зур нәтиҗәләргә алып килә: тормыш һәм кеше турында, кешенең тормышта никадәр батыр яки никадәр мескен була алуы турында уйландыра.

Яшьтәшләренең язмышы турында кайгырту, табигый рәвештә, шагыйрьне, гомумән, буын турында уйлануларга алып килә:

Чабылгач та, таң атканда
чыклар белән кем көлә?

...Хәер, без үлән генә,
җирдә бер келәм генә...

Кояшка дип, күккә багып
үскән идек гел үргә.
Яшәргәнне күрсәләр дә,
корган чакта кем күрә?

Хәер, без үлән генә,
җирдә бер келәм генә!..

(*«Чабылгач та, таң атканда...»*)

Әйе, буыннар да, җир келәме — үләннәр кебек, яшьлек тә алышына. Ләкин аның матурлыгы дөньяның күзен ача, аңа үз-үзенең кем икәнен күрсәтә. Әйе, безнең дә яшьлек чоры үтәр, ләкин үзебезне, үз сүзебезне, үз эшебезне раслап, тормышның алга барганлыгын раслап үтәр! Һәм, намуслы яшьлек булып, җирдә мәңге яшел төс калыр! «Җирдә бер келәм генә...» дип, бер карауга гомернең кыскалыгына гына ишарә кебек тоелган шигырь яшьлекнең нәнә шул асыл хасиятен, аның фәлсәфи асылын ачып сала — җиргә, тормышка яңалык килү күренешен сурәтләп бирә. Әйе, нурлар чәчеп, ярсып, көрәшеп, рухланып тормышка яшьлек килә. Анда дөнья үзенең яңа матурлыгын, башламаган гомерен, чигенмәс намусын, саф йөрәген күрә. Дөнья яшьлекне олы

өметләр белән көтә. Һәм менә шушы килү һәм көтү рухын биргән картинаның үзәгендә, шушы зур иҗтимагый күренеш яктылыгында без яңадан шагыйрь шәхесен, аның уйга чумган йөзен күрәбез.

Бүген фейерверк чәеп,
фанфаралар уйнап та,
киләчәгең турында син
карамасаң уйлап та, —

ни мәгънә буш иҗаттан,
бүгенге рәсми синнән, —
әгәр киләсе буыннар
баш тартса исемеңнән.

Әкияттәге кебек, тормышта да төрле юллар бар: бусыннан китсәң — дан-дәрәҗә аласың; бусыннан китсәң — мал-мөлкәт табасың, ә бусыннан китсәң — «бары» кеше булып каласың. Хәзер безнең өчен ачык: шагыйрь соңгысын, ахыр чиккәчә кеше булып калуны яклый. Аның юлы шуннан бара. Ләкин бу юл — авыр юл. Ул шагыйрьне көрәшкә тартып кертә һәм шуның белән аны ныгыта, олыгайта. Ә кайвакытларда шагыйрь нәрсәнедер югалтканлыгын сизеп ала һәм борчыла, эзләнә башлый.

Әллә кайсы гына үр менгәндә
күз нурымның угын җил алды,
аяз көндә чыккан яшен кебек
мәхәббәтем ничә югалды...
Ә кешеләр — мин югалткан саен,
«Табасың!» дип гел мактадылар.
Чагыштырып карап, күзләремә,
күңелемә бер бакмадылар...

*(«Әй, кайтасы килә кайчакта...»)*

Әйе, шагыйрь күңелендә кемнәргәдер үпкә дә бар. Үпкә — тәбәнәк каланчадан карап, зур сүзләр сөйләүчеләргә. Кайчандыр аларның сүзен тыңлап торган шагыйрь бүген мәсьәләне бөтен җитдилегендә һәм тирәнлегендә күтәрә: безнең һаман-һаман яраклашуыбыз гел яхшыга китерә микән? Шул вакытта югалткан нәрсәләр ни өчен соң соңыннан искә төшеп үзәкне өзә икән?!

Әнә шул сорауларга җавап эзли-эзли шагыйрь ике зур көчнең — Яшьлек белән Чынбарлыкның тартышу кырына, көрәш мәйданына килеп чыга, һәм аның җаны инде шул ике көч арасында талпына башлый. Яшьлек хыялы — матур, саф һәм дәртле, ә Чынбарлык исә — кырыс, усал һәм нык. Китаптагы кайбер шигырьләрдә шагыйрьнең бу ике көчнең уртак ноктасын, чын матурлыкны табып җиткерә алмавы күренә. Менә шундый шигырьләрнең берсе. Ул:

Әйтәсең: «Минем йөрәк, — дип, —
кайгылар каберлеге...»
Санамыйм андый йөрәкне
дөньяга кадерлегә, —

дип башланып китә һәм:

Яшеңне йот! Елмай! Хәтта
Эчтән бетсәң дә көеп.
Әйтсен кеше: «Йөрәге аның —
Чәчәк бәйләме! — » диеп, —

диган юллар белән тәмамлана. Сүз дә юк, чәчәк бәйләме — матур, сокландыргыч нәрсә инде ул. Ләкин тормыш бит әле йөрәкнең тагын нык, гадел һәм олы булуын да таләп итә. Шуңа күрә шагыйрьнең йөрәкне чәчәк бәйләме итеп

күрергә теләве дә безнең өчен — тормыш ныклыгы, реаль җирлеге, киләчәге булмаган яшьлек хыялы булып тоела. «Дошманым юк. Дус-белеш бар» дип башланып киткән шигырь дә ышандырып җиткерми. Моның сәбәбе дә әнә шул ныклыкны таба алмауда, әлбәттә.

Билгеле, шагыйрьнең юлы мондый шигырьләрдән арырак китә һәм барган саен аның җанында Яшьлек белән Чынбарлык дуслаша, аралаша баралар. Шагыйрьнең иҗаты аларның һәр икесенә тигез таяна, алардан бердәй көч һәм хис ала башлый. «Аның җаны яралы...», «Язгы дәрт белән өздерә...», «Үлемнәре белән үлемсезлек», «Яшәсен», «Яңабаштан — булмый» — болар инде шагыйрьнең тормышта чын поэзияне — нык матурлыкны табуы турында ышанычлы итеп сөйлиләр. Аларда күтәрелгән тирән һәм төпле фикерләргә бер үк вакытта яшьлек ялкыны да, сафлык та хас.

Шагыйрь җаны тормышта күпне күрә, заманыбызның рухи тормышындагы күп өермәләрне, «тугыз баллы дулкыннарны» кичерә. Ул үзен һәм халкын борчыган нәрсәләр турында зур сөйләшү алып бара, тормыш үзе көн тәртибенә куйган олы сорауларны әйләнеп үтми. «Наз»дагы халыклар язмышы, халыкның бөек уллары турындагы шигырьләр зур фикер һәм көчле хис белән язылган. Менә бу юллар шагыйрьнең нинди шәхес икәнен тулы һәм матур итеп ачып бирәдер дип уйлыйм:

Төзү, кору, кискен үзгәрүләрнең
мәгънәсен эзлим күңелдә.
Борынгы ямь белән килер ямьнең
чагылышы бармы күңелдә?

(*«Төзү, кору, кискен үзгәрүләрнең»...*)

Китаптагы әнә шундый шигырьләрне күбрәк укыган саен, күңелдә шагыйрьгә ышаныч арта, аның заман алдында, заманның иң үткен мәсьәләләре алдында намуслы шагыйрь икәнлеген ныграк аңлый барасың. Әйе, Равил Фәйзуллин — заманның тынгысыз йөрәкле шагыйре. Ә менә шул шагыйрьнең мәхәббәте нинди соң? Мәхәббәт турында «Наз» китабының махсус бүлеге җырлый. «Аккошлар»ны тыңлап карыйк:

Китәсез дә мени,
китәсез дә мени,
китәсез дә мени, аккошлар?

Бу җыр шагыйрь йөрәгендәге мәхәббәтнең бөтен төсмерләрен ачып бирә төсле. Мәхәббәт шагыйрьгә никадәр бәхетле минутлар, тиңе юк гүзәллек алып килгән. Мәхәббәт шагыйрьнең тормышын җырга, ялкынга әверелдергән. Ләкин... Әнә аккошлар, күтәрелеп китәргә җыенып, канат кагыналар. Күңелдә, йөрәктә ак ялкын, үзәк өзгеч, моңлы җыр — китәсез дә мени аккошлар?

Шагыйрьнең мәхәббәт турында матур шигырьләре бик күп. Аларның күбесе җырга тиң һәм алар күңелдә тирән бер моң булып утырып калалар да. Менә берсе:

Мин сиңа йомшак таң җиле
юллаган идем.
Чәчләреңнән иркәләр дип
уйлаган идем.

Сәфәреңдә илләр кичеп,
тауларда куныи,
ул сиңа ирешкән икән
зилзилә булып.

Мин сине сагынып бер җыр
чыгарган идем.
Җан дуслар аны яратып
тыңлаган иде.

Жыр сиңа ошар дип йөрдем,
ваемсыз булып.
Ә ул сиңа барып җиткән
хаин сүз булып.

...Хәзер җилләр дә юлламыйм.
Чыгармыйм җыр да.
Әгәр теләсәң җанымны,
Үзең кил, тыңла.

*(«Мин сиңа йомшак таң җиле...»)*

«Тимим күңелемә» һәм «Беренче дә, иң соңгы да түгел»... дигән шигырьләр дә укучыны мәхәббәтнең олылыгы, кырыс хакыйкате белән тетрәндерәләр.

...Ә безнең бу мәхәббәт,
тиңдәшсез мәхәббәт,
күз яшьле мәхәббәт
җыр булып калсын!

*(«Тимим күңелемә»)*

Шагыйрь үзенең мәхәббәт шигырьләрендә дә үз буынына, үз заманына турылыклы булып кала. Без анда нәкъ менә бүгенге яшьләргә хас мәхәббәт хисләре белән очрашабыз. Яшьләребезнең иң саф гүзәллеккә, эчкерсез матурлыкка омтылуы, мәхәббәт җылысына сусавы, тормышта шуны эзләве, ялгышулары — Р. Фәйзуллин шигырьләренең нигезендә шул хисләр ята. Аларны сурәтләгәндә шагыйрь кайнар һәм табигый мәхәббәткә тугры булып кала, мәхәббәтнең кабатланмас матурлыгын һәм бөеклеген, димәк, шуның белән бергә, гомумән кеше тормышының да матурлыгын, мәхәббәтнең кабатланмас матурлыгын һәм бөеклеген, байлыгын күрсәтеп бирә. Әнә шуңа күрә Равил Фәйзуллинның мәхәббәт шигырьләрен укыганда: «Әйе, шагыйрьнең мәхәббәте дә ялкынлы икән!» дисең.

Китапның соңгы бүлеге — «Нюанслар иле». Аларны Фәйзуллин иҗатының байрагы кебегрәк итеп күз алдына китерәсең. Без, гадәттә, байракларга карап илләрне, дәүләтләрне аерабыз. «Нюанслар иле» дә әнә шундый. Ул нюансларның һәрберсе диярлек Тормышны һәм Матурлыкны үзенә шул кадәр күп сеңдергән, алар күз нурларыннан сыгылган энҗе бөртекләре кебек. Һәм, билгеле, башка шигырьләре белән чагыштырганда алар бик үзенчәлекле дә. Бүтән шигырьләрдә шигъри юл яки строфа ялкынына төреп бирелгән сүзләр бу нюансларда башта ялангач, хиссез, салкын калалар кебек. Ләкин нюансны укып чыккач, безнең өчен моңарчы ачылмый, бар көчен, мәгънәсен күрсәтми торган әнә шул сүзләр үзара тыгыз бәйләнешкә керәләр һәм синең алда бер поэтик күренеш — нюанс барлыкка килә. Шуннан инде сиңа хис ага, тормыш ага, хатирәләүләр, хыяллар кире кайта һәм алар барысы җыйналып күңелдә давыл куптара. Ә бит башта салкын сүзләр генә кебек иде. Күңелең сай һәм дөньяң ярлы булса, ялгышасың икән шул! «Көзге яңгыр» дип исемләнгән нюанс әнә шулай тәэсир итә торганнарның берсе.

Торналар китеп бара.
Кош канатлары орынгач,
болытларның күңеле тулды.

Шигъри күңелләрдә нинди генә хисләр, нинди күзаллаулар тудырмый икән бу күренеш!

Бу илдә шулай ук халык әйтеменә яки афоризмга охшап шигырьләр дә байтак.

Шатлыкны бик җиңел димә,
Кайгыны бик авыр алма.
Һәр икеве — олы сынау
кешелеге булган җанга.

*(«Җиңел димә».)*

Хәер, «Нюанслар иле» турында матбугатта байтак язылды. Ләкин, минемчә, аларның шагыйрь иҗаты өчен әһәмияте ачыкланмыйчарак калды шикелле. Ә бит алар — шагыйрь дөньясының нигезе, аның бүгенге уңышларының тамыры. Бүген Равил Фәйзуллин поэзиясен характерлый торган төп сыйфатларның әнә шулардан үсеп киткәнен күрәбез. Ә нindиләр соң алар? Һәм гомумән «Нюанслар иле»нең дә, шагыйрьнең бүгенге шигырьләренең дә сәнгать көче нәрсәдә, алар ни рәвешле тәэсир итәләр?

Равил Фәйзуллин шигырьләрен укыганда без шагыйрьнең дөньяга, әйләнә-тирәдәге тормышка карашы никадәр игътибарлы, сизгер һәм тирән икәнен, аның тормыштагы кечкенә генә күренешләрдә дә зур фикерләр, көчле хисләр тоя алуын һәм аларны укучыда да уята, кузгата алуын күрәбез. «Образлы фикерләү» дигән хикмәтнең нинди зур көчкә ия булуына сокланабыз. Ә бит, уйлап карасаң, нәкъ менә образлылык, көчле, тирән гомумиләштерүгә, дөньяның катлаулы диалектикасын аңлауга булыша торган образлылык безнең яшь иҗат көчләренең байтагына җитми. Ә образлы тою, күрү сәләте булмагач, ирексездән нәсихәт, авторның укучыга мораль укуы, сай мәгънәле сүзләр боткасы башлана. Әнә шундыйлар янына хәзер менә бу шигырьне куеп карыйк:

Еллар китә...
Чайкала-чайкала
Иделдә ай кала.

Без китәбез...
Җир — бирә,
Җир — ала...
Озатып җыр кала.

*(«Ай кала».)*

Бу кыска юлларга нәрсәдер өстәргә тырышу яки аларны аңлатырга маташу бөтенләй урынсыз эш. Чын сәнгать әсәренең һәр күзәнәге сулый, сиңа ялкын өрә, яндыра башлый! Шагыйрь иҗатына хас булган менә шундый образлылык, сәнгать көченең муллыгы табигый рәвештә шигырьләрнең һәм гомумән Равил Фәйзуллин поэзиясенең тыгызлыгына китерә.

Равил Фәйзуллин иҗатының шигърилеге, сәнгать ягы турында уйланган саен, үзең өчен яңадан-яңа нәтиҗәләргә, кызыклы фикерләргә килэсең һәм сәнгать дөньясына ныграк кергән, поэзияне ныграк тоя башлаган кебек буласың. «Наз» китабына кергән шигырьләрне уку минем үземне, мәсәлән, шундый нәтиҗәгә китерде: шигырьдә чын хис һәм олы хис булса гына ул көчле сәнгать әсәре була ала икән. Нәкъ менә Равил Фәйзуллин иҗатының чын кешелек хисләренә, көчле тойгыларга, үзе кичергән, бөтен йөрәк белән тетрәнеп кичергән күңел гарасатларына байлыгы аның поэзиясенең көчен һәм ялкынын билгеләи. Шигырь язучылар бик күбәйгән бүгенге көндә, мөгаен, бу таләп — чын, ихлас хис булу таләбе аеруча кирәктер. Чөнки хәзер кайчагында хисне ясалма юл белән — югары сүзләр, өндәү билгеләрен күпләп кую юлы белән ясарга тырышу тенденциясе дә сизелә башлады.

Равил Фәйзуллин шигырьләрендәге хиснең олылыгы шунда: ул кешене көчле итә, бөек итә, матур итә һәм саф итә.

*

*   *

Менә яңа китапның соңгы битен дә ябып куйдык. Без әле аны тагын кабат-кабат алып укырбыз, укыган саен яңа фикерләр, яңа хисләр табарбыз, китап турындагы тәэсирләребезне дусларыбыз белән уртаклашырбыз. Ә хәзергә безне икенче бер нәрсә уйландыра.

«Наз» җыентыгына кергән шигырьләрне укыган вакытта да, китапны укып чыккач та уйлар кабат-кабат классик поэзиягә, өлкәннәр поэзиясенә кайта.

Мәкаләнең башында без Лермонтов һәм Сибгат Хәким шигырьләренең никадәр көчкә ия булуы, тормышның чын моңына әйләнүе турында сөйләгән идек.

Югарыда карап үткәнебезчә, Равил Фәйзуллин поэзиясе дә классик поэзиянең күп кенә төп сыйфатларына ия, аның иң кадерле һәм олы идеалларына тугры поэзия. Ләкин, шул ук вакытта, күңел шагыйрь шигырьләренең ничектер бүтәнчәрәк икәнен, икенче яңа сыйфатларга ия булуын да сизмичә калмыйм. Һәм китапны укып чыккач, әнә шул тойгы — шагыйрь иҗатының үзенчәлеген аңларга тырышу тойгысы тынгы бирми башлый. Чыннан да, эш нәрсәдә соң?

Равил Фәйзуллин поэзиясенең үзенчәлеген ачыклау өчен безгә, барыннан да элек, аның буынының тормышта үткән юлын, язмышын карап үтәргә кирәк. Бу буынның җанын, акылын, характерын нинди рәк дөнья, нинди рәк мөнәсәбәтләр формалаштырды соң?

Равил Фәйзуллин — сугыштан соң туган буын вәкиле. Шәхес формалашудагы хәлиткеч чор бу буын өчен алтмышынчы еллар булды. Ә ул еллар, ныклабрак карасаң, бөтенләй яңа тарих. Алтмышынчы еллар — илебез экономикасының нык үсү чоры, тормышның һәр тармагына фән-техника революциясе үтеп керә башлаган һәм аңа шундук яңа сулыш өргән чор. Бу — бөек могҗиза — беренче мәртәбә кешенең космоска очу заманы. Һәм шуларга һичшиксез бәйле рәвештә, бу заман кешенең дөньяга һәм үз-үзенә күзен ачкан заман, хезмәт кешесенең үзен чын мәгънәсендә иҗат кешесе, яңалыкны җирдә урнаштыручы бөек көч итеп тоя һәм яши башлаган заман.

Тормышның әнә шулай җанланган һәм рухи яктан баеган чоры авыл тормышына да зур үзгәрешләр алып килде. Авыл хуҗалыгына моңарчы күрелмәгән көчле техниканың килүе, шуның нәтиҗәсендә эшче көчләрнең берникадәр бушавы һәм, икенче яктан, илебезнең төрле почмакларында, Татарстанның үзендә зур төзелешләрнең, завод-фабрикаларның канат җәюе күпчелек яшьләрнең барыр юлын авыл хуҗалыгыннан, җирдән аерды. Алар өчен авыл «туган ягым — яшел бишек» булып калды. Өлкән буын әдибе әйткән бу сүзләр нәкъ менә яшьләр авызыннан чыккан кебек иде. Чөнки «яшел бишек» — бу буынның бала чагы үткән урын, ә «туган ягым» — авылдан киткән кеше авызыннан төшми торган сагыну сүзе.

Ләкин тормышның объектив агышы, аның көчле ихтыяҗлары таләбе буенча, әлеге буынның язмышы авылдан, Җирдән аерылса да, бу аерылу тормыштан, киң мәгънәдәге җирдән аерылу түгел иде. Бу зуррак, киңрәк тормышка кушылып китү иде. Меңләгән яшь кешеләр өчен тормышта тапкан бу яңа җирлек, яңа «җир» — төзелеш мәйданнары, завод-фабрикалар, уку йортлары, фәнни лабораторияләр булды. Аларда заманның кайнар тормышы киңрәк һәм тирәнрәк агыла иде, яшәеш кызу һәм ашкынулы ритмлы иде. Әнә шундый актив атмосфера бу буын характерына байтак үзенчәлекләр салды, аны югары омтылышлы социаль яктан актив һәм көчле интеллектуаль дөньялы итеп үстерде. Бу сыйфатларга ия булу исә үз чиратында буынның көчен нык арттыра, аны социалистик җәмгыять үсешендә бик мөһим бер көч итә иде. Һәм әнә шул олы миссияне үтәү, үзенә салынган зур потенциаль энергияне эшкә ашыру максаты белән дәртләнеп, әлеге буын тормышка килеп керде. Ә анда башланып киткән зур яңарыш ул буыннан күп проблемаларны хәл итүне һәм күп кенә үткен мәсьәләләрне көн тәртибенә куюны таләп итә иде. Аларның күбесе: кеше һәм аның тормыштагы урыны, яшәве, аның халык алдында, тарих алдында җаваплылыгы турындагы мәсьәләләр булды.

Әнә шул чакта, һәр вакыттагыча, буын байракчылары — шагыйрьләр алга чыкты. Үз яшьтәшләренең рухы аларның җаны булды, җыры булды. Һәм менә шул факт — буын шагыйрьләренең заманга һәм үз буыннарына тугры булуы аларның иҗатындагы үзенчәлекле якларны китереп чыгарды.

Яшьләр иҗатында һәм бигрәк тә Равил Фәйзуллин иҗатында иң беренче күзгә ташланган үзенчәлек, мөгаен: заманның рухи тормышына, аның проблемаларына игътибарның нык артуыдыр. Чыннан да, ул буын шагыйрьләренә карасак, без аларда тормышның аерым эпизодларыннан, вакыйгаларыннан бигрәк, кеше җанының төрле-төрле халәтләрен, аның тирән мәгънәгә ия

булган мизгелләрен күбрәк күрербез. Моңа «Наз» китабына кергән шигырьләр дә ачык мисал. Хәтта бер шигырендә Равил Фәйзуллин бу тенденцияне ачыктан-ачык әйтеп бирә:

Шигырьләрем — бер халәте
тәнгә сыймаган җанның!

Ә конкрет алганда нинди халәт соң алар?

Аларда шагыйрьнең тормышка булган көчле мәхәббәте, аны бар катлаулылыгында тоеп яратуы, тормыштагы һәм дөньядагы сафлыкка, матурлыкка табынуы, аның өчен борчылуы һәм көрәше, кеше гомеренең һәр мизгелен аңларга омтылуы, шагыйрь җанның әйләнә-тирә тормышка утә нык сизгерлеге, нечкәлеге. Шул ук вакытта болар бүгенге яшь буынның характеры да, аны башкалардан аерып күрсәтә торган үзенчәлек тә. Һәм алар шагыйрь иҗатына да башка буын шагыйрьләренекенә охшамаган яңа сыйфатлар өстиләр. Күргәнебезчә, аларның беренчесе рухи проблемаларга, кеше җанына көчле игътибар булды.

Шагыйрь иҗатына хас икенче үзенчәлек шулай ук аның үз буыны характеры белән нык бәйләнгән. Билгеле булганча, тормышка алтмышынчы елларда килгән бу буын күп белемле, тирән фикерле, югары интеллектуаль дөньялы булуы белән танылды. Әлбәттә, аларның поэзиясе дә шуңа тиң, шул дәрәҗәдә булырга тиеш иде. Һәм әнә шундый объектив таләп шигырьләрдә эчке поэзиянең көчәюенә, тирән һәм катлаулы образлар тууга китерде. Билгеле, монда катлаулы образлар булу төп максат түгел. Ләкин бит әле шундый нәрсә бар: һәр фикер бары тик үз формасын гына, үзенчә яңгырашын гына эзли, аны гади генә итеп әйтәм дисәң, ул бөтен төсмерләрен, тәэсир көчен югалта. Анныры, гадилек таләп итүчеләр, бүгенге яшьләрнең үзара сөйләшүен карагыз. Ул гадимени?! Кыскасы, эчке поэзиянең көчәюе — Равил Фәйзуллин иҗатына тормышның үзе тарафыннан кертелгән үзенчәлек булды.

Равил Фәйзуллин шигырьләрендә күзгә ташланган тагын бер үзенчәлек — тематик киңлек. Юк, бу инде, кайбер яшь шагыйрьләр кебек һәр нәрсәгә карап шигырь чыгарырга көчәнү түгел, ә күңелнең байлыгы, күзнең үткенлеге. Ә тематика киңәюен исә тормышта яңа җирлек тапкан яшь буынның үзенең әйләнә-тирәсенә карануы, аны өйрәнүе, белергә, аңларга тырышуы дип карарга кирәктер. Анда бит әле яшисе һәм тир түгәсе, сөясе һәм көрәшәсе бар!..

Шулай итеп, без Равил Фәйзуллин поэзиясендә шактый гына яңа сыйфатлар, яшь буыннан, яңа буыннан килә торган сыйфатлар күрәбез. Шагыйрь үз буынына җырлары, фикерләре белән генә түгел, ә үзенең иҗади карашлары, иҗат принциплары белән дә охшаш һәм аңа турылыклы. Аның йөрәге аерылгысыз булып буын язмышына һәм әнә шул язмыш аша заман тормышына, ил тормышына тоташкан. Шул җирлектән шагыйрь бүген үзенә Ныклык һәм Матурлык ала. Үзенең шундый ныклы нигезе, таянычы булганга сөенеп, үзен ил эчендә, тормыш эчендә, кешеләр арасында сизгәнгә күрә, шагыйрь язмышының олы мәгънәсен аңлаганга күрә Равил Фәйзуллин бер шигырендә:

Безгә ак болыт булырга
язмаган шул... —

ди.

Бу юллар бүген яшь буынның тормыш девизы булып яңгырый.

*Спасск — Дальний шәһәре.*

# ӘДӘБИ ТЕЛ ТАРИХЫ ҺӘМ БҮГЕНГЕ КӨН

Әдәби телнең хәзерге торышы, үткәне һәм киләчәге киң җәмәгатьчелекне һәр вакыт кызыксындырып, вакыт-вакыт кызу бәхәсләр кузгатып килә. Һәм бу гаҗәп тә түгел, чөнки тел — күп гасырлы культура, ул — халыкның буыннан-буынга күз карасы кебек саклап, туплап килгән рухи байлыгы.

Әдәби тел тарихын өйрәнү милли культура хәзинәләренең ничек туплануын, күренекле әдип һәм галимнәрнең әдәби тел үсешенә керткән өлешен ачыкларга, хәзерге язма һәм сөйләү нормаларының ничек барлыкка килүен күзалларга һәм, иң әһәмиятлесе, әдәби телебезнең бүгенге хәлен тирәнтен аңларга, аның үсеш тенденцияләрен дөрес билгеләргә, әдәби тел алдында хәзерге көндә торган мәсьәләләрне аек акыл белән хәл итәргә ярдәм итә.

Соңгы елларда татар әдәби теленең барлыкка килү һәм үсү юлларын ятырткан, аның аерым мәсьәләләрен күтәргән күп кенә хезмәтләр дөнья күрде. Әмма әдәби тел тарихын һәрьяклап, тирәнтен өйрәнүгә багышланган зур монографик хезмәт юк иде әле. Филология фәннәре докторы В. Хаковның Казан университеты нәшриятында басылып чыккан «Татар милли әдәби теленең барлыкка килүе һәм үсеше» исемле хезмәте — менә шул максатка ирешү юлында уңышлы бер адым.

В. Хаков — бу өлкәдә билгеле автор. Аның әдәби тел тарихына, татар стилистикасына, аерым язучыларның теленә, төрле стильләрне өйрәнүгә багышланган берничә китабы һәм дистәләрчә мәкаләләре белгечләр арасында зур кызыксыну уятты. Бу хезмәтендә дә ул тирән теоретик мәсьәләләр кузгата һәм аларны үзенә хас җентеклелек, тәфсиллек белән бай фактик материал нигезендә чишә.

Тел тарихы турында уйланганда, гадәттә, безнең бабаларыбыз нинди телдә сөйләшкән, ул тел ничек аталган? дигән сорау туа. Шул сорауга җавап бирү йөзеннән, автор татар халкының этногенезына (килеп чыгышына) бәйле мәсьәләләрне күтәрә, татар теленә генә хас сөйләү һәм язу нормаларының борын-борыннан ничек формалашып килүен яктырта, элекке чорларга кыскача экскурс ясый. Идел-Кама буенда яшәгән җирле төрки кабиләләр (башлыча, болгарлар һәм кыпчаклар), ди ул, хәзерге татар халкының барлыкка килүендә һәм формалашуында зур роль уйнаганнар.

Билгеле булганча, хәзерге телнең нигезендә кайсы борынгы тел ятуын билгеләр өчен, шул телнең үзенә генә хас, аның асылын тәшкил иткән төп үзенчәлекләрне борынгы язма истәлекләр белән чагыштырып чыгарга кирәк. Галим Идел буе һәм Дунай болгарларыннан калган борынгы язмаларны һәм XIII—XIV йөзләрдә төзелгән кыпчак сүзлекләрен җентекләп өйрәнә һәм төрле тарихи шартлар нигезендә борынгы болгар теленең кыпчак теле тарафыннан ассимиляцияләнә (йотыла) бару закончалыгын һәм татар әдәби теленең нигезендә кыпчак теле ятуын ачыклый.

Дөрес, татар теленең кыпчак төркеменә яки кыпчак-болгар төркемчәсенә каравы фәндә күптән билгеле. В. Хаковның яңа сүзе һәм фәнгә керткән

өлеше шунда — ул бай фактлар нигезендә һәрьяклап (авазлар төзелеше, грамматика һәм сүзлек составы ягыннан) бу фикернең дөреслеген раслый. Авторның китергән дәлилләре һәм чагыштырулары (28—44 битләр) галимнәр өчен генә түгел, киң катлау укучыларга да кызыклы булыр дип ышанабыз.

Татар телендә борынгы болгар теле үзенчәлекләре сакланганмы соң? Әлбәттә, сакланган. Бу бигрәк тә авазлар системасында (ирен сузыкларының башка кыпчак телләренә караганда үзгәлеге, р-з авазларының чиратлашуы, «җ»еләштерү) һәм сүзлек составында (аерым алганда, җир-су атамаларында) ачык күренә. Болгар теле элементлары татар теленең урта диалектында ныграк сакланса, кыпчак-угыз традицион язма теленең морфологик үзенчәлекләре әдәби телдә күбрәк табыла. Кыскасы, татар әдәби теле Идел-Урал буенда таралган төрле болгар һәм кыпчак сөйләшләре нигезендә борынгы төрки тел күренешләре белән кушылып барлыкка килә.

Хәзерге татар әдәби теле катлаулы тарихи юл үткән, аның татар халкы милләт булып оешканга кадәрге һәм ул милләт булып формалашканнан соңгы үсеш дәверләре бар. Традицион язма тел үзенчәлекләрен саклап һәм төрле алынмалар белән чуарланып, гомум халык сөйләменнән аерылыбрак торганга, милләт барлыкка килгәнче булган язма әдәби телне китап теле дип атау гадәткә кергән. Диалект-ара сөйләү теле үзенчәлекләренең, барлык сөйләш вәкилләре өчен норма буларак, бердәм, мәҗбүри төс алуы милләт формалашкач (автор фикеренчә, XIX йөз уртасыннан) гына тормышка аша.

Әмма милли әдәби тел белән милләт формалашканчы кулланышта булган әдәби тел бер-берсеннән нык аерыла дип, алар арасына таш стена кую да дөрес булмас иде. Кызганычка каршы, мондый караш соңгы вакытларга кадәр яшәп тә килде. В. Хаков татар әдәби теленең үсеше тоташ процесс булу фикерен принципиаль рәвештә яклап чыга. «Борынгы тел үрнәкләрен, язма истәлекләрне тикшереп карау,— ди ул,— татар әдәби теленең халык өчен бөтенләй ят булмаганлыгын, тулаем рәвештә читтән алынмаганлыгын күрсәтә. Һичшиксез, аның составында катлаулы тарихи үсеш юлы белән бәйләнешле төрле элементлар булган. Гасырлар дәвамында халык сөйләү теле белән язма әдәби тел арасында була килгән аерма милли тел формалашу чорында бетү тенденциясенә бара» (15—16 бит).

Автор XIX йөзнең уртасына кадәр әдәби телдә өч стиль (югары, урта һәм түбән) яшәгән дигән фикерне куәтли. Соңгы икесенең (бу стильләрдә эш кәгазьләре алып барыла, фәнни-популяр, матур әдәбият һәм халык иҗаты әсәрләре языла) милли әдәби телнең фонетик-морфологик, лексик-стилистик нормаларын формалаштыруда нигез булып хезмәт итүен күрсәтә. Бу бүлек — хезмәтнең фән өчен иң әһәмиятле һәм кыйммәтле өлешләренең берсе.

Әдәби телне халык тудырган, аны гасырлар буена баеткан, үстергән, тормышның төрле тармакларында кулланырга яраклы, мөкәммәл хәлгә китергән. Шул ук вакытта әдәби тел инде тулысынча камилләшкән һәм аның гомум халык сөйләү теле, аерым алганда, җирле сөйләшләр исәбенә байыйсы юк, киресенчә, диалектизмнар әдәби телне чуарландыруга гына китерә дип уйлау да дөреслеккә туры килмәс иде. В. Хаков китабыннан күренгәнчә, мондый ялгыш караш элек тә яшәгән һәм ул әдәби телне халыктан аерырга омтылучы сыйныфлар өчен генә хезмәт иткән, әдәби телнең халыклашу юлында киртә булып торган. Халкыбызның алдынгы вәкилләре моны яхшы аңлаганнар, әдәби телне халык сөйләү теленә якынайтырга күп көч куйганнар һәм, халык теленең, шул исәптән үз диалектларының бетмәс-төкәнмәс эчке мөмкинлекләреннән файдаланып әдәби телне яңа баскычка күтәргәннәр.

Әгәр без җирле сөйләшләрне милли тел яшәешенең бер формасы итеп таныйбыз (совет тел белемендә ул нәкъ шулай куела да!) һәм халык сөйләү телен әдәби телнең бетмәс-төкәнмәс чыганагы итеп саныйбыз икән, үтә тар диалектизмнарга яки фонетик вариантларга каршы көрәшне барлык җирле сөйләш сүзләренә җәелдерергә, матур әдәбият телен төссезләндерергә, әдәби телне аның төп чыганагыннан аерырга тиеш түгелбез. Күренекле әдипләребезнең әдәби телне җирле сөйләш

сүзләре исәбенә баету тәҗрибәсе, алар тырышлыгы белән әдәби телгә кереп киткән тоҗым, күләвек, аҗаган, илгәзәк, туера, иңкел, имәнеч, игәч һ. б. ш. сүзләр әле бу байлыкның төбенә төшеп җиттек дияргә иртә булуы турында сөйли.

Әлбәттә, әдәби телне гомум халык сөйләү теле исәбенә баетуны диалектизмнарга гына кайтарып калдыру мәсьәләгә берьяклы килү булыр иде. Китапның икенче бүлеге аның башка юлларын — сүз ясау ысулларын (әдәби тел сүзенең мәгънәләрен киңәйтү, синонимнардан файдалануны һ. б.) анализлауга багышланган. Автор, бер яктан, үтә тар диалектизмнар яки фонетик вариантлар белән һәм, икенче яктан, халык кабул иткән алынмалар урынына телнең рухына туры килми торган ясалма сүзләр уйлап чыгару белән мавыгуның әдәби тел үсешендә перспективасыз икәнлеген фактлар өстендә ышандырырлык итеп раслый. Хезмәтнең бу өлеше хәзерге көндә дә актуаль яңгырый.

Милли әдәби телнең үсеше һәм формалашуы функциональ стильләр (матур әдәбият, публицистика, рәсми-канцелярия, хат стильләре һәм фәнни стиль) белән тыгыз бәйләнгән. В. Хаков, татар тел белемендә беренче буларак, һәр функциональ стильнең үзенчәлекләрен билгели һәм аларның үсеш тарихы турында тулы мәгълүмат бирә.

Татар халкының фәнни мирасы турында сөйләгәндә, төгәл фәннәр, табигать фәннәре буенча хезмәтләр бөтенләй диярлек булмаган дигән ялгыш караш яшәп килде. Фәнни стильгә багышланган бүлектә бу стильнең тамырлары Болгар чорына барып тоташуы, татар галимнәренең, тарих, философия, юриспруденция кебек иҗтимагый фәннәрдән тыш, медицина (Әхмәт әл Болгари), математика (1542 елгы «Мәҗмәгел кавагыйдә») кебек төгәл фәннәрдән, табигать фәннәреннән дә оригиналь хезмәтләр иҗат итеп калдырулары турында кызыклы мәгълүматлар бар.

XIX йөзнең икенче яртысы һәм XX йөзнең башында, Россиядәге тирән экономик һәм политик үзгәрешләр һәм демократик мәгърифәтчелек хәрәкәтенең киңәюе нәтиҗәсендә, татар әдәби телендә иҗтимагый һәм табигать фәннәренең нигезләрен, яңа казанышларын халыкка җиткерүне максат итеп куйган фәнни әдәбият һәм аның стиле киң үсеш ала.

Фәнни стильдә лексик яктан иң әһәмиятлесе — терминология мәсьәләсе. В. Хаков фәннәрнең төрле тармакларына караган терминологиянең барлыкка килү тарихын, терминнар ясалу юлларын, кайсы чорда нинди фән тармагы буенча һәм кем тарафыннан беренче мәртәбә нинди атама кулланылуын бик бай материал нигезендә яктырта. Тик биология һәм авыл хуҗалыгы терминологиясен формалаштыруда өч исем (К. Насыйри, Ф. Мөхетдин, Х. Сахаветдин) белән генә чикләнмәскә, татар халкы арасында табигать белемнәрен таратуда күп көч куйган һәм фәнни стильнең үсешенә сизелерлек йогынты ясаган атаклы мәгърифәтче Гали Мәхмүдов, саф татар телендә язылган утыздан артык фәнни-популяр брошюралар авторы Совет власте елларында Хезмәт батыры исеменә лаек булган Ибраһим Терегуловның хезмәтләре, һичшиксез, тәкъдир ителергә тиешле иде.

Бу бүлектә галимнең тагы бер күзәтүе гаять гыйбрәтле: татар мәгърифәтчеләре терминология тудыруда һәр фәннең үзенчәлегеннән чыгып эш иткән булганнар. Әгәр математика, физика, техник фәннәргә караган терминология күпчелек очракта алынма сүзләр исәбенә формалашса, авыл хуҗалыгы, биология һәм иҗтимагый фәннәргә караган атамаларның зур өлешен алар халыкның гасырлар буена тупланган үз хәзинәсеннән алганнар. Шул ук И. Терегулов үлән исемнәрен авылларда халыктан җыеп йөргән. (СССР Фәннәр академиясенең Казан тел, әдәбият һәм тарих институты архивында ул төзегән гербарийларның бер өлеше хәзер дә саклана.)

Татар милли әдәби теле тарихы төгәл фәннәр терминологиясенең XIX йөзнең икенче яртысыннан башлап интернациональ яки рус терминнары исәбенә баю тенденциясен күрсәтә. Шуңа күрә **паровоз** урынына **буйөрткеч**, ә хәзерге көннәрдә **выключатель** урынына **өздергеч-тоташтыргыч** кебек ясалма сүзләр белән мавыгу бу төр терминологиянең үзенчәлеген һәм үсеш тенденциясен истә тотмаудан килә. Димәк, галимнең хезмәте актуаль мәсьәләләрне кузгата, аннан бүгенге көн практикасы

өчен файдалы, гыйбрәтле мәгълүматлар алырга була.

Хәзерге вакытта бара торган фәнни-техник революция һәм фәндәге яңадан-яңа ачышлар нәтиҗәсендә, фәнни-популяр, вакытлы һәм матур әдәбиятта шул кадәр яңа атамалар кулланыла, аларны аңлар өчен югары яки урта махсус белеме булган укучыларга да сүзлекләргә мөрәҗәгать итәргә туры килә. Кайчакта яңа яки үтә махсус атамаларны кул астында яткан сүзлекләрдән табып та булмый. Әйтик, А. Расихның «Ике буйдак» романындагы **инбридинг** сүзе С. Ожеговның «Рус теле сүзлеге»ндә генә түгел, хәтта 4 томлык рус сүзлегендә (академик басма) юк. Ә киң катлау укучылар ни эшләргә тиеш? Матур әдәбият әсәрләрендәге **пироколлодий, инжектор, прагматист, квазар** яки киң катлау укучыларга исәпләнгән көндәлек матбугат битләрендәге **интерцептор, элерон, компенсатор, модификатор** кебек үтә тар кулланыштагы атамалар шул өлкәләрдә эшләүче аерым белгечләрдән башка тагы кемнәргә генә аңлашыла икән?

Революциягә кадәрге демократик татар матбугаты һәм большевистик «Урал» газетасы (сугышка кадәр «Кызыл Татарстан» үзе дә!) һәр яңа яки сирәк очрый торган атамаларга аңлатма биреп баруны үзләренең бурычлары итеп санаганнар. Күренекле әдипләребез, публицистларыбызның бу күркәм традициясен яңартырга кирәк түгелме икән? Татар телендәге рус һәм интернациональ атамалар сүзлеген чыгаруга да вакыт җиткәндер.

Рәсми-канцелярия кәгазьләре халык тормышында зур урын тота. Хезмәттән күренгәнчә, Болгар дәүләте, Казан ханлыгы чорында һәм Казан, Әстерхан ханлыклары, Башкортстан Рус дәүләтенә кушылганнан соң да дәүләт күләм әһәмиятле фәрманнар, ярлыклар, указлар, манифестлар, дипломатия документлары, һәртөрле законнар, инструкцияләр, җирле идарә яки эш кәгазьләре (договорлар, гаризалар, метрика дәфтәрләре, ышанычнамәләр һ. б.) элек кыпчак, аннан соң татар әдәби телендә дә язылып килгәннәр.

Автор һәр төр документ яки эш кәгазенең үзенчәлекләрен ача һәм аларны тел ягыннан төп ике төркемгә бүлә, дәүләт күләм документларның традицион китап телендә, ә гади эш кәгазьләренең тел-стиле гомум халык теленнән аз аерылуын күзәтә.

Шуны басым ясап әйтергә кирәк, В. Хаков кульязма һәм басма истәлекләр арасыннан теге яки бу стильне характерлый, шул стиль үсешендә аерым этап булып торганнарын гына сайлап алырга тырышкан, фәнни әйләнештә булмаган бик күп яңа чыганаклар тәкъдим иткән. Шулай да рәсми-канцелярия стиле турында алдагы тикшеренүләрдә күбрәк кульязма материалга игътибар итәргә кирәктер. Казан, Өфе, Оренбург, Әстерхан архив киштәләрендә саклана торган һәм киң халык массасы тарафыннан һәркемгә аңлаешлы саф татар әдәби телендә, билгеле бер традицион штамп белән язылган калын-калын кантон, метрика кенәгәләре, Казан татар ратушасы, Оренбург дини назариятындагы меңәрләгән төрле шикаятьләр, гаризалар, актлар, хатлар һ. б. бу стильнең бераз алдарак формалашуын расларга нигез бирә.

Эш кәгазьләренең үрнәкләре заманында белешмә рәвешендә басылып та чыкканнар икән. Хәзер дә күпчелек татар авылларында эш кәгазьләре ана телендә алып барыла. Әмма аларның басма үрнәкләре булмау зур уңайсызлыклар тудыра. Күрәсең, эш кәгазьләренең мондый үрнәк типларын чыгарырга күптән вакыттыр.

Мондый зур монографик хезмәт кимчелекләрдән тулысынча азат дип әйтергә җыенмыйбыз. Аерым мәсьәләләрдә автор белән бәхәскә керергә мөмкин. Әмма күпчелек кимчелекләр хезмәтнең асылына карамыйлар, хезмәтнең кыйммәтен киметә алмыйлар, ә кайберләре игътибарсызлык аркасында киткән булырга тиеш. Шундыйлар исәбенә без «Нәһҗелфарадис»ның авторы бер үк биттә ике төрле бирелү (Гали, ә берничә юлдан соң Мәхмүт Болгари), кайбер шартлы кыскартмаларның нәрсә аңлатканнары ачылмау (72 биттә: **Пт, УЖУ**), Чиләбе шәһәренең Челәбе дип язылуы кебек һичшиксез төзәтелергә мөмкин булган ялгышларны кертер идек. Яки Х. Ямашевныкы дип китерелгән өзекләр (174—75 битләр), чынлыкта, РСДРПның Казан комитеты тарафыннан 1903—07 елларда чыгарылган прокламацияләрдән алынганнар. Шуңа күрә бу өземтәләрнең я чыганакларын

күрсәтергә, я аларны Х. Ямашев тәрҗемә итүен раслаган хезмәтләргә ишарә итәргә кирәк иде.

В. Хаков татар әдәби тел тарихының сөрелмәгән, әле бер генә галимнең дә кулы тимәгән тирән катламнарын күтәрә һәм искиткеч бай фактик материал нигезендә, фәннең хәзерге көн таләпләренә җавап бирерлек тиешле теоретик югарылыкта яктырта. Галимнең бу китабы — әдәби тел тарихын өйрәнүдә яңа баскыч. Ул татар әдәби теленең башка телләр арасында тоткан урынын Союз күләмендә дөрес билгеләргә, аны борын-борыннан үсеп килгән, бай язма традицияләре булган әдәби телләр исемлегенә хаклы рәвештә кертергә ярдәм итәр. Монографиянең, докторлык диссертациясе буларак, белгечләр тарафыннан уңай бәя алуы үзе дә күп нәрсә турында сөйли.

Китап төрки телләрне өйрәнүчеләргә, укытучыларга, иҗат кешеләренә, студентларга, матбугат вәкилләренә атап язылган. Алар В. Хаков хезмәтеннән, һичшиксез, кызыклы күзәтүләр, яңа фактлар табарлар. Шуның белән бергә, автор күтәргән күп кенә мәсьәләләр бүгенге көн өчен дә актуаль яңгырыйлар. Ул үзенең яңа мәгълүматлары, яңа фикерләре, гади, ачык теле белән киң катлау укучыларына да юл табар.

**ИСКӘНДӘР АБДУЛЛИН**

# ҮТКӘН ГАСЫРЛАРГА СӘЯХӘТ

1773—1775 елларда бөтен Россияне тетрәткән крестьяннар восстаниесе турында ике меңнән артык фәнни хезмәт язылган. Пугачев хәрәкәте күп санлы матур әдәбият әсәрләрендә яктыртылган. Шуларга өстәп, тагын нинди яңа сүз әйтергә, нинди яңа мәсьәләләр күтәрергә мөмкин?.. Емельян Пугачев җитәкчелегендәге восстание бастырылганнан соң ике гасыр вакыт узды. Кеше кулы тимәгән яңа документлар кайда гына калды икән? Калса да, алар инде кулга тотып карарлык, эшкә ярарлык хәлдәме икән?..

Татар крестьяннарының Пугачев хәрәкәтендә катнашуларын өйрәнергә керешкәнче, шундый характердагы шикшөбһәләр, икеләнүләр, ихтимал, С. Алишевны да борчымый калмагандыр. Ләкин ул, бернигә карамый, шушы авыр эшкә алына. Еллар буе Мәскәү, Ленинград, Казан, Оренбург, Уфа һәм башка шәһәрләрнең архив киштәләрендә казына, гасырлар буе тузанга күмелеп ятып, саргаеп беткән, танымаслык хәлгә килгән меңнәрчә документларны өйрәнеп чыга. Архив документлары арасында моңарчы беркемнең кулы тимәгән бик күп яңа документлар таба. С. Алишевның «Пугачев восстаниесендә Урта Идел буе татарлары»[1] дигән хезмәте үзе тапкан шул яңа материаллар нигезендә языла.

Хезмәт төрлесе төрле зурлыктагы өч бүлектән тора. Беренче бүлек татар крестьяннарын Пугачев восстаниесенә катнашырга этәргән тарихи сәбәпләрне ачыклауга багышланган. Шул максаттан чыгып, автор XVIII йөзнең икенче яртысында Казан губернасында хөкем сөргән иҗтимагый тәртипләрне анализлый, халыкның социаль-экономик хәленә тулы күзәтү ясый. Билгеле булганча, бу — Россия империясендә капиталистик мөнәсәбәтләр урнаша башлаган, патша Россиясе капиталистик үсеш юлына аяк баскан чор. Моннан татар халкы да читтә калмый. Мәсәлән, бу елларда Казанның үзендә һәм губернаның башка төбәкләрендә 65 мануфактура предприятиесе булган. (Китап ахырында аларның тулы исемлеге китерелә). Татар халкы арасында тукыма, күн, сабын җитештерү нык алга китә. Шуның белән бергә, губерна территориясендә дистәләрчә металлургия

[1] С. Х. Алишев. Татары Среднего Поволжья в Пугачевском восстании. Рус телендә. Татарстан китап нәшрияты. 1973 ел. Фәнни редакторы — тарих фәннәре кандидаты Ж. Гыйльманов.

мануфактуралары эшләп килә. Авыл җирләрендә товарлыклы икмәк җитештерү үскәннән-үсә бара.

Капиталистик мөнәсәбәтләр киңрәк җәелгән саен, халыкның социаль-экономик хәле дә авырлаша бара. Милли окраиналарда моңа тагын милли-колониаль изү килеп өстәлә. С. Алишев китабында милли изүнең барлык формалары (көчләп чукындыру, татар крестьяннарының җирсезлектән интегүләре, күп төрле түләүләр, рекрут алулар, татарларны меңәрләп-меңәрләп ерак төзелешләргә куулар һ. б. һ. б.) турында тулы мәгълүмат бирелә.

Барлык төр изүләр халык массаларының царизм строена булган нәфрәтен соңгы чиккә китереп җиткерә. Җаек буйларында Пугачев хәрәкәте башлануга, аңа, һич икеләнүсез, бик күп милләт вәкилләре, шул исәптән татар халкы да, килеп кушыла.

Алда әйтелгәнчә, Е. Пугачев җитәкчелегендәге крестьяннар восстаниесе беренче көненнән үк үз тирәсенә төрле милләтләрне туплавы белән аерылып тора. Җаек казакълары (алар арасында төрле милләт вәкилләре, шул җөмләдән татарлар да, күп булган) арасында башланып киткән хәрәкәткә озаклямый татар, башкорт, чуваш, калмык һәм башка милләтләрнең вәкилләре кушылып китә, рус крестьяннары белән бергәләп, алар царизм строен җимерү өчен дәһшәтле көрәшкә күтәреләләр. С. Алишев хезмәтенең тагын бер уңай ягы шунда, ул татар халкының милли-азатлык хәрәкәтен ил күләмендә барган сыйнфый көрәш белән бәйләп аңлата, милли-азатлык хәрәкәтенең сыйнфый көрәштән аерылгысыз булуына басым ясый. Бу идея китапның беренче битеннән алып ахырына кадәр кызыл җеп булып сузыла.

Авторның әлеге карашын тулысынча хуплаган хәлдә, аның игътибарын милли-азатлык хәрәкәте белән бәйле тагын бер мәсьәләгә юнәлтеп үтәсе килә. Сүз дә юк, югары катлау вәкилләре, кайсы милләттән булуларына карамастан, 1773—1775 елгы восстаниедә патшаны яклап, аның ягыннан торып чыгыш ясыйлар. Шуның белән бергә, югары катлау вәкилләре арасыннан восстаниечеләр ягыннан торып көрәшүчеләр дә булмаган түгел. Менә бу мәсьәләгә ачыклык кертү, аңа тарихчы-марксист күзлегеннән торып фәнни бәя бирү, һичшиксез, китапның әһәмиятен тагын да күтәргән булыр иде. Дөрес, А. Г. Усманов «Кинзә Арсланов — Пугачевның көрәштәше» дигән мәкаләсендә моңа берникадәр тукталып үтә. («Исторические записки». 71 том, СССР Фәннәр Академиясе нәшрияты. Мәскәү. 1962. 114 бит). Ләкин ул да кайбер башкорт феодалларының, шул исәптән Кинзә Арслановның да, восстаниечеләр ягында торып чыгыш ясауларын аларның патша политикасыннан ризасызлыклары белән генә бәйләп күрсәтә.

Моңа кадәр чыккан хезмәтләрдә татар крестьяннарының Е. Пугачев восстаниесендә ничек катнашулары җитәрлек яктыртылмый иде. С. Алишев китабында бу хакта беренче мәртәбә тулы мәгълүмат бирелә. Ул хәзерге Татарстан территориясендә барган сугыш хәрәкәтләрен искиткеч дәрәҗәдә нечкәләп өйрәнгән һәм алар турында бик күп яңа материал туплаган. Хезмәт ахырында восстаниедә катнашкан татар авылларының зур исемлеге китерелә. Архив документларыннан күренгәнчә, Казан һәм Уфа янындагы хәрәкәтләрдә 85 меңгә якын татар крестьяннары катнаша. Дүртиле авылында, мәсәлән, өчәр һәм дүртәр йөз кешедән, Көлкәмәр авылында бишәр йөз кешедән, Богородское авылында сигез йөз кешедән торган сугышчан отрядлар була.

Хезмәт белән танышканда, тагын бер яңалык күзгә ташлана. Моңа кадәр чыккан хезмәтләрдә восстаниедә катнашкан татар командирлары, аларның кем булулары, фамилияләре, кай җирләрдә сугышулары турында мәгълүматлар аз очрый иде. С. Алишев китабында алар хакында бик күп кызыклы материаллар тупланган. Мәсәлән, анда восстаниедә катнашкан татар командирларының, Пугачев полковникларының исемлеге бирелә. Китаптан күренгәнчә, сугыш хәрәкәтләре белән Татарстан территориясендә генә дә алтмыш җиде татар командиры җитәкчелек иткән. (196—197 битләр.) Автор восстаниенең күренекле җитәкчеләре Мәсъгут Гомәров, Бәхтияр Канкаев, Аит Уразметов, Осип Енгалычев, Канзафар Усаев, Әбҗәлил Сөләйманов, Каранай Муратов һәм башкалар турында

кызыклы документлар китерә, аларның эшчәнлеге, оста хәрби җитәкче булулары турында яза. (Бәхтияр Канкаевның һәм Мәсъгут Гомәровның художник Б. Әльменов тарафыннан эшләнгән портретларын бирү китапны тагын да матурлый төшкән.)

Автор моңа кадәр чыккан хезмәтләргә дөрес бәя бирә, алардан тәнкыйть күзлеге аша карап файдалана. Шул ук вакытта ул Пугачев штабында татар телендә язылган приказларны, өндәмәләрне, указларны һәм башка документларны беренче булып фәнни әйләнешкә кертә, беренче мәртәбә рус теленә тәрҗемә итеп, дөньяга чыгара. Елга кичүләрен саклау турындагы бер приказны тулысы белән китерәбез:

«Полковник Бәхтияр Канкаев углыннан бирелде приказ. Син, керәшен Герачим Сабай углына. Чистай кичүенә һәм кичү әһелләренең үзләренә. Әүвәл Кичек авылына янә Тәрбирде Чаллысына янә Букәш авылына янә Чураш авылына янә Казаклар авылына янә Сатылган авылына янә Мукшы авылына янә Чаллы Башына һәрвакытта даимчелек илән ун-унбиш кеше тотмак үзләренә. Кичүдә ошбу эш тапшырылды. Кичек авылының Мәнди Тукташ углына һәрвакытта яхшыдин һәм ямандин хәбәре булса югарыда язылган Герачимга репортаватъ итмәгә. Бу мәскүр югарыдагы язылган сигез авыл җәмәгатьләрини поход сорап һичкем рәнҗетмәгәй. Ошбу мәскүр кичү боердык. Атланганнары булта һәм кайтарырга һәр көн элгәре анларны кеше сорап рәнҗетмәскә». (211—212 битләр.)

Татар телендәге менә шундый документларга таянып, автор Е. И. Пугачев хәрәкәтенең яңа битләрен ача. Әлбәттә, С. Алишев тапкан барлык документларны татар һәм рус телләрендә аерым китап итеп чыгару файдалы булыр иде. Ул чорларда башкорт, кыргыз һәм башка мөселман халыкларына адресланган барлык эш кәгазьләренең татар телендә язылганын исәпкә алсак, мондый китапның (документлар җыентыгының) кирәклеге ачык аңлашылыр.

Билгеле, хезмәттә киңәйтәсе, ачыклыйсы төшәсе мәсьәләләр дә бар. Шуларның берсе Гобәйдула Әмиров турындагы материаллар. Ул Пугачев восстаниесендә катнаша, восстание җиңелгәннән соң, Бохарага, аннан Һиндстанга китә. Г. Әмиров Һиндстанда утыз елга якын яши һәм бу ил турында, аның шәһәрләре, өлкәләре турында бик бай материал язып калдыра. Аның кульязмалары Һиндстанны өйрәнүчеләр өчен ифрат кыйммәтле һәм әһәмиятле чыганак булып санала. С. Алишев китабында бу кешегә киңрәк урын бирелсә дә, начар булмас иде. Унсигезенче гасырдагы татар, һөнәрчеләре турында да шул ук сүзләрне кабатлыйсы килә. Моңа кадәрге әдәбиятта бу турыда бер нәрсә дә әйтелми. С. Алишев үзенең китабында Канкаев боерыгы буенча И. Әюповның дары ясавы, Терси авылы кешеләренең корал ясап Урта Азиягә сатулары турында яза. Димәк, унсигезенче гасырда һәм әле аңа кадәр үк татарлар арасында төрле әйберләр ясаучы оста һөнәрчеләр булган. Менә боларны һәрьяктан җентекләп өйрәнү галимнәребезнең кичектергесез бурычы.

«Пугачев „восстаниесендә Урта Идел буе татарлары» дигән китап киң катлау укучылар өчен чыгарылган. Ә тиражы нибары мең данә. Табигый, ул китап кибетләренә чыгуга сатылып та бетте. Әгәр нәшриятыбыз, татар теленә тәрҗемә иттереп, зуррак тираж белән аның яңа басмасын чыгарса, бик шәп булыр иде.

Җыеп әйткәндә, С. Х. Алишев монографиясенең дөньяга чыгуын без хуп күрәбез һәм тарихи хезмәтләр арасында ул тиешле урын алыр дип ышанабыз.

**Р. НӘФИКОВ,**
тарих фәннәре докторы, профессор.
**М. МӨЛЕКОВ,**
тарих фәннәре кандидаты.

# УКУЧЫЛАР СҮЗЕ

*Журналыбызның узган елгы 8—12 саннарында өлкән әдибебез Шәйхи Маннурның «Агымсуларга карап» исемле повесте басылган иде. Редакциягә килгән хатларга караганда, бу әсәрне журнал укучылары көтеп алып, кызыксынып укыганнар. Түбәндә шул күп санлы хатларның берничәсен урнаштырабыз.*

Шәйхи Маннур ага!

Чистай дусларыгызның берсе Әсгать Юсуповтан бу хат. Күп сәлам үзегезгә! «Агымсуларга карап»ны укыгач, тукта, мин әйтәм, мин дә бит чорның гиганты булган ул төзелешнең актив катнашчысы идем, үзем әле Чистайныкы да, дәшми калу килешмәс, дидем.

Тик шунысы бар, мин ГЭСта түгел, ә «Запорожсталь»дә, бетон салу белән Союзда дан тоткан Хәйруллин бригадасында идем. «Запорожсталь»нең котлованын казудан башлап, бетон белән тутырганга кадәр генә түгел, арматур эшләрендә дә катнаштык. Беренче бишьеллыкның комплекслы олы төзелеше иде ул «Запорожсталь»: домналары, мартеннары, Шамот заводы прокат корпуслары, тагын ниләр генә юк иде анда! Без бетон салганга кадәр казыган котлованның күләменә күз салсаң, хәзер баш җитмәслек: төбеннән өскә кадәр дүртәр кат киштәләп, югарыга балчык ташлау — бар да көрәк белән! Сезгә бетонны «кукушка» ташыган, ә без аны үзебез таш ватып, цементны да тачкалар белән ташып, үзебез ясап, кул белән сала идек. Күрәсең, «кукушка»лар күп булмагандыр. Хәзерге заман техникасы белән эшләүне чагыштырсаң, адәм ышанмаслык эш бит! Шулай да бишьеллык дүрт елда үтәлде. Безнең күкрәкләргә «Ударник первой пятилетки» дигән ул вакытның шактый зур даны булган значокларны юкка гына такмадылар бугай!

Сез Сәгъдиевне кызык итеп искә аласыз. Мин эшләгәндә күп тиражлы газета татар телендә дә чыга һәм ул шуның редакторы иде. Бер заман үзебезнең бригаданың уңышлары турында бер хәбәр язган идем мин аңа, үз белдегем белән генә. Килеп тә чыкты бу минем янга шунда ук. Ничек һәм ниндирәк материаллар туплап җибәрү кирәклеген өйрәтеп китте. Аларны да үтәдем мин. Шуннан үз янына эшләргә чакыра бу. Карасаң, үз урынына калдырырга чамалаган икән ул мине. Бөтен эшен үземә йөкләп калдырганын сизми дә калдым дисәм, һич ялгыш булмас. Минем бит белем бик сай. 4 еллык белемнең яртысын 1917 нче елга кадәр мулладан, яртысын революциядән соң совет мөгаллименнән алган идем. Шуның белән редактор булып кара инде менә.

Ләкин мин иптәш Сәгъдиевнең миңа ясаган уңай йогынтысын һич тә исәптән чыгарып ташлый алмыйм. Ул башта мине үз газетасына хәбәрләр язарга өйрәтте. Аннары Мәскәүдә татарча чыга торган «Эшче» газетасының хәбәрчесе итте. Авылга әйләнеп кайткач та яздым мин аңа, газета ябылганга кадәр аның актив хәбәрчесе булдым. Сәгъдиев миңа очерклар, хикәяләр язарга куша, өйрәтә, уңышсыз булса, югалып калмаска өнди иде. «Эшче»дә «Чабаталы» имзасы белән чыккан фельетоннар минеке иде. «Атака»да «Утлы көннәр» повестем басылды. Әнә шундый башлангыч эшләрем өчен мин үземне Сәгъдиевкә һәр вакыт бурычлы саныйм. Әйбәт кеше иде ул.

Озак тормады, безнең дан тоткан бетончыларга да эш бетте. Күбесе Чистай егетләреннән торган бригада членнары өйләренә таралышты. Днепр төзелешенә әзме-күпме хезмәт өлеше кертеп, мин дә өйгә кайтып киттем. Эшчеләр арасында

«үсеп» кайткан кешене тиз күреп алдылар. Башта Вахитов исемендәге колхозның партячейка секретаре итеп сайладылар. Озак та үтмәде, райком үз аппаратына инструктор итеп алды. Аннан завкультпроп, икенче секретарь һ. б.

Анысын да әйтим, шулай эш арасында биш балабыз үсеп өлгергән. Миннән бер дә сорап тормыйча, югары белем алдылар да, Татарстанда берәве дә калмыйча, бөтен СССРга таралдылар: Ульяновск, Свердловск, Киев, Ставрополь, Владивосток — менә кайларда ул балакайлар хәзер.

Әле 21 январь көнне Мостай Кәримнең «Кыз урлау» спектаклен карарга карчык белән клубка барган идек. Аны уньеллык мәктәп укытучылары куйды. Кәлә-кәлә эч катып бетте. Иртән урамга чыксам, кешеләр үземне тәбрик итәләр: минем Приморьедагы Арсеньев шәһәрендә яшәүче малайның хатын Казан телестудиясеннән тапшырганнар. Ни Азат үзе әйтмәде язганын, ни студиядән хәбәр итмәгәннәр. Әрнедек ишетмәгәнгә. Без, картлар, шул балаларның эшләре, тормышлары белән рухланып яшибез ич. Шул Азаты инде конструкторлык бюросы начальнигы булып эшләгән җиреннән зур заводның партком секретаре итеп сайланган. «Әти, синең юлдан киттем, ахры» дип язган иде. КАИны бетерде ул. Төзүчеләр институтын тәгәлләп Уралга киткәне Свердловскиның бер заводында баш инженер. Боларны мактанып язуым түгел, Маннур ага. Совет хөкүмәте кемнәрне генә кеше итмәде! Колхоз төзелешенең башында булып, авыл хуҗалыгын үзгәртеп төзү чорында күргән авырлыкларның берсе дә бушка китмәвен хәзерге көндә үз күзең белән күрү нинди зур шатлык. Кулак һөҗүменнән дә читтә калмадым. Сәнәк белән чәнечтеләр, чак кына күзсез калмадым. Партия үзенең турылыклы улларын хур итми: картайгач та персональ пенсия билгеләп, тормышыбызны тәэмин итеп тора. Әле керәш фронтыннан читкә киткән юк. Үзем дә катнашырга тырышам, иптәшләр дә нагрузка белән «сыйлап» кына торалар. Халык контроле группаларында, стенгазета чыгаруда катнашам, иптәшләр суды председателе һ. б.— җитмәгәнмени?

Әсәрегезне йотылып укып чыктым, Маннур туган, рәхмәт яхшы эчтәлекле повестең өчен.

Кайнар сәлам белән **ӘСГАТЬ ЮСУПОВ.**

Арча районы, Яңа Кенәр авылы.

*
* *

Менә «Агымсуларга карап» белән дә аерылыштык. Ямансу булып китте. Әллә үземнең ата-бабаларымның үткәнен хәтерләткәнгә, авыл тормышы, булдыклы, гадел һәм тәвәккәл Пәрхулла абзый, ана назыннан мәхрүм булган нечкә күңелле Хөршит һәм Шәйхелисламнар бик тә якын һәм үз булып калдылар. Повесть халык сөйләменең матур үрнәкләре белән бизәлгән сокландыгыч тел белән агымсулардай салмак кына хикәя ителә. Уйландыра, дулкынландыра, күңелне кузгатып, әллә кайларга алып китә. Ул гаять җиңел һәм бер тын белән укыла. Аның исеме дә бик отышлы сайланган — моңлы бер җырдай яңгырап тора.

**Н. ЗАРИПОВА.**

Кукмара районы, Мәчкәрә авылы.

*
* *

Шәйхи абый!

Сезнең баштан үткәннәр минекенә дә бик охшый (әлбәттә, барысы да түгел). Ятим үсүләр, укуга булган зур теләк, азрак каләм тәбрәтергә сәләтлелек тә булу, 1921 елда ачлыктан качып «яңа җирләргә» китү һ. б. лар минем тормышта да күп булды.

**ГАПИЕТДИНОВА.**

Казан.

*
* *

Безгә, өлкән буын кешеләренә, «Агымсуларга карап» повестендагы вакыйгаларның бары да таныш, бары да кызык. Буялган, шомартылган, ялтыратылган бер нәрсә дә юк әсәрдә. Персонажлар, аларның һәр беренең шәхси үзенчәлекләре, холыклары бик дөрес, бик төгәл бирелгән.

**И. ҖӘЛИЛЕВ,**
Фрунзе шәһәре.

*
* *

Хөрмәтле олы язучыбыз Шәйхи Маннур!

«Агымсуларга карап» повестен мин тирән кызыксыну белән укып, Сезнең «Университетларыгыз» дип кабул иттем. Чыннан да шулай. А. М. Горькийның шул исемдәге китабы белән янәшә торырлык хезмәт. Бары тик заманнары гына азрак икенчерәк. Гаять тирән эчтәлекле, тәрбияви яктан бик әһәмиятле. Юлында очраган авырлык-кыенлыкларны, үтә алмаслык дип караган киртәләрне җимереп, алдыңа куйган изге бурычыңны үтәү өчен көрәштән бер дә чигенмәскә, кыю, көчле булырга өйрәтә.

Әсәр автобиографик. Әмма аны болай тар итеп чикләргә кирәкмәс. Чөнки анда туган ил тормышы, халык тормышы, аның кичерешләре, көрәше, искене җимереп, яңаны төзи башлавы бик ачык һәм тирән күрсәтелгән. Повестьта халыклар дуслыгы да матур сурәтләнгән.

Хатын-кыз, ана образы искиткеч шәп. Мин сезнең китапларны Г. Ибраһимов, М. Горький китаплары кебек үк яратып, кызыксынып укыйм. Чөнки сезнең китапларда ясалмалык, кемгә булса да ияреп кабатлау юк. Менә шуңа күрә ул тулысы белән йөрәккә барып тоташа һәм онытылмаслык булып күңелдә кала.

Сезгә сәламәтлек, корычтай ныклык, озын гомер, киләчәктә яңа әсәрләр бирүегезгә нык ышанып, укучыгыз

**САРА КИЛЬМЕТОВА,**
Казан.

# ГАБРОВО МӘЗӘКЛӘРЕ

*Алтыннан да кыйммәт торган май бирүче роза чәчәге үзәненең үзәге булган Казанлык шәһәрен үтеп, түбәсе болытлар белән капланган мәһабәт Шипка аша Габрово шәһәренә килеп керәсең. Габрово Балкан тауларының төньяк сөзәклегенә, Янтра елгасы буена урнашкан Болгария шәһәрләренең берсе. Ул промышленность үзәге. Тукыма, аяк киеме промышленностеннан тыш, тире иләү, металл эшкәртү, станоклар, инструментлар, электрон-исәпләү машиналары белән электрокар, электрофильтр бирүче дистәләгән завод-фабрикалар шәһәре ул.*

*Ләкин, болгар язучысы Радой Ралин әйтмешли, тукымасы белән планетадагы кешеләрне киендереп һәм башмаклары белән җир шары халкын тәэмин итеп бетерә алмаса да, Габрово бөтен кешелек дөньясын көлдерә алырлык тапкырлыкка ия булган шәһәр ул.*

*Чыннан да, габровлылар турында нәрсә генә сөйләмиләр. Янәсе:*

*...габровлылар өйләнгәндә нечкәрәк, ябыграк кызлар алырга тырышалар — чөнки андый кызларга өйдә урын да, кием-салым өчен материал да аз кирәк булачак;*

*...кибеттән әйбер алганда товарларын шул көнге газетага төреп бирүләрен таләп итәләр — шуның белән көндәлек матбугатка өстәмә акча түләүдән котылалар;*

*...торган бүлмәләренең стеналарын, түшәмнәрен беркайчан да агартмыйлар — имеш, акшарлау бүлмәне тарайта һәм тәбәнәкләндерә;*

*...тугач та песи балаларының койрыкларын кисәләр, янәсе, өйгә кергәндәге вакытны кыскартып, бүлмәдәге җылыны саклап калалар;*

*...ял көннәрендә сәгатьләрен туктаталар — бу сәгать эчендәге механизмнарның гомерен озайта;*

*...габровлылар туганнарына яки күршеләренә әҗәткә кавын, карбыз, бәрәңге кебек нәрсәләр бирмиләр: юка кабыклы урынына калын кабыклыны алудан куркалар;*

*...утка мөмкин чаклы экономия ясарга тырышалар, ут кирәк чакта гына яндырыла. Мәсәлән, кунак килә икән, ул чишенгәндә (киемен тиешле урынга элеп куйсын өчен), ашаганда (караңгыдан файдаланып артык ашап ташламасын өчен — бу аның сәламәтлегенә зыян) һәм аны озатканда (ялгыш хуҗаның киемнәрен киеп китмәсен өчен). Шул ук вакытта кунаклар да ут яндырылмаудан файдаланып чалбар, юбка кебек киемнәрен салып куялар (кырышылудан, тузудан саклыйлар);*

*...әмма тавык кетәгендә төне буе ут ягып торалар, янәсе, таң аткан дип белеп, тавыклар йомырка салырга тотынсыннар;*

*...урамдагы температура бүлмәнекенә караганда җылырак булса, тәрәзәләрен ачып, өйдәге салкын һаваны тышка чыгаралар, тыштагы җылыны өйгә кертәләр;*

*...парикмахерда кырынганнан соң биткә ягыла торган кершәнне һәм йөзгә сиптерелә торган одеколонны кәгазьгә төреп һәм шешәгә салдырып өйләренә алып кайталар, хатыннарына бирәләр һ. б. һ. б.*

*Бу мәзәкләр Габрово халкының йорт җанлыклы, булган әйберне саклап тотучан һәм саранрак булуларын күрсәтә. Дөрес, борынгы заманнардан ук ата-баба мирасы булып килгән бу сыйфатлар габровлыларның канына сеңгән. Ләкин бу сыйфатлар өчен алар бер дә кимсенмиләр, киресенчә, үзләре турында яңадан-яңа мәзәкләр чыгарып кына торалар һәм рәхәтләнеп сөйлиләр. Шушы мәзәкләр инде габровлыларның данын бөтен дөньяга тараткан да.*

*Габровлылар эш сөючән, намус белән яшәүче, тырыш һәм шул ук вакытта шаян күңелле, гаҗәеп тапкыр кешеләр.*

*Миңа рәттән соңгы ике елда Болгариядә булырга һәм һәр ике баруда да Габрово шәһәрендә тукталырга туры килде. Габровлыларның гаҗәеп тапкырлыгын чагылдырган шушы мәзәкләрне анда ишеткән идем. Габрово мәзәкләре бик күп телләрдә басылганнар. Шактыйлары аерым җыентык булып рус телендә дә чыгарылдылар. Түбәндә тәкъдим ителгән мәзәкләр асылда Габрово шәһәрендә габровлыларның үз авызларыннан, вагонда, пароходта, самолетта һәм автобусларда гидлар сөйләве буенча язылып алынды. Әлбәттә, сөйләгән вакытта габровлылар бу мәзәкләрне еш кына үзгәртәләр, үзләреннән өстиләр, эшкәртәләр. Шуңа күрә, ихтимал, аларның кайберләренең матбугатта басылган вариантларына туры килмәве дә мөмкин. Шул гаҗәеп мәзәкләрнең бер өлешен «Казан утлары» укучыларына тәкъдим итәм.*

**Ш. РАХМАНКУЛОВ.**

*
* *

Бер малай атасына ияреп базарга чыккан. Сатучы балага чикләвек бирергә теләп:

— Учларыңны тот. Хәзер үзеңне сыйлыйм, — дигән.

— Юк, атаемның учына салыгыз, — ди икән малай.

— Ник, чикләвек яратмыйсыңмыни? — дигәч:

— Яратам. Минекенә караганда атаемның учлары зуррак бит, — дип җавап биргән.

*
* *

— Әти, мин бүген өч стотинок[1] янга калдырдым...

— Яхшы иткәнсең, балам! Ничек акылың җитте соң?

— Иртә белән трамвайга утырмадым. Дәрескә соңга калмас өчен мәктәпкә хәтле аның артыннан чабып бардым...

— Аз гына хаталык ясагансың. Такси артыннан чабалар аны, акчаң күбрәк калыр иде...

*
* *

Мәктәп баласы трамвайда бара. Кондуктор аңардан:

— Ничәнче класста укыйсың? — дип сорый.

Бала:

— Бишенчедә, — ди.

— Яшең ничәдә?

— Җиде тулды, — дип җавап бирә малай, бу яшьтәге балалардан билет сорамауларын күздә тотып.

*
* *

Студент яшендәге бер егет бабасы янына килеп:

— Бабакай! Яңа мода кергән бит: бабалары оныкларына автомашина бүләк итәләр икән, — дип сүз башлаган.

Ә бабасы көрсенгән булып:

— И оныккаем, оныккаем, нигә аны элегрәк әйтмәдең. Ул мода бит Габрово шәһәреннән әле кичә генә чыгып китте... соңладың шул, балакаем! — дип җавап биргән.

*
* *

Бер егет үзе яратып йөргән кызына:

— Акыллым минем! Синең белән сөйләшү өчен матур сүзләр табуы авыр шул миңа. Чибәрлегең алдында каушап калам, — дигән.

— Ә син һөнәреңнең күпме табыш бирүе турында сөйлә, күп акча кыюлык ачкычы бирә ул. Җебеп торуга караганда ачкычың белән кочак йозагын ачарга тырыш, — дип җавап биргән кыз.

---

[1] Стотинок — тиен

* *

Бер кыз күңеле ятмаган егеттән котылу нияте белән аны үзләренә чакыра.

— Әти-әниләрем өйдә булмасалар, минем яныма керерсең, — ди. Егет аптырап:

— Мин аларның өйдә юклыкларын ничек белермен? — дип сорый.

— Бүлмәмнең тәрәзәсе янына килеп бас, алар өйдә булмасалар, мин тротуарга бер лев[1] көмеш акча ташлармын, син шул акчаны миңа керткән булырсың...

Караңгы төшкәч, егет килә. Акча ташлана. Егет эзләргә тотына. Куллары белән җирне сыпыра-сыпыра буялып бетә, әмма акчаны таба алмый. Бик озак вакыт үткәннән соң кыз тәрәзәсен ачып караса, чүгәләп, кайгыга батып утырган егетне күрә.

— Нишләп утырасың?

— Эзлим бит...

— Ә, эзлә-эзлә... Ул лев инде минем кесәмдә. Мин аны җепкә бәйләп ташладым да кире тартып алдым... Шулай, егет, моннан соң Габрово кызлары янына килгәндә акыл җыеп бара күр, — ди дә тәрәзәсен ябып куя.

*
* *

— Әби, бүген төшемдә синең миңа кечкенә шоколад биргәнеңне күрдем, — ди бер малай.

Әбисе:

— Гел шулай сүз тыңласаң, тәртипле һәм акыллы булсаң, төшеңдә әле зур шоколад биргәнемне дә күрерсең, — дип җавап бирә.

*
* *

— Әби, келәмне какканда мин бер стотинок таптым.

— Озаграк итеп, тузаны беткәнче каксаң, әллә нәрсәләр табарсың әле, кагуыңны дәвам ит.

*
* *

Габрово шәһәрендә яшәүче бер ханым кибеткә керә дә сатучыдан:

— Миңа кара тавык салган йомыркалардан бер илләне санап бирегез әле,— дип сорый.

Сатучы аптырап кала.

— Ул йомыркаларны нинди төстәге тавык салганлыгын мин ничек аерыйм... Үзегез белсәгез, карап алыгыз, — ди.

Ханым кәрзиндәге йомыркалардан иң эреләрен генә сайларга тотына.

*
* *

Урта яшьләрдәге өч габровлы ресторанга керә. Урын алганнан соң икесе кулларын юарга китәләр. Бу вакытта өченчесе менюдагы кыйммәтле ашларның һәм эчемлекләрнең исемнәрен сызып ташлый — янәсе, алар беткән. Иптәшләре килгәч:

---

[1] Лев — сум.

— Теләгән ашыгызны, яраткан эчемлекләрегезне сайлагыз, бу юлы мин сыйларга булдым, — ди.

*
* *

Габровлы София шәһәренә килә һәм гостиницада кунарга була.
— Кунган өчен күпме түләргә кирәк? — дип сорый ул.
— Беренче каттагы бер кешелек бүлмә 10 лев, икенче кат — 8, өченче — 6, дүртенчесе — 4, бишенче — 2 лев, ә алтынчы кат 50 стотинок, җиденче — 25, сигезенче — 10 стотинок, — дип аңлатып бирә администратор.
Габровлы уйлап тора-тора да китәргә җыена башлый.
— Нигә тукталмыйсыз, түләү бит артык югары түгел.
— Юк, түләү хаклары югары түгел, әмма гостиницагыз тәбәнәк. Мин тагы да югарырак катта йокларга гадәтләнгәнмен,— ди.

*
* *

Габровлы авылда яшәгән туганын үзенә кунакка чакыра һәм телефон аша ничек итеп очрашу турында аңлата.
— Абзыкай, сине үзем каршылый алмам, эшем тыгыз. Вокзалга хатыным төшәр. Сез бит әле беренче тапкыр очрашасыз, бер-берегезне белмисез. Үзеңне таныту өчен вагоннан төшкәндә сул кулыңда ике симез каз булсын, ә уң кулыңда, бер дә булмаганда, бик үк ябык булмаган сарык түше булса да ярар...

*
* *

Ике габровлы бәхәсләшеп чиркәүгә керәләр, янәсе, кем азрак сәдака бирә — шул җиңә. Беренче булып кем бирергә тиешлекне акча чөеп хәл итәләр. Күн ягы төшкәне : «Болай булгач мин җиндем» дип, кружкага бер стотинок ташлый. Икенчесе, кружка тоткан чиркәү әһеленә карап, җитди генә:
— Салынган стотинокны икебез өчен кабул итеп ал һәм догада бул, — ди.

*
* *

Габроводан ерак түгел бер шәһәрдә көлке кичәсе оештыралар. Артистлар чакырыла. Халык та күп җыйнала. Әмма кичә тамашачыларны канәгатьләндерми. Көлү генә түгел, тамашачылар елмаймыйлар да.
Кичә беткәннән соң артистлардан:
— Иртәгә кичәгезне кайсы шәһәрдә күрсәтәсез? — дип сорыйлар. Алар:
— Габровода,— дип җавап бирәләр.
— Анда да шул ук программамы?
— Әйе.
Тамашачыларның йөзләре ачылып китә, шатлыклары эчләренә сыймый башлый.
— Бик шәп! Габровлыларга шулай кирәк,— дип куаналар.

*
* *

Бер габровлының теше сызлый һәм аны алдыртырга дип, кичкә таба врачка килә.

— Бер тешне суырганга 2 лев, электр энергиясе өчен 1 лев түләгез, — ди врач.

— Яхшы, ул чакта мин иртәгә көндез электр энергиясе кирәк булмаганда килермен, — ди габровлы.

*
* *

Кушылып, ике күрше ишәк сатып алалар.

— Кайсы як яртысы синеке?

— Баш ягы, — ди һич тә уйлап тормыйча икенчесе.

— Яхшы, — диде беренчесе, ишәк койрыгына кунган чебенне куып: — Мин үз ягымдагы эшне бетердем. Хәзер син базарга бар да ашарына алып кайт. Ашатканнан соң абзарга ябып куярсың.

*
* *

Бер габровлының телевизоры ватыла — күрсәтүен күрсәтә, ә тавыш юк.

— Хатын, — ди ул, — күршеләрдә телевизор карап утыралар, бар әле, кереп әйт, тавышын катырак куйсыннар.

*
* *

Бер сәүдәгәр кибете өчен художникка арыслан төшкән вывеска ясатырга була.

— Сезгә ничек ясарга: бәйләнмәгән яки бәйләнеп куелган арыслан булсынмы? Бәйләнгәне 200 лев, бәйләнмәгәне 100 лев тора, — ди художник.

Вывеска эшләнә һәм шул ук көнне эленеп тә куела. Төнлә каты яңгыр ява. Иртәгесен сәүдәгәр кибетен ачыйм дип барса, вывескадагы буяу юылып арыслан сурәтенең югалганын күрә һәм шунда ук художникка китә.

— Сез бит үзегез бәйләнмәгәнне ясарга куштыгыз. Әгәр дә бәйләп куелган арыслан ясатсагыз, ул качмас иде, чөнки анысы майлы буяу белән ясала, — ди художник.

*
* *

Габровода яшәүче бер ханым урамда таныш врачын очрата һәм шуннан файдаланып бушлай рецепт яздырып алырга уйлый.

— Хөрмәтле доктор, бу көннәрдә үземне начар хис итәм: башым да әйләнә, аппетит та начар... Зинһар өчен, рецепт кына язып бирегезче.

— Рәхим итеп чишенегез, мин сезне карармын, — ди врач.

*
* *

Урман карауччысы бер браконьер-габровлыны тота. Акт төзеп штраф алырга уйлый. Әмма гаепле бик үтенеп сорагач, бу юлга акт төземи кала. Габровлы яхшылыгы өчен урман каравылчысын кунакка чакыра. Кичтән алып таңга чаклы эчәләр-ашыйлар, ашыйлар-эчәләр.

Кунакны озатканда габровлы:

— Кара әле, начальник! Яңадан тотылсам, зинһар өчен, өстемнән акт язып штраф ала күр,— ди.

*
* *

Озын гына тар күпернең уртасында ике габровлы — шофер очраша. Бензин әрәм итәселәре килми, берсе дә артка чигенми. Берсе газет ала да укырга тотына, янәсе, тегесе көтеп торыр-торыр да машинасын артка чигендерер. Әмма шоферның икенчесе дә кабинасыннан чыга һәм капот өстенә менеп утыра.

— Кара әле, коллега! Үзең укып бетергәч, газетыңны миңа бирерсең әле, мин дә укырмын,— ди ул иптәшенә карап.

*
* *

Габровода торучы берәүгә кунак килгәч, хуҗа хатыны иртәнге чәйгә бер йомырка пешерә. Кунак ашаганда кечкенә баласы аннан күзен алмый карап тора. Анасы:

— Кеше ашаганны карап торма, балам... Ул абый буйвол түгел лә... бер йомырканы ашап бетермәс, сиңа да калыр әле, — дип, баласын юаткан була.

*
* *

Бик авыр хәлдәге авыру, врач киңәше буенча, үз шәһәренә, өенә кайтырга уйлый. Һәр станциядә көч-хәл белән генә төшеп, алдагы станциягә хәтле генә билет ала. Купеда баручы пассажирлар:

— Нигә сез турыдан-туры Габровога чаклы билет алмыйсыз, — дип сорыйлар. Ул аларга:

— Ә мин Габровога җиткәнче юлда үлеп калсам? — ди.

*
* *

Ике сәүдәгәр: берсе Габроводан, икенчесе Казанлыктан Тырново шәһәренә барырга җәяүләп юлга чыгалар. Шәһәрдән бер-ике километр чамасы киткәч, габровлы:

— Кара әле, другар [1]. Миңа бурычка 50 лев акча биреп тормассыңмы. Тырновога барып җиткәч тә түләр идем,— ди.

— Бирүен бирермен, тик... ышанычлы булсын өчен заклад төсендә бирәр нәрсә бирмәссеңме? — ди иптәше.

— Менә сиңа чемоданым, аның эчендә 100 левлык товар.

Габровлы 50 левны ала, иптәшенә чемоданын бирә.

Тырново шәһәренең базар чатына килеп җиткәч тә габровлы:

— Менә бурычымны түлим, 50 лев акчаңны ал да чемоданымны бир, — ди.

*
* *

Чит илдән килгән бер кешене Габрово больницасына китерәләр һәм аңа ашыгыч ярдәм күрсәтеп кан бирәләр.

Беренче тапкыр кан җибәргәч, авыру донорга бик зур рәхмәт әйтә һәм 25 лев бирергә була, икенче тапкырында рәхмәтен әйтеп-нитеп тормый, теләр-теләмәс кенә:

— Ярар инде, ун лев бирермен, — ди.

Ә инде өченче тапкыр кан алгач, донорга күтәрелеп тә карамый, акча да тәкъдим итми. Чөнки бу вакытта аның тамырлары габровлы каны белән тулган була.

---

[1] Другар — иптәш дигән сүз.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ ПАРТИЯ ҖЫЕЛЫШЫ

Татарстан язучылар союзы партия оешмасы әледән-әле коммунист язучыларның иҗат отчетларын тыңлап тора. Шундый җыелышларның тагын берсе шушы елның 26 мартында Габдулла Тукай исемендәге клубта уздырылды. Ул Г. Паушкин белән Б. Камаловлар иҗатына багышланган иде.

Җыелышта катнашучылар филология фәннәре кандидаты В. Воздвиженскийның Г. Паушкин иҗаты һәм язучы Х. Сарьянның Б. Камалов иҗаты турындагы докладларын тыңладылар. Г. Паушкин һәм Б. Камалов иҗатлары турында фикер алышуда Н. Дәүли, Т. Журавлев, Г. Ахунов, В. Монасыйповлар катнашты. Докладчылар да, чыгыш ясаучылар да һәр ике коммунистның иҗат активлыгын, заманның актуаль мәсьәләләре, бүгенге тормыш белән якыннан кызыксынып яшәүләрен билгеләп үттеләр, алар иҗатында очраган аерым кимчелекләргә тукталдылар.

Г. Паушкин һәм Б. Камалов каләмдәш дусларын үзләренең иҗат планнары белән таныштырдылар, изге теләкләре, файдалы киңәшләре өчен докладчыларга һәм чыгыш ясаучыларга рәхмәт хисләрен белдерделәр.

## ЖУРНАЛ ТИКШЕРҮ

Татарстан язучылар союзы идарәсенең 3 апрельдә уздырылган утырышында «Казан утлары» журналының 1973 елгы 7—12 саннарында басылган материаллар тикшерелде.

Журналда басылган проза әсәрләре турында Г. Шәрәфетдинов, шагыйрьләр иҗаты турында Ә. Баянов, әдәби тәнкыйть һәм рецензияләр турында М. Госманов, очерклар турында Р. Нуруллина сөйләде. Докладлар нигездә төпле һәм тирән фикерле, кыю һәм туры сүзле булды. Докладчыларның барысы да диярлек журналда басылган әсәрләргә зур, җитди таләпләр югарылыгыннан торып бәя бирделәр.

Фикер алышуларда Н. Дәүли, Р. Ишморат, Г. Кашшаф һәм башка иптәшләр катнашты. Алар докладларда кузгатылган мәсьәләләрне тагын да ачыклый һәм тирәнәйтә төштеләр, докладчыларның аерым фикерләре белән бәхәскә керделәр.

Ахырдан журналның баш редакторы Г. Ахунов чыгыш ясады. Ул язучылар җәмәгатьчелеген журнал редакциясенең эш планнары белән таныштырды, «Казан утлары» журналы һәм барлык язучылар алдында торган бурычлар турында сөйләде.

## БЕРЛӘШМӘ ҖИТӘКЧЕЛӘРЕ СЕМИНАРЫ

Апрель башларында Татарстан язучылар союзы идарәсе республикабызның төрле район һәм шәһәрләрендә эшләп килгән әдәби берләшмә җитәкчеләренең ике көнлек семинарын үткәрде.

Семинарны, кыскача кереш сүз сөйләп, Язучылар союзы идарәсенең председатель урынбасары Г. Кашшаф ачты. Берләшмә җитәкчеләре алдында язучылардан Н. Исәнбәт, Х. Туфан, С. Хәким, Т. Журавлев, Г. Паушкин, Р. Мостафин, Х. Сарьян, Т. Миңнуллин, Ю. Белостоцкий, Татарстан язучылар союзы идарәсенең җаваплы секретаре Р. Фәйзуллин, «Казан утлары» журналының баш редакторы Г. Ахунов, «Идел» альманахының редакторы Ф. Шәфигуллин, Татарстан китап нәшриятының яшьләр-балалар редакциясе мөдире Ш. Рәкыйповлар чыгыш ясады. Алар иҗат тәҗрибәләре белән уртаклаштылар, яшь язучыларны тәрбияләү буенча әдәби берләшмәләр алдында торган бурычлар турында сөйләделәр. Җ. Рәхимов, И. Винокуров, М. Лукин, М. Вәлиев семинарда катнашучыларны үзләре җитәкчелек иткән берләшмәләрнең эше белән таныштырдылар.

Берләшмә җитәкчеләре «Казан утлары» журналын тикшерүгә багышланган җыелышта да катнаштылар, Казан университеты студентлары көче белән оештырылган әдәби-музыкаль кичәдә булдылар.

## КамАЗда ӘДӘБИ КОНКУРС

Республикабыз промышленность предприятиеләре, колхозлары һәм совхозлары белән Татарстан язучылар союзының иҗади элемтәсе ныгытканнан-ныгый бара. Әле күптән түгел генә әсәрләрендә бүгенге авыл кешесе образын калку итеп гәүдәләндерүче язучыларыбыз Вакыйф Нуруллин пәм Хәниф Хәйруллин Питрәч районы Вахитов исемендәге колхоз премиясенә лаек булганнар иде.

Быел да иң яхшы әсәрләргә смотр-конкурслар үткәрү турында Язучылар союзы белән промышленность оешмалары һәм колхозлар арасында иҗади килешүләр төзелде. Шуларның иң әһәмиятлесе — тугызынчы бишьеллыкның зур гиганты булган Кама автозаводын төзүче «Камгэсэнергострой» производство берләшмәсе игълан иткән смотр-конкурс.

Күптән түгел берләшмә парткомы һәм постройкомының берләштерелгән утыры-

шында смотр-конкурс шартларын раслаган карар кабул ителде. Конкурс шартлары буенча «Камгэсэнергострой» производство берләшмәсе Татарстан язучылары тарафыннан Кама автомобиль заводын һәм Чаллы шәһәрен төзүче хезмәт иияләре, тугызынчы бишьеллык алдынгылары турында иҗат ителгән иң яхшы әдәби әсәрләргә беренче дәрәҗә бер премия, икенче дәрәҗә ике премия һәм өченче дәрәҗә ике премия булдырырга карар кылды.

КамАЗчылар игълан иткән бу смотр-конкурста катнашу өчен Татарстан язучылар союзы автогигант турында иҗат ителгән яңа әсәрләр тәкъдим итте. Алар арасында Ә. Баяновның «Ут һәм Су» романы, Р. Мингалимовның «Күз карасы» поэмасы, Э. Касыймовның яңа хикәяләре һәм очерклары, М. Газизовның шигырьләр циклы һәм Чаллыда яшәүче рус шагыйрьләренең әсәрләре бар.

## ИҖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ

Март-апрель айларында Татарстан язучылар союзы каршындагы иҗат секцияләренең отчет-сайлау җыелышлары булып узды. Ул җыелышларда татар әдәбиятындагы аерым жанрларның торышына төпле анализ ясалды, язучылар коллективы алдында торган актуаль мәсьәләләр күтәрелде, секция бюроларының яңа составлары сайланды.

Шагыйрьләр секциясенең отчет-сайлау җыелышы 5 апрельдә язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында үткәрелде. Бюро председателе Х. Туфан җыелышта катнашучыларны соңгы елларда дөнья күргән поэзия әсәрләре белән таныштырды. Доклад буенча фикер алышуларда С. Хәким, Г. Латыйп, Ә. Баянов, Р. Фәйзуллин, Р. Мингалимов һәм башка шагыйрьләр катнашты.

Шагыйрьләр секциясенең яңа составына сигез кеше (Х. Туфан, И. Юзеев, Ә. Баянов, Г. Рәхим, Р. Мингалимов, Р. Гатауллин, Зөлфәт, Г. Садә) кертелде. Бюроның председателе итеп И. Юзеев сайланды.

* * *

Проза секциясенең 8 апрельдә уздырылган утырышында бюро председателе Б. Камаловның отчеты тыңланды. Аннан проза секциясенең эше, проза әдәбиятына караган мәсьәләләр буенча сөйләшү башланып китте. Фикер алышуларда Г. Кашшаф, Г. Бәширов, Г. Ахунов, Р. Фәйзуллин, Х. Сарьян, М. Хәмитов, М. Хәбибуллиннар катнашты. Алар секция бюросының эшенә уңай бәя бирделәр, киләчәктә секциянең эшен тагын да җанландыру буенча конкрет тәкъдимнәр керттеләр.

Утырыш А. Расих, Б. Камалов, М. Мәһдиев, Х. Сарьян, Ф. Мансуров, К. Тимбикова, Ә. Гаффаровларны кертеп, бюроның яңа составын сайлады.

* * *

Тагын бер көннән балалар әдәбияты секциясенең дә отчет-сайлау утырышы булды. Секция председателе Р. Мингалимов бюроның отчет чорындагы эшчәнлеге турында сөйләде, балалар өчен чыккан китапларга анализ ясады. Утырышта Г. Бакиров, Ә. Бикчәнтәева, Н. Гайсин, Ш. Галиев, Р. Фәйзуллин, Ш. Рәкыйпов, Х. Сарьян, Р. Хафизова, Г. Хәсәнов, В. Монасыйпов, М. Мазунов һәм башкалар чыгыш ясады.

Бюроның яңа составына Г. Гобәй, Л. Ихсанова, Ш. Галиев, Ш. Рәкыйпов, Х. Халиков кертелде. Бюро председателе итеп Л. Ихсанова билгеләнде.

## «КАЗАН ЯЗЫ»

Апрель аенда башкалабыз Казан клубларында, культура сарайларында «Казан язы» дигән әдәби-музыкаль кичәләр булып үтте. Татарстан язучылар союзының матур әдәбиятны пропагандалау бюросы оештырган ул кичәләрдә бик күп танылган язучылар һәм артистлар катнашты.

Беренче кичә 3 апрельдә мехчыларның культура сараенда үткәрелде. Мехкомбинат эшчеләре каршында С. Хәким, Г. Ахунов, И. Юзеев, Р. Фәйзуллин, М. Мәһдиев, Т. Миннуллин, В. Нуруллин, М. Хәбибуллиннар чыгыш ясады.

5 апрельдә республикабыз язучылары сәүдә хезмәткәрләре клубында чыгыш ясадылар. Матур әдәбият сөючеләр белән очрашуда Г. Паушкин, Р. Фәйзуллин, Р. Мостафин, М. Мәһдиев, Т. Миннуллин, Г. Рәхим, В. Нуруллин, Р. Мингалимовлар катнашты.

8 апрельдә язучыларны шәһәребезнең Киров районы хезмәт иияләре кунакка чакырды. Татарстанның Х еллыгы исемендәге культура сараенда уздырылган кичәдә Р. Фәйзуллин, М. Мәһдиев, Г. Рәхим, В. Нуруллин, Р. Мингалимов һәм М. Газар чыгыш ясады.

Шундый кичәләр төзүчеләр культура сараенда, «Спартак» комбинатының культура сараенда, җитен комбинатында, Урицкий исемендәге клубта һәм башка урыннарда үткәрелде.

## УКУЧЫЛАР КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

Ш. Маннурның «Агымсуларга карап» повестен Тулбай авылы халкы көтеп алды. Әдипнең бала чагы шушы авылда үтә. Авылның әсәрдә чагылыш тапкан үткәне гаять оста бирелгән, дип сөйли өлкән яшьтәгеләр. Повестьны яше дә, карты да яратып укыды. Яшьләр ата-бабаларының элеккеге тормышлары, ә өлкән яшьтәгеләр үзләренең авыр яшьлекләре белән очрашкан кебек булдылар. Авыл китапханәсендә Ш. Маннурның яңа әсәре буенча укучылар конференциясе уздырылды.

Икенче конференция Олыяз авылында үткәрелде. Конференциядә роман авторы Ш. Маннур һәм «Казан утлары» журналының баш редакторы, прозаик Г. Ахунов катнашты.

## «ЯШЬ ЛЕНИНЧЫ»НЫҢ 50 ЕЛЛЫГЫН КАРШЫЛАП

1974 елның октябрь аенда республикабызның балалар газетасы «Яшь ленинчы»ның чыга башлавына 50 ел тула. Әлеге

юбилейга хәзерлек уңаеннан, газета редакциясе республика мәктәпләрендә укучылар конференцияләре үткәрә башлады.

Шундый беренче конференция март ахырларында республикабызның Саба районында уздырылды. Районның төрле мәктәпләреннән җыелган пионерлар каршында шагыйрь Ш. Галиев һәм Р. Миннуллиннар чыгыш ясады.

* * *

Арча районында уздырылган икенче конференциядә Г. Тукай премиясе лауреатлары С. Хәким, Г. Ахунов, Ш. Галиев, М. Җәлил премиясе лауреаты И. Юзеев, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, скульптор Б. Урманче һәм «Яшь ленинчы» газетасының редакторы В. Ихсанова, газетаның мәктәп бүлеге мөдире И. Сәмигуллина катнашты. Алар районның төрле мәктәпләреннән килгән пионерлар алдында чыгыш ясадылар, педагогия училищесы укучылары белән очраштылар.

## ДУСЛЫК ХИСЛӘРЕ

Күренекле язучыбыз А. Расих, Ашхабадта булып, төркмән халык язучысы, Социалистик Хезмәт Герое Берды Кербабаевка 80 яшь тулуга багышланган тантанада катнашты. Ул юбилярны Татарстан язучылары исеменнән котлады, аңа истәлек бүләкләре тапшырды.

## ТРАДИЦИОН ФЕСТИВАЛЬ

Һәр елның апрель аенда республикабыз башкаласы Казанда бөек юлбашчыбыз Владимир Ильич Ленинның туган көненә багышланган музыкаль фестивальләр үткәрелеп килә.

1974 елгы уникенче фестиваль РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, РСФСР дәүләт премиясе лауреаты, Венада һәм Прагада үткәрелгән Халыкара конкурслар лауреаты, дирижер һәм композитор Мурад Кажлаевның иҗат кичәсе белән башланып китте. Тамашачылар бу көнне «Тау кызы» балетыннан өзекләр, Рәсүл Гамзатов шигырьләренә язылган җырлар, гитара һәм оркестр өчен симфо-джаз новеллалар тыңладылар. Концертта Дагстан АССР радио һәм телевидениесенең Темирлан Джандаров җитәкчелегендәге концерт ансамбле, ТАССР дәүләт симфоник оркестры, Халыкара һәм бөтен Союз конкурслары лауреаты Леонид Сметанников, ССР Союзы Зур театры артисткасы Галина Дебинская, Халыкара конкурслар лауреаты Николай Громин, Москонцерт солисткасы Татьяна Дасковскаялар катнашты.

Соңгы еллардагы фестивальләр ТАССРның дәүләт симфоник оркестрыннан башка узмый. Быелгы концертларда бу оркестр күренекле совет композиторларының күп кенә яңа әсәрләрен башкарды. Оркестр белән СССРның халык артисты Натан Рахлин, РСФСРның халык артисты Фоат Мансуров, Филиппиннан килгән кунагыбыз Родентор Ромеро дирижерлык итте.

Казан тамашачылары Пятницкий исемендәге Хезмәт Кызыл Байрагы орденлы дәүләт академия рус халык хоры чыгышларын аеруча яратып тыңладылар. Мәшһүр коллективның беренче концерты 24 апрельдә В. И. Ленин исемендәге культура сараенда булды.

Фестиваль 28 апрельдә Спорт сараенда сәнгать осталарының зур концерты белән тәмамланды. Тамашачылар бу көнне РСФСРның халык артисткасы Венера Шәрипова, РСФСРның атказанган артисты Илһам Шакиров, ТАССРның халык артисткасы Әлфия Афзалова, җырчылар Зиннур Нурмөхәммәтов, Флера Сөләйманова, нәфис сүз остасы Фәйзи Юсупов һәм башка татар артистлары белән очраштылар.

## САМАТ ШАКИРГА 50 ЯШЬ

Күпләгән шигырь китаплары, Бөек Ватан сугышы геройларына багышланган мәкалә, очерклары белән укучыларга яхшы таныш язучыбыз Самат Шакирга 15 апрельдә 50 яшь тулды. Шул уңай белән республикабыз газета-журналларында язучының яңа әсәрләре басылды, телевидение һәм радио аша аның иҗатына багышланган тапшырулар яңгырады.

Совет әдәбияты өлкәсендәге хезмәтләре өчен һәм 50 яшь тулу уңае белән, язучы Самат Фәтхерахман улы Шакиров (Самат Шакир) КПСС өлкә комитеты һәм Татарстан АССР Министрлар Советының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМ

Филология фәннәре өлкәсендәге зур хезмәтләре һәм озак еллык педагоглык эшчәнлеге өчен Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре, филология фәннәре докторы, профессор Мөхәммәт Хәйрулла улы Гайнуллинга **РСФСРның атказанган фән эшлеклесе** дигән мактаулы исем бирелде.

## ХЕЗМӘТКӘ ХӨРМӘТ

Совет кинематографиясендә актив һәм нәтиҗәле эшләүләре өчен һәм Татарстан киносының 50 еллыгы уңае белән Казан кинохроника студиясенең кинооператоры Вил Кәрим улы Аллабирдин, студиянең директоры Анатолий Николаевич Краев, студиянең төгәл аппаратуралар мастеры Виктор Сергеевич Семиков, студиянең тавыш операторы Ася Павловна Храмова КПСС өлкә комитеты һәм ТАССР Министрлар Советының **Мактау грамоталары** белән бүләкләнделәр.

## ЯҢА СПЕКТАКЛЬЛӘР

Г. Камал исемендәге Ленин орденлы татар дәүләт академия театры тамашачыларга Хәй Вахитның «Давыл» исемле әсәре буенча эшләнгән яңа спектакль күрсәтә башлады.

Водолазлар тормышын, аларның табигать көчләренә каршы көрәшен чагылдырган бу драманы сәхнәгә Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Празат

Исәнбәт куйган. Художнигы — Татарстан АССРның халык художнигы Мәэмүн Сутюшев.

Спектакльдә рольләрне РСФСРның һәм ТАССРның халык артистлары Ф. Халитов, Ш. Биктимеров, РСФСРның атказанган артисткасы В. Минкина, ТАССРның халык артистлары Г. Надрюков, Ш. Әсфәндиярова, Р. Хәйретдинова, ТАССРның атказанган артисты Ә. Шакиров, артистлар И. Йоматолов, Ф. Хәйруллина, Ф. Әхтәмова, И. Баһманов, И. Вәлиев, Ш. Галиуллиннар башкара.

* * *

Казан дәүләт курчак театры быелгы сезонда үзенең икенче премьерасын әзерләде. Чехословакия драматургы Йозеф Кайнарның чех халык иҗаты мотивларына нигезләп язылган «Златовласка» («Алтынчәч») әкияте буенча куелган спектакльне балалар яратып кабул итте.

Пьесада Яхшылык һәм Яманлык корольләренең көрәше, батыр егет Иржик һәм Златовласка образлары аша хезмәт кешесенең бөеклеге, аның җәнлекләргә һәм кешеләргә яхшы мөнәсәбәте, бөтен авырлыкларны җиңеп чыгарга сәләтле икәнлеге сурәтләнә. Батыр һәм тапкыр егет Иржик, Яманлык короленең бөтен мәкерләрен җимереп, гүзәл кыз Златовласкага өйләнә.

Спектакльнең режиссеры Людмила Рабинович, художнигы Михаил Эльберг. Төп рольләрне Татарстанның атказанган артисткасы Вера Третьякова, Геннадий Вишняков, Гәүһәр Игошина, Рәшидә Утяева, Нажия һәм Анатолий Шестопаловлар башкара.

## ҖЫРЧЫ ИСТӘЛЕГЕНӘ БАГЫШЛАП

5 апрельдә Казан шәһәренең Актерлар йортында Татарстанның халык артисты Рәшит Ваһаповның тууына 65 ел тулуга багышланган кичә уздырылды. Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге һәм сәхнә ветераннары советы тарафыннан оештырылган бу кичәдә халкыбызның яраткан җырчысы турында истәлекләр сөйләнде, аның башкаруында язып алынган җырлар тыңланды.

## НӘҖИБӘ ИХСАНОВА КИЧӘСЕ

8 апрельдә Актерлар йортында Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры артисткасы Нәҗибә Ихсанованың иҗат кичәсе булды. Кичәдә ул катнашкан спектакльләрдән өзекләр күрсәтелде.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

Татарстан язучылар союзының Әлмәт бүлегендә яшь шагыйрь Мәхмүт Газизовның иҗаты тикшерелде. Тикшерүдә катнашкан язучылар шагыйрь иҗатының елдан-ел үсә баруын билгеләп үттеләр, авторга күп кенә файдалы киңәшләр бирделәр.

* * *

«Азнакайнефть» идарәсе китапханәсендә язучы М. Хәсәновның Кама автогигантын төзүчеләргә багышлап язылган «Кама таңнары» романы буенча китап укучылар конференциясе уздырылды.

* * *

Тагын берничә көннән әдәбият сөючеләр шул ук китапханәдә «Зәңгәр ут» яктысына җыйналдылар. Кунакка язучылар союзының Әлмәт бүлегеннән драматург Ю. Әминов белән С. Кальметов та чакырылган иде.

Кичәдә Ю. Әминов татар драматургиясенең торышы һәм республика театрларының репертуары белән таныштырды. С. Кальметов һәм М. Хәсәнов үзләренең әсәрләрен укыдылар.

* * *

## ЛЕНИНОГОРСК «ЧИШМӘ»СЕ

Нефтьчеләр шәһәре Лениногорскида язучылар, үзешчән композиторлар, рәссамнар, башкаручылардан торган әдәбият-сәнгать берләшмәсе оештырылды.

«Чишмә» дип исемләнгән берләшмә әдәбият һәм сәнгатьне киңрәк пропагандалауны үзенең төп бурычы итеп куйды. Шушы максаттан чыгып, «Чишмә» Техника йортының зур залында халык тарафыннан җылы кабул ителгән, әдәби-музыкаль кичә уздырды, рәссамнарның яңа әсәрләреннән күргәзмә оештырылды, авылларда төрле очрашулар үткәрә башлады.

## ТАТАРЧА ФИЛЬМ

Язучы Ф. И. Наседкинның Ленин комсомолы премиясе белән бүләкләнгән «Бөек йолкышлар» исемле романы революциядән соң авылда кулакларга каршы һәм томаналыкны бетерүгә юнәлдерелгән көрәш, бу көрәштә комсомоллар тоткан роль турында сөйли. Режиссер Л. Мирский шушы роман буенча нәфис фильм эшләгән иде.

Казан кинохроника студиясе бу фильмның татарчалаштырылган вариантын экраннарга чыгарды. Төп рольләрне Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры артистлары Ш. Биктимеров, Р. Таҗетдинов, Һ. Солтанов, И. Хәйруллин, Р. Шәрәфиев, Х. Җәләлов, Н. Гәрәева һәм башкалар татарчалаштырды. Дубляж режиссеры — ТАССРның халык артисты Ф. Шәрәфиев.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ
# (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210